ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.2002





**Әхмәт Ерикәй**
**1902—1967**

# Казан утлары
# Qazan utları

2002

12

(962)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,
Татарстан Язучылар берлеге,
редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉ 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎ Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Әхмәт ЕРИКӘЙ. Халкыма. *Шигырь* .......... 5
Мәдинә МАЛИКОВА. Өермә. *Детектив роман* .......... 6
Әхсән БАЯН. И, гомер, дип өзелә гөл. *Шигырьләр* .......... 52
Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН. Йөрәккә тамган язгы тамчылар. *Хикәя* .......... 58
Рәшит ШИҺАП. Моңнар яши жирдә. *Шигырьләр* .......... 76
Гөлчәчәк ГАЛИЕВА. Барсам. *Хикәя* .......... 104
Харис ЗАКИРОВ. Ләхет. *Хикәя* .......... 125

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Әмирхан ЕНИКИ. Әйтелмәгән васыять .......... 79

ҺӘР ТӨБӘКТӘ—БЕЗНЕҢ КАЛӘМДӘШЛӘР

Узып баручы елдан шигъри бәйләм (Ч. МУСИН,Ф. ШӘЕХ, П. АПУШЕВ, М. САФИН, Ф. СУФИЯРОВ, М. ВАФИН, Л. СӘГЫЙДУЛЛИНА шигырьләре) .......... 112

ПУБЛИЦИСТИКА

Сәвия МИХАЙЛОВА. XIX гасырда Казан университетында шәрык телләрен өйрәнү .......... 129
Журналыбыз турында (*М. Госманов, Б. Мамбет*) .......... 46, 159

СӘНГАТЬ

Филүсә АРСЛАНОВА. Сәнгатькә багышланган гомер .......... 147

КИТАП КҮЗӘТҮ

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Ак казлар чакыруы .......... 151
Равия ЗАРИПОВА. Бала күңеле .......... 156

Коръән татар телендә .......... 162

ӘХМӘТ ЕРИКӘЙНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Әхмәт ЕРИКӘЙ. Төрле еллардан жырлар *(Кереш сүз беләи)* .......... 173
Безнең календарь .......... 178, 180

ЮМОР-САТИРА

Дамир ГЫЙСМЕТДИНОВ. Юмористик хикәяләр .......... 181
2002 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге .......... 185
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .......... 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман-детектив М. МАЛИКОВОЙ "Буря" *(окончание)*, рассказы М. ХАБИБУЛЛИНА "Весенняя капель", Г. ГАЛИЕВОЙ "Барсам" и рассказ Х. ЗАКИРОВА «Могила»; стихи А. ЕРИКЕЯ, А. БАЯНА *(с предисловием Р. Гаташа)*, Р. ШИГАПА.
"Из сокровищницы татарских рассказов": А. ЕНИКИ "Не высказанное завещание".
"Поэтические голоса наших земляков": стихи Ч. МУСИНА, Ф. ШАЕХА, П. АПУШЕВА, М. САФИНА, Ф. СУФИЯРОВА, М. ВАФИНА, Л. САГИДУЛЛИНОЙ.
"О нашем журнале": заметки М. УСМАНОВА, Б. МАМБЕТ.
"Публицистика": статья С. МИХАЙЛОВОЙ "Изучение восточных языков в Казанском университете XIX веке."
"Искусство": статья Ф. АРСЛАНОВОЙ посвящена творчеству А. Абдуллина.
"Книжное обозрение": статьи Р. ШАРАФЕЕВА "Зов белых гусей" и Р. ЗАРИПОВОЙ "Душа ребенка".
Коран на татарском языке.
В номере отмечаются 100-летие А. Ерикея, 90-летие М. Нугмана, 75-летие М. Хабибуллина и 70-летие Г. Мухаметшина.
"Юмор-сатира": рассказы Д. ГИСМУТДИНОВА.
Библиографический список произведений, опубликованных в 2002 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Зимний пейзаж—фотоэтюд; писатель Г. Гумеров.

## IN OUR ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry": M. MALIKOVA'S novel «The storm» *(ending)*, M. KHABIBULLIN'S story «The spring thaw», G. GALIEVA'S story «Barsam», , Kh. ZAKIROV'S story; the verses of A. ERIKEY, A. BAYAN *(with R.Gatash's preface)*, R. SHIGAP.
"From the treasury of Tatar stories": A. ENIKEY «Not read testament»
"Our countrymen's poetry»: the verses of CH. MUSIN, F. SHAEKH, P. APUSHEV, M. SAFIN, F. SUFIAROV, M. VAFIN, L. SAGIDULLIN.
"About our magazine": the notes of M. USMANOV; B. MAMBET.
"Journalism": S. MIKHAILOVA'S article «East languages learning at the Kazan university XIX c.»
"Art": F. ARSLANOVA'S article devoted to A. Abdullin's creative works. "Book review": R. SHARAFEEV'S article «The summons of white gooses», R. ZARIPOVA'S article «The soul of the child».
"Koran in Tatar language".
Our jubilees: 100th anniversary of A. Enikey, 90th anniversary of M. Nugman, 75 th anniversary of M. Khabibullin, 70th anniversary of G. Mukhametshin.
"Humour and satira": D. GISMUTDINOV'S stories.
Bibliographical list of the works, published at 2002 y.
The diary of social and cultural life.
On our covers: Winter view—photo-etude; writer G. Gumerov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.11.2002 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108¹/₁₆.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9134. Заказ Б—710
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2002 ел.

# Әхмәт Ерикәй

## Халкыма

Яшен кебек гайрәтемне
Корбан итмим зәүкыма;
Даннарым, дәртем, дәрманым—
Бар да туган халкыма.

Имгәк булуны халкыма...
Сыйдыралмыйм гаклыма;
Турылыклы хезмәт итәргә
Ант иттем мин халкыма.

Бар булсам да, бар түгел мин,
Тап төшерсәм антыма;
Сүзем алмаз, күңлем ихлас
Минем—бөек халкыма.

Халкым: «алга!» дигән икән,
Кем әйләнер артына?
Мин сулыш алсам, сулышым
Хезмәт итсен халкыма!

Каерылмас канатларым:
«Халкыма!» дип талпына;
Ник кирәге бар канатның
Юл булмаса халкыма?!

Сүнеп бетсеннәр йолдызлар,
Син дә, кояш, балкыма,
Бет мәңгегә, балкыма син,
Балкымасаң халкыма!..

*1944*

**Мәдинә Маликова**

# ӨЕРМӘ

ДЕТЕКТИВ РОМАН

* * *

Жәүһәриянең ак яулыгын маңгаеннан түбән төшереп бәйләгәннәр, борын очы белән күгәргән иреннәре генә күренеп тора. Акка төрелеп, өстән чәчкәле япма капланган бу гәүдә бөтенләй чит, ят кебек тоелды. Күңелдә бушлык, фәкать бушлык кына... Һәм үлем каршында гына була торган көчсезлек, чарасызлык... Харис кулындагы эре кызыл розаларны аллы-гөлле япма өстендәге башка чәчәкләр янына куйды да, башын иеп, аз гына тынып торды. Аннары стена буендагы урындыкларда утырган биш-алты апа янына килеп, баш иеп, кайгы уртаклашты. Ул аларның кайсысы Жәүһәриянең әнисе икәнен белми иде...

Ә тышта жилсез, кояшлы иртә. Ишек алдында нечкә, ак сынлы, яшел яулыклы каеннар, төз, биек тирәкләр тезелеп баскан. Аяк астында чыпчыклар чыркылдап тыпырчына, күгәрченнәр сикергәли. Җиһанда тормыш, яшәү тантана итә.

Ишек алдына жыелган кешеләрне күзгә күренмәс кайгы томаны урап алган иде кебек, алар ягыннан женазада гына була торган сагыш бөркелә иде. Халык ике төркемгә бүленгән. Бер якта түбәтәйле абзыйлар, ак яулыклы апалар тыныч кына, әкрен тавыш белән сөйләшеп тора. Алар арасында яшел жиләне белән Рәзинә карчык күзгә чалынды. Икенче төркемдә ир-атларның пеләшләре ялтырый, яланбашлы хатын-кызларның кыска итәкләре жилпенә—анда ыгы-зыгы киләләр, кереп-чыгып йөриләр. Мөгаен, гәзит әһелләредер, шагыйрьләрдер, дип уйлады Харис.

Читтәрәк, автобуска елышып, Мансур Хужиевич басып тора. Аннан да ары, юл кырыенда ук таныш "УАЗ"игы янында гадәттәгечә ыспай күксел костюм кигән, яланбаш Даниф күренде. Сүз кушарга бер кеше бар ичмасам. Харис ана таба юнәлде.

—Килеп яхшы иткәнсең,—диде ул исәнләшкәч.

---

Ахыры. Башы 11 санда.

—Артистларны, шагыйрьләрне соңгы юлга озатырга бөтен халык килсә дә гаҗәп түгел,—диде Даниф.—Алар бит сина бик якын тоела, урамда күрсәң дә кул биреп исәнләшәсе килә... Аннары, без хәзер бер оешма кешеләре бит инде.

Алар шулай янәшә басып, мәрхүмәне, аның артыннан чәчәк бәйләмнәрен һәм такыяларны алып чыкканнарын читтән генә күзәтеп тордылар. Оркестр уйнады, ачык түшле хатыннар, шәрә беләкле ирләр очынып-очынып урынына-вакытына килешле сүзләр сөйләделәр.

Детектив әсәрләрдә, үтерүче үз корбанының җеназасына килә, дип язалар. Хак микән? Харис шуны уйлады. Әгәр дөрес булса, мондагыларның берсе—җинаятьче, димәк?! Кем ул, кайсы төркемдә? Түбәтәй кигәнме, яланбашмы? Читтән карап торамы, әллә, әнә теге чал чәчле абзый кебек, уртага чыгып басып, чыраена кайгылы кыяфәт биреп, шома сүзләр сөйлиме?

—Шагыйрә Жанна Баянова әдәбиятка бик матур, затлы өлеш кертте,—диде абзый.— Аның шигырьләре тел җәүһәрләреннән үрелгән асыл муенсага тиң иде. Яңадан-яңа яшь буыннар аларны яратып укыячак, үзенә җан азыгы табачак, юнәлеш алып, якты, дөрес юлга басачак әле!

"Нинди әдәбиятка өлеш керткән? Яшьләрне нинди юлга өнди, кая алып бара ул—урыс телендә язган татар баласы?"

Җәүһәрия язмышының бу ягы Харисны элек бер дә уйландырмый иде. Тирә-якта күп чөнки андыйлар. Ә менә хәзер, аерып алып сөйләгәч, төрле уйлар кузгалды...

Зират бик ямьле урынга, тау күкрәгенә урнашкан, аннан киң җәелгән аланлык, каенлык күренеп тора. Дөньяда фаҗигалар, кансызлык, вакытсыз үлем булуны күңел кабул итә алмый иде. Кабер эргәсенә якынлашкач, әледән-әле күзләрен сөртеп торган ак яулыклы апалар, сабыр чырайлы абзыйлар бер якка, яланбашлы хатыннар, ирләр икенче якка бастылар. Гадәтенчә карадан киенгән Букштейн аерылып, күзгә ташланып, ике арада, уртада калды.

"Бу халыкны житмеш ел буе бутадылар-бутадылар, камыр урынына изеләр-бастылар, әмма барыбер бер иш итеп укмаштырып бетерә алмадылар",—дип уйлады Харис.

Мәрхүмәне гүргә индерергә кәләпүш кигән ирләр төште. Инде кабер күмелеп, калку түтәл кебек өелгән кызыл балчыкны такыялар, төре чәчәкләр каплагач, яшел чапан кигән, башына ак чалма ураган яшь мулла чүгәләп: "Әгүзе..."—дип ясин чыгарга әзерләнгәч, Букштейн бөтенләй артка чигенде. Һәм ияген чөя төшеп, бер генә мизгелгә башын Харис тарафына борып алды. Күзлеге аша карашы күренмәде, ләкин аннан бөркелгән нәфрәт уты бәгырьне көйдереп алгандай итте.

Харисның җанына ут капкандай булды, ялкыны дөрләп күтәрелде дә мине томалады. Нишләп әле ул кичә бу аләмне тикшерүче каршында яклап утырды? Каян килеп иман чаткысы булсын мондый кара кап эчендә? Ул үтергән Җәүһәрияне! Ул, ул! Һәм бер селтәнүдә генә түгел, әкренләп һәлакәткә китергән. Кыргый җәнлекләр тулы кара урман кебек яшәештә ялгыз калдырган ул аны! Әйе, Җәүһәрия королева Мария Стюарттан ким түгел иде. Мария аның урынында булса, мецнәргә ярдәм итә алыр идеме икән әле! Шәһәр өстенә Кызыл Ай калкыту турында хыяллана алыр идеме икән? Ә менә Букштейн... Аны ничек Стюартның сөйгәне белән чагыштырмак кирәк! Гомеренең ахырына кадәр королевасына тугры хезмәт иткән рыцарь белән...

Ә бу Букштейн нәрсәгә хезмәт итә соң? Илен ташлап, хатынын, баласын калдырып, нәрсә эзләп киткән ул Каф таулары артына, Кара дингезнең теге ягына?

Әгәр, Харис белән Даниф кафега кереп, Җәүһәриянең мәетенә юлыкмасалар, кайда йөрер иде икән бу бәндә хәзерге минутларда?

Иерусалим дигән каланың бер тыкырыгындагы кибеттә үлчәүгә дуңгыз мае салып маташыр иде, мөгаен. Анда, үлчәү янында кара күзлекне

салырга туры киләдер. Сатучыга кара күзлек килешми. Андыйны сатып алучы яратмый. Ул күзлеген, мөгаен, Тель-Авивтан Мәскәүдәге Шереметьево аэропортына кайтып төшкәч кенә, кесәсеннән чыгарып, очлы борынына атландырып куядыр. Уйларын яшерер өчен. Мин бөтен эчегезне күрәм, ә сез мине күрә алмыйсыз, дияр өчен. Ә анда, чит-ят илләрдә, син килмешәккә әллә кем булып йөрергә ирек бирмәсләр.

Харис Эдуардны ак башлык кигән, ак алъяпкыч бәйләгән килеш, каршында басып торган сатып алучы юан корсаклы абзыйга (сало яраткан кешенең корсак үсми калмас) ярарга тырышып елмайган хәлдә күз алдына китерде...

Көлке! Акча дигәндә, дөнья малы өчен шул рәвешле төрләнә торган хамелеон, фатир хәтле фатир турында сүз барганда, җан ачуы чыгып, аяк астындагы сынык пычакны алып бер селтәнеп бәрүдән тыелып кала алырмы? Әгәр дә ул хатыны артыннан бинага барып, аны башка берәү кочагында күреп алган булса?!

Һа-ай, Җәүһәрия! Соңгы сулышыңны алганда, кемне күреп, шулкадәр хәйран калган идең син?

...Чыгып барганда, Харис, үзе дә абайламыйча, Нуржиһан апа белән янәшә китте.

—Халидә, син безнең Харис Мирзаяновичны таныйсыңмы соң?—диде Нуржиһан сары чәчле, нечкә сынлы, урта яшьләрдәге хатынга.—Безнең хуҗабыз ул бит инде хәзер.

—Ишеткәнем бар, күргәнем юк иде.

Халидәнең зәңгәр күзләре Хариска шундый кистереп, үлчәгәндәй сынап карады ки, Харис ихтыярсыздан башын читкә борды.

—Мин мәдәният йортының китапханәчесе,—диде хатын нечкә, салкынча бармаклары белән Харисның кулын шактый ук нык кысып.—Һәм Җәүһәриянең дусты. Ул сезнең хакта еш сөйли торган иде.

—Гаҗәп,—диде Харис.—Ниләр сөйләде икән ул? Без сирәк очраша идек бит.

—Ул сезгә ышана иде, сезгә генә таяна иде.

—Ялгышасыздыр. Сез аны дөрес аңламагансыздыр. Нинди таяныч була алыйм, ди, мин ана? Бер ярдәмем дә тимәде бит.

—Мондый җәмгыятьләр тирәсенә эшлексез, нәфесле адәмнәр сарылучан, ә безгә шик тудырмый торган, абруебызга тап төшерми торган кешеләр кирәк, дия торган иде ул. Шуна урынбасар итеп сезне куйды да. Мин сезнең белән бик күптәннән сөйләшәсем килеп йөрим...

"Ник ул нәкъ менә сезне урынбасары итеп тоткан? Ник башка берәүне түгел?"—дип сораган иде Мансур Хуҗиевич. Башкаларга ышанмаган! Үзенә бердәнбер таяныч итеп Җәүһәрия Харисны санаган. "Мин нинди таяныч булыйм аңа?! Ялгыз булган шул ул, ялгыз, ялгыз..."

Анын уйларын бүлеп, зират капкасыннан зур төркем керә башлады. Алдан алтынсу сырлар белән бизәлгән имән табут капкачы, анын артыннан аллы-гөлле такыялар һәм ниһаять табут үзе. Артта карадан киенгән апалар һәм яланбашлы ир-атлар. Ике яктан кырыккан башлы таза егетләр килә, каршы очраганнарга:

—Юл бирегез! Читкәрәк! Читкәрәк!—дип ысылдыйлар.

Харис белән юлдашларына кырыйгарак китәргә, сарайга охшаган корылма янынарак елышырга туры килде. Корылманың ишегеннән көрәк тотып чыгып килгән зәңгәр комбинезонлы зират эшчесе дә алар янында туктап калды.

Табут капкачын тотып баручыларның берсе, озын буйлы, нәзек сынлы, сары чәчле егет борылып: "Исәнмесез!"—диде. Харис аптырап як-ягына каранды: кемне сәламли ул? Халидә белән Нуржиһан үзара сөйләшеп торалар, Даниф якындагы ташка текәлгән, берәр танышының кабере булса кирәк. Узып барганның сәламен алучы юк. Ә теге һаман болайга карап бара, җавап көтә...

Мондый җирдә авыз ачып йөрү юньлегә илтми, әнә ул сөртенде,

авып китте, ничектер капкачка тотынгандай итеп кенә егылмый калды.

—Тишеккә тотынмый булдыра алмыйлар шул,— дигән тавыш ишетте Харис. Зират эшчесе икән. Харисның борылып караганын күреп, зәңгәрсу башлыгының пластмасс козырегын каш өстендә төзәткәләп куйды. Урта яшьләрдәге бу абзыйның арык чыраенда күзәтүчән һәм сөйләшүчән икәнлеге ярылып ята иде.

—Нинди тишек?—дип сорады Харис.

—Аларның кешечә генә булмас инде. Братва бит! Табутны таза имәннән, чәчкә-яфрак уйдырып ясаталар. Ул гына житми, тишек тиштерәләр!

—Кай төшенә?

—Уналтыны төбенә, уналтыны капкачына.

—Ә нәрсәгә ул?

—Без дә шулай дип сорадык. Капкачын тиштерүегез аңлашыла, дибез, һава керсен, ди торгансыздыр. Төбенә ник кирәк? Син нәрсә, диләр, без аны жирдән сөйрәп алып барырбызмыни? Күтәреп барганда, бармакларны кая тыгарбыз? Алар бит бармакларын тырпайтып йөрергә күнеккән! Жилпәзә урынына. "Браток! Үченне алырбыз!Сине һәлак иткәннәрне кара канга тончыктырырбыз!" имеш. Атна үтми, тагын килеп житәләр. Тагын имән табут, тагын тишек тиштерәләр, тагын бармакларын тырпайтып, үч алырга ант итәләр. Кәмит!

—Шулай еш йөриләрмени?

—Әле узган атнада гына берсен күмеп киткәннәр иде... Бу тарафка эзләре суынып тормый. Үзара атышалар, суешалар...

Ул арада табут күтәреп килүчеләр якынайган иде. Аллагыларның берсе, утызлар тирәсендәге таза кеше, борылды да: "Привет!"—диде. Һәм кояшта янган тупас чыраена елмаю галәмәте чыгаргандай итте. Ләкин тимер төсле күзләренең карашы жанны өшетерлек. "Үтерүче күзе!"—дигән уй килде башка. Харис янә артына әйләнеп карады, кемне сәламләгәннәрен тагын аңламады. Ә тегеләр инде узып киткәннәр иде, тупас чырайлы адәмнең колак яфрагы астыннан жилкәсенә таба сузылган яра эзе дикъкатьне жәлеп итте.

Харис, әле генә күзе ачылгандай, каберләрне күздән кичерде. Киң сукмакның ике ягына да зур-зур кара гранит ташлар бастырып куелган. Ташларның төсе, рәвеше бер үк. Тик уң яктагыларына язуы-сурәте көнгә каратып куелган, сулдагыларына—төнгә каратып. Гуяки алар бер-берсенә каршы сафларга тезелеп басканнар. Аерма—исем-фамилияләрдә: бер якта татарлар ята, икенчесендә—урыслар. Фани дөньяда үзләренең нәсел-ыруын, ата-бабасын белмәгән, берсеннән берсен төркемнәренә карап кына аерган бәндәләр, бакый дөньяга киткәндә, бөтенләй үзләре сангга сукмаган билге—милләт буенча бүленеп, төрле тарафларга карап ятканнар.

Тишекле табутлар да, гранит ташлар да, аларга уелган сурәтләр дә бертөрле югыйсә: мәрхүмнәр бөтен буена бастырып ясалган. Төрекләр теккән күн куртка, кытайлар теккән джинсы чалбар, итальяннар теккән ботинкалар бик жентекләп сурәтләнгән, сәдәфләренә, каптырмаларына кадәр чекрәеп тора. Гуяки, кешенең үзенә түгел, өстендәге чүпрәк-чапракка куелган бу һәйкәлләр! Мәрхүмнәрнең чырайлары конвейердан чыккан кебек, бер-берсенә нык охшаган. Хәер, ташка ясалган сурәтләргә карап сирәк очракта гына кешенең үз рәвешен күз алдына китерә аласың.

Мәрхүмнәргә түгел, гуяки чорга, кансызлык, әхлаксызлык заманына һәйкәл иде зиратның бу урамы. Һәм иң тетрәндергәне шул иде: ул ташларга уелган саннарда мәрхүм егетләрнең гомере егерме белән утыз биш арасында чикләнгән. Сугыш кырында һәлак булганнар диярсең!

Хәер, алар сугыша бит инде. Зират урамы буйлап табут күтәреп барган егетләрнең кырылган башларына, нык, таза арт чүмечләренә шомланып карап калды Харис: киләсесендә боларның кайсысы тишекле табутның эчендә булыр. Һәм аның мәңгелек йорты урамның кайсы ягында урнашыр икән?

Тәрәзләре кара-каршы караган урам озынаая, сузыла бара. Җәүһәрияне дә бүген аның аргы башына илтеп урнаштырдылар... Ләкин ни катышы бар аның бу сафтагы бәндәләргә? Ни уртаклыгы бар алар белән?

Ә бәлки, бу уртаклык очраклы түгелдер? Ә бәлки, шагыйрәнең заман хәлләре белән бәйләнеше Харис белмәгәнчә булгандыр? Нәрсә белә иде соң ул Җәүһәриянең тормышы турында? Уйлары, кичерешләре, фаҗигасе турында ни белә иде?

—Карагыз әле, Насибә түгелме соң анда? Насибә бит! Лиана белән!— диде Халидә.—Нишләп йөри икән? Җәүһәрияне җирләгәндә күренмәгән иде!..

Һәм ул, кара төркем артыннан бераз ара калдырып, әкрен атлап килгән базык гәүдәле хатын белән аннан бер баш калкып торган сылу сынлы яшь кызга күрсәтте. Кызның кара чәче баш өстенә күпертеп куелган, чәчәкле, юка күлмәк-чалбары җил искән саен тәненә сыланып, ымсындырып тора. Хатын аксыл, юка чәчле, юантык гәүдәле. Өстендәге затлы кызыллы-каралы кофтасы һәм атлас юбкасы да аның гадилеген, фәкыйрьлеген киметә алмый иде.

Ул борылып карады, исәнләште, туктап калды.

—Нишләп йөрисез болай?—дип сорады Нурҗиһан.—Җеназага соңардыгыз бит!

—Әй, безнең үзебезнең дә җеназа бүген,—диде Насибә аска карап.

—Кемен?!

—Кияү буласы кешене үтергәннәр. Бүген генә белдек. Туен да үткәзә алмыйча тол калды менә Лианабыз.

Насибә моны ничектер битараф тавыш белән сөйли, Лианасы исә сукмак уртасында, читкә карап басып тора иде. Хатыннар ах-вах итеп, ничек, нәрсә булганын сораша башладылар.

—Киявегезнең гаиләсе бик бай, ахрысы, табутның шәбен ясатканнар...

—Дуслары күп, шулар тырышты,—диде Насибә җавапны кыска тотып.

Арттан боларны тыңлап торган зират әһеле ачы көлемсерәде:

—Общак акчасына шулай шапырыналар, безнең төркем сезнекеннән ким түгел, дияселәре килә.

Насибә аның сүзләрен әллә ишетмәде, әллә ишетмәмешкә салышты. Сукмакка борылды да, кызы белән бергә, инде шактый ераклашкан кара төркем артыннан китте.

—Бу теге кафеда утыра торган Насибәме әллә?—дип сорады Харис Нурҗиһаннан.

—Шул инде, шул. Бездә бер генә Насибә. Кызы корсакка узган мескеннең. Өйләнешеп өлгермәделәр, әнә, егетен үтереп ташлаганнар, ди бит.

—Нәрсә, аның кызы братва белән бәйләнгәнме әллә?

Нурҗиһан аптырап китте.

—Нишлә-әп?

—Киявен братва күмә түгелме соң?

—Кит аннан! Лиана андый булмас! Белмәгәндер! Йә тотып көчләгәннәрдер мескенкәйне! Бала гына бит әле ул!

—Ә Насибә үзе?

—Насибә бер мәхлук инде шунда. Берүзенә өч бала, ире ташлап киткән. Шешә җыеп тамак туйдыра. Үзе милициянең тулай торагында яши. Бандитлар белән бәйләнә торган түгел!

—Хәзер туп—туры җәмгыятькә барабыз,—диде Харис.—Әйдәгез, безнең машинага утырыгыз. Даниф! Апаларны үзебез белән алып кайтабызмы?

—Минем машина алты йөз кило күтәрә,—диде Даниф.—Шуннан артмасалар, рәхим итсеннәр.

* * *

“Кем белән исәнләште икән Равил дигәннәре? Минем белән микәнни? Ә теге бүре күзле адәм кемгә “Привет” диде?—дип уйланды Халидә зираттан кайтканда.—Харисқа дисәң, ул җавап бирмәде. Миңа дисәң... Ярый, Равиле мине, бәлки, истә калдыргандыр да. Ә монысы каян истә тотсын? Инде исәнләшәсе килсә дә, миндәй олы хатынга ул нишләп “Привет” дисен? Әшнәсе түгел лә! Хәер, әдәп-тәртипне белә торган бәндәләрме... Бәлки, теге чакта, кафеның ишегалдында күрешкәч, мине хәтеренә сендереп калдырганнардыр. Бәлки, шул чакта бер-ике авыз сүз алышканны онытмаганнардыр. Ә мин аларның сәламен алмадым менә...”

Шулай дип уйлады Халидә, әмма ул адәмнәрне танымаганга салышуына үкенмәде. Андыйлар белән, бигрәк тә бүре күзлесе белән, исәнләшәсе дә сөйләшәсе дә килми иде инде.

Ә Җәүһәрия сөйләшә. Бик күпләр белән, шул исәптән муенында яра эзе калган бу кеше белән дә.

Һаман шул кафе аркасында, шуның тирәсендә. Янмады да ичмасам шул хәрабә!

...Май башында Җәүһәрия аны җәмгыятьнең яңа бинасын карарга чакырган иде. Халидә китапханәне иртәрәк, сәгать биштә үк япты да, троллейбуска утырып киттеләр.

Троллейбустан төшкәч, олы урамнан тыкырыкка борылып, бина түбәсендәге кыйшайган хәрефләрне, каралык бөркеп торган пыяласыз тәрәзәләрне күрүгә күңеле нык төште Халидәнең. Урамы аулак, бинасы артык зур. Тирә-яны буш, тын, ташландык.

Җәүһәрия юлдашының кичерешләрен тоеп алды.

—Ямьсезме?—диде ул, көр тавыш белән.—Матурлыйбыз без аны! Кереп кенә урнашыйк. Күр дә тор, көзгә тәрәзәләре ялтырап торыр, түбәсендә Кызыл Ай балкыр. Без килүгә ишегеннән каршыбызга ак халатлы кызлар йөгерешеп чыга торган итәрбез.

—Син керешсәң була инде ул,—диде Халидә елмаерга тырышып.

Әмма таланган бинаның зур залларыннан караңгы чоланнарына, төрле зурлыктагы бүлмәләренә кереп-чыгып йөргәндә, шомлануы, өметсезлеге артканнан-арта гына барды. Бер чоланда түшәмгә хәтле өелгән тартмалы шешәләр, икенче бер бүлмәдә тездән диярлек кәгазь-мәгазь, өченчесендә ямьшәйгән, ватылган савыт-саба. Өске катта сәләмә өемнәре—күрәсең, йортсыз-җирсез сукбайларның куну урыны.

Өсләренә яу килгән чакта да кешеләр үз милекләрен бу рәвешле җимереп, ватып, таптап-изеп, ташлап качмыйлардыр! Бәлки, дошман явы таптап узган җирләр шундый буладыр? Ләкин бу елларда Казанга дошман гаскәре бәреп кермәде, монда яшәүчеләр үз йортларында калды, эшләгән урыннарыннан да беркемне дә кылыч болгап, мылтык атып куып чыгармадылар. Инде бинаны бер кулдан икенчесенә тапшыралар икән, анда эшләгән кешеләрне дә, алдан сөйләшеп, хезмәт кенәгәләренә имза салып, мөһер басып озаталар. Бинаны бу рәвешле пыран-заран китерү нигә кирәк? Шәһәр хуҗалары да, район җитәкчеләре дә үз урынында бит!

Ниндидер башка сыймаслык афәт ояланган иде бу тирәгә. Ул афәт биргә аяк баскан һәркемгә яный иде шикелле.

Ә Җәүһәрия моны сизми-тоймый иде кебек. Хәер, бөтенләй үк күңеленә тимичә булмагандыр. Югыйсә ул иптәшкә Халидәне чакырмас, бинаны үзе генә карап кайтыр иде. Хәзер исә ул юлдашы алдында юри батырая иде бугай. Өске катны карап чыкканнан соң, әллә нинди караңгы баскычлардан аска төшеп киттеләр—электр янмый, лампочкаларны—розеткаларны гына түгел, тимерчыбыкларын да каезлап алганнар. Астагы биек, озын, кап-караңгы коридорга барып керүгә, аяклар тубыктан салкын суга чумды. Йә шунда берәр базның авызы ачык булса? Төшеп китәрсең,

эзләп тә таба алмаслар. Каяндыр шаулап су акканы ишетелә иде.

—Каян ага соң бу су?—диде Җәүһәрия. —Барып карыйк әле. Шырпы аласы калган икән...

—Әллә иртәгә сугылабызмы?—дип йомшак кына каршы төшеп карады Халидә.—Фонарь алып килер идек.

—Тукта, белик инде, каян ага икән?

Шулай диде дә, салкын суны сандалилары белән ерып, стенага тотынып, алга китте Җәүһәрия. Халидә, шактый калышып, аңа иярде. Бераздан күз ияләнә төште. Стена буенда беләк юанлыгы торба өзелгән иде. Әйе-әйе, сынган да, тишелгән дә түгел, торбаның шактый өлешен гүя кисеп алганнар. Су шарлавык булып бетон идәнгә төшә дә каядыр аска агып юкка чыга.

—Менә күрденме, без монда бернишли алмыйбыз,—диде Халидә.

—Ничек инде, бернишли алмыйбыз? Һаман шушылай агып торсынмыни?—диде Җәүһәрия кызып.—Авария бит бу! Хәзер үк хәбәр итәргә кирәк! Килсеннәр, туктатсыннар!

Коридорда ишек берничә иде, алар шуларның берсе аша бинаның икенче ягына чыктылар. Анда да иркен ишегалды, ак кирпечтән салынган сарайлар бар икән. Ә аргы башта, бинаның үзендә үк автомобильләр төзәтә торган мастерской ачканнар. Аның зур тимер ишеге ачык, эчтә "Жигули"ларны төзәтеп маташалар, тыштагы ак "Нива" янында ике кеше сөйләшеп тора. Хатыннарны күргәч, борылып карадылар. Аларның берсе боздай салкын карашлы таза ир иде. Муенында кыйгачлап яра эзе бүртеп тора...

Җәүһәрия туп-туры аларга таба атлады. Исәнләштеләр. Дөресрәге, аларның сәламенә ирләрнең икенчесе—яшьрәге, юка гәүдәле, ак чырайлы егет җавап бирде. Җәүһәрия үзенең хәер җәмгыяте җитәкчесе икәнен, бинаның җәмгыятькә арендага бирелүен әйтте. Таныштылар. Егет Равил исемле икән, мастерскойның хуҗасы. Ә теге адәм күп сөйләшеп тормады, эчкә кереп китте. Хатыннар белән бөтенләй кызыксынмады шикелле. Шулай булгач, нишләп бүген Халидәгә сәлам бирсен, ди, ул? Әллә кайчан оныткандыр инде.

Ләкин Халидә аның үзен, аннан да бигрәк күз карашындагы катылыкны нык хәтерләп калган иде. "Үтерүче..."—дип уйлаган иде ул.

Һәм Җәүһәриянең теге Равил белән сөйләшкәнен читтән генә тыңлап торды. Егетнең бөтен кыяфәтендә күңел төшенкелеге ярылып ята иде.

—Монда мин хуҗа, дип килүчеләр сез генә түгел инде,—диде ул.—Шәһәр хуҗалары әле берәүгә, әле икенчегә вәгъдә итәләр. Аларга ышансаң! Менә безнең дә документлар тәртиптә дә бит, барыбер атна эчендә бинаны бушатырга кушып кәгазь җибәргәннәр.

—Бина безнеке бит хәзер!—диде Җәүһәрия.—Шуңадыр.

—Нишләмәкче буласыз инде биредә?

Җәүһәрия хәер ашханәсе, кунып чыгу урыннары, шәфкать туташлары укыта торган курслар турында сөйләгәндә, Равилнең чырае караңгыланганнан караңгылана барып, күз карашы җиргә төбәлде. Моны сизеп Җәүһәрия:

—Безгә машина ремонтлау мастерское да артык булмас, бәлки, бергә эшләрбез,—дип тә куйды.—Ни генә булмасын, бинаны тәмам җимерүгә юл куярга ярамый!

Ләкин егет бик ачылып китмәде, бина тирәсендәге ыгы-зыгы, тәртипсезлек өметсезлеккә дучар иткән идеме, әллә башка берәр сәбәбе бар идеме, анысы Халидәгә аңлашылып җитмәде.

—Эчтә су агып ята. Нишләп туктатмыйлар икән?—дип сорады Җәүһәрия.

—Бардыр инде,—дип җавап кайтарды Равил битараф тавыш белән.—Караучысыз калгач. Шәһәр советының каравыл ялларга акчасы юк, диләр. Ә безнең кебекләргә хуҗа булырга ирек бирмиләр.

Шунын белән сүз өзелде. Егет ниләндер пошаманда, әллә каян килеп чыккан апалар белән әңгәмә корырга теләге юк, шул ук вакытта аларны үпкәләтәсе дә килми иде булса кирәк: ә бәлки, чыннан да бинаны хәер җәмгыятенә биреп куярлар! Шул ук вакытта ул теге боз күзле адәмнән дә шүрли шикелле, вакыт-вакыт аның тарафына күз салгалап куя иде.

Хатыннарга саубуллашудан башка чара калмады. Кире кафега кереп киткәндә, Халидә борылып караган иде: теге таза адәм янә ак "Нива" янына чыгып баскан, алар, хатыннар ягына ишарәләп, Равил белән нидер сөйләшәләр.

Ләкин әлеге күренеш шундук онытылды, чөнки Җәүһәрия агып торган су өчен бик борчыла иде.

—Әйдә, тизрәк район хакимиятенә,—диде ул.

—Эш сәгате бетте бит инде!

—Анда дежурный утыра, галәттән тыш хәлләр булганда, шундук чарасын күрә.

Берәр нәрсә белән мавыкса, унга-сулга карамый, тирәсендәгеләрне үзенә ияртеп, бөтереп алып үз дигәнен эшләтә торган көче бар иде Җәүһәриянен. Бу юлы да шулай булды: алар район хакимиятенә йөгерделәр. Һәм ни гаҗәп, юллары уңды: тышкы ишектән аларның каршысына күксел пинжәгенең изүен ачып җибәргән, төз сынлы, ыспай кеше килеп чыкты. Җәүһәрия аның юлына аркылы басты.

—Артур Кимович! Исәнмесез!

Баксаң, бу хакимият башлыгы үзе икән. Аларның шулай эштә соңлап утырулары табигый хәл. Тырышалар! Вакытларын да, көчләрен дә кызганмыйча, шәһәрне, халыкны кайгырталар.

—Нинди зур бәхет!—диде куанычыннан нишләргә белмәгән Җәүһәрия. — Үзегез туры килдегез! "Баллы күл" кафесында зур авария! Торба өзелгән! Су бәреп ага!

—Кайсы кафе? — дип бик тыныч тавыш белән кабатлап сорады хакимият башлыгы.

—"Баллы күл" кафесы! Туклану комбинаты!..

—Ә-ә, улмыни! Сез кем соң әле?

Җәүһәрия бутала-бутала үзенен хәер җәмгыяте житәкчесе икәнен, кафе бинасының җәмгыятькә арендага бирелгәнен аңлатырга керешге. Ул әңгәмәдешенең тынлыйсы килмәгәнен, менә-менә кузгалып, үз юлы белән китеп барачагын сизә, сүзен әйтеп калырга ашыга иде.

—Мин сездә булдым бит. Документларга кул куйдырдым,—дип өзгәләнде ул.

—Ә сезнең ике миллиард акчагыз бармы?

—Ике миллиард? Нәрсәгә?

—Бина ике миллиард тора. Сез ул акчаны түләмәгән бит әле.

—Ләкин су агуны барыбер туктатырга кирәк!

—Ике миллиард акчагыз булгач, сөйләшербез.

Читтәрәк басып торган Халидәгә бик сәер иде боларны ишетү. Сукыр белән чукракның сөйләшүе кебек. Берсе су дип тәкърарлый, икенчесе—ике миллиардны такылдый. Бу рәвешле сүз көрәштерү район хуҗасын туйдырды булса кирәк, ул катгый итеп:

—Ул су анда ярты ел ага инде!—диде дә, җиңгән кыяфәттә башын чөеп, тротуар кырыенда торган кара "Волга"сына утырып, китеп тә барды.

—Бина кемнеке булса да су агуны туктатырга кирәк! Нигезне юа бит ул!—дип сулкылдаган тавыш белән өзгәләнеп калды Җәүһәрия. Аннары Халидәгә борылды:

—Ишеттеңме?

—Ишеттем,—диде Халидә төшенке тавыш белән.—Ул су анда ярты ел ага инде, диде.

—Ничек алай әйтә ала ул? Шундый житәкче буламыни? Без менә кемнәрнең кул астында яшибез! Бу шәһәргә шулар хуҗамыни хәзер?!

Мондый мөнәсәбәт Халидәне дә хәйран калдырган иде. Заводларның ябылганын, автоколонналарның таланганын белә ул, ләкин бер торбага чөй кагарга иренеп, шул кадәр каза ясаулары берничек тә акылга сыярдай хәл түгел иде.

Иртәгесен Җәүһәриянең йөзе агарып, суырылып килгән иде. Төннәр буе кафе турында уйлап яткан икән. Аннары да атна-ун көн буе гел шул тишек торбаны гына сөйләде. Эчә торган судыр бит ул, болай агып әрәм була, житмәсә бинаның нигезен юа, жимерә, диде.

Сөйләп кенә калмады, шәһәр буйлап шул суны юллап чабарга тотынды. Барган бер жиреннән күңеле төшеп кайта. "Водоканалга барган идем, анда әйттеләр, завод торбасы ул, безнеке түгел, заводка мөрәҗәгать ит",—диделәр... "Заводка барган идем, безнең су түгел ул, Водоканалныкы, диделәр"... Исе китеп, хәйран калып, әрнеп сөйли иде ул бу хакта.

—Кафе янына барып, шул тирәдәге братвалар белән әйбәтләп сөйләштем әле,—диде ул атнадан артык шулай тинтерәп йөргәннән соң.—һәр районда төркемнәр бар, диләр бит. Шулар бер чарасын күрмәс микән.

Моны ишетүгә, Халидә теге боз карашлы адәмне хәтеренә китерде дә, тетрәнеп китте.

—Син нәрсә, Җәүһәрия! Бандитлар белән эш йөртмәкчеме әллә?!

—Эш йөртергә дип... Үзебез күрдек бит инде, администрация анда чын хужа түгел... Кулларыннан эш килми. Әллә теләмиләрме...

—Ә сиңа нәрсәгә ул? Анда озак тотарлармы әле үзеңне, юкмы? Район башлыгы ике миллиард сорады, онытдыңмы әллә?

—Ярый, ахыр чиктә бинаны безгә бирмәсеннәр дә,—диде Җәүһәрия.—Ләкин бүген аңа мин хужа бит! Хужа була торып, аның жимерттеримме? Ул бина кем исемендә генә булса да, барыбер шәһәрнеке, безнеке, халыкныкы!

Тагын чыгып китте шәһәр буйлап. Ахыр чиктә тәки үзенекен иткән икән. Ике көннән соң килеп кергәндә, йөзе яктырган, кәефе күтәренке иде.

—Торбаны томалаганнар,—диде ул.

—Кемнәр?

—Шундагы егетләр.

—Ничек томалаганнар?

—Анысы нәрсәгә миңа? Иң мөһиме—су акмый хәзер. Шул житкән.

—Ә күпме алдылар?

—Соңыннан сөйләшербез, диделәр.

—Вакытында исәп-хисап ясау яхшырак булмас микән?

—Бер кранны борып куйган өчен ат бәясе сорамаслар әле,—дип кул селтәде Җәүһәрия.—Милиция начальнигына хат яздым. Телефоннан да сөйләштем. Бинаны талауны туктатыгыз, дидем.

—Исе киттеме?..

—Карарбыз, ачыкларбыз, диде.

Милициянең нәрсә караганы соңрак ачыкланды: Насибә янына участковыйны жибәргәннәр. Аның аша, һәр йорт янына милиция посты куеп булмый, бинаны хужа үзе сакларга тиеш, дип әйттергәннәр.

Җәүһәрия тагын "братвалар" янына китте. Инде саклау мәсьәләсендә. Тегеләр моны да бик тиз хәл кылганнар. Ишекләрнең зурысына йозак салып, кечеләрен кадаклаганнар да, төнгә эченә эт жибәрә торган иткәннәр. Тирә-юньдә яшәүчеләр арасында: "Кафе тирәсендә эзегез булмасын, хәзер аңа без хужа!"—дип сүз таратканнар.

Әйе, властьтан аермалы буларак, кулларыннан эш килә шул андый егетләрнең! Ләкин алар бер нәрсәне дә бушка эшләмәсләр. Бише белән генә түгел, уны-йөзе белән кайтарырлык булса гына тотынырлар. Нәрсә таләп иттеләр икән алар шагыйрәдән, нинди шартлар куйдылар икән аңа?

Ул, мөгаен, бөтенесен дә Халидәгә әйтеп бетермәгәндер. Бу бүре күзле адәм белән мөнәсәбәте нинди булган аның?

Мең төрле шикле уй болганды Халидәдә, ләкин бу хакта милициягә дә, башка берәүгә дә әйтеп булмый иде. Чөнки бер ачык дәлил дә, бер телгә алып әйтерлек анык фикер дә юк. Фәкать эчке бер сиземләү генә, сызланган күңелнең тирән төпкелендә янган бер көйдергеч чаткы гына бар.

Уйлар буталды. Халидә өйгә кайткач ире Альберт белән сөйләшәсен уйлап, бераз тынычланды. Аның белән киңәшмичә торып, бу хакта берәүгә дә тешне агартмаска карар кылды. Аның ире, заводта гади инженер гына булса да, күп укый, күп уйлана, дөнья хәлләрен белә, кемнең кемлеген таный.

Шагыйрәнең хәер җәмгыяте оештыруын ишеткәч тә ул моңа бик шикләнеп караган иде.

—Андыйны шагыйрьләр булдыра алмый,—дигән иде.—Чөнки алар үзләре хәерче. Хәер җәмгыятьләрен патша заманында да байлар оештырган. Бик зур суманы банкка салып куйганнар, шуннан килгән процентны фәкыйрьләргә өләшкәннәр. Ә бит зур суманы анда бирү өчен бик бай булырга кирәк. Анда берәү дә соңгысын бирми. Димәк, артык акча булу кирәк. Ә артык акча кемдә ул? Менә, мәсәлән, фәкыйрьләргә бик күп ярдәм иткән берәү турында язганнар монда. Укып кара әле!

Мәкаләдә Колумбиянең атаклы наркобароны хакында язылган иде. Ул зур җинаятьчел оешма булдырып, наркотикларны күп илләргә тараткан. Аның кешеләре миллионлаган яшьләрне наркотик кулланырга өйрәткәннәр, шул рәвешле аларны һәлакәткә җиткереп, гаиләләренә кара бәхетсезлек китергәннәр. Күпме ачы күз яше, күпме кан коелган шул наркотиклар аркасында! Наркобарон исә баеганнан баеган. Күп илләрнең хөкүмәтләре аны тотып төрмәгә ябарга тырышканнвр. Ләкин акча коткара шул. Наркобарон бай яшәп, исеме дөньяга танылып, үз үлеме белән үлгән. Үлгәннән соң бик күпләр аны... изге дип игълан иткәннәр. Чөнки ул бик күп фәкыйрь-ятимнәргә, гарип-горабаларга ярдәм иткән икән. Хәзерге вакытта аның каберенә сукмак өзелми, чәчәкләр шиңеп өлгерми, дип язганнар...

Бик тә гыйбрәтле кыйсса иде бу. Кеше талап тапкан малның бер өлешен фәкыйрьләргә биреп, гөнаһларын юарга тырышучылар азмы бездә? Шул юл белән макталучылар, дәрәҗә алучылар азмы?

Ник кирәк иде шагыйрәгә шундый катлаулы дөньяга керүзе керү? Ышанычлы дип санаган бердәнбер кешесе—бу төзүче-инженер берничек тә ярдәм итә алмый иде бит аңа. Өстендәге таушалган костюмы белән бөдрә чәченнән башка берние дә юк чөнки. Хәер җәмгыять җитәкчесенә, теләсә-теләмәсә дә, көчле, акчалы кешеләр каршына барып басарга, шулар белән эш итәргә туры киләчәк иде. Ә алар ничек көч туплаган, каян байлык җыйган, анысын кем белеп бетерсен?

Һәм кая илтеп чыгара сине алар белән аралашу?

* * *

—Мин монда утыра алмыйм,—диде Халидә җәмгыятьнең бүлмәсенә кайткач.—Сулышым кысыла, буыннарым сызлый башлый. Әйдәгез, китапханәгә меник.

Чыннан да, икенче каттагы чиста җыештырылган, шактый иркен, җиләс һавалы биек бүлмәгә барып кергәч, рәхәт булып китте. Стена буендагы шкафларда тезелеп торган китаплар, өстәлләрдә яткан журналлар мәктәп елларын, студент чакларны искә төшерә иде. Заманның керекарасы бирегә үтеп керә алмый, таш күңелле, бүре карашлы бәндәләрнең юлы бу тирәдән узмый.

—Менә, Җәүһәриянең китаплары,—дип, өстәленнән ике китап алып, Хариска сузды Халидә.—Басылып чыгуга, бүләк иткән иде.

Татар кызының рус телендә яралган күңел моңнары... "Звездный водопад", "Заморозки для подснежника"... Харис китап тышындагы такыялы кыз сурәтенә карап торды. Нечкә сызыклар белән ясалган бу

рәсемдә Җәүһәриянең чалымнары бар иде кебек. Тик күз карашындагы тирән сафлыкны гына тасвирлап бирә алмаган рәссам... Аңа мәңгелеккә сенеп калган гаҗәпләнүне генә күрсәтә алмаган...

Ул, тирән көрсенеп, китапның уртасын ачты да күзенә беренче чалынган юлларны укыды:

Давыл купты, чатнап яшен сукты,
Йөрәккәем авыр яралы;
Сизә күнелем: синең үткәнеңдә
Мин сынган гөл булып каламын...

Кемгә атап язган ул бу юлларны? Кемнең хәтерендә сынган гөл булып калган? Харисның үткәнендә шулай калды бит ул!...

Шигырьләре сагыш белән, тынгысызлык, афәт белән тулы Җәүһәриянен. Җилләр-өермәләр, яшеннәр, упкын-чоңгыллар... Ә күзләре иләксез иде, игътибар белән карасаң, җаны түренә кадәр күренеп тора иде кебек. Ул сафлык-садәлек, беркатлылык белән мөлдерәмә тулы иде шикелле. Баксаң, анда тынмас давыл шаулаган, алдагы һәлакәтен сиземләү яшене уйнаган икән, Харис кына күрә белмәгән.

—Мин сездән шуны сорамакчы идем,—диде Харис Халидәгә борылып.—Зиратта табут күтәреп безнең турдан узган егетләрне сез белмисезме?

—Мин аларны башта сезнең танышлар, дип уйлаган идем.

—Бәлки, сезнең кешеләр булгандыр?

—Алай ук түгел инде... Бер тапкыр күргән идем. Кафега барган идек без Җәүһәрия белән. Шунда...

—Димәк, алар Җәүһәриянең танышлары?

Халидә авыр сулап, урындыгына утырды. Башын иде. Хариска аның сары ефәк бөдрәләре генә күренә иде.

—Шагыйрә белән урам жуликлары арасында нинди уртаклык булды икән?—диде Харис.

Халидә кинәт башын күтәрде дә, зәңгәр күзләреннән ук очыргандай итеп, Хариска ачу, әрнү белән текәлде:

—Ә кая барсын?—диде каты итеп.—Кемнән ярдәм сорасын? Сез менә бик намуслы, ул сезгә ышана иде... Ярдәм иттегезме соң? Кафенең эченә ургып аккан суны туктаттыгызмы? Бинага каравыл куештыгызмы? Түбәсенә Кызыл Ай куярга килдегезме? Юк бит! Юк! Акыллы, көчле, намуслы ирләрнең берсе дә ярдәм итмәде!

Харис мондый гаепләүне, бу кадәрле ярсуны көтмәгән иде, югалып калды, ни диярә белмәде. Халидә торып, графиннан су салып эчте.

—Ә братва ничек ярдәм итте?—дип сорады Харис.

—Бинаның эченә шарлавык кебек су ага иде, аны туктаттылар. Ишекләрен бикләп, каравыл куйдылар.

—Ә ул аларның кемнәр икәнен белә идеме?

—Ак чырайлысы Равил, шундагы машиналар төзәтү мастерскоеның хуҗасы.

—Ә муены яралысы?

—Анысын бик белмим. Машинасын төзәттерергә килгән булгандыр, бәлки, шунда күзгә чалынып киткән иде.

—Әйе, ул онытыла торган кеше түгел,—диде Харис сузып.—Җәүһәрия шулардан игелек күрермен, дип уйлады микәнни?

—"Братва" дип маңгайларына язып куелмаган. Эш кешеләре бит. Машина ремонтлыйлар әнә.

Һәм Халидә, Харисны күрәсе килмәгәндәй, борылып, карашын тәрәзә артына, чәчәккә күмелгән куе юкә агачына төбәде. Ул каршысында утырган яшь чырайлы, беркатлы тоелган ирдән бигрәк, үз уйларына, үз күңеленә килгән шик-шөбһәгә ярсый, аларга каршы дәлилләр китерергә тырыша иде.

—Кешеләрдән гел яхшылык кына көтте бит ул. Күзенә китереп төртмәсән, бернинди начарлыкны күрә белми иде,—дип өстәде аннары.—

Үзе өчен йөрүе дә түгел иде. Бандит кулыннан көн күрергә калмаган!

—Шулай да, нинди акчага яшәде соң ул?—дип сак кына сорады Харис.—Соңгы вакытта шагыйрьләргә гонорар түләү беткән, дип ишеттем. Эш хакы алмаган, диләр...

Халидә урыныннан кузгалды да, ишек янындагы шкафтан чия төсендәге кыска итәкле жилән, хәзергечә әйткәндә, "кардиган" алды.

—Менә шушының белән тамагын туйдырды ул... Күлмәкләр, кофталар бәйләп сата иде. Монысын минем бер танышым сораган иде. Илтеп биреп, акчасын алырга өлгермәдем. Менә карагыз! Күргәзмәгә куярлык.

Түше, инсәләре ука белән чигелгән, бик затлы, зәвыклы, нәфис кием иде бу. Базардагы төрек малы моның янына якын да килә алмый... "Әйтәм аны, гел бәйләгән әйбер кия торган иде...—дип уйлады Харис.— Үзенең кул хезмәтедер дип кем уйлаган... "

—Мескенкәем, шагыйрә башы белән базарда үзе бәйләгән әйберләрне сатып йөрде. Гарьлегеннән елаган чаклары да булды!

—Соңгы елларда күпләрнең хәле мөшкелләнде шул,—диде Харис тыныч тавыш белән.

—Нишләп соңгы елларда гына булсын! Гомере буе шул эш белән шөгыльләнде! Ул шушы мәдәният йортында әдәби түгәрәк житәкчесе иде. Аның инде оклады ташка үлчим. Шагыйрьләргә шигырь өчен беркайчан да иркен яшәрлек итеп түләмәделәр. Рухи азык житештерүче талантлы балаларын безнең халык беркайчан зурлап бәяләмәде, аларны ашатырга теләмәде... Икенче китабының акчасына, язучылар төркеме белән, Япониягә барганнар иде алар. Шуннан бәйләү машиналарына кызыгып кайткан иде мескенкәем. Андагы кибетләрдә искиткеч сырлар, бизәкләр ясый торганнары бар, дип сөйләгән иде. Тик акчасы житмәгән, чит илләргә барганда утызар доллар гына алыштыралар иде бит. Японнар безгә мыскыллап кына карыйлар, хәерчене кем ихтирам итсен, дип, бик гарьләнеп кайткан иде. Үзе өчен генә түгел, ил өчен гарьләнгән иде... Үз кадерен үзе белми торган халык... Үз талантларына юл бирми торган халык... Башка бер илдә туган булса, ялтырап балкып торачак иде. Шигырьләре белән дә, милләте өчен кылган гамәлләре белән дә. Студент чагында ук китабы чыгып, язучылар союзына кабул ителгән тагын шундый кем бар? Юк андый! Бердәнбер иде ул! Ләкин... язмышы тоташ фажига булды шул...

Харис учындагы китапчыкларга карады: "Заморозки для подснежника"... Татарча ничек була? "Умырзаяга кырау"? "Умырзая өчен кыраулар"? "Чыктым аркылы күпер" түгелме бу? Татар шагыйрәсе бөтенләй башка сүзләр табар иде!

—Кайсы халыкның кызы иде соң ул?—дип борчылып сорады Харис.—Нинди әдәбиятны үстерде?

—Аның гына түгел, гомумән шәһәр балаларының уртак фажигасе шул бит инде! Совет халкының милләте бер дип санала иде. Соңгы елларда гына, кем кайсы милләт баласы, дигән сорау алга килеп басты. Жәүһәрия кебекләр ике ут арасында калган кебек булдылар. Үз халкыннан читләшкәннәр, чит халык аларны үзенеке дип танымый. Халкы өчен нидер эшлисе килеп оештырды инде ул бу жәмгыятьне. Үз башына йөргән икән.

—Сез шул жәмгыять аркасындадыр, дип уйлыйсызмыни?

—Ире түгел бит инде! Ни генә дисәләр дә Букштейн андыйга бара торган түгел!

—Ә сез аны яхшы беләсезме?

—Күнелем сизә. Мондый жинаятькә бару өчен баш жүя торган псих булырга кирәк. Яисә хатынының шашып яратырга һәм үлеп көнләшергә.

—Ә көнләшергә сәбәп бар идеме?—дип сорады Харис.

—Сез нәрсә! Без аны жирләп кенә кайттык... Гайбәтен сатарга!

—Гайбәт түгел... Алар ире белән асылда аерылышканнар бугай бит!

—Җәүһәрия якут таш кебек чиста иде! Никахланышмыйча, качып-посып яшерен мөнәсәбәтләргә керә торган түгел!

—Инде... Бүгенге заманда...

—Минем бу турыда сөйләшәсем дә килми. Ә Букштейн хакында шуны әйтә алам: ул мондыйга сәләтсез.

—Каян беләсез?

—Йә, үзегез уйлап карагыз,—диде Халидә,—көнләшсен, ди, Букштейн, кызып китеп, сугып җибәргәндә, артык каты бәреп куйсын, ди. Ләкин ник ул аның күзен чокысын?

—Ничек... күзен?..—дип телен чак әйләндереп сорады Харис.

—Нәрсә, белмисезме әллә? Шулкадәр ерткычларча җәзалап үтергәннәр бит мескенкәемне,—диде Халидә.—Татардыр әле мөртәт. Инде үтерәсе булгач, күзләрен ник сытты икән? Күз кабакларынан гел дым саркып торды, һаман елаган шикелле. Адәм затының ерткычлыгына чик-чама юк.

Харисның башы әйләнеп китте.Чыннан да, җеназада мәрхүмәнең күзләрен яулык белән каплаганнар иде шул. Ләкин... Җәүһәриянең күзләрен ул үзе йомдырды бит. Исән иде, якты иде күз алмалары... Әллә теге гәзит мәкаләсендә язылганнар дөрес булганмы? Тикшерү максатында күз бәбәкләрен алып, криминалистларга биргәннәрме?

* * *

Кич белән гәзит актаргалап утырганда, Харис, "Казан урамнарында тагын атыш" дигән мәкаләгә юлыкты. "Узган атнада шәһәрдәге җинаятьчел төркемнәр арасында янә канлы бәрелеш булды. Берәүнең улы туган икән дә, бәхетле әти әшнәләре белән "бәбинең тәпиен юган". Кызып киткәч, дәртләре кабынып, "кызлар" чакырырга булганнар болар. "Бәйрәм" тәмамлангач, фахишәләрне акча түләмичә генә куып чыгарганнар.

Соңгы вакытта бу урамда үзенә аерым бер җинаятьчел төркем оеша башлаган һәм алар "төнге күбәләкләрне" үз канатлары астына алганнар икән. Алар "бәхетле әти"нең һәм аның кунакларының эзенә тиз төшкәннәр. Һәр ике як элекке "Баллы күл" кафесына бара торган аулак урамда очрашкан. Низаг чыккан, атыш киткән. Икесе, шул исәптән теге "бәхетле әти" дә, больницада җан тәслим кылган.

Мәрхүмнәрнең буйдагы "Баллы күл" кафесы янындагы машиналар төзәтү мастерскоенда эшләүче егерме яшьлек Геннадий Козлов булып чыккан. Ул узган көздә армиядән кайтып, кыш буе эшсез йөргән, әле күптән түгел генә эшли башлаган. Тикшерү бара.

Соңгы вакытта шәһәрнең ул урамнары куркыныч урынга әйләнде, андагы хәлләр тикшерү органнарына эш артыннан эш тудырып тора. Шагыйрә Жанна Баянованың (Җәүһәрия Байбулатова) мәете дә "Баллы күл" кафесыннан табылган иде. Кызганыч ки, тикшерүчеләр бу җинаятьне "кайнар эзләр буенча" ача алмадылар. Бүгенгәчә аларның хәтта нигезле, анык фаразы да юк шикелле. Болай барса, Казан озакламый бу юнәлештә Мәскәүне узып китәчәк. Анда да бит күренекле шәхесләрне үтереп торалар, җинаятьчеләр табылмый."

Харис мәкаләнең соңгы өлешен тагын бер тапкыр укып чыкты. "Тикшерүчеләрнең нигезле фаразы" юк, димәк. Ә мәкалә авторының фаразы бар икән—җинаятьчел төркемгә ишарә ясаган.

Ул, вакыт соң булуга карамастан, Мансур Хуҗиевичның өенә шылтыратты. Иртәгесен тугызда очрашырга сүз куештылар.

...Харис ишекне ачканда, тикшерүче ялгызы түгел, өстәл кырыенда, ишеккә аркасы белән, бер ир утыра иде. Ул кеше кинәт борылып, аксыл кашлары астыннан сөзеп карады. Таза муенында кызарып, бүртеп торган

җөй күзгә ташланды. Карашыннан тимер салкыны бәрде. Харис аны таныды: зиратта табутның бер почмагыннан тотып барган адәм иде бу.

—Килдегезме, исәнмесез,—дип, урыныннан кузгалып, Хариска кулын сузды Мансур Хужиевич.—Бик яхшы. Ашыкмыйсызмы?

—Вакыт бар.

—Алайса бераз гына көтегез. Безнең эш хәзер бетә.

Харис, коридорга чыгып, кыршылган урындыкка утырды. Ул ишекне ныклап ябып житкермәгән икән, эчтә сөйләшкәннәре ишетелеп тора иде.

—Сез бер дә юкка минем белән вакыт сарыф итәсез, иптәш майор,—диде каргылдаган тавыш, генерал Лебедька охшатып.

—Берсен дә күрмәдем, белмәдем, дисен инде, Матвей,—диде Мансур Хужиевич.—Фахишәләр өчен атышкан егетләргә катышым юк, димәкче буласың.

—Тавык артыннан чапкан һәр әтәчкә каравылмы әллә мин бу районда? Сез бик яхшы беләсез: ул кичне мин эштә идем—банкта сакта! Минем алиби—железный!

—Ләкин атышта катнашканнарның дүртесе—сезнең егетләр! Корал каян килгән аларга?

—Ә "Караташ"ка каян килгән? Аларга тешегез үтми! Монда килеп, безнекеләрне чүкеп кенә йөрмәкчеләр! Цеховиклардан ясак жыймакчылар! Житте безнең районны саварга! Без монда тәртип урнаштырдык һәм шул тәртипне саклыйбыз гына. Безгә моның өчен рәхмәт әйтү тиеш! Элек дружинникларны әнә ничек мактый идегез. Ә без дружинниклардан киммени?

—Козлов та синең дружинник идеме?

—Кем булса да ул корбан! Аны үтергәннәр! Сволочьлар! Әфганда чакта очрамадылар! Анда без аларны башкача биетер идек! Симергәннәр монда, жыен селәгәйне талап! Тәртип юк, тыючы юк, каршы әйтүче юк!

"Аңлашылды,—дип уйлады Харис.—Әфган синдромы бу Матвейда. Төркем оештырып йөри, димәк. Ерак та түгел, кафе тирәсендә".

—"Караташ"ларны акылга утыртасың килгәч, очрашуга ник үзең бармадың соң?

—Ул кичне мин банкта дежур идем, дидем бит!

—Ташла, ипи-тоз белән каршы алмасларын чамалагансыңдыр. Үз жаның үзеңә газиздер

—Мин огнеметлар астында яткан солдат, иптәш майор! Үзегез белән чагыштырмагыз! Әгәр мин барсам, аяк астымда мүкәләп йөрерләр иде! Тәртәгә кертәм әле мин аларны!

—Инде килеп "Караташ"ка бернинди мөнәсәбәте булмаган кешеләрнең мәетләре безнең районда табыла башлады.

—Нинди мәет, кайда мәет?

—Ә кафеда табылган шагыйрәнең мәете?

—Анысын инде безгә тага алмыйсыз, иптәш майор. Анысы сезнеке.

—Ничек безнеке?

—Анысы милиция ипие. Әзме безнең районда алкашлар хатыннарын имгәтә, йә суеп ташлый? Йә азгын хатыннар ирләренең башына житә? Йә сөяркәләрен сарык урынына чалып ыргыталар? Аның ишегә без ник тыгылыйк? Сез белегез, сез күрегез! Анда сезгә лафа! Жинаятьләрне сәгатендә ачасыз! Жинаять коралы—канга баткан ипи пычагы, үтерүчесе ләх исерек, шунда ук аунап ята. Жинаять ачыла, гаепле ябыла, сезнең погоннарга яңа йолдызлар тагыла... Анда безнең бер дәхелебез дә юк.

—Син, Шайдулин, шамакайланма. Бытовуха турында сүз бармый. Жинаять жәмәгать бинасында булган.

—Нинди жәмәгать бинасы булсын ул хәрабә? Бомжлар оясы! Үзе бомждан кай ягы белән аерыла иде соң ул такмаза язып йөргән жилбәзәк хатын? Нинди мәйданга, нинди бинага хужа булмакчы! Бете дә юк үзенең расчетный счетында!

—Ә син каян беләсең аның расчетный счетында акча барын-югын?

—Бу заманда информациясез булмый, иптәш майор.

—Андый информация банктан читкә чыгарга тиеш түгел.

—Мин банкта эшлим дә бит инде.

—Синең ишек төбеннән узарга хакың юк. Әгәр мин моны ходка җибәрсәм...

—Аның белән генә бернишләтә алмыйсыз, иптәш майор! Ә безгә кемнең бәясе ни хак икәнен белеп торырга кирәк. Ансыз булмый. Так что ул хатын бер тиен дә тормый иде. Алай да, килеп ялынгач, ярдәм иттек. Кранны яптык, каравыл куйдык.

—Аның өчен ул сезгә нәрсә вәгъдә итте инде?

—Аннан ни аласың? Соңгы вакытта, бинаны аңа бирмиләр, дигән сүз китте.

—Кем әйтте?

—Анысын администрациядән сорагыз. Җилләр шул яктан исә. Аңлыйсыздыр, ул хатын белән кем кул пычратсын? Ире килеп сөяркәсе белән тоткандыр да, чамасыз ярсыган хәлдә...

—Иртәнге тугыздамы?

—Сөяркәләрне нәкъ шул сәгатьтә тоталар да инде! Безнең егетләр аның эше карчык-корчыкка ымсынырга калмаган! Ачылып килгән чәчкә кебекләре җитәрлек.

Харис урыныннан сикереп торып, ишекне ачты да йөгереп барып урындыкта утырган адәмнең яңагына сугып җибәрде. Ул моның ничек килеп чыкканын үзе дә сизми калды. Шул ук мизгелдә ул атылып китеп, китап шкафына барып бәрелде. Шайдулин күз иярмәс хәрәкәт белән аны алып аткан иде. Ул чатнаган башын калкытканда, теге адәм кыргый ярсу белән кызарынып, Мансур Хуҗиев шаккатып аңа текәлгәннәр иде.

—Лейтенант! Отставить!

Әкрен тавыш белән, әмма эчке куәт салып әйтелгән бу команда, хәрәкәт ясап өлгермәгән, ләкин тәне киерелгән Шайдулинны туктатты.

—Ә сез, Харис Мирзаянович, утырыгыз.

Тикшерүче Харисны бүлмәдән чыгармады. Димәк, муены ертылган бәндә каршында аны милициягә якын, кирәк кеше итеп күрсәтте. Ә бу—Харисны үз итүне, нык яклауны аңлата иде.

—Тагын берәр нәрсә өсти аласызмы, Шайдулин?—дип сорады Мансур Хуҗиевич берни булмагандай.

—Ул ахмак хатынның башына, мөгаен, менә шушындый берәү җиткән. Берәр псих эше бу. Бөтен яктан туры килә. Икенче урынга ирен куярга кирәк.

—Нишләп икенче?

—Хатын өчен башын югалта торган ир сирәк. Үзем ир. Беләм. Ә син, күсәк, әгәр үзең бәреп үтермәгән булсаң, мангаеңны кашы. Мөгезең чыккандыр. Синнән башка тагын сөяркәсе булган, шул чалып ыргыткан аны, беләсең килсә!

—Ярый. Башка әйтер сүзең булмаса, хәзергә саубуллашыйк. Сак булырга тырыш, мина кырына кереп барасың бугай,—диде аңа Мансур Хуҗиевич.

—Мина кырларын узу безнең һөнәр бит инде ул,—диде Шайдулин. Аннары Хариска борылып, мылтык-карашын төбәп:

—Хәзергә,—дип өстәде.—Юллар кисешер кебек әле. Күңел шулай тоя.

Шулай диде дә, хәрбиләрчә төгәл хәрәкәт белән борылып, ишеккә юнәлде.

—Син нәрсә, туган, шаштыңмы әллә? Минем кабинетта кеше кыйнарга!..—диде Мансур Хуҗиевич Хариска.

—Мәрхүмәне пычратырга, аның намусына шакшы төкереген чәчәргә ярыймы?

—Миннән торса икән. Кызганыч, шакшы адәмнәр күп йөри торган

жиргә Байбулатова үзе барып кергән. Андый чакта кешегә кер-тузан куна шул инде.

—Ә бу бандит кем соң?

—Бандит ук дип атарга нигез юк әле. Әфганда сугышкан егет. Хәзер банкта сакчы булып эшли.

—Күз буяу өчендер инде.

—Без дә шулай дип уйлыйбыз. Ну, тамак туйдырырга да кирәк бит. Безнең мәгълүматлар буенча, ул бу тирәдә төркем оештырып йөри. Монда "Караташ" төркеме бик канат җәйгән иде. Хәзер болар аларны кысрыкламакчы. Әгәр чынлап тотынсалар, эшләр булачак әле.

—Һәммәсен белеп торасыз үзегез, ә, диде Харис әрнеп.

Ул: "Ә җаннарны кыюны туктата алмыйсыз",—диярга теләгән иде, тыелып калды.

—Нәрсә, белми торсак әйбәтрәк булыр иде, димәкчеме әллә? Ә сезгә сабыр һәм бик сак булырга кирәк,—диде Мансур Хуҗиевич.

Харис, шкаф кырыена бәрелгән башын учы белән капшады. Фикерләрен тупларга тырышты. "Бәлки, Халидә хаклыдыр, Букштейн чыннан да ерткыч була алмастыр,—дип уйлады ул.—Ә менә Матвей Шайдулин дигән бу адәмнең кеше күзен чукып алуына ышанып була!"

—Шуны сорамакчы идем: күз бәбәкләрен тикшерү нәрсә күрсәтте соң?—дип сорады ул Мансур Хуҗиевичтан.

—Кемнең күз бәбәкләрен?

—Байбулатованың инде.

—Ләкин аның күз бәбәген алмаганнар, аларны үтерүче тишкән. Судмедэксперт шулай дип язган.

—Ничек үтерүче тишсен? Аның күзләре исән иде. Мин үзем йомдырдым.

—Бутамыйсызмы?

—Ничек бутыйм? Күзләре шар ачык иде. Бер генә түгел, берничә тапкыр күз кабакларын төшердем. Аннары битенә кульяулыгымны яптым. Моргка шул килеш илтеп тапшырдык.

—Беркая да китмәдегез, гел янында булдыгызмы?

—Кафеда сез киткәннән соң, озак та тормадык, моргка киттек. Алып кертеп яткырганчы, яныннан китмәдем.

—Алай булгач, моргта кылган булып чыгалар ул эшне.

—Мин тикшерү максатындадыр, дип уйладым. Күз бәбәгендә үтерүченең сурәте кала, дигәнне ишеткәнем бар.

—Бик яхшы булыр иде!—диде Мансур Хуҗиевич.—Ләкин ул детектив язучыларның фантазиясе генә шул әлегә. Андый тикшерүләр гомумән үткәрелми. Һәрхәлдә, моны ачыкларга кирәк.

—Димәк, Букштейннан шик төшә инде болай булгач?—диде Харис.

—Нишләп алай дип уйлыйсыз?

—Ни дисәң дә, тәрбияле кеше бит. Ул кадәр садист булыр микән?

—Ә бәлки, бераз тынычлангач, детективларда укыганы исенә төшкәндер. Күз бәбәгенә сурәтем сеңеп калмады микән, дип уйлана башлагандыр. Чарасын күрергә кирәк, дигән фикергә килгәндер. Хәзер менә тагын безгә эш арта. Морг тирәсенә килгәнме ул, анда танышбелешләре булганмы, мәет янында үзе генә калмаганмы... Һәммәсен ачыкларга туры киләчәк...

* * *

Саф алтын кирпечләрдән өелгән диварны күргәнегез бармы? Әнә ул—каршыгызда. Елык-елык итә, күзләрне камаштыра. Дивар янында, нур чәчеп, алтын баганалар калка башлый. Алар зурая, биегәя, рәвешен үзгәртә. Ниһаять, күңелне ымсындырып, кызыктырып, тылсымлы капка булып, өч хәреф торып баса: "МММ". Шулар аша узсаң, байлык-зиннәт иленә барып керәсең, ди көр тавыш. Әкияттәге

кебек. Юк, әкияттәгедән җинелрәк, чөнки монда байыйм дигән кешегә дию муенын борырга да, аждаһа башын кисәргә дә, явыз патшаның мәкерле табышмакларын чишәргә дә кирәкми. Миенне түндерәсе дә юк, беләкне талдырасы да. Фәкать диварга уелган тишеккә акча тыгып, аннан "МММ" дип язылган кәгазьләр генә алырга кирәк. Берәр айдан акчаңны уны белән кайтарып бирерләр, өстенә алтын сибелгәндәй булырсың.

Баксаң-күрсәң, андый тылсымлы капкалар тагын бар икән. Әнә бер хатын, гөлләр арасында утырып, сабыеның башын сыйпый. "Русский Дом Селенга" дигән оешманың кәгазьләрен алган да шуннан соң бәхеткә тиенгән. Ул арада тагын бер күренеш: ике мәгълүм артист елмаеп тәкърарлыйлар: "Хопер-инвест—отличная компания, Хопер-инвест—отличная компания".

Харис телевизор экранында балкыган алтын баганаларга, байлыкка тиенгән адәмнәрнең тук һәм канәгать чырайларына йөзен чытып карап-карап торды да, ян стена буендагы кәнәфидә утырган әңгәмәдәшенә борылды. Һәм... нидер әйтергә ачкан авызын йомарга да онытып, тын калды. Даниф бөтен гәүдәсе белән телевизорга таба тартылган, кызарынган йөзендә яшькелт күзләре зураеп, чекерәеп яна иде. Көн саен әллә ничә тапкыр кабатланып торган рекламаны беренче тапкыр күргән, диярсең.

—Син нәрсә, Даниф, бу жуликларның сүзенә ышанасыңмы әллә? Шуларның кәгазен сатып алсаң, каршыңа алтын тавы ишелер, дип уйламыйсыңдыр бит?

—Рычагын табып, вакытында төртә белергә кирәк! Минутын ычкындырмаска! Бер селтәнүдә ишелә ул алтын таулары! Заманы шундый!

—Ишеп караганың бармы әллә?

—Ишкән кешеләрне күргән бар,—диде Даниф иреннәрен чәйнәп.

—Акча үзеннән-үзе балаламый! Орлыгы юк, түтәлдә дә үстереп булмый. Байлык, әнә, басуда гына юктан бар була. Бер орлыкны чәчсәң, ун булып үсә. Эшләргә кирәк! Чәчәргә, урырга! Ә болар—жуликлар, күз буып кеше талаучылар!

—Ләкин меңәр процентны түлиләр, вәгъдәләрендә торалар!

—Алар бит акчаны бирәүдән ала да икенчесенә бирә. Халыкны ымсындыру өчен. Ахыр чиктә, акчаны күп итеп җыеп алгач, конторларын ташлап качачаклар, күр дә тор. Аларга ышанып, барлы-юклы акчаңны илтеп бирә күрмә тагын! Ачык авыз булма!

Харис китапханәнең уку бүлмәсендә җәмгыятьнең элекке еллардан калган бухгалтерия документларын караштырып утыра иде. Монда тыныч, борчучы юк. Даниф аны эзләп кергән иде. Туктаусыз эшләп торган телевизор экранындагы реклама хакында шунда сүз алышып алдылар.

—Акча булса, "МММ" я "РДС" аша балалатып алу яхшы булыр иде дә бит,—диде Даниф көрсенеп.—Юк шул әле ул акча. Хәзергә. Менә цехлар яхшылап эшләп китсә инде... Барабызмы?

Берничә көн инде ул Харисны яңа ачкан цехларына барып килергә үгетли иде. Кадак ясый башлаган һәм капчыклар, бияләйләр тектерә икән. Инде әллә ничә тапкыр, хикмәтле сумкасыннан калькуляторын алып, Харисның борынына ук терәп, дигәндәй, санап та күрсәтте: ай саен кадак сатып күпме табыш алачак та, капчык-бияләйләрдән нихәтле керем керәчәк. Иркенрәк бинага, ягъни теге кафега урнашып, цехларны киңәйтеп җибәрсәң, эшләр гел харап алга барачак икән. Электр булмау гына тоткарлый. Кафедан, табигый инде, электр чыбыкларын өзеп куйганнар, шуларны тоташтыру гына кирәк. Моның артыннан, билгеле, Харис чабарга тиеш, ә чабу өчен дәрт кирәк.

Харисның исә бу эшкә һич тә дәрте юк иде. Моңа кадәр ул, ыкмык итеп, цехларга баруны суза килде. Тикшерүче Мансур Хуҗиевичның кушканын үтәп, җәмгыятьнең өч еллык бухгалтерия кәгазьләрен бик җентекләп карап чыгасы бар иде. Ә ул узган елгыны гына актарды бит әле. Аннары тагын шунысы да бар: Даниф акча табу ысулларын күп

кулланды, булачак табышларын калькуляторында да күп тапкырлар санады. Гөмбә сатып ничек баеп китәчәген, бия савып, умарта үрчетеп, дача йортлары торгызып күпме акча табачагын... Андыйрык планнарны Харис эшли торган төзү трестында да күп тапкырлар корып карадылар. Бөтен ягын уйлап, керем булырына инанып эшкә тотынасың. Алны-ялны белмичә, эш хакы да алмыйча, дигәндәй, тырышып, бинаны торгызып куясың. Ахырдан санап карасаң, исләрең-акылларың китә: эш хакы алу түгел, муеннан бурычка баткан буласың... Салымнар арткан, кирпеч-бетонга хаклар шашып күтәрелгән, йортка заказ биргән оешма акча түләми, ул арада инфляция син аласы акчаны чүпкә әйләндергән...

Ә телевизордан, әнә, тагын "МММ" ны, "РДС"ны мактыйлар, акчаңны шунда илтеп биреп, түшәмгә төкереп тик ятарга өндиләр. Табыш сиңа үзе йөгереп киләчәк, имеш...

Харис, көрсенеп, өстәлдән кәгазьләрен җыярга кереште. Кешенең һәр сүзенә каршы төшеп, гел-гел кирегә сукалап кына булмый бит инде! Телевизордан сөйләгәнне хурла, Данифның гозерен үтәмә... Эшләргә маташып йөри бит кеше, цех ачкан әнә...

—Әйдә соң, карап кайтыйк булмаса,—диде ул.

Кәгазьләрне җәмгыять бүлмәсенә алып төшеп, зәңгәр сейфка шартлатып бикләде дә, Нурҗиһанга бүген бүтән килмәячәген әйтеп, ишегалдына чыкты. Калтырча "Уазик"ның кояштан кызган бөркү кабинасына утырды.

Данифның цехлары тимер-бетон эшләнмәләр комбинатында иде. Иркен ишегалдына кергәннән соң, машина белән шактый бардылар. Йөзләрчә метрларга сузылган биек тимер-бетон корылмалар тирәсендә кеше-кара күренми, ишегалдындагы ике-өч "КамАЗ" да, мөгаен, күптән кузгалмаган иде. Корылмаларның берсе янында туктадылар, аның бер башыннан шакылдаган тавыш ишетелә.

—Шушындамыни?— дип сорады Харис.

—Шушында.

—Ә син кысан дип зарланасың.

—Минеке түгел бит ул! Хуҗалары бар! Бүген үк бушатырга кушалар!

—Ник? Буш тора лабаса?

—Сатып җибәрмәкчеләр.

Элекке елларны Харис, бетон блоклар, панельләр юллап, биредә еш килә торган иде. Корылмаларның эчендә көне-төне хәрәкәт, гөрелдәү тынмый, ишегалдында "КамАЗ"лар тезелеп чират тора иде. Хәзерге тынлык, бушлык Хариска бик авыр тәэсир итте. Кая киткән мондагы эшчеләр? Кайсы юлларда йөри икән биредә киләсе машиналар? Ни сәбәптән туктап калды икән төзелеш-корылышлар?

Яңа йортлар кирәк бит, шәһәрдә гомере буе фатир көтеп яшәгән халык санап бетергесез. Ярый, чүпрәк-чапракны "челнок"лар сыртына салып, чит илдән ташый алабыз. Ләкин йортлар салыр өчен бетон диварларны Каф таулары артыннан кайтарып булмый! Идән, түшәм, баганаларны аннан китерә алмыйсың!

Мондый корылмаларны, краннарны, станокларны болай ташландык хәлдә тоту үзе җинаять!

Данифның цех дигәне чолан хәтле генә тәрәзәсез бер бүлмә булып чыкты. Уртага кадак ясый торган станок кертеп куйганнар. Ян-як стена буена унбиш-егерме тартма өелеп тора, аның кайсылары ялтырап торган кадак белән тулган, кайсылары буш. Икенче стена буенда озын, юан тимерчыбык өеме. Комбинезон кигән, колакларын кара колакчыннар белән каплаган алтмыш тирәсендәге чандыр абзый станок янында кайнаша.

—Ну ничек?—дип аның колагына авызын терәп диярлек сорады Даниф.

—Бара...

—Озакламый иркенгә күчәбез! Тагын станоклар кайтарабыз! Бергәләп эшләрсез! Җиңелрәк булыр!

Станокның тукылдавы, чинавы таш диварларга бәрелеп, кайтаваз булып яңгырый, сөйләшергә ирек бирми иде.

Даниф, горурланып, тартмадан елтырап торган кадаклар алып, Харисның битенә диярек китереп тәрәде.

—Шәп бит, ә!

Бүлмәдән чыгып, бинаның шул ук очындагы тимер баскычтан икенче катка күтәрелделәр. Данифның тагын бер "цехы" шунда икән. Стена-түшәменең акшары кубып коелган, идәне яргаланган котсыз бүлмәдә хан заманыннан калган биш тегү машинасы куелган. Тегү фабрикаларында шундыйлар белән тегәләр иде. Хәзер ул фабрикалар бөлде, тегүчеләре урамга чыгарып җибәрелде. Аларга эшне үзләрен- үзләре табарга кушылды. Фабрикаларның биналарында башка ниндидер оешмалар ачтылар, ә тегү машиналарын бушка өләшкәннәр, кайсыларын тәрәзәдән урамга томырганнар, дип тә сөйләгәннәр иде. Даниф шуннан җыеп кайткан булса кирәк.

Биш хатын киндер бияләй тегә.

—Бусы бригадир,—дип алтынчысы белән таныштырды Даниф.

Өлкән яшьтәге талчыккан кыяфәтле апа Хариска, нәрсәдер өмет иткәндәй, текәлеп һәм сынап карады. Харис карашын читкә борды—анын күнелен кызгану хисе биләп алды. Буш, тын, котсыз зур корылманың бер почмагында, тузан эчендә, чүплектән алып кергән, кыршылган машиналарда юк-бар әмәлләп, чикерткәдәй сикергәләп йөргән шушы Данифның күзенә карап утыр әле син! Гөрләп торган зур цехларда, ышанычлы, җаваплы житәкчеләрнең кул астында, зур коллективларда жимерттереп эшләгән кешеләр бит алар! Монда казганунын мәгънәсезлеге көн кебек ачык! Тик кая барсыннар? Башкача ничек көн күрсеннәр?

Ләкин, өметсез шайтан, диләр, бу апалар да дөньялар һаман болай бармас, бер жае чыгар, дип уйлыйлар. Хужа белән килгән бу яңа кеше берәр юлын тапмасмы, дип өметләнәләр иде.

—Шушы арада яна урынга күчәчәкбез. Тагын кешеләр алырга туры килер. Уйлый торыгыз,—диде Даниф бригадирга.

Кире чыгу юлына барганда:

—Ике цехны да бер тиен акча тотмыйча оештырдым,—дип мактанып барды ул.—Кадак станогын бер танышым бирде, тегү машиналарын фабрика директоры үзе тәкъдим итте. Эш кешесен таныйлар, бәялиләр!

Ишегалдында алар янына пычракка каткан зәңгәр "Жигули" килеп туктады. Алгы утыргычтан иненә озын баулы ак сумка аскан, култык астына папка кыстырган нечкә сынлы кыз чыгып басты да, Данифка карап елмайды. Тузан, кер, шомлы тынлык, төшенкелек хөкем сөргән дөньяда бу яшь кыз бала язын шәһәр ишегалдындагы асфальтны тишеп чыккан тузганак чәчәге кебек балкып тора иде. Күзенә төшкән кыска чәче жете сары, күзләреннән, йөзеннән жылы бөркелә, муены неп-нечкә, нәфис... Каян килгән, нишли бу манекенщица монда? Баксаң, Данифның бухгалтеры икән. Кадак ясаучы абзый белән бияләй тегүче апалар эшләгән акчаны санарга ялланган. Модада шул хәзер акча санау кәсебе!

Харис, дөньясын онытып, чибәркәйгә карап торган арада, машинадан ике яшь егет тункаешып чыктылар—алары компьютер тоткан иде: берсе мониторын, икенчесе процессорын.

—Компьютеры да синамы әллә?!—дип шаккатып сорады Харис Данифтан.

—Бухгалтер кешегә ансыз булмый.

—Акчам юк дисең үзең, бөлдем дисең, ыштансызга каеш билбау була түгелме соң бу? Аның хакын каплар өчен күпме кадак, күпме бияләй сатарга кирәк?

—Компьютерсыз аны санап бетереп булмый,—дип сүзне шаяруга борырга тырышты Даниф.

—Түлисе салымнарыгызны да шунда чутлап чыгарасызмы?

—Анысын ничек түләми котылып булганын санарга кирәк...

Бер егет тәэминатчы, икенчесе менеджер икән. Димәк, теге алты хатын белән бер абзый бу өчәүнең тамагын туйдырырга, аларның машинасын ремонтлау, бензин салу өчен, компьютер хакын түләү өчен дә эшләргә тиешләр икән. Аның өстенә Даниф үзе дә бар бит әле. Ул—директор! Аның өстенә—хөкүмәт, ана йөзләгән төр салым түлисе... Аның өстенә электр өчен... Бина өчен...

Даниф белмиме моны? Нишләп белмәсен, мондый эшләрдә күп буталган, алай гынамы, шактый кыйналган егет бит ул! Бөтенләй томана түгел. Шулай булгач, ник йөри әвәрә килеп? Шуның өстенә, күпме кешенең башын катыра бит әле!

Машинада кире кайтканда, Харис шулай уйлады. Даниф исә һаман үзенекен такылдый иде:

—Әлбәттә, бу күләм белән генә табыш алу кыен. Кинәергә кирәк. Бина бар хәзер безнең, электр гына тоташтырасы. Инвалидларны эшкә алырбыз, алардан салымны аз түләтәләр. Станокларын бушка табарбыз. Минем элемтәләр житәрлек. Икәүләп тотынсакмы! Беребез президент, икенчебез башкаручы директор...

—Миннән булмый,—диде Харис.

—Нишләп?

—Борын ис сизми минем.

—Хушбуй цехы ачмабыз ла...

—Бизнес исе сизмим мин...

Рульдә утырган Даниф, аңа борылып, гажәпләнеп карады:

—Нәрсә исен сизмим, дисез?

—Бизнес исен, дим.

—Аның исе буламыни?

—Бизнес ул тере нәрсә, минемчә. Туа, зурая, мантый, чәчәк ата, жимеш бирә...

—Жимеш! Акча, диегез! Ә акчаның исе булмый! Деньги не пахнут!—Данифка бу кызык тоелды, ул ачылып китте, көлеп жибәрде.

—Акчаның, бәлки, исе юктыр. Анысы да кем өчен ничек бит. Күп кешегә хәләл акча гына килешә, хәрамын күңелләре кабул итми. Ис сизү түгелме бу? Урысларда "дохлое дело" дигән сүз бар. Кайсыбер эшгамәлне үләксәгә тиңлиләр. Өметсез, аңа бәйләнсәң мантымаячаксың, дигән сүз. "Живое дело" дигәне бар тагын. Эшләве рәхәт, әжере дә бар, дигән сүз. Эшнең була тересе, була үлесе, димәк. Тересе сәламәт сабый кебектер, аннан хуш ис анкыйдыр. Ә теге үләксә дигәненнән мәет сасысы киләдер. Менә мин шуларны аера белмим,—диде Харис.

Ул инде Данифның: "Мин үзем дә шулайрак шул",—дип әйткәнен көтә иде. Һич булмаса, кинаяне аңлар, ә бәлки, үпкәләр, дип уйлаган иде. Ләкин Даниф, каш жыерасы урында, янә көлеп жибәрде:

—Президент кеше станоклар тирәсендә иснәнеп йөрмәс инде,—диде.—Аның өчен башкаручы директор бар.

—Синме инде ул?

—Кафедра эшне бик кызу тотарга кирәк,—диде Даниф үз уйларына мавыгып.—Иртәгә-берсекөнгә кереп утырырга. Электрны тоташтыру озак түгел. Мин инде инвалидларны да табып куйдым. Зур залга гарипләрне тезеп утыртсак, аннан безне беркем дә куып чыгара алмаячак!

—Ә эш барып чыкмаса? Теге чакта уңмадың бит!

Данифның чырае агарып китте.

—Син аның белән чагыштырып утырма! Монда бөтенләй башка хәл! Заман бүтән! Шартлар, законнар икенче! Приватизация бара! Бераз кыймылдагач, менә бит эшлибез, дип, бинаны хосусыйлаштырасың. Аннары сатарга да була.

—Нигә соң син бу мәсьәләне Байбулатова белән хәл итмәден?

Фу, шайтан, сүзгә мавыгып киткәннәр! Даниф светофорда яшел утның жемел-жемел килгәнен күрми калган, алдагы "Жигули"ның туктаганын сизмәде, "УАЗ"игы белән аның артына барып керә язды.

Харис маңгае белән алгы пыялага бәрелде. Йөрәк жу итте.

—Авызны йомыбрак барыйк әле,— диде ул сулышы киселгәнен сиздермәскә тырышып.—Урамда машинаның хисабы юк. Сак булырга кирәк.

—Белми калдым... Уйлап житкермәдем...—диде Даниф.

—Шул-шул менә! Алга гына карап бар!

—Мин аны әйтмим әле...

—Нәрсәне әйтәсең?

—Кафены...

—Ә-ә...

Харис соңгы соравын онытып та өлгергән иде инде. Бераз вакыт дәшми-тынмый гына бардылар. Ләкин озак түгел. Даниф тагын телгә килде.

—Кайчан барасыз соң?—диде ул башын бормый гына.

—Кая?

—Район главасына. Аның рөхсәтеннән башка электрны тоташтырмаячаклар.

—Шылтыратып карармын,—диде Харис авырсынып кына.

Даниф борылып, юлдашына кистереп карады.

—Кемгә?

—Главага, дисең бит.

—Мин бит сезгә главага шылтыратырга, димәдем. Барырга, дидем.

Харисның сабырлыгы төкәнә башлады.

—Соң башта шылтыратырга кирәк бит инде. Кайчан кабул итә, шуны белешергә.

—Ну, Харис Мирзаянович, сез бигрәк беркатлы фикер йөртәсез кайчакта,—диде Даниф жиңелчә шаярган кебек итеп.—Дөнья күрмәгән кеше шикелле. Главаның туганымы сез, кодасымы. Бергә утырып эчкәнегез бармы...

Харис дәшмәде.

—Ул сезне ачык чырай белән каршы алсын өчен,—диде Даниф йомшак кына,—сүзе үтәрлек берәүнең алдан шылтыратып куюы кирәк.

—Андый кешем юк минем,—диде Харис. Аңа жинел булып китте, йөз суы түгеп, соранып йөрисе килеп тормый иде әле.

—Югарыдан эш йөртергә кирәк, шунсыз булмый!—диде Даниф.—Хөсәен Гайфулловичка барырга кирәк башта. Жәмгыять аның фатихасы белән оештырылган, бинаны да ул бирдергән бит.

Харисның исенә төште: чыннан да Жәүһәрия Хөсәен Гайфуллович жәмгыятьне оештыруны бик хуплады, бина бирергә вәгъдә итте, дигән иде шул.

—Ә син каян беләсең?—дип сорады ул Данифтан.

—Газетада жәмгыять турында мәкалә чыкты бит. Шунда әйтелгән иде. Сез укымадыгызмыни? Әллә оныттыгызмы? Шактый вакыт узды шул.

—Хөсәен Гайфуллович Жәүһәрияне белгән, яңа яхшылык эшләгән. Мине белми бит ул,—диде Харис.—Нәрсә дип барыйм мин аңа?

—Бармыйсыз инде алайса...—диде теш арасыннан, ничектер эчке бер ачу белән Даниф. Аннары каты пышылдап:—Мокыт!..—дип өстәде.

—Нәрсә дисең?

—Үземне әйтәм, ахмак, дим... Кеше кулына карап торырга... Башка юлын табарга кирәк!..

—Тап, тап,—диде Харис.—Бик яхшы булыр.

Бу сүз аны тәмам туйдырган иде.

* * *

Икенче иртәне Харис жәмгыятькә сонарыбрак килде. Нуржиһан зәңгәр халатын киеп, яулыгын чөеп куйган да эшкә тотынган: киштәләрдәге әйбер-караны тәртипкә сала. Стена буендагы

урындыкта Насибә утыра, бите-борыны кызарынган, күзләре яшьле. Янында, аның иненә кулын салып, Халидә басып тора.

Харис исәнләште дә, бухгалтер кәгазьләрен алырга дип сейфны ачты, әдәп саклап кына:

—Бер-бер хәл булдымы әллә?—дип сорады.

Хатыннар шуны гына көтеп торганнар икән. Нуржиһан эшен ташлап, Харис янына килеп басты, Насибә елавын онытып, ана текәлде, Халидә дә таләпчән карашын ана төбәде. Күренеп тора, һәммәсе анардан нидер өметләнәләр иде. Харис эчтән куырылып килде: алар теләгәнне булдыра алмаячагын күнеле сизде чөнки.

—Менә бер баланың ятим калу-калмавы хәл ителә әле монда,—диде Нуржиһан.

—Аны җыелыш җыеп, тавышка куеп хәл итәләрмени?—диде Харис.—Тәкъдирдә ни язылган булса, шул килә адәм башына, дигәннәр борынгылар. Язмыштан узмыш юк. Ятим калырга язган икән, әҗәл килә дә баланың ата-анасын алып китә. Сездән-бездән сорап тормый.

Харисның болай җинелчә сөйләшүе Халидәгә ошамады, ул сынын турайтып, чәнчеп-чәнчеп карады.

—Әҗәл үзенекен эшләгән бит инде,—диде.—Туачак баланың атасын алып киткән. Хәтерләмисезмени, Җәүһәрия белән бер көнне җирләделәр.

—Анасы исәндер бит?

—Исән. Тик ана булыр җире юк.

—Бала тапкач, ана булмый нишләсен?

—Үзе бала әле ул. Үзен асрыйсы бар.

—Ходай тәгалә җан биргәнгә җүн бирер иде әле, баланы үземнеке дип яздырыр идем дә үзем үстерер идем,—диде Насибә. Аның ачык күзләреннән яшь бөртекләре тәгәри башлады.—Тик кайда асрыйм соң мин аны? Кая сыендырыйм? Ун квадрат метрда болай да дүрт җан! Аннан да чыгарга кушалар, милициянен тулай торагы бит ул! Ә безнең анда эшләүчебез юк!

—Күп балалы гаиләне урамга куып чыгармыйлар, закон рөхсәт итми,—диде Харис.

—Кыш көне генә куа алмыйлар, җәй көне дуылдатып урамга чыгарып утырталар. Законы шундый икән...

—Фатир сорагыз! Чиратка басмаган идегезмени?

—Чират бар иде, әтиләре киткәч, сыздылар! Әле кичә тагын барган идем, андагы хатын тиргәп җибәрде. Уйнаштан бала ясаган бер кешегә хөкүмәт квартир бирә башласа, кая китә ул, ди. Тапкансыз икән ансат юл, мәктәп яшендәге кызыгыздан бала таптырып, квартир алмакчы, ди. Алайга китсә, ди, бөтен кыз балалар алтынчы класстан бүксә күпертеп йөри башлар! Намуслы кешегә бирергә квартир калмас! Андыйларның ата-аналарын җавапка тартырга кирәк... Балаларын юньләп тәрбияләмәгән өчен җәза бирергә, ди...

Насибә сыгылып төшеп, елый башлады. Харис дәшмәде. Анынча, теге хатынның сүзләрендә дөреслек бар иде.

—Роддомда калдырырга туры килә инде-е-е...—диде Насибә борынын мышкылдатып.— Алып кайта алмабыз инде...

—Авызыңнан җил алсын!—диде Нуржиһан булдыра алганча нык итеп.—Дүрт саның исән була торып, үз балаңны ташлыйлар димени! Ходай язмаганны! Җәүһәрия исән булса, болай дип авызыңны да ача алмас идең. Ул сина җебеп төшәргә рөхсәт итмәс иде, квартирын да алып бирешер иде...

"Аңлашылды,—дип уйлады Харис.—Болар өчәүләшеп квартир кыса башлыйлар хәзер миннән... "

Ләкин каршы әйтергә өлгермәде, ишектән, бик каударланып, чүпрәк букча күтәреп, бәләкәй гәүдәле, иртә картайган кыяфәтле марҗа түтәй килеп керде.

—Жанна Баяновага рәхмәтләремне әйтергә килгән идем,—диде ул.—

Әйткәннәр иде аны баштук, ярдәм итсә шул гына итә ала сиңа, дип. Хак, шулай булып чыкты да.

Түтәй белән Нурҗиһан ах-ух килеп сөйләшкән арада, Халидә Хариска мәсьәләнең асылын аңлатып бирде: ике ел элек түтәйнең музыка мәктәбендә укып йөргән кызын хулиган малайлар трамвайдан атып бәргәннәр. Кызыкай чигәсе белән рельска барып төшкән... Бик озак больницада яткан, ләкин сихәтләнә алмаган— сул ягы хәрәкәтсез калган. Аягына баса алмый, идәндә яны белән мүкәләп кенә йөри, үзен-үзен дә белештереп бетерми икән.

Халидәнең сүзе колагына чалынып, түтәй үзе дә Хариска борылды:

—Уң кулы исән анын, шунын белән мине тукмый,—диде.—Икәү бәргәләнеп яшибез шулай. Мин эшкә урнаша алмыйм, анын ялгызын калдырып булмый... Суыткычыбыз бик иске иде, ахыр чиктә бөтенләй ватылды.

Шуннан соң инде бу түтәйгә Җәүһәрия янына керергә киңәш иткәннәр

Җәүһәрия кунакханә директорына барып сөйләшкән. Аннан бер суыткыч табып, түтәйгә илтеп биргәннәр.

—Бу эсседә суыткычсыз ничек яшәмәк кирәк? Бөтенләй гаҗизләнгән идек. Рәхәткә тиендек хәзер. Рәхмәтләр яусын сезгә,—дип хатын, букчасыннан ике консервы чыгарды да, көчләп-көчләп Нурҗиһанның кулына сонарга кереште.

Нурҗиһан исә кучтәнәчне алмаска маташа иде.

—Юк, безгә ярамый, рөхсәт юк! Әнә, хуҗа кушмый!—дип Хариска ишарә ясады ул.

—Алмасагыз, үпкәлим! Мин башка берничек тә сезгә рәхмәтемне белдерә алмыйм. Ичмасам, утырып чәй эчәрсез...

Бер елап, бер елмаеп, мең рәхмәтләр укып чыгып китте хатын.

—Күрденме?—диде Нурҗиһан Насибәгә.—Акылдан шашкан гарип баласын да ташламый кеше! Юләрләр йортына илтеп тыкмый. Моннан ары андый сүзне әйтәсе булма безгә! Мә, менә бу банкаларны ал да, өеңә кайтып, балаларың белән тәмләп чәй эч! Без барда ач булмассыз!

—Сез үзегез дә бүген бар, иртәгә юк,—диде Насибә борынын мышкылдатып.—Җәүһәрия булмагач, кем тота моны?

—Таралырга тормыйбыз әле. Эш бара бит. Харис Мирзаянович килде менә. Кафе да ачылыр иншалла... Анда сиңа да, кызыңа да эш табылыр... Бирешмә генә... Безнең эшкә кулың ятып кына тора. Елап утырма монда, Зөбәйдә апага бар әнә. Тагын шылтыратты, килсен, ди. Син генә юындыра аласың аны, башка беркем булдыра алмый...

Ватан сугышы ветераны артистка Зөбәйдә апа ялгызы яши, балалары да, туганнары да юк икән. Күршеләре кибеттән ипи-сөтен кайтарып бирәләр, тик менә юындыру ягы читен. Чөнки апаның аяклары йөрми, ваннага бик авырлык белән генә керә, житмәсә, сугышны узган кешеләргә хас булганча, холыксыз үзе. Аны фәкать Насибә генә көйли ала икән.

—Бар, бар, жилләнеп кайтырсың,—дип аны тыкырдатты Нурҗиһан.— Харис Мирзаянович ташламас. Квартир мәсьәләсен дә кузгатыр. Анда Җәүһәриянең хаты ята бит инде. Шуны юлларбыз.

—Чынлапмы? Юлларсызмы?—дип Хариска текәлде Насибә.

Әле генә чыгып киткән түтәй Харисның күңелен ирексездән нечкәртеп җибәргән иде. Ул Насибәгә "юк" дия алмады.

—Тырышырмын,—диде. Шулай итеп, туачак сабыйны ятим итүгә каршы тавыш биргәнен сизми дә калды.

Насибә юанып чыгып китте.

—Монда сезгә бер хат бар иде,—дип, Хариска озынча конверт сузды Халидә.

Хат район хакимиятеннән иде. "Баллы күл" кафесын ике ай арендада тоткан өчен сигез миллион акча түләргә кирәклеген, әгәр акча вакытында түләнмәсә, көненә бер процент пеня саналачагын һәм әлеге бурычларны,

хөкем чыгымнарын да өстәп, арбитраж суды аша мәжбүри алачакларын язганнар. Шунда ук: "Сезнен аренда килешүен өзүегез турындагы хатыгызны алдык. Бер ай эчендә бинаны бушатырга һәм тәртипкә китереп, тиешле комиссиягә тапшырырга кирәклеге турында кисәтәбез",—диелгән иде.

Димәк, башта кафе өчен җәмгыятьтән бик күп акча түләтәчәкләр, ә бер айдан бинаны бөтенләй тартып алалар, дигән сүз. Нәрсә? "Сезнен хатыгызны алдык..."—дигәннәрме? Нинди хат? Кем язган? Җәүһәрия язган иде микәнни?

Моннан берничә ел элек шушындыйрак хәлгә юлыкса, Харис кычкырып көләр, аннары, чиктән тыш ярсып, район хакимиятенә чабар иде. Аренда хакы нишләп шулкадәр күп? Һәм әле кереп тә утырмаган бина өчен хәер җәмгыяте ул хәтле акчаны каян алып түләсен? Һәм, иң кызыгы, ни сәбәпле килешү өзелә?

Әмма соңгы елларның үткен кайчылары Харис күңелендәге кошның канат очларын нык кыскарткан иде инде. Ул башын салып уйга чумды.

Даниф хаклы, дигән фикергә килде ул. Эшне югарыдан йөртми булмый. Хөсәен Гайфулловичка барырга кирәк.

—Сез китапханәгә кереп утырасыздыр бит? Әйдәгез!—диде Халидә.

Харис уйларыннан айнып китте. Хатны чалбар кесәсенә тыгып, сейфтан папкаларны алды. Кәгазь актаруны җене сөйми дә бит, нишлисен, тикшерүче элекке елгы акча документларын карап чыгарга кушты. Имештер ки, шуларда Байбулатованы үтергән кешегә илтүче җеп очы ятмый микән. Шуны Харис күреп алмасмы. Каян күрсен ул аны? Һәм ничек килеп керсен андый җеп очы монда, рәтле-башлы акча кермәгән документларга? Алай да тикшерүченен сүзен аяк астына салып булмый иде. Папкалары да бер кочак житмәсә. Юк акчага күпме кәгазь үрчегән! Харис, уф дип пошкырды да, тураеп, Халидәгә:

—Әйдәгез,—диде.

* * *

Зур житәкчеләрне иртәнге якта тоту унай. Эш көне сәгать тугызда башлана, дип саналса да, алар һәммәсе иртәнге сигездә инде үз кабинетларында булалар. Бөтен мөһим мәсьәләләр шул вакытта, эш башланыр алдыннан, саф баштан хәл кылына... Шуны белгәнгә күрә, Харис Хөсәен Гайфулловичка сигез тулар-тулмас шылтыратты. Ни гажәп, аңа секретарь хатын түгел, ир кеше җавап бирде. Эше бик тыгыз кешедәй эндәшүеннән Харис аның Хөсәен Гайфуллович икәнен аңлап алды. Карасана, республиканың иң зур житәкчеләреннән берсе телефон трубкасын үзе ала! Харис, бик кыска гына итеп, үзенең Җәүһәрия Байбулатова урынында хәер җәмгыяте житәкчесе булып калганын, кафены алуда кыенлыклар килеп чыкканын, бу мәсьәләдә киңәшергә теләгәнен аңлатты.

—Сәгать өчтә килегез,—диде Хөсәен Гайфуллович.

Харис, билгеле, әйтелгәннән алданрак килеп, иркен, якты алгы бүлмәдә бераз көтеп утырды. Түгәрәкләп ясалган өстәл янында, компьютер каршында утырган секретарь хатын: "Хөсәен Гайфулловичның вакыты бик кысан, зинһар, йомышыгызны кыска, аңлаешлы итеп сөйләгез, биш минутка сыярга тырышыгыз",—дип нык кисәтеп куйды.

Яше алтмыштан узып киткән, пеләш башлы, йомры гәүдәле, утырган урынында да тыпырдап, боргаланып торучы Хөсәен Гайфуллович, кабинетының бик затлы, киеменең кыйбатлы һәм ятышлы булуына карамастан, авыл агайларына хас гадилекне, беркатлылыкны саклаган иде. Ул Җәүһәриянең үлемен әрнеп кабул иткән икән. Аның өчен аяныч югалту булган бу. Ләкин менә женазага бара алмаган. Чөнки мактаулы исем дә, дәүләт бүләге дә алырга өлгермәгән шагыйрә Жанна Баянованың үлеме республика житәкчеләрен кузгатырлык вакыйга була алмый.

Хәлбуки, Хөсәен Гайфуллович Җәүһәрия белән шактый якыннан таныш булган икән.

—Беләсезме, без туксанынчы елны бергәләп Японияга барган идек, язучылар төркеме белән,—дип, тирән сулап, хатирәләргә бирелеп алды ул.—Шунда мин аны Мәскәүдән, Литвадан, Грузиядән килгән язучылар арасында, алар белән чагыштырып, карап тора идем. Берсеннән дә ким түгел иде ул. Төс-кыяфәт белән күбесеннән өстен иде. Чибәр, буйлы, затлы, белемле, талантлы, унган, үткен хатын. Менә, татарлар шушындый алар дип, бөтен дөнья каршында мактанып күрсәтерлек. Ләкин чыгып булмый андый мәйданга, үзебезне күрсәтеп булмый! Ә мин өметтә идем әле, Җәүһәрия яшь, заманнар үзгәрә, ул күтәрелер, танылыр, дөньяга күренер, без татарларны халыкара мәйданда күпмедер дәрәҗәдә яхшы яктан танытырга өлешен кертер дип ышана идем. Бик кызганыч болай булуы...

Кафе тирәсендәге хәлләрне ул ике сүздән аңлады: кемнәрдер Байбулатованың үлеменнән файдаланып, ул бинаны үзенә алмакчы.

Бөтен гәүдәсе белән ян өстәлгә борылды да, телефон төймәсенә басып, секретарена кем беләндер тоташтырырга кушты. Тиз тоташтырдылар.

—Рәшит!—дип кызарынып кычкырды ул трубкага.—Ник син Байбулатовага биргән бинаны кире аласың?.. Үлмәгән ул, аны үтергәннәр! Сиңа шул фаҗигадән файдалану оят булырга тиеш! Җәмгыяте калган бит аның!..

Аннары теге баштагының сүзен тыңлап, беразга тынып калды.

Бу кешенең күңелендәге теләндә, ни кичергәннәре күз алдында иде. Аның кыяфәтендә, үз-үзен тотышында, тавышында, күз карашында бөтен яшәеше чагыла иде шикелле. Авылда туган, әбисеннән догалар, “Кыйссасел әнбияләр” тыңлап, Шәриф Камал, Ибраһим Гази, Габдрахман Әпсәләмов китапларын укып үскән. Хәрәкәтчән, актив булган, илгә, халыкка хезмәт итәм, дип ышанып яшәгән. Җитәкче эшләргә күтәрелгәч, Салих Батыев кебекләрдән үрнәк алган. Бар иде заманында Татарстанның шундый иң зур җитәкчесе. Республиканың Югары Советы председателе, дип атала иде, әмма чит илдәге татарлар аңа хатлар язганда: “Президент әфәнде!”—дип башлыйлар, һәм ул моның белән чиксез горурлана иде. Ана урамнан телефоннан шылтыратып була һәм ул, президент, еш кына трубканы үзе ала, зарыңны тыңлый, ярдәм итәргә тырыша торган иде.

Күренеп тора, Хөсәен Гайфуллович шул мәктәптә тәрбияләнгән җитәкче инде. Узып барган гасырның кәре-пычрагы, чүп-чары арасында ялтырап яткан ватык көзгенең саф бер кыйпылчыгы иде ул.

Ул телефонны тыңлаган арада Харисның башыннан шундый уйлар узды.

—Рәшит! Бир инде шул бинаны! Бир инде! Бөтен шәһәрне сатып бетердегез, ичмасам шушысы изге эшкә хезмәт итсен! Хәер җәмгыяте бит ул!—дип өзгәләнеп кычкырды Хөсәен Гайфуллович телефоннан.—Килер ул сиңа! Кабул ит! Сөйләш! Хәл ит кешечә!

Аннары трубканы куйды да, Хариска борылып:

—Син бар ана, ул кабул итәр,—диде.—Бина синеке булыр. Документларны үзгәртеп язарлар, хуҗа буларак кул куярсың. Фәкать шул гына.

“Сезнеке” яисә “җәмгыятьнеке” булыр димәде. Приватизация, ягъни дәүләт малын үзләштерү чоры китергән шаукым иде бу. Эш йөрткәндә, предприятиеләрнең, оешмаларның исемен атап түгел, җитәкчеләрнең исемен әйтеп сөйләшәләр. Асылда чын хуҗаның кем икәнен белгәнгә күрә шулай.

Инде саубуллашып чыгып барганда, Харис кесәсендәге кәгазьне исенә төшерде: Насибәгә фатир алуда ярдәм сорап Хөсәен Гайфулловичка язган хат бу... Ул ишек төбеннән кире борылды.

—Гафу итегез, Җәүһәриянең күп балалы ялгыз бер анага вәгъдәсе

булган икән, квартир алып бирүдә ярдәм итәргә. Бу хәлләрдән соң ул хатынны чираттан сызганнар.

—Хайваннар...—диде теш арасыннан Хөсәен Гайфуллович.

—Кайсы район?

—Казансу арты...

—Кая, калдырыгыз хатыгызны. Артур Кимович белән сөйләшермен...

Һәм янә телефон төймәсенә басты:

—Гөлгенә,—диде секретарена, —Артур Кимович белән тоташтыр әле.

Эссе көндә дә жиләс, иркен, тыныч Кремль урамы буйлап, зәнгәрсу чыршылар ышыгыннан Спас капкасына таба барганда, туктап борылды да, каерылып Сөембикә манарасына, аның очында очкынланып балкыган айга карады Харис. Аннары карашын президент сараеның түбәсе өстендә жилпенгән әләмгә төбәде. Ничә гасырлардан соң калыкты бу ай!.. Күпме гомерләрдән соң татарның үз байрагы күтәрелде.

Ә нигә шагыйрә Җәүһәриянең татлы хыяллары тормышка ашмаска тиеш? Нигә әле зур бинаның түбәсенә, утлы хәрефләр белән "Шәфкать йорты" дип язып, уртасына еракларда күренеп торырлык итеп Кызыл Ай бастырып куймаска?

...Әмма ул атна буе һәр иртәне шылтыратып торса да, тиешле жиргә берничә тапкыр үзе барса да, Рәшит исемле түрәне күреп сөйләшә алмады. Биек, жиләс булмәдәге имән өстәл артында утырган ыспай егет— ярдәмче: "Мин сезне кабул итү исемлегенә яздым... Үзебез хәбәр итәрбез... Иртәгә шылтыратыгыз... Бер атнадан..."—дип, коры гына борып жибәрә торды. Рәшит—яна заман жимеше, алдагы гасыр житәкчесе—телефон шылтыраган саен трубканы үзе ала торганнардан түгел иде.

Аптырагач, Харис тагын Хөсәен Гайфуллович белән телефоннан сөйләште. Хәлне аңлатты. Ләкин биналарны арендага бирү турындагы килешүләргә Рәшит кенә кул куя ала, аннан өстәгеләр түгел. Зур житәкченең көчсез, чарасыз булуын күреп, Харис аны кызганып куйды. Күрәсең, заман егетләре бу кешенең үз урынында озак утырмаячагын сизеп алганнар иде инде. Хәер, утырып торса да... Өстәге начальникнын "айт" дигәненә "тайт" дип тора торган коммунистлар заманы узды. Хәзер, кесәң калын булса, өстәгеләргә үзен "үрә кат!" дип кычкыра аласың...

Алай да, бөтенләй игътибарсыз калдырырга жөрьәт итмәгәннәр иде, күрәсең, имән өстәл артында утырган кәттә егет, ниһаять, сезнең мәсьәлә буенча район житәкчесе Артур Кимовичка барырга кирәк, диде.

Ә Артур Кимович нәкъ шул көнне рәсми делегация белән Франциягә китеп барган икән. Заман шундый: ил чикләрендәге тимер коймаларга капкалар уелды, халык ургылып ике якка да әрле-бирле иркенләп йөри башлады. Чит илләрнең матур тәжрибәсен өйрәнү кирәклеге беләнде. Житәкчеләр акыл жыярга ерак сәфәрләргә еш һәм бик теләп йөри торган булып киттеләр. Дәүләт хисабына. Таланган, жимерелгән биналар, исрафка аккан сулар кайгысымыни!

* * *

Иртәнге якта Насибәне кафега Харис үзе илтергә булды. Бинаның жәмгыятьнеке икәнен белгертеп торырга, бераз булса да кыймылдарга кирәк, дип исәпли иде ул.

Данифның "УАЗ"игына бераз он-ярма, кием-салым чыгарып салдылар да кузгалдылар. Насибә әйтүенчә, ул тирәдәге мохтажлар инде аңа ияләшеп тә өлгергәннәр, килгәнен көтеп кенә торалар, китергәнне бик сөенеп алалар икән.

Олы урамнан борылуга, кафенең ишегалдыннан бер ир заты, аның артыннан һау-һаулап өреп ике эт килеп чыкты. Ир кешенең башында,

кин кырыйлары дулкынланып килгән, чит илләргә еш йөрүче кәттә егетләрдә генә очрый торган кара эшләпә, өстендә хәзерге заманның горур эшкуарлары яратып кия торган бик модный кара плащ иде. Култык астына барсетка гына житми.

Каян килеп чыккан бу шәп егет? Мондый ташландык жирдә бер ялгызы, машинасыз, шоферсыз, каравылсыз, эт өрдереп, кеше көлдереп дигәндәй, нишләп йөри?

Сәер иде, аңлаешсыз хәл иде бу!

—Тукта!—диде Харис Данифка. Теге адәм, сулуына кабып, машина ишегенең тоткасына килеп ябышты. Эшләпә астыннан сакал-мыек баскан, жыерчыклы арык чырай күренде, кызарган күзләр ачу, гажизлек белән карады. Күптән тазартылмаган черек тешле авыздан тәмсез ис бәрелде. Баксаң, затлы кием эченә сасы йолкыш кереп оялаган икән!

—Китегез! Пшол! —дип кулын изәп кычкырды Харис этләргә.— Тәмам азды бу эт асраучылар. Көпә-көндез урам уртасында кеше талаталар, ә!

—Алар шундый!—дип Харисның күзләренә мөлдерәп карады йолкыш адәм.—Халыкның малына хужа булып алдылар да якын килгән бер кешене эттән талаталар хәзер!

Ул арада капка ягыннан:

—Артур! Ким! Минем янга!—дигән тавыш ишетелде. Этләр шул якка чапты.

—Паразитлар! Бандитлар!—дип алар артыннан ике кулын болгап, нечкә тавыш белән кычкырып калды йолкыш.—Ни хакыгыз бар?!

Харис машинадан төште дә, аны баштанаяк күздән кичерде. Жилбәгәй киткән плащ итәкләре астыннан таушалган, ләкин кыйммәтле чалбар-костюмга, тузан астыннан да елтырап торган лаклы туфлиларга шаккатып карады.

—Дәхеле юк аларның бу бинада!—дип, йодрыклары белән буш урам тарафына кизәнеп, дулавын дәвам итте йолкыш.—Каравыл куярга хаклары юк!

Харис аның плащ жиңеннән тырпаеп чыккан кулларына карады да, имәнеп китте: йодрыклары күгелжем-кызыл тукмак кебек, тырнаксыз бармаклары кәкерәеп каткан.

—Семен! Син тагын мондамыни?—диде авырлык белән машинадан төшеп килгән Насибә чыраен сытып.—Шешә чүлдерергә йөрүеңдер әле... Баш төзәтергә...

—Сине көтеп йөри идем,— диде Семен шундук кикриге шиңеп.— Миңа эчке кием кирәк. Керләнеп бетте...

—Бер атна элек кенә баштанаяк киендердек бит без сине! Банкирлар китергән киемнәрдән сайлап алып бирдек,—дип сукранды Насибә. Аның тавышында монарчы ишетелмәгән каты авазлар, байбичәләргә хас эреләнү сизелде. Семеннан шактый тәбәнәк булса да, ул аңа башын артка ташлап, керфекләрен кысып карый иде.

—Гел өстә бит... тәнгә дә салып булмый... Төрле жирдә куныллы... Самосыровога[1] барсам, анда сайлап алырга әйбер күбрәк инде күбрәген, барырга ерак. Юып булмый бит, куллар эшләми...

Семен Насибәнең соравына жавап бирә, үзе әле Хариска, әле Данифка караштырып ала иде.

—Кем бу?—дип сорады Харис Насибәдән.

—Бомж,—диде Насибә кыска гына.—Эштә кулын яндырган, инвалид. Бездән ярдәм ала. Шушында кунып йөри.

—Тегеләр моннан да куарлар иде әле!—дип, бина артына кулын изәп, сүзгә кушылды Семен.—Ярый, яңа хужалар килеп, кикрикләрен шиндерделәр. Тәнгә ишекне бикләргә дә, эчкә эт жибәрергә дә рөхсәт юк хәзер аларга. Үзләрен куалар! Бүгеннән бинаны бушатырга кушылган!

---

[1]Самосырово — Казан читендәге иң зур чүплек башы.

Соңгыларын әйткәндә, ул тураеп китте, очлы ияген чөеп куйды, үч алу тантанасыннан ямьсез йөзе кызарып чыкты.

Нәрсәгә куана әле ул? Эт хуҗаларын моннан куганга мы?

Туктале, Җәүһәриянең соравы буенча, кафены сакларга алынган егетләр түгелме соң алар? Кем куа аларны бирелән? Кем бинаны бушатырга куша? Бинага җәмгыять хуҗа, ә җәмгыятькә Харис баш.

—Кем турында сөйлисең син?—дип сорады ул йолкыштан.

—Чын хуҗа килә монда хәзер! Байлар килә!—дип, куктән пилмән явасын көткәндәй, күзләрен кысып, башын югары күтәрде Семен. Аның чыраена татлы елмаю галәмәте чыкты.—Мондагы урам шпаналарының койрыкларына басачаклар әле. Безгә дә ярдәм итми калмаслар. Акчалары житәрлек!

—Кемнәр?!

—Фамилияләрен алар белә,—дип, янә кафеның теге ягына ымлады Семен.

—Барып белешик әле,—диде Харис Данифка карап. Ә Даниф машинадан кием тулы тартманы кулына алган иде инде.

—Ярый алайса, син әйберләрне кертә тор, мин барып киләм,—диде Харис.

Бинаның икенче ягында, урам як кырыендагы машина төзәтү мастерскоенда гөрләп эш бара иде. Өч машина эчтә, капка төбендә "Нива" белән "девятка" чират көтеп тора. Бер күз салуда шуны аңлап алды Харис: биредә хезмәтне менә дигән оештыручылар һәм алтын куллы осталар эшли иде.

Мастерскойның эче бик биек, бинаның нигезеннән алып, өченче катның түшәменә кадәр; Харисның хәтерләвенчә, элек бу төштә йөк ташый торган лифт һәм запас баскыч иде. Лифтны да, баскычны да алганнар, шулай итеп киң генә мәйдан бушаган. Стеналар бөтен биеклегенә акшарланган, ике якка да берничә рәт итеп жылыткыч батареялар куелган, өч автокүтәргеч бик җайлы итеп, шул ук вакытта мәйданның кадерен белеп урнаштырылган. Пөхтә зәңгәр комбинезон кигән биш-алты ир-ат, капка төбенә килеп баскан ят кешегә бөтенләй игътибар бирмичә, үз эшләрендә булдылар. Ике урында "Жигули"ны күтәргәннәр, өченчесендә күксел "Ока"га развал ясыйлар иде. Харис эченнән генә егетләрнең эшенә сокланып куйды: развалны, бигрәк тә "Ока" машинасына, сирәк жирдә ясыйлар, ә болар кирәкнен бөтенесен булдырганнар!

Әйе, бу заманда мондый эш урынын булдыру уен-муен түгел! Күпме көч, күпме акча кергән, күпме нервы тузгандыр!

Бу инде сиңа Данифның кемнәрдер чыгарып ташлаган станок-машиналарны түшәменнән ком коелып торган бинаның бер почмагына китереп тутырып, нәрсәдер майтарырга маташуы түгел! Аларны арбага салып, теләсә кая илтеп була. Ә менә мондыйны куптарып кузгалу хезмәт кешесе өчен зур фаҗига иде, билгеле. Яңа урын каян табасың, анда ничек барып урнашасың...

"Ока" янында киңәш биреп торган озын буйлы, төз сынлы кеше борылып карады да Хариска таба юнәлде.

Зиратта, Харислар турыннан узганда, кемгәдер елмаеп сәлам биргән һәм, абынып китеп, кулыннан табут капкачын төшерә язган егет иде бу. Ул ишек алдына чыгуга, теге ике овчарка килеп, сырпалана башладылар.

—Исәнмесез,—диде егет.—Ни йомыш?

Аның ак йөзендә, кысылган яшькелт күзләрендә, басып торышында ниндидер сагаю сизелде.

—Исәнмесез. Мин хәер җәмгыятенең хәзерге җитәкчесе булам. Исемем Харис Мирзаянович. Ә сез, ишетүемчә, Равил исемле, шулай бит?

—Ну, шулай булсын, ди. Сезгә нәрсә кирәк соң?

Равилнең шома ак чырае шактый караңгы иде.

—Сөйләшергә кирәк иде.

—Нәрсә турында?

—Белүемчә, бинаны тәртиптә тотуга сез алынгансыз. Төнлә монда сез каравыл куясыз икән.

—Кем әйтте?

—Җәүһәрия Газизовна белән сезнең арада шундый килешү булган бит. Ул килешүләр хәзер дә үз көчендә кала.

—Шулаймы-ыни?—дип мыскыллап сузып сорады Равил.—Килешү дисез, димәк... Хуҗа дисез... Ә вәкаләтегез бармы соң? Документларга кул куярга... пичәт басарга хокукыгыз бармы?

—Әйттем ич инде, җәмгыятьнең житәкчесе мин хәзер, дип. Чөнки Байбулатованың урынбасары мин идем.

—Сез?! Ә нәрсә белән раслый аласыз?

Нәрсә белән расларга? Бер мизгелгә Харис аптырап калды. Ләкин шундук исенә төште: документы бар бит аның! Җәүһәрия ясап калдырган таныкнамәсе.

Ул кесәсеннән айлы-лаләле катыргыны чыгарды. Равил аны кулына алып ачты да, бик озаклап укыды.

—Чыннан да...—диде.—Монысының да срогы чыкмаган... Пичәте дә чын...—Аннары катыргыны кире сузып:—Бер түтәйгә ничә урынбасар соң сез анда?—дип сорады.

—Нишләп алай дисез?

—Аның бер урынбасары бу бинаны сатып җибәрде бит инде, шуңа әйтәм,—диде Равил.—Байбулатованың үлгәненә кайчан, ә шәхсән сезнең монарчы күзгә-башка чалынганыгыз юк әле. Андый хәлләр булганда, чын хуҗа минутында йөгереп килә!

—Ә кем килде? Кем?

—Чын хуҗа үз өендәгене күршесеннән сорашып йөрми. Фирмагызга кайтыгыз да үзара аңлашыгыз. Сездән башка да баш каткан монда,—дип мастерской эченә таба юнәлде Равил.

Харис бу кешедән бик мөһим бер нәрсәне белешергә өлгерми каласын аңлады. Артыннан барып, комбинезон җиңеннән эләктереп алды.

—Туктагыз. Бер сорау...

—Әйттем ич, сорауларны үзара...

—Теге көнне, фаҗига булган көнне әйтәм... Каравыл булгандыр бит?

—Без бинаны кичке сигездән иртәнге җидегә кадәр генә сакладык. Сигезенче яртыда килә идек тә этләрне үз яныбызга чыгара идек. Көндезгесен җәмгыять үзе карый иде, ягъни сез дигән сүз. Әгәр чыннан да урынбасар дип саналган булсагыз. Милиция моны кат-кат сорашты инде.

—Равил, кил әле!—дип кычкырды берәү мастерской эченнән.

Ул янә китәргә борылды.

—Әйтегезче, зинһарь,—диде Харис,—теге чакта, зиратта, кем белән исәнләшкән идегез сез?

Равилнең чырае үзгәреп китте. Ул, ни дияргә белмәгәндәй, бераз тынып торды. Аннары:

—Карагыз әле,—диде.—Бу наданлыгыгыз белән мондый эшләрдән читтәрәк йөрергә кирәк сезгә!

—Нишләп алай дисез?

—Хәер, Байбулатова кебекләр янына гел җыен әтрәк-әләм ышыкланырга тырышты шул. Бер яхшыга мең яман елыша.

Харис кинәт үзен читтән, Равилнең күзләре белән күргәндәй булды. "Бер түтәйгә берничә урынбасар..." Җиңел генә акча эләктерергә маташып, эш кешеләре тирәсендә ышкылып йөрүче булдыксыз адәмнәр кавеменнән булып күренмиме ул? Нәкъ шулай!

Гарьләндерде бу. Үзеннең төшеп калганнардан түгеллегенңе күрсәтү теләге уятты.

—Бина безнеке,—диде Харис.—Мәсьәлә иң югары инстанцияләрдә хәл ителде. Байбулатова белән төзелгән килешү үз көчендә булачак.

—Шулаймы?

Равил икеләнеп калды. Башын аска иде, тирән көрсенде.

—Бар да без теләгәнчә булса...—диде ул сузып. Аннары ишек алдын, бинаны сагышлы караш белән күздән кичерде дә:—Дөнья бәһасе торырлык бина бит бу!—диде.—Урыны шәп! Үзе иркен, үзе аулак! Күрше урам турыдан-туры Мәскәү трассасына чыга. Нинди зур транспорт ташкыны уза! Заманча итеп, мотель ясап булачак: Мәйданы зур, машиналар торыр өчен иркен. Әйләндереп кенә аласы. Кафе, ресторан, гостиница ачасың... Ишегалдында машиналарны юу, төзәтү, карау урыны... Без акча эшләр идек, ә бинаның теге башында хәер җәмгыяте үз эшен җәелдерер иде... Урам якка "Мотель" дип язып куяр идек, ә түбәнең уртасына биек итеп Кызыл Ай...

Сонгысын ишетүгә, Харис сискәнеп китте. Кызыл Ай эләбез! Димәк, бу егет белән Җәүһәрия арасында житди сөйләшү булган. Ә бәлки, уртак планнар да кора башлаганнардыр...

Харис кара төннәрдә кызыллы-яшелле лампочка тезмәләренә уралган бинаны, утларын жемелдәткән машиналарны, гөрләп эшләп торган ашханә, мастерскойларны күз алдына китерде. Әгәр бу хыяллар тормышка ашса, берәүләргә йөрәген җилкендереп эшләргә, куйган тырышлыгы өчен тиешле акчаны алырга, икенчеләргә ерак юлларда арып-талчыкканнан соң иркенләп ял итәргә мөмкинлек булачак иде. Өченчеләр гарип-ятимнәрне кайгырта алачак иде... Каланың ин фәкыйрьләрдән саналган бу почмагы җанланып, мантып китәчәк иде.

Җәүһәриянең хыялларын ышанмыйча кабул иткән, Данифның "бизнес-планнары"на мыскыллап, көлеп караган Харис Равил сөйләгәннәрне бөтен күнеле белән кабул итте. Чөнки үз көчен һәм мөмкинлекләрен барлаган, алда торган эшләрне ныклап уйлаган, унган һәм акыллы егет сөйли иде моны, дөньяның тоткасы булган Ир, Эш Кешесе сөйли иде.

Тик комачауламаска гына кирәк, аяк кына чалмаска!

Ләкин шунда ук Харис Равилнең кем кавеменнән икәнен уйлап куйды. Матвей Шайдулин төркеменнән түгелме ул?

—Теге Шайдулин... Матвей... ул ни ди соң бу хакта?

Әлеге сораудан Равил сискәнер, каушап китәр, дип уйлаган иде Харис. Ләкин егетнең керфеге дә селкенмәде.

—Нәрсә Матвей... Анын үз һөнәре... Кемнең мал-мөлкәте мул, шуны сакларга яллана... Ана эш табылыр... Монда мәсьәлә Матвейдан узган инде...

Равилнең йөзе сүрелде, уйчан карашы аска төбәлде.

—Монда ул түгел, сез әйткән зур түрәләр дә, ай-һай, берәр нәрсә эшли алыр микән... Зур акчалар, танк колоннасы кебек, һәммәсен сытып-сындырып килә...

Һәм ул кинәт башын күтәрде дә, әрнеп дәвам итте...

—Әрәм итәләр бинаны сволочьлар! Җыен жулик хакимият белән бергә берләштеләр дә бөтен шәһәрне, илне әәҗүҗ-мәәҗүҗ кавеме кебек умырып, йотып киләләр! Юлларына аркылы басканны чәйнәп кенә ыргыталар!

Һәм, Харисның башында мең табышмак калдырып, мастерскоена кереп китте. Эчкә кергәч, борылды да:

—Артур! Ким! Урамга чыкмагыз!—дип кычкырды. Этләргә икән. Артур да Ким... Сәер исемнәр... Һәм бик таныш... Туктале, район хуҗасы Артур Кимович ләбаса!

Үчен алган егет! Теге түрә бәгыренә нык уткән, күрәсен!

* * *

Мансур Хужиевичның бүлмәсендә кечкенә телевизор эшләп утыра иде. Әледән-әле, тапшыруны өзеп, реклама бирәләр. Тагын "МММ" алтын кирпечләрдән диварлар өя, "РДС" дигәне кояшны күк йөзенә күтәреп, алтын нурлар сиптерә.

—Бу "РДС"ны ябып куймаганнар микәнни әле һаман?—диде Харис кашларын җыерып.

—Әллә сез андыйларны тиз генә ябып була дисезме?

—"Известия" газетасында язып чыктылар, әнә, аларның бер самолет тулы акчаларын алганнар.

—Минем күзгә чалынмаган иде.

—Әле кичәге гәзиттә укыдым. Себердә халыктан җыйган акчаны, махсус самолет яллап, Волгоградка озатканнар. "РДС"ның үзәге Волгоградта бит, шуннан бөтен Рәсәйгә җәтмә сузып, халыкны алдап акча җыялар. Самолет аэродромга килеп төшүгә, милиция килеп баскан да, бөтен акчаларына арест салган. Машиналарга төяп, банкка озатканнар. Аннары Мәскәүгә. Казнага, ягъни.

—Ул акчалардан салым түләнмәгән, дигән сылтау тапканнардыр инде,—диде Мансур Хуҗиевич.—Чиновниклар белән бүлешеп өлгермәгәннәрдер.

—Шул-шул менә... Хөкүмәт бандитларны кеше талаган өчен җавапка тартмый. Талаган акчаңнан хөкүмәткә өлеш чыгармадың, дип кенә бәйләнә. Халыкны бандитлар белән берләшеп хөкүмәт үзе талый, дигән сүз түгелмени бу?

—Түгел,—диде Мансур Хуҗиевич сабыр гына.—Чөнки акчаны җуликларга халык үзе илтеп бирә. Берәү дә мәҗбүр итми.

—Мәҗбүр итми, ләкин алдый! Ә алдау—җинаять! Мошенничество өчен җинаять кодексында статья бар! Шуны кулланып булмыймыни?

—Булмый,—диде Мансур Хуҗиевич бер дә исе китмәгәндәй. —Аны дәлиллисе бар әле. Исбатлыйсы. Ә аларның адвокат ялларга акчалары җитәрлек.... Аннары... Аларны утырту хөкүмәт файдасына түгел.

—Нишләп?

—Әле менә Рәсәй президенты булып сайланыр алдыннан Ельцинның шул ук Себергә барулары турында гәзит мәкаләләрен игътибар белән укыган идегезме?

Харис аңа гаҗәпләнеп карады. Дәшмәде.

—Алдан сайлаучылар белән очрашырга Ельцин бара, артыннан вагон белән акча бара. Ул кергән заводларның эшчеләренә еллар буе алынмаган эш хакын түләү өчен.

—Ә бүтән эшчеләр ач килеш кала бирә. Гаҗәп инде,—диде Харис.—Үзләренә кирәк чакта, акчаны табалар. Ельцин—Себергә, "РДС"—Себердән... Акча әйләнеше шулай тәэмин ителә шул бездә. Бу яктан уйлап карасаң, чыннан да, җуликларның халыкны талавы хөкүмәткә дә файдалы булып чыга. Чиновниклар белән җинаятьчеләр береккән, аерып алырлык түгел. Ә милиция, прокуратура күрмәгәнгә салыша!

—Син мина, Мәскәүгә барып, генеральный прокурордан ордер алып, президент аппаратында тентү ясарга кушмассың бит? Бөтен дөньяның күз алдында үзенең парламентын утка тоткан ил башы турында сүз барганын онытмыйк...

Мансур Хуҗиевич тирән итеп көрсенде дә:

—Урыс әйтмешли, вернемся к нашим баранам,—диде.—Үзебезнең тәкәләрне барлыйк әле. Нинди яңалыклар бар?

—Бер хикмәтле кәгазь килде безгә.

Харис портфеленнән район хакимиятеннән алынган хатны чыгарып, тикшерүчегә бирде.

—Сез кафе бинасыннан баш тарттыгызмыни?—дип сорады Мансур Хуҗиевич хатны ашыкмыйча, җентекләп укып чыкканнан соң.

—Хикмәт шунда, җәмгыятьтән андый кәгазь киткәне юк. Җәүһәрия хатларны аерым папкага теркәп барган, мин карап чыктым. Димәк, аны кемдер башка берәү җибәргән.

—Рәсми документ бит инде...—диде тикшерүче, уйга калып.—Тиешле имза салынган, мөһер басылган булырга тиеш. Димәк, югалган мөһернең эзе күренгән икән.

—Мин район хакимиятенә барып сораган идем. Күрсәтмәделәр. Документлар папкасы башлыкның өстәлендә, кул куяр өчен әзерләнгән, диделәр.

—Артур Кимовичны көтәләр, димәк. Күп калмаган, Бүген-иртәгә ул Франциядән кайтып житәргә тиеш.

Харис аңа гажәпләнеп карады. Аныңча, тикшерүче бу очракта, сикереп торып, ялган документны тизрәк кулга төшерер өчен хакимияткә чыгып чабарга тиеш иде. Ә ул кыймшанырга уйламый да!

—Ялган документ! Урланган пичәт сугылган!—диде Харис тавышын күтәрә төшеп.

—Аның ялган икәнеген ничек исбатлап булыр икән соң?—дип, керфекләрен күтәреп, сабыр гына сорады Мансур Хужиевич.—Элегрәк булса, документ кулдан язылса яисә машинкада басылса, криминалистлар кем язганын, кайсы машинкада басылганын ачыкларга тырышып карарлар иде. Хәзер ансат түгел... Хат, мөгаен, бюрократларга хас такыр жөмләләр белән язылгандыр... компьютерда жыелып, принтерда басылгандыр... Ә принтерлар һәммәсе бертөсле... Пичәте, әлбәттә инде, чындыр... Шуның өчен чәлдергәннәрдер дә инде аны... Хат кәнсәләрдән үткән, кем кулларына гына кереп чыкмаган... Бармак эзләрен тикшерүдән дә мәгънә юк.

—Криминалистларыгызга эш кимегән икән,—дип, чеметтермичә түзә алмады Харис.

Тикшерүче моны да колагына элмичә генә уздырып жибәрде.

—Уйларга кирәк,—диде.—Бәлки, башта главаның фикерен белү әйбәтрәк булыр. Документлар тирәсендә шау-шу куптарганны чиновниклар яратмый. Безнең эшләр килеп кысылса, тәмам женнәре котыра. Ачулары килсә, сезнең белән сөйләшеп тә тормаслар, бинаны берсүзсез жәмгыятьтән тартып алырлар. Аларның тәртәсе кыска! Ә менә главаның үзе янына кереп, Хөсәен Гайфулловичның кушканнарын аның исенә төшерсәгез, күзенә карап хәлне аңлатсагыз, үзегезнең вәкаләтләрне раслый торган бөтен документларның күчермәсен алып, бинаны үзегездә калдыруны үтенеп яна хат әзерләп барсагыз, ул чакта сарык та исән, бүре дә тук булыр иде, бәлки. Ягъни, бина да үзегездә калыр, теге хатны да, гамәлдән чыгарылуы сәбәпле, үзегез кире кайтарып алыр идегез. Менә шунда инде аны шау-шусыз, шыпырт кына криминалистларга бирергә булыр иде. Шунысы да бар: хакимияттә эшләүчеләр арасында ул хатның авторы белән элемтәдә торучы юк, дип кем ышандыра ала?

Тикшерүче белән килешми мөмкин түгел. Харис, көрсенеп, сүзне икенчегә борды.

—Кичә мин андагы мастерскойның хужасы белән сөйләшкән идем, ул бик шикле күренә Шактый күп нәрсәләрне белә булса кирәк.

Һәм ул Равилнең, бинадан куалар, дип пошынуын, төшенкелеккә бирелгәнен, бер түтәйнең күпләгән урынбасарлары хакындагы сәер сүзләрен әйтте.

—Ул тирәдә берәү үзен Байбулатованың урынбасары дип атап йөргән инде, күрәсең. Равил аны белә булырга тиеш.

—Кем икәнен әйтмәдеме?

—Миңа ник әйтсен ул аны? Сүз арасында ялгыш кына ычкындырды. Менә сез сорасагыз...

—Мин сорашканда, сүзләрне бик сайлап кына әйтә шул ул, ялгышын ычкындырмый,—диде Мансур Хужиевич.—Без аның белән сөйләштек. Бер генә дә түгел.

—Минем күз алдында сорарга була. Миңа әйткәненнән ваз кичә алмас.

—Алыр... Ул ничек дип әйткән дә син ни дип аңлагансың... Менә ул сөйләгәннәр магнитофонга язып алынган булса икән... Ул чакта сорашырга булыр иде,—дип куйды тикшерүче.

—Бер урынбасар бинаны сатып жибәрде бит инде, диде.

—Сату турында сүзләр йөри анысы, андый мәгълүмат бар. Әнә,

боларга, —дип Мансур Хужиевич телевизор экранына ишарәләде. Анда янә "РДС" дигән өч хәреф нур чәчә иде.

—"РДС"камы? Аның акчасын алганнар бит инде!

—Себердән җыйганын алганнар. Ә монда җыйганы калган. Тизрәк кая да булса тыгып куясылары килә торгандыр. Мәсәлән, әнә шул бинага. Минутында ике миллиардны бирергә әзер торалар, ди.

—Каян килеп кысылганнар соң алар монда?

—Кемдер тоташтырган. Юл күрсәткән. Арадашчылык иткән. Ә арадашчылык өчен ун проценттан егерме процентка кадәр түләнә бу заманда. Ике миллиардтан санап карагыз... Күрдегезме, нинди акчалар турында сүз бара? Ә "РДС" вакланып тормый...

Харис уйларының очына чыга алмыйча, башын иде. Мәсьәлә ул күз алдына китергәннән күпкә катлаулы, күпкә тирән иде.

—Кая карама алдау, талау, хыянәт, җинаять. Күз алдында урам саен нииндидер Шайдуллиннар банда оештыра. Ул Равилгә бандитлар белән бәйләнү ник кирәккән? Эш кешесе бит ул! Җәүһәрия алар арасына ничек барып кергән?

—Мин дә шушы сорауларга җавап эзләп баш ватам,—диде уйчан тавыш белән Мансур Хужиевич.—Әгәр барлык адәмнәр туфрактан яратылган булса, башта ул туфракны бер казанга салып болгатканнардыр, дип күз алдына китерәм кайчакта. Ул казанга фәрештәләр гел изгелек, аклык кына өстәп болгатып торгандыр. Менә шунда, алар карап житкермәгән арада, иблис чиләкләп-подаукалап һәртөрле пычрак китереп тондыргандыр. Болгату житмәгәнгә, кемгәдер изгелек күбрәк кереп калгандыр, кемгәдер шакшысы нык төшкәндер. Гадәти тормышта кешеләрнең күпчелеге үзен ак итеп күрсәтергә тырыша, эчендәге каралыкны яшерә. Ләкин килә бер көн, дөнья болгана, җаннар актарыла, шул чакта күнел төбендә яткан әшәкелек калкып чыга. Үз урынынны таба алмау, фәкыйрьлек, житмәүчелек кешенең кешелеген кимәтә шул ул. Тыныч вакытта һәркемнең үзенең нык урыны бар иде. Матвей батыр солдат. Равил авиация заводында менә дигән станоклар көйләүче... Ә менә хәзер һәммәсе үз тамырларыннан куптарылып ташланган.

—Бу болганышны ничек туктатырга соң?

—Һәркем үз эшен тиешенчә башкарса, дөнья ипләнми калмас. Булдыра алганыңны эшләргә кирәк. Равил кебек. Байбулатова кебек. Хәйрия эше кулыннан килгән, шуны эшләргә тырышкан. Мең нәргә ярдәм иткән, милләтне яхшы итеп күрсәтергә омтылган... Безгә дә үз эшебезне шулай эшләргә генә кала... Ә син документларны карап чыктыңмы соң әле?—дип кинәт сүзне борып куйды ул.

—Бу елгысы белән узган елның яртысын күздән кичердем. Җыен вак-төяк анда. Акчасы ташка үлчим.

—Алай да очына чык инде син аның,—диде Мансур Хужиевич, куе кашлары астыннан сөзеп карап.—Кирәкле мәгълүмат гадәттә һич уйламаган жирдән килеп чыга. Җеп очы бик кечкенә әйбергә уралган була.

Харисның күнелен нәрсәдер борчып тора иде. Бер ыммы, ишарәме, әллә берәр кәгазьдәге санмы, фамилияме... Ләкин шул ноктага барып житәм дигәндә генә, уйлар сибелә, кирәкле нәрсәне башкалары күмеп китә. Уйларының чәбәләнүе, жанының тынгысызлануы хакында ул тикшерүчегә әйтә алмады, чөнки үзе дә анлап житкермәгән иде әле.

* * *

Бу заманның байлык-муллыгы халык тормышына шифалы янгыр булып түгел, чәчәк чире кебек, тап-тимгел булып, кутыр булып төште. Һәрхәлдә Хариска "Казансу" банкының бинасы шәһәр тәнендәге шундый бер кутыр булып күренә иде.

Монарчы күрелмәгән тизлек белән бастырып куелган ул бина бик матур иде югыйсә: гранит нигез өстенә бер-берсенә ябыштырып куелган

тимер ырмаулы карасу көзгеләрдән генә тора. Харис, башын артка ташлап, баю ягына авышкан кояш нурларында хәтәр ялтыраган тоташ тәрәзә-диварларга карады. Түбә каядыр биеккә, ак мендәр-болыт кисәгенә омтылган, махсус корымланган пыялаларның һәркайсының эченә бик күп серләр яшерелгән кебек иде.

Бу банкның серләре турында шәһәрдә күп сөйлиләр, газитләрдә язгалап торалар. Имештер, банк хуҗалары дөньякүләм атаклы рәссамнарның картиналарын җыю белән мавыгалар икән... Бик кыйбатка сатып алынган картиналарының берсе музейдан урланган, имеш... Сочи тирәсендәге зур йортлары өчен үзара тыныша алмагач, банк хуҗасын үтереп ташлаганнар, бу эштә хатынының кулы уйнаган, имеш...

Хәер, шәһәр халкы арасында йөргән имеш-мимешләр, Казансу елгасын шадралаткан дулкыннар кебек, бу бинаның гранит нигезеннән өскәрәк күтәрелә алмыйлар иде булса кирәк. Һәрхәлдә кемнендер зыян күргәне сизелми. Урамнарда зур такталар белән "Казансу" банкының рекламалары бастырып куелган, анда кыска чәчле, ерык авызлы, бәхетле хатын сурәте. Аны бөтен буен шундый оста итеп ясаганнар, затлы итәге җиргә тиеп тора. Харисның мондый рекламаларны Чаллы урамнарында да күргәне булды—бик кин җәелгән иде, күрәсең, мадамның кара итәге, тиз генә җыйдырта алмаслар.

Әнә, тыйнак, тәбәнәк, кыршылган йорт-куралары белән бөтен район аның ышыгында утыра. Түбәсендә җилфер-җилфер флаг болганган өч катлы район хакимияте бинасы, анасы итәгенә ябышкан маңка малай кебек, мескенләнеп калган.

Банк хакимияткә кояшны каплап куйган. Югарыдан түбәнгә берәр төрле йомышлары төшсә, каршы әйтүче булыр микән? Ай-һай! Каршы әйтә алсалар, яннарына шушы рәвешле ыржайган пыяла багана бастырып куярга рөхсәт бирмәсләр иде. Кайда бар икән ул тагын—хакимият янәшәсендә берәр байның шушы рәвешле кукраеп урнашканы!

Харисның башына бер чагыштыру килде: узган гасырда дворяннарның затлы сарайлары янында эт өерләре өчен махсус зур абзарлар төзи торган булганнар. Бу ике бина шуларны хәтерләтмиме?

...Ул чыннан да бик затлы, кыйммәтле, тәрбияле, кадерле этне хәтерләтә иде. Озынча чырай, үткен күзләрнең зирәк карашы, шома, ялтыравык чәч, ипле, җайлы хәрәкәтләр. Шәһәр фатирларында асралып, хуҗалары белән бер ятакта кочаклашып йоклый торган этләр шундый була. Тән тиресе кебек ипле күксел пинҗәк түшендә ялтыраган депутат значогы да нәселле эткә ярышта җингән өчен бирелгән медальне хәтерләтте.

Равилнең Артур белән Ким кушаматлы овчаркалары искә төшкәч, Харисның көләсе килеп китте. Ләкин тыелырга, эчендәгене тышка чыгармаска кирәк иде.

—Исәнмесез, Артур Кимович,—дип, житди, шул ук вакытта итәгатьле кыланырга тырышып, кырлары чәчкәле кызыл келәм буйлап тузанлы кроссовкалары белән йомшак атлап, залдай иркен бүлмәнең түренә юнәлде ул.

Район хакимиятенең башлыгы зур ялтыравык өстәле артыннан аягүрә басты да, күрешер өчен озынча, ак, хуш исле кулын сузды.

—О-о! Сезмени ул Байбулатованың урынбасары! Мин бик шат. Районыбызда шундый игелекле оешманың даими эшләп торуы безнең өчен зур дәрәҗә. Узыгыз, утырыгыз,—дип, үз өстәленә "Т" хәрефе ясап терәп куелган ян өстәл кырыендагы урындыкларга ишарәләде ул.

Хакимият башлыгының кулы йомшак һәм салкынча иде. Харис аны кысты да, биек аркалы урындыкка җилкәләрен терәп, җайлап утырды. Монда килгәндәге борчулары кинәт юкка чыкты, ул җиңеләеп китте. Район хуҗасының ачык чыраена, җылы сүзләренә караганда, эшләр уң булачак, борчыган мәсьәләләр хәл ителәчәк иде.

—Сезнең үтенечегезне канәгатьләндердек,—диде Артур Кимович үз

урынына утыргач.— Хөсәен Гайфуллович әйткәч була инде. Хәер, турыдан-туры мина гына килсәгез дә, шундук хәл итәр идек. Көчсез-хәлсезләрне, мескен-бичараларны кайгырту безнең иң изге бурычыбыз. Бу юнәлештә без киләчәктә дә сезнең белән кулга-кул тотынышып эшләрбез, дип уйлыйм. Әле менә Франциядә дә бу өлкәдә эшләрнен ничек баруы белән бик нык кызыксындык. Картлар йортында булдык. Анда һәр кешегә аерым бүлмә, ваннасы, кухнясы бар... аскы катта медпункт, ашханә, клуб кебек ял урыны, тирә-ягы гөлбакча...

Һәм ул Франциядәге картлар йортының уңайлыгы, матурлыгы, оҗмахка бәрабәр булуы, андагы медпункт, клуб, ял бүлмәләре хакында тәмләп озак сөйләде.

Җитәкче кешенең вакыт кадерен белмичә,бу кадәр буш сүз сөйләве Хариска гаҗәп тоелды. Ләкин аны туктатып булмый иде. Ул хуҗа! Ул түрә! Хәер, сөйләсен соң! Хәзер генә ул шундый зур яхшылык эшләде бит. Харисның кулындагы кәгазь-үтенечкә генә кул куйсын да...

Ниһаять, Франция турындагы кыйсса ахырына якынлашты, хуҗа, киң елмаеп, торып басты да, өстәл аша кулын сузды—саубуллаша башлады.

—Кирәк чакта туп-туры үземә килегез. Проблемаларыгызны хәл кылырга тырышырбыз,—диде.

Харис күтәрелеп, аның сузылган кулына кәгазь сонды. Теге ялган хатны юкка чыгарып, кафе бинасын җәмгыятьтә калдыруны сорап язган хат иде бу, аны Харис Мансур Хуҗиевичның киңәше буенча әзерләп килгән иде. Чыннан да, монда сөйләшкән сүз һавага оча да китә, ахыр чиктә мәсьәлә кәгазьләрдә язылган буенча хәл ителә бит!

—Менә хат,—диде Харис.

—Нинди хат?

Район башлыгының йөзе җитдиләнде, ул кире кәнәфиенә утырды. Бер битлек кәгазьне ул шактый озак укыды. Аннары башын күтәреп, Хариска:

—Сез соң нәрсә телисез?—диде. Аның зәңгәргә манылган пыяла кебек күзләрендә чиксез гаҗәпләнү ярылып ята иде.—Сез безгә аренда килешүен өзү турында үзегез гариза яздыгыз бит.

—Ләкин ул ялган гариза! Аны без түгел, ниндидер жулик җибәргән!

Хуҗаның озынча чырае тагын да сузылыбрак китте, күзләренә тимер төсе инде.

—Аңа җитәкченең үз кулы куелган, пичәте басылган,—диде ул салкын гына.—Үзегездә тәртип урнаштырырга кирәк! Без монда һәр оешмадан килгән кәгазьнең дөреслеген тикшереп утырыр өчен түгел! Безгә рәсми документ килде, ул төп нөсхә иде. Аның нигезендә без хакимият башлыгының карарын чыгардык һәм бинаны саттык.

—Ничек саттыгыз?

—Закон нигезендә саттык. Ике миллиард ярымга. Ә сезнең белән мәсьәлә хәл кылынган: ике якның да ризалыгы белән аренда килешүе өзелде. Ике атнадан сез бинаны бушатып, тулысынча тәртипкә китереп, комиссия карары белән яңа хуҗаларга тапшырырга тиеш.

Харисның башы миңгерәп китте. Әле генә мәсьәлә хәл кылынды, дип сөендергәннәр иде түгелме аны? Ул теленә беренче килгән сорауны бирде:

—Алайса ни өчен сигез миллион акча таләп итәсез соң сез бездән?

—Килешү буенча аренда хакы аена дүрт миллион. Ике айга санагыз...

—Ә нишләп ике айга? Килешүгә кул куйганга бер генә ай бит!

—Сездән хат килгәнче бер ай узган иде,—диде Артур Кимович сабыр булырга тырышып.—Хатыгызда, бер айдан соң килешүне өзәбез, дип язылган. Бинаны хәзергәчә сез билисез. Әлегә бушатып, комиссиягә тапшырганыгыз юк. Димәк, аренда хакын түләргә тиешсез. Сез ул эшне артык сузмагыз. Пенялар җыелса, аның өстенә штрафлар өстәлсә, ул сумма бермә-бер генә түгел, дистәләгән тапкыр арта. Бухгалтерыгыз беләдер бит... Законга каршы барып булмый.

—Ләкин без ул бинада берни эшли алмадык. Без анда кереп утырмадык бит әле. Ичмасам, калган бер айга...

—Карагыз әле, килешүне укып карадыгызмы соң сез? Сүзнең дә дөресен сөйләргә кирәк. Минем белүемчә, анда сезнең пункт ачылган, вывескасы эленгән. Ничек инде сез, без анда урнашмадык, дип әйтә аласыз?

Артур Кимович нык сабырсызлана башлаган иде.

—Ә шулай да, кемгә саттыгыз сез ул бинаны?—дип сорады Харис.

—"РДС", "Русский Дом Селенга" алды аны,—диде глава.—Андый бай, зур акчалы оешмаларның районга килеп ныклап урнашуы халык өчен үзе бер яхшылык,—дип өстәде ул.

—Ләкин сез әле генә Хөсәен Гайфулловичның үтенече буенча...

—Әйе, аның киңәшен тотып һәм сезнең үтенечегезне искә алып, без күп балалы Турсункаевага өч бүлмәле фатир бирдек. Тузган торак программасы буенча төзелгән өр-яңа йорттан. Ышаныгыз: моны хәл итү безгә җиңел булмады. Бу очракта хәтта чират тәртибен бозуга бардык! Мәрхүмә Байбулатованың якты хатирәсен билгеләп үтү йөзеннән, махсус карар чыгардык моның өчен. Сез моны бәяләргә тиеш!

—Ә теге хатны кире алып булмыймы?—диде Харис тикшерүченең, документны тавыш-тынсыз кулга төшерү мәслихәт, дигәнен искә төшереп.

—Нинди хат тагын?

—Аренда килешүен өзү турындагы бездән җибәрелгән документ.

—Сез аны ике нөсхәдә әзерләргә тиеш идегез! Берсен безгә җибәрергә, икенчесен үзегездә сакларга! Күренеп тора: кадрлар мәсьәләсе бик начар куелган сезнең җәмгыятьтә!

Һәм ул салмак, сагаюлы, киеренке хәрәкәт белән тураеп басты. Гадәттә бүлмәгә ят кеше килеп кергәндә этләр шулай тартылып, ыргылырга әзерләнеп, торып баса.

Хариска чыгып китәргә вакыт житкән иде.

* * *

Бухгалтер ялларга җәмгыятьнең акчасы булмаган, Җәүһәрия ул эшне үзе алып барган. Һәм хис-тойгылардан ерак торган, фәкать канун-кагыйдәләргә генә буйсынырга тиеш булган бу эшкә, шагыйрәнең шигърилеге җилдәй бәреп кереп, еш кына буталчыклык тудырган. Әле пенсия фондыннан, әле салым инспекциясенең төрле бүлекләреннән ике айга бер килеп торган тикшерүчеләр аның өстеннән актлар язганнар, штрафлар түләткәннәр, кәгазьләрен төзәтеп язарга мәҗбүр иткәннәр. Ул "Милосердная помощь" дип язган—аңа "Материальная помощь" дип төзәтергә кушканнар... Ул Нурҗиһанга кулына бирелгән эш хакын бер генә җиргә язып, кул куйдырып биргән, аны исә бу суманы берничә урынга, әллә ничә төрле салымның һәркайсын аерым күрсәтеп язарга кирәклеге турында катгый кисәткәннәр...

Кергән-чыккан һәр сум бухгалтериядә ким дигәндә биш-алты тапкыр тәфсилләп теркәлеп куела икән. Керү ордеры, чыгу ордеры, аванс отчеты, касса кенәгәсе, товар чеклары, төп кенәгә... Бу шөгыльгә күнеле ятмаган кешенең мие түнми нишләсен! Папкаларны актарганда, кафе бинасында таралып яткан папка-кенәгәләрне, кәгазь-мәгазьләрне күз алдына китерде Харис.

Күренеп тора: Җәүһәрия бер айлык исәп-хисап эшен бер утыруда башкарып чыгарга тырышкан. Чекларны, квитанцияләрне ай буе болай гына жыеп килгән дә, аннары һәммәсен тиешенчә язып, кулын куеп, мөһер сугып, тәртипкә китереп, ак кәтүк җебе белән бөтенесен берләштереп тегеп куярга. Тирән итеп сулыш алгандыр да, каршысына әллә ничә төрле бланкны, кенәгәләрне тезеп, мөһерен алып куйгандыр, батыраеп кулына каләмен алгандыр. Тиз генә язарга да котылырга.

Ләкин ансат кына котылырлык түгел—язулар күп. Папканың алгы кәгазьләрендә хәрефләр тигез, имза пөхтә итеп, "Байбулатова" сүзе тулысынча язылып, ахырына бөтеркә ясап куелган. Аннары хәрефләр тынгысызланып, сикерешә башлый, мөһер тоныклана, имза кыскарып, "Бая" дигәнгә охшап

кала. Кайнар йөрәк хисләрен тылсымлы юллар итеп тезәргә яратылган шигъри каләм асфальт астына төшәлә торган чуер таш кебек гел бертөсле сүзләрне, саннарны язудан ялкый, тыпырчына...

Әйе, сүзләр бер үк: "алынды", "бирелде", "тапшырылды", "күчерелде"... Саннар исә күп тикшерүләр аша үткән. Харис нәрсә эзләгәнен үзе дә белми, ул фәкать, кайда пөхтә-тигез, кайда таркау хәрефләргә карап, Җәүһәриянең талчыгуын, сабырсызлануын үз күңеленнән үткәргәндәй була иде.

Ул шулай китапханәдә күп сәгатьләр үткәрде. Тикшерү эшенә ярдәм итәрлек нәрсә дә булса табарына бөтенләй өмете юк иде. Ләкин кинәт уч төбе кадәр кәгазьдә тукталып калды. Керем ордеры иде бу. Гадәти бухгалтерия кәгазе. Кассага акча кергәнне раслый торганы. Тик андагы бер сүз Харисның күзенә бәрелде: "вакытлыча бурычка, кире кайтару шарты белән". Хәер җәмгыятенә акчаны гадәттә әҗәткә түгел, химаягә, ягъни бөтенләйгә бирәләр. Аерым бер кешедән әҗәткә акча алу хәер җәмгыяте эшеме? Бигрәк тә мондый инфляция чорында! Бүген берне аласың, иртәгә унны илтеп бирергә кирәк? Алты мең бурыч! Алты мен!

Алынган да һәм шунда ук тотылган да: Нуржиһанга ике айга эш хакы һәм еллык премия итеп бирелгән, салымнар түләнгән. Алты мең акча нәкъ шуңа житкән. Ләкин ник кирәк булган соң әҗәткә акча алып, Нуржиһанга премия бирү?! Харис ашыгып приказларны карый башлады. Әһә, аңлашылды: нәкъ шул айда Нуржиһанның пенсиясен яңадан карарга кирәк булган. Менә нәрсә өчен тырышкан икән Җәүһәрия! Нуржиһанның пенсиясен арттыру өчен! Менә ни өчен бурычка кергән!

Ярый, иң кирәк чакта әҗәткә биреп торучысы табылган. Мәрхәмәтле жан. Һәм Харис ул кешенең фамилиясен жентекләп укып чыкты... Аның тәненә эссе бәргәндәй булды... Менә кем биргән әҗәткә акча!..

Җәүһәрия аңа бу бурычын кайчан кайтарган сон? Ә бәлки, кайтармагандыр да?

Ул ашыгып касса кенәгәсен кулына алды. Кассага акча сирәк кергән, шундук чыгып барган. Әҗәткә акча алу турында язу бар, ә бирү хакында— юк. Туктале, теге иртәне Җәүһәрия алты миллион бурычын түләргә ашкынган бит! Котылачакмын, дип сөенә-сөенә чыгып киткән! Шушы бурычыннан түгел микән? Елдан артык вакыт эчендә алты меңнең алты миллионга әйләнүе бер дә гаҗәп түгел ләбаса!

Харис тагын кенәгәдәге фамилиягә карады. Һәм күңелен тырнап торган сораулар, кинаяле сүзләр, сәер тоелган вакыйгалар, ымнар, ишарәләр— һәммәсе бер жепкә тезелгән шикелле булды.

Хәзер үк очрашып, күзенә карап сорарга мы?

Әллә тикшерүчегә бу кәгазьне күрсәтергә, фаразларны аңа сөйләргәме?

Ләкин аңа барып сөйләрлек нинди анык дәлил бар соң әле? Әҗәткә акча биреп тору гаеп эшме? Һәм Җәүһәрияне нәкъ шул әҗәтне түләргә ашкынган, дип кем әйтә ала? Ә бәлки, аның бөтенләй башка берәүгә тагын бурычы булгандыр? Ничек кенә булса да, бурыч түләү белән аның үтерелүен бергә китереп төйнәргә житди нигез юк бит!

Харис, папкаларны жыештырды да, аскы катка, Нуржиһан янына төшеп китте.

Апа беркайчан бетми торган шөгыле белән мәшгуль—кысан бүлмәдәге әйберләрне тәртипкә салып маташа иде.

Ишек ачылганны ишетеп, әйбер-кара тулы киштәләр янынннан борылып карады, башына өстән бер өем эшләпә килеп төште.

—Тенкәгә тиделәр инде шушылар,—дип сукранды ул аларны иелеп алганда.—Алып та китмиләр ичмасам.

Харисның хәтеренә келт итеп, модный киемнәр киеп, кафе янындагы этләрдән качып килгән йолкыш килеп төште.

—Берсен киеп йөриләр түгелме соң,—диде ул.

—Шул бер Семен алды инде,—диде Нуржиһан.

—Плашын да сез бирдегезме?

—Без инде, кем булсын тагын. Банкирлар китергән киемнәр арасыннан чыкты.

Харисның башында бер уй төенләнә башлаган иде.

—Андый плащлар тагын бармы?—дип сорады ул.

—Бар әле, бар! Эссе вакыт бит, плащка бик исләре китми байгышларның. Майка да трусик сорыйлар. Иртәгене кайгырта белми бит алар, бүгенге белән яшиләр.

—Мина алырга ярыймы?

Харис Нуржиһанны гаҗәпләнер дип уйлаган иде, ләкин апа аның соравын бик табигый кабул итте.

—Үзем дә әйтмәкче идем,—диде.—Кыенсындым гына. Андыйны җыен сукбайга әрәм итәсе дә түгел. Теләсә кайда аунап, ике көндә эштән чыгаралар. Яраса, ал да ки рәхәтләнеп. Янгырлы көннәр өчен менә дигән...

Ул эшләпәләрне өстәлгә китереп куйды да, иелеп, зур тартмадан мул тегелгән кара плащ тартып чыгарды.

—Бусы бик әйбәт менә. Ошатсаң, үтүкләп тә бирермен.

Харис папкаларны сейфка урнаштыргач, өстәл янына утырды.

—Нуржиһан апа, сез пенсиягезне янадан санатыр алдыннан берьюлы шактый акча алгансыз. Гафу итегез, сер итеп кенә сорыйм... Сез аның күпмесен дә булса... кайтарып бирмәдегезме?

Нуржиһан аның алдына кара плащ белән читләре дулкынланып килгән ялтыр тасмалы эшләпә китереп куйды да:

—Ничек инде бер бирелгән зарплатаны кире алсыннар,—диде.— Андый хәл буламыни дөньяда.

Күренеп тора, апакайга сеңгән сәвит тәрбиясе чыкмаган, чыгачак та түгел. Заман хәйләләренә башы җитми иде аның.

—Ул айлар өчен Җәүһәрия үзенә эш хакы чутламаган. Түләүсез ялда, дип язып куйган. Шуна соравым,—диде Харис.

—Аның акча алу-алмавын мин каян белим инде...

—Ә ул сезгә акчаны каян алып биргән иде, анысын да белмисезме?

—Аның ишегә кысылмадым мин! Җитәкче кеше акчаны каян таба, кая куя, анысы минем эшмени!.. Ишетсәм дә онытткан булыр идем. Хәтерем бик начар бит. Ишеткәнне—күргәнне дә минутында онытып куям.

Нуржиһан апа сүзнең никадәр җитди икәнлеген аңламады, кире киштәләр янына барып, алам-салам актарырга керешә.

Бурычка биргән кешенең үзе белән очрашырга кирәк... Үзеннән әйттерергә. Ул, билгеле, Хариска ачылмаячак. Башка берәү катнашсын, куркытсын, каушатсын... Димәк, башка берәү рәвешенә керергә кирәк.

Харис тагын теге көнне кафе артыннан чабып чыккан адәмне күз алдына китерде. Плащ белән эшләпәдән нинди булып күренгән иде дә, битенә карагач, кем булып чыкты. Димәк, бу киемнәрне кисәң, башыңны аскарак исәң, үзеңне танытмаска да була! Яисә... шул Семен дип танытырга! Буй-сыннары бер чама.

Курчак уены уйнаргамы? Ә нигә уйнамаска?! Харисның үзен күпме вакытлар әвәрә китереп, аңгыра малай урынына мингерәтеп йөрткәннәр... Уенчык итеп, курчак ясап...

Уйнарга... Серен алырга... Ләкин тагын шунысы бар: икәүдән-икәү сөйләшкән сүз кешене гаепләү өчен ныклы дәлил була алмый. Тикшерүче шулай диде. “Магнитофон тасмасына язылган булса икән!..”—диде ул.

Харис өстәлдән плащ белән эшләпәне алды да Нуржиһаннан:

—Болар сыярлык сумка юкмы?—дип сорады.

—Бар, нишләп булмасын. Банкирлар һәр әйберне аерым чытырга салып китергәннәр.

“Чытыр” дигәне полиэтилен капчык икән. Харис киемнәрне әйбәтләп төрде дә, кире китапханәгә, Халидә янына кереп китте.

Аңа магнитофон кирәк иде.

—Бар минем магнитофон, нишләп булмасын,— диде Халидә.—Элек, завод бай чакта, безгә кирәк-яракны алып кына торалар иде. Бөтен

мероприятиеләрне язып бара торган идек. Җәүһәриянең укучылар белән очрашканы да һәммәсе язылган.

Харисның күңеленә эссе жил бәреп кергәндәй булды.

—Сездә аның язмалары сакланамыни?

—Сакланмыйча! Ул бит монда өлкән класс укучылары белән шигъри осталык дәресләре үткәрә иде. Балалар исләре китеп, дөньяларын онытып тынлыйлар иде. Андый язмаларны югалталармы соң!

—Мина да биреп торырсыз әле!—дип, балаларча беркатлылык белән сорап куйды Харис.

—Кире кайтару шарты белән. Югалтмаслык булсагыз гына. "Сони" магнитофоны бик җыйнак, киң плащ астына яшерергә уңайлы иде.

Инде хәзер ике мәсьәләне хәл итәргә кирәк: очрашу өчен бик аулак урын сайларга һәм анда чакыруны мөмкин кадәр шомлырак һәм серлерәк итәргә. Чакырылган кешенең бәгырен ялкын теле өтеп алырлык булсын! Чалбар балагына ут капкандай чыгып чабарлык итсен!

Әгәр ул чыннан да гаепле булса...

Әгәр гаебе булмаса, ул чакта чакыруны бирәрсенең мәгънәсез шаяруы дип кенә кабул итәр дә ертып ташлар. Беркая барып та тормас.

* * *

"Сезнең өчен бик мөһим хәбәр сезгә мәгълүм бинаның ишек алдындагы ванна астында. Редис". Әйе, нәкъ шулай кул куярга кирәк бу телеграммага: "Редис". Белгән кеше "РДС" дигәнне шундук аңлап алыр.

Почтаның тәрәзәчеге аша әлеге язуны сузганда, Харис эчтән генә үзеннән-үзе көлеп куйды: гел бала-чага уены инде бу! Ир кеше шуның ише белән шөгыльләнә димени?

Телеграфистка, үзе дә редис кебек түгәрәк, тыгыз битле, кызыл иренле кыз, икеләнеп калды: кабул итәргәме мондый сәер сүзләрне, юкмы?

Харис аңа күз кысып елмайды:

—Курыкмагыз, монда сүгенү сүзе юк!

—Анысы түгел. Имзада хата җибәргәнсез түгелме?

—Кушамат ул, псевдоним. Дуслар мине шулай атый.

—Алайса, менә бу сызык астына адресыгызны, дөрес исем-фамилиягезне языгыз.

—Анысы була,—диде Харис һәм башына килгән адресны, исем-фамилияне язып куйды.

Ә бу вакытта кафенең ишек алдындагы ванна астында, тәрәзәсез бүлмәдән алынган исәп-хисап кенәгәсе ята, аның тышына эре-эре хәрефләр белән тырмаштырып: "Мин бөтенесен дә беләм. Кичке сәгать унда кафеда булам. Шунда очрашмасак, иртәгә иртән бүтән җирдә башкалар белән очрашачакмын",—дип язылган иде.

Харисның үзенә ул тирәдә бүтән чуалырга кирәкми, билгеләнгән вакытка— сәгать унга гына барырга... Равилнең мастерское инде ябык була, бина тирәсе бөтенләй аулак кала. Ә көн якты әле, урамнан кешеләр үтеп-сүтеп тора, алар арасында Харис бик күзгә ташланмас. Ул урам яктан килер, ә теге адәм кафенең аргы башындагы агачлыктан керер яисә арткы ишегалдыннан. Һәм Харисның якынлашканын бина эчендә посып, берәр ярыктан күзәтеп торыр. Әгәр бу уенга катнашырга ниятләсә... Харисның шиге дөрес булып чыкса...

Ул көн буе очрашуның ничек-ничек булачагын уйлады, бөтен ваклыкларны кат-кат күз алдыннан үткәрергә тырышты. Урам яктан килгәндә яшеренеп торудан мәгънә юк. Ләкин менә бина эченә кергәч, бик сак булырга туры килер. Якты җирдә кара-каршы очрашмаска... Үзенне танытмаска. Шуңа күрә тиз генә теге караңгы коридорга үтеп керергә кирәк.

Ярый, алар дөм-караңгыда очрашырлар. Харис тавышын үзгәртер,

тамагы шешкән йолкыш кебек ысылдап кына сөйләшер. Теге иртәне һәммәсен күреп тордым, дияр, акча таләп итәр.

Шуннан ни булыр?! Килгән адәм үзен куркыткан йолкышка берсүзсез миллионнар бирергә риза булырмы? Акча тоттырырмын да котылырмын, дип уйлармы? Шулай итеп, язмышын очраклы сукбайга ышанып тапшырырмы? Әгәр ул чыннан да үтерүче булып чыкса?! Ул куркып калачак, куркуы анын бөтен акылын томалап алачак. Андый чакта нишләр ул?! Үзе өчен берләнбер котылу чарасы—шантажлаучыны беркайчан беркемгә бернәрсә әйтә алмаслык итү, дигән фикергә килмәсме? Ә ул анын чарасын белә... Бер тапкыр кулланып та караган инде... Урыны да шул ук!..

Җәүһәриянен үле гәүдәсе күз алдына килде... Шагыйрә дә очрашуга барганда үзенә нинди куркыныч янаганын белмәгән бит... Башына да китермәгән... Ярый ла, ул адәм актыгы үзе генә килсә? Әгәр берничә булсалар? Шунда посып, күмәкләп көтеп торсалар?

Бу уйлардан Харисның тәненә тир бәрде. Уеннан уймак чыкмагае!

Тикшерүче кат-кат кисәтте бит аны, ул-бу сизелә калса миңа хәбәр ит, үз белдеген белән бернәрсә дә эшләмә, диде.

Олы урамнан борылышка барып житә язган иде инде ул. Кулындагы полиэтилен капчыктан бөгәрләнгән плащ белән эшләпәне ала башлаган иде. Туктап, аз гына уйланып торды да, кире борылып, каршы яктагы тугыз катлы йорт почмагындагы телефон-автоматка таба юнәлде.

Мансур Хужиевич өйдә юк иде—хатын-кыз тавышы, хатыны булса кирәк, шулай диде. Эшендә дә җавап бирүче юк. Нишләргә? Харис милиция бүлегенә шылтыратты.

—Милиция. Дежур Денисов тыңлый.

—Сез тикшерүче Мансур Хужиевич белән хәзер үк элемтәгә керә аласызмы?

—Нәрсәгә?

—Минем фамилиям Әхмәтнуров. Мансур Хужиевич мине яхшы белә, ул миңа кирәк чакта шылтыратырга кушкан иде. Миңа Байбулатованың үтерелүенә бәйләнешле бик мөһим мәгълүматны ачыкларга мөмкинлек туды. Унбиш минуттан "Баллы күл" кафесында очрашу булачак...

—Кемнәр очраша? Сез каян шылтыратасыз? Ул сезне ничек таба ала?

—Сез ана мин әйткәннәрне генә тапшырыгыз...

Харис трубканы куйды. Ул тынычланган иде инде. Чыннан да, юк нәрсә белән милициянең башын катыра түгелме ул?.. Килүче булмас та әле. Ванна астындагы кенәгә дә урынында ятадыр... Көлкегә калмагаең һәм милицияне юкка борчыганың өчен Мансур Хужиевичтан гафу үтенергә туры килмәгәе... Теге дежур Денисов таба алмаса ярар иде үзен...

Харис, кире урам аша чыкты да, иске агач йортның ишек алдына кереп, плащ белән эшләпәне алып киде. Шулай итеп, капкадан берәү керде, бөтенләй икенче кеше килеп чыкты. Хәер, кафе моннан күренми, күзәтеп торучы бар дип фараз кылсак та, бу үзгәрешне сизә алмагандыр.

Ул, башын ия төшеп, битен эшләпә чите белән күләгәләп, йөрешен үзгәртеп, чаттан борылды, аулак урам буйлап узды, капкадан кереп, шар ачык тимер ишеккә юнәлде. Башын бормый гына ванна тарафына күз салды, ул теге кенәгәне почмагы күренерлек итеп куйган иде. Кенәгә урынында, яшел чирәм өстендә, өзелгән ак тузганак башы гына ята иде. Язуны алганнар...

Караңгыга барып кергәнче, каршыга килеп чыкмасалар гына ярар иде... Күзгә-күз очрашканчы, теге коридорга гына барып ирешәсе иде...

Харис, идәненә кәгазь түшәлгән таныш бүлмә аша ашыгып узып, тар аралыклар аша үтте дә караңгылыкка чумды. Салкын, юеш диварга аркасы белән сөялеп, тынып калды. Йөрәк дөп-дөп тибә, колаклар чыңлый иде. Ул, берәр тавыш ишетелмәсме, дип шактый вакыт кыймшанмыйча басып торды. Коридор гадәттәгедән дә зуррак, караңгырак тоелды. Аның аргы башыннан, кечерәк кенә ачыклыктан, томан саркыгандай булып, аксыллык сирпелә иде. Күрәсең, кечкенә ишектер. Берәрсе аннан керәсе итсә, шундук шәйләнәчәк. Күз дәияләшеп килә инде, Хариска сиздерми

генә якын килү мөмкин түгел...

Чуп-чуп, чуп-чуп килеп карангыда, салкын дымлылыкта сулы идәнгә эре тамчылар тама. Чуп-чуп, чуп-чуп... Тамчылар да шундый дәһшәтле тавыш чыгара ала икән...

Ә бәлки, Җәүһәрия дә теге иртәне нәкъ шушылай, тамчыларның кисәтүле чупылдавын тыңлап басып торгандыр? Ә бәлки, борынгы дәһшәтле зинданнарны хәтерләткән бу таш диварлар аның тән җылысын суыргандыр, йөрәгенең күкрәк куышына бәргәләнүен боз битарафлыгы белән тыңлагандыр? Харис, күзләрен йомды да шагыйрәнең соңгы минутларын күз алдына китерергә тырышты. Тамчылар чупылдавы аша шул иртәнге сөйләшү ишетелә кебек тоелды. Гүя...

...—Нигә монда чакырдың?—ди Җәүһәрия.

—Мәсьәлә бик җитди. Икәүдән-икәү генә хәл итә торган. Жанночка, милая!..

—Кагылма миңа!—ди Җәүһәрия җырчыларныкы кебек назлы, көйле тавышына катылык, тупаслык бирергә тырышып.—Хәзер үк мин сиңа бурычымны түлим дә, араны өзәбез.

—Ничек өзәбез! Нәрсәгә? Акылыңа кил, Жанночка! Ни сөйлисең син?

Әйе, ул Җәүһәриягә нәкъ менә Жанночка дип эндәшә. Үз итеп, якын итеп... Хариска караганда күпкә якынрак итеп... Ул үзенә шундый хокуклар дәгъвалый, алай гына түгел, шундый хокуклары барлыгына инана.

"А-ай, Җәүһәрия, нишләдең син? Ялгызлык ни хәлгә җиткерде сине? Мондый чүп бәндә белән ничек бәйләндең син?"

Ләкин Харисның бу соравы сонарды шул инде, сонарды. Ә теге көнне шагыйрә карангыда, аулакта, куркыныч бәндә белән ялгызы басып тора...

—Акылыма килгәнгә сөйлим дә,—ди ул.—Менә, акчаны ал да... Инфляцияне исәпләп санадым... Төп-төгәл алты миллион...

—Жанночка!.. Нинди алты миллион? Ким дигәндә дүрт йөз миллион турында сүз бара! Ике миллиардтан егерме процент! Ике йөз миллион бүген. Калганы бераздан. Аңлыйсыңмы?

—Анламыйм. Мин сиңа бury-



## *Журналыбыз турында*

**Миркасыйм Госманов,**
академик.

*«Казан утлары» бәйрәме—бөтен татар халкының олуг бәйрәмнәренең берсе, чөнки шагыйрь әйтмешли, иң авыр елларда да тегермәндә тартылмаган татар теле кебек, татар әдәбиятын, татар сәнгатен иң авыр шартларда да ул саклап, ул яшәтеп килде. Бу турыда күп сөйләргә була. Бер-ике мисал гына китереп узыйм. Университетта эшләп, кульъязмалар җыю буенча миңа элеккеге Советлар берлегенең һәрбер почмагында диярлек булырга туры килде. Әйтик, Рязань ягыннан алып Иркутскига—Байкал күленә кадәр, Киров, Пермь якларыннан алып Астрахань, Бакуларга кадәр. Шунда һәрбер авылның һәр йортында диярлек булырга туры килде. Йортларга кергәндә башта бер уй: гаилә ничек, бу гаиләдә культура-мәдәният ничек? Татарлык ничек? Шуны аңлата торган бер-ике галәмәт була. Аларның берсе «Казан утлары», икенчесе—элеккеге «Азат хатын», бүгенге «Сөембикә» журналы. Әгәр дә шундый йортларга туры киләсең икән, бу авылда, бу төбәктә безнең экспедициянең юллары һичшиксез уңа дигән сүз. Менә шуның өчен мин «Казан утлары»н төрле төбәкләргә сибелгән безнең халыкны, милләттәшләребезне оештырып торучы органнарның берсе дип саныйм.*

*Журнал юбилеена Татарстаннан-Башкортстаннан, Идел буенынң төбәкләреннән генә түгел, Урта Азиядән дә, Казакъстаннан да вәкилләр килгән, Америкадан, Австралиядән, Германиядән, Финляндиядән дә кунаклар бар! Димәк «Казан утлары» элеккеге Советлар берлегендә генә түгел, хәтта бөтен дөнья татарларын да бергә кушу сәләтенә ия икән.*

*Тагын бер нәрсәгә игътибарымны юнәлтәсем килә: журналда элек һәм*

чым турында гына сөйлим!

—Анла, алар акчаны машиналап, самолетлап ташый, бөтен илдән! Кая куярга белмиләр! Менә шушы минутта синең кулыңа ике йөз миллионны бирәчәкләр. Кул гына куясы да пичәт кенә басасы. Биш минутлык эш! Мондый мөмкинлек фәкать синдә генә, Жанночка! Пичәтең дә сумкаңда.

—Булса ни, халык малын жуликларга авыштыру өчен бирелмәгән ул. Житмәсә халыкны алдап җыйган акча турында сүз бара! Җинаятьче түгел мин сиңа!

—Җәүһәрия. Тынычлан. Монда бернинди җинаять турында сүз бармый. Бөтен документларны иң яхшы юристлар әзерләгән. Бөтенесе исәпләнгән-саналган! Акыл белән эшләсәң, бер миллиард безнең кулда! Уйлап кара: аннан синең хәерчеләреңә күпме өлеш чыгарып була!

—Теге Колумбия наркобароннары кебекме? Башта халыкны тала, аннары шуннан бераз өлеш чыгар! Син мине шулар белән бер рәткә куймакчымы?

—Жанночка! Монда беркемгә бернинди зыян килми бит! Уйлап кара!

—Мин һәммәсен уйладым. Бина җәмгыятькә бирелде һәм җәмгыятьнеке булып калачак. Түбәсендә Кызыл Ай булачак! Әйдә, яктыга чыгыйк, акчаны санап бирәм.

—Яктыга дисең...

—Документка кул куярга кирәк. Акчаны алганлыгына.

—Жанночка...

—Алай дип дәшмә миңа бүтән!

...Әйе, ул шулай дигән. Нәкъ менә шул сүзләре, бөтенләй читләштерүе тегенең күңел төбендә анарчы басылып яткан, беркем белмәгән, сизмәгән каралыкны ургытып чыгаргандыр да. Кулыннан йөз миллионлаган акча шуып чыкканны сизгәч, Җәүһәриянең аны бөтенләй куганына ышангач, ярсып, караңгыдан чыкканда аяк астыннан теге сынык пычакны алгандыр да ул...

...Харисның колагына аяк атлаган тавыш килеп бәрелгәндәй булды. Әллә тегеләрнең адымнары диварларга сеңеп калып яңардымы икән?

Юк ла, ишегалды ягыннан, күләгәдәге ишектән кергәнме, берәү якынлаша иде.

*хәзер эшләгән хезмәткәрләр татар бүлегендә, ягъни хәзерге татар философиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетына нигез булган татар бүлегендә укып чыккан кешеләр. Һәм ышанам: киләчәктә дә «Казан утлары»нда, нигездә, бездә укып чыккан кешеләр эшләячәк. Ә бу исә «Казан утлары»ның узганы белән бүгенгесен генә түгел, татар халкының, татар мәдәниятенең узганы белән аның киләчәген дә «Казан утлары» бәйләргә ярдәм итәчәк дигән сүз.*

*Гасырыбызның башында бик күп журналлар чыккан: «Шура», «Таң», «Ялт-Йолт», «Әлгасрелҗәдит»... Шуларны исәпләсәк, безнең журнал бәйрәмен генә түгел, ә бәлки гасыр буена сузылган журналистикабыз тарихын да искә алып бәйрәм итәргә хакыбыз бар. Гасыр башында чыккан бер журналның исеме миңа бигрәк тә ошый. Ул—балалар журналы «Ак юл». Бу журналны искә төшерүем—«Казан утлары»ның киләчәгенә ак юл теләп каласым килүдән.*

—Син кайда?—диде каты пышылдау тавышы.

—Монда,—дип пышылдап җавап бирде Харис гәүдәсен дивардан аермыйча гына.

—Ни кирәк сиңа, йолкыш?

—Миңа түгел. Сиңа кирәк.

—Синнәнме?

—Миннән.

—Нәрсәң бар соң синең, йолкыш?

—Бик кыйммәтле информация.

—Синдәме? Минем өченме?

—Әйе синең өчен. Хакы унбиш ел тора.

—Шантажларга уйлыйсыңмы?

—Шантаж түгел. Синең өчен бик файдалы алыш-биреш. Кыйбат түгел. Нибары алты миллион. Алты миллион гына. Теге иртәне сиңа шулкадәр бирделәр бит?

—Син... каян беләсең?

—Ә мин монда иртүк кергән идем... Этләр чыгып китүгә... Әйберләрем монда иде бит минем... Син пичәтне алдың да, сумканы шунда менгереп ташладың. Шулай түгелме? Гаепне минем өскә өймәкче идең...

—Хайван!

—Ну-ну! Сиңа минем белән ягымлырак булырга кирәк. Кем әле монда кеше үтерүче!

—Син... моны шулай дип сөйләп йөрисеңме?

—Юләрме әллә мин? Мондый очракта дәшмәү алтын. Әйткәнемчә, алты миллион тора ул...

Җавап урынына кинәт каты ыңгырашканга охшаш тавыш ишетелде. Харис аңлап алды: аны таныдылар. Тавышыннан. Мавыгып китеп, соңгы сүзләрен үз тавышы белән әйтеп ташлады шул.

Кыргый җәнлек сиземләве белән ул муенын җыерып, иңбашын күтәрде, авыр пычак плащны телеп, кулбаш сөягенә бәрелде.

Шул ук мизгелдә коридорның ике очында да фонарьлар кабынды һәм кырыс команда яңгырады:

—Ни с места! Все на пол!

Фонарьләр яктысында каршы торган гәүдә тагын аңа ташланды. Ул читкә чак тайпылып өлгерде. Шул арада ике яктан тишекле кара битлек кигән, автоматлар тоткан егетләр чабып килеп җиттеләр. Фонарьларны аңа һәм каршыда басып торган кешегә төбәделәр. Аның кызарынып бүртенгән чыраена, ярсудан шома тимер төсенә кергән күзләренә гаҗәпләнеп карады Харис. Менә нинди дә була аласың икән син, бизнесмен Даниф!

Харис, сул кулы белән уң иңбашын кыскан хәлдә, Данифка текәлеп баскан, йөгереп килгән егетләрдән сакланырга уйламаган да иде. Иелергә дә, борылырга да өлгермәде, касыгына китереп типтеләр, йөзе белән сулы бетон идәнгә сыладылар, кулларын артка каердылар. Ул чамасыз авыртудан һушыннан язды.

* * *

Мансур Хуҗиевичның кашлары гадәттәгедән дә ныграк тырпайган иде. Ул өстәл аша мангай астыннан сөзеп карады. Аның каршында утырган Харис, башын иеп, марля белән муенына асылган кулын сыпыргалады.

—Көн болытлап тора шул, сызлыйдыр,—диде тикшерүче.

—Анысы сызлар да бетәр,—диде Харис.—Анда кемнең ник бәргәне аңлашыла. Менә монысы аңлашылмый.—Ул бармаклары белән күгәргән күз төпләрен, шешкән борынын капшады—Ни өчен алар мине шулай иттеләр?

—Үз белдегең белән йөргән өчен. Әйткәнне тыңламаган өчен.

—Мин сезгә шылтыраткан идем. Таба алмадым.

—Кинәшмичә, алдан әзерләнмичә, андый эшкә баралар димени? Җинаятьчене кулга алу—иң куркыныч нәрсә ул. Ярый әле, соң булса да

шылтыраткансын. Югыйсә бу минутларда бөтенләй башка җирдә яткан булыр идең. Утка бастырдың син безнең барчабызны. Әле дә егетләр өлгерделәр.

—Бик шәп иттеләр инде,—диде Харис йөзен чытып. Һәм тагын битен сыйпады.

—Спецназ. Әфганны узган егетләр. Аларның ысулы шундый.

—Әллә теге Матвей Шайдулин да булган инде араларында?

—Ул булса, эшне чистарак башкарган булыр иде. Кешенең чыраена андый тамгалар салу осталык билгесе түгел инде ул. Нишлисең, Матвей кебек профессионалларны безнең арага тартып булмый шул әле.

—Аз түлисез!—диде Харис.

—Түләү мәсьәләсендә безнең хөкүмәтебез яна байлардан уздыра алмый шул әле.

—Димәк, алга таба да шулай эшләячәк икәнсез,—дип көрсенде Харис.—Өермә кебек бәреп керәләр дә тотып бәрәләр... Гаепләме кеше юкмы, аны карап тору юк.

—Кем гаепле, кем гаепсез икәнне аеру алар эше түгел. Аларның вазифасы—объектларны исән килеш откарлау.

—Бу исән килеш дип аталамыни?

—Егетләргә үпкәләргә кирәкми. Бик ашыгыч иде бит. Дежурный мина шылтыратты, мин дежур капитанга. Әйбәтләп аңлатырга да вакыт булмады. Ун минуттан барып җитәргә, кем бар шуны тоткарларга...

—Ә теге?—Харис тотлыгып калды: исемен әйтергә теле әйләнмәде, башкача атарга сүз таба алмады. Мансур Хуҗиевич аны аңлады.

—Камерада. Байбулатованы ничек үтергәнен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде инде. Шунысы аңлашылмый: син аларның күптән таныш икәнен белмәдеңмени соң?

—Белмәдем шул. Ул танышлыкларын бик нык яшерде. Аннары... гел янымда йөргән кешедән шикләнергә башыма да килмәде.

— Алай да ахыр чиктә ничек эзенә төштең?

—Җәүһәриянең күзләре әйтте,—диде Харис.

—Ничек? Аларны чокыганнар иде бит.

—Әйе шул... Мин теге әҗәткә акча алу турындагы кәгазьне күргәч, бөтенесен өр-яңадан күз алдымнан уздырдым. Мәрхүмәне без Данифның машинасында илткән идек бит... Моргка барып җиткәч...

...Әйе, морг ишегалдына барып туктагач, Харис машинадан төште дә Сашага ияреп, ишектән керде. Ләкин аны коридорда туктаттылар, эчке яктан зәңгәрсу ситсы күлмәк-штан белән шундый ук кәләпүш кигән мыеклы егет чыкты да, Сашаның документын карап, эчкә уздырды, Хариска исә коры гына: "Ә сез монда гына көтегез",—диде. Харис шунда, бетон стеналар эчендә, пәрдәсез зур тәрәзә янында күпме басып торгандыр, аңышмады. Ярты сәгать чамасы вакыт узгандыр, бәлки. Эчтән Саша, теге егет, зәңгәрсу киемнән тагын икәү носилка белән җәймә күтәреп чыктылар да, машинага юнәлделәр. Харисны мәет янына якын китермәделәр, аның турыннан узганда носилка ак җәймә белән капланган иде инде.

—Син бит мина мәетне үз кулым белән илтеп тапшырдым, бер минутка да яныңнан китмәдем, дигән идең.

—Кем уйлаган бит аны... Аның алдыннан гына без мәетнең күзләрендә үтерүченең сурәте сакланамы-юкмы, дип сөйләшеп барган идек.

—Аны Даниф ишеткән инде...

—Бергә идек бит!

—Разведчик уены уйнарга керешкәнче, бөтенесен яхшылап уйларга кирәк иде,—диде Мансур Хуҗиевич.

—Һәркем үзенә тиешлене эшләргә тиеш, дисез инде... Соңгы көннәрдә больница койкасында ятканда, мин шактый уйландым. Тик әлегә хәтле очына чыга алмыйм: зиратта Шайдулин кемгә сәлам бирде икән соң?

Мансур Хуҗиевич, шуны да аңламыйсыңмыни, дигән кебек, борынын мышкылдатып, көлемсерәп куйды.

—Даниф алар тирәсендә шактый чуалган бит! Равил дә, Матвей да аны бик яхшы белгәннәр! Алар бинага ныклап кереп утырырга теләгәннәр,

ә теге болардан акча каерырга өметләнгән. Ләкин Шайдулиннар төркеме оешып кына килә, акчалары күп түгел. Ә монда чутсыз акчаны кая куярга белмәгән "РДС" килеп чыккан. Даниф егерме процент бәрабәренә бинадан баш тартуны тәэмин итәргә алынган. Соңгы вакытта ул, "вице-президент" дигән таныкнамәсен күрсәтеп, Равилдән бинаны бушатуны таләп итеп йөргән. Чөнки "РДС" вәкилләренә, мин хужа, дип исбатлыйсы килгән!

—Ә Җәүһәрия?

—Нәрсә Җәүһәрия?

Харис дәшмәде, йөзен күрсәтмәскә теләп, башын рәшәткәле тәрәзәгә таба борды. Мансур Хуҗиевич аны аңлады.

—Җәүһәриягә һөҗүм көчле булган,—диде ул.—Төрле яктан. Акча белән дә ымсындырып караганнар... Хис ягыннан да... Аның кайнар канлы булуын, ялгыз яшәвен искә алып, Даниф гашыйк булып кыланган, сөяркәсе булырга маташкан...

—Ләкин була алмаган!—диде Харис нык итеп.

—Ул яктан бирешкән булса, бина мәсьәләсендә генә каршы тора алмас иде инде,—дип тыныч кына йомгаклап куйды Мансур Хуҗиевич.

* * *

...Ул "09" телефоны аша "РДС"ның Казандагы вәкилен эзләп тапты. Көр тавышлы егет җавап бирде.

—Сез хәер җәмгыятенең бинасын тартып алганыгызны беләсезме?—дип сорады Харис.

—Что сез, что сез! Бина буш иде!

—Без анда эшли идек, вывескабыз да бар иде.

—Андый вывесканы шаярып кем элмәс. Сез борчылмагыз, бер ай эчендә без аны ремонтлап чыгачакбыз. Шушы арада югары оешмадан акча килергә тиеш.

—Волгоградтанмы?!

—Әйе. Мәсьәлә хәл ителгән инде.Шунда сезнең җәмгыятькә яхшы гына бер бүлмә бирербез. Бергәләп эшләрбез.

—Нәрсә булачак соң анда?—дип сораудан тыелып кала алмады Харис.

—Офис,—диде егет.

Офис?! Димәк, кантур?! Дистәләгән тонналар ризыкны саклау, каклау, ыслау, пешерү өчен, һәр көнне йөзләгән кешегә табын әзерләп сыйлау өчен, дистәләгән мәктәпләргә азык хәстәрләү өчен, яңа пешекчеләрнең осталыгын чарлау өчен, ахыр чиктә зур табыш алу өчен махсус салынган өч катлы мәһабәт бинада—кантур?

Харис шул биек залларда тезелгән шома өстәлләрне, алар өстендә экраннары белән күзне камаштырып утырган мониторларны, аларга текәлгән сыек сынлы егет-кызларны, алар каршында әледән-әле зыңгылдаган телефоннарны күз алдына китерде. Хәерчегә калган халыктан алдап-йолдап тагын күпме акча җыярга кирәк булачак бу галәмәт офисны урындык-өстәл, компьютер-принтерлар белән тутыру өчен һәм алар тирәсендә ыгы-зыгы килүче әрәм тамакларны асрау өчен! Ә бит булдырмакчылар! Халыкны сыгачакларына, әллә ничә дистә компьютерда бушка килгән акчаны санап утырачакларына ышаналар!

—Алло! Алло!—ди иде телефоннан көр тавыш.

Харис дәшмәде. Авыр сулап, телефон трубкасын куйды.

... Тагын бер атнадан Нурҗиһан:

—Кафеда безнең әйбәт кенә бер өстәлебез, ике урындыгыбыз калды. Шуларны алып кайтып, Насибәгә бирергә иде,— диде.—Яңа квартирына куяр әйберсе юк.

Харис, тресттан "УАЗ"ик сорап алды да, "Баллы күл"гә китте. Язмышның шаяруыдыр инде, бу машина Данифның машинасына бик тә охшаган иде.

Ишегалдындагы ваннадан җилләр искән, өстәл белән урындыклар да күренмәде. Бәлки, эчкәрәк алып кергәннәрдер, дип, Харис бинаны йөреп

чыкты. Җимереклек, арусызлык тагын да көчәйгән иде. Чоландагы шешәләр юкка чыккан. Җәүһәрия җан биргән бүлмәдә, ике-өч урында сүнгән учак эзләре каралып ята—кәгазьләрне уртага өеп яндырганнар.

Кафе тыкрыгыннан олы урамга чыкканда Харис каерылып артка карады. Аның түбәсендәге зур хәрефләр, тагын да каралыбрак, тагын да чалшаебрак тырпаеп торалар иде. Җәүһәриянең: "О-ой, нишләдем соң әле ми-ин?!"—дигән тавышы күңелдә яңгырады. А-ай, Җәүһәрия, нишләдең соң син?! Никләргә генә ят мохиткә барып кердең?!

Озакламый газитләрдә "РДС"ның житәкчеләрен кулга алу, җинаятьчел гамәлләрен тикшерү турында хәбәрләр басылып чыкты. Кафе бинасын сатып алган егетләргә дә Волгоградтан акча килү өмете өзелгән иде инде. Төп хуҗалары керемнең күп өлешен чит ил банкларына күчереп өлгергән икән дә үзләре дә, чикләр аша үтеп, көнбатышның бик зур, бик матур шәһәрләрендәге затлы йортларында иркенләп яшәп яталар икән.

Алардан аермалы буларак, Данифның язмышы, закон кармагына эләгеп, гадел юл белән китте. Хәер, аның ише вак-төяк бәндәләр, илдә тәртип барлыгын, җинаятьчеләрнең каты җәзага тартылып торуын исбат итү, тәртип саклау органнарының яхшы эшләвен дәлилләү өчен хезмәт итә дә инде.

...Харис китапханә бүлмәсендә җәмгыятьнең папкаларын рәткә китереп утыра иде.

Күрше өстәл артында утырган Халидә урыныннан торып басты да, ачык тәрәзә каршына барып, чәчәккә, бал исенә күмелгән зур юкә агачына караган хәлдә:

—Хәзер нишлисез инде?—дип сорады.

—Формаль эшләр күп әле,—диде Харис.—Мондый оешманы ябу өчен дә шактый чабарга кирәк икән.

—Шулай итеп, ябарга дисез инде...

—Япмас идек тә, кем эшләр анда? Менә сез алынасызмы? Зур бер бина даулап алырсыз... Түбәсенә Кызыл Ай бастырып куярсыз!

Харис Җәүһәриянең үз халкын игелек кылуда бөтен дөньяга таныту турындагы хыялларын исенә төшерде. Ничек дулкынланып, очынып сөйли иде ул бу хакта!

—Дөньяның берәр кыйтгасында фаҗига-мазар булуга, тиз арада барып житәрсез,—дип дәвам итте Харис сүзен.—Татарстанның байрагын Кызыл Айлы байрак белән янәшә күтәреп куярсыз да каза күргән адәм балаларына ярдәм итә башларсыз. Шулай итеп, татар халкының абруен үстерерсез.

Халидә борылып карады, аның күзләрендә курку чагылды:

—Нәрсә сез... Минем кулдан киләме...

Бераз вакыт кәгазь кыштырдавы гына ишетелеп торды. Аннары Халидә, тәрәзәгә караган килеш, әкрен тавыш белән:

—Монда сезгә терәкләр түгел. Шәһәр уртасындагы биек бинага Кызыл Ай бастырып куйдыртмаслар...—диде.—Җәүһәрия кебекне дә таба алмаслар. Берданбер иде ул. Аны алыштырырлык юк бүтән.

—Нигә булмасын?—диде Харис.—Халыкның уллары-кызлары житәрлек. Бәяли генә белмибез. Кеше кадерен белү юк бездә. Кайчан да булса зурга омтыла торган көчле, кыю шәхесләр табылыр, җәмгыять янадан ачылыр. Менә дигән бинага ия булыр. Түбәсендә Кызыл Ай балкып торыр... Тик...

Ул ярты сүздә тынып калды. Сыкранулы эчке тавыш кына үзәкне өзеп кат-кат кабатлады: "Тик минем өчен генә табылмас... Минем өчен генә Җәүһәрияне һичкем алыштыра алмас..."

Харис өстәлдәге кечкенә магнитофонның төймәсенә басты. Аннан назлы-ягымлы тавыш ишетелде:

"Гөрләп килгәч яна, якты язлар,
Үтеп киткәч салкын кышларың,
Синең сагыш тулы хәтереңдә
Мин асыл гөл булып шытармын."

*2001-2002 ел.*

## ӨЛКӘН КАЛӘМДӘШ ӘХСӘН БАЯНГА БЕР ЛИРИК БӘЯН



*Әхсән Баянның 75 еллык юбилее безнең олуг бәйрәмебез—«Казан утлары»ның 80 яше тулган һәм киң билгеләнгән елда узуы—бер гыйбрәтле, үзенчәлекле фал, безнеңчә. Очраклы түгелдер ул: шагыйрь озак еллар журналыбыз редакциясендә—әүвәл җаваплы сәркатип, аннан баш мөхәррир урынбасары булып эшләгән каләмдәшебез бит! Һәм аның иҗаты да—һәммәбезнеке кебек!—«Казан утлары» белән аерылгысыз бәйләнгән. Әдәби җәмәгатьчелектә кызыксыну, хәтта бәхәсләр уяткан «Сез аңларсыз мине» поэмасы, «Яшьлегемне эзлим», «Дүрт монолог» кебек повестьлары 60 елларда басылып, Әхсән Баяновны укучыга киң танытса, аннан соңгы еллардагы «Тау ягы повесте», «Төлке тоту кыен түгел», «Аязучан болытлы һава», «Аргы яр», «Агыйделдә ак пароход» һ. б. повестьлары, «Ут һәм Су» романы нәкъ менә безнең журналда басылып, танылу алды—азак китапларына, «Сайланма әсәрләр»енә керде; үзенчәлекле лирик-фәлсәфи прозасы өчен әдип Г. Тукай премиясенә дә лаек булды (1999 елда!). Шулай ук—«Сәяхәтнамә», «Ак чәчәкләр» (Такташка багышланган) поэмалары да журналыбызның калку әсәрләреннән булса, әдипнең шигъри драма үрнәкләре—«Һәйкәл», «Алтын кашбау» һ. б. нәкъ менә «Казан утлары» аша укучыга иреште.*

*Кырык елдан артык вакыт эчендә җитди шигъри бәйләмнәрен, мәкаләләрен, яшь каләмдәшләренә фатиха-кереш сүзләрен дә журналыбызда бастырды ул. Кыскасы, чын-чыннан, «Казан утлары»ның үз әдибе, үз шагыйре!*

*Һәм әдипнең үз иҗаты хакында фикерләр, тәнкыйть, әдәби портретлар, мәкаләләр дә басылды журналыбызда. Сибгат Хәким, Әмирхан Еники язганнар аеруча хәтердә калган. Гариф ага Ахунов мәкаләсе дә. Ә Аяз абыйның безнең журналда дөнья күргән мәкаләсенең исеме дә нәкъ үзенчә усал иде: «Үзең кем, укучы?» Кырык ел буе бер мохиттә кайнап, дус, фикердәш булып яшәгәнгә, җитмәсә әле якташлар да булганга, мин дә Әхсән Баян иҗатына беркайчан да битараф булмадым—шактый санда эрелевраклы язмаларым басыла торды. Өлкән каләмдәш үзе дә яшьрәкләргә бик игътибарлы булды—мөгаен, бу яктан күпләр аңа рәхмәтледер. Мин дә...*

*Башкортстанның Илеш районыннан алар өчәү: мәрхүм Хәсән Сарьян, юбилярыбыз Әхсән ага һәм Роберт Миңнуллин (Дүртенчесе—шагыйрь һәм прозаик, талантлы егет Марат Кәбиров та «Сары йортлар сере» исемле кызыклы повесте белән журналыбызда күренде быел!) ... Үзенчәлекле өч холык, өч стиль, өч дөнья... Өчесе дә якын дус, фикердәш булганга, иҗатларын да бик яхшы беләм дия алам, горурланам да... Якташ булганга түгел, талантлы каләмдәшләрем өчен горурлык бу!*

*Әхсән Баян—өчесе арасында үзгә, аерылып торган холыклы (иҗатында да өслүбе—шуннан!) үз чоры, замандашлары белән туры карап, кискен сөйләшүдән, хәтта бәхәс-көрәшләрдән курыкмаган, дәверенә карата сораулар куеп, катгый җавап көткән, әмма үзе тиз җәрәхәтләнүчән нечкә күңелле, кызу канлы—егерменче гасырның нәкъ менә икенче яртысы формалаштырган әдип. Моңсу, элегик, хәтта әрнүле ноталар өстенлек иткән фәлсәфәле лирика, җете төсләр, каршылыклы уйлар шагыйре. Бик актив, заманча хәрәкәтчән, уйлы-фикерле шәхес яши аның шигъриятендә.*

*Шунсы гаҗәп: бу лирик геройда ниндидер мәңгелек яшьлек, һаман дәвамлы хисләр, кыршылыклы фикерләр ташкыны... Хәтта ниндидер үпкә-зар да бар кебек. Әмма тынычлану, суыну, канәгатьлек юк, һаман эзләнү, ашкыну, ташыну...*

*Һаман яза, күп яза шагыйрь. Житмеш биш яшьлек чал аксакал гел яшь омтылышлы, яучан, даучан шәхес булып күзаллана. Соңгы язганнары—юбилеена тәкъдим иткән шигырьләрендә дә, диюем. Өлкән агайларыбыз арасында үзенчә почеркы белән аерылып, «Бу—мин!» дип кычкырып әйтеп тора кебек...*

*Ун елдан соң да, аннан соң да шулай, үзгәрмичә, яшь кал, «Кальбеңдә ниләр бар, бәян ит», Әхсән ага Баян!*

**Рәдиф ГАТАШ**

# Әхсән Баян

## И, ГОМЕР, ДИП ӨЗЕЛӘ ГӨЛ

### Иртәләр килгән саен

**Һәр көн саен, иртән торгач,**
**Тәрәзәләрдән карыйм.**
**Болытлымы, аязмы дип,**
**Һаваның хәлен барлыйм.**
**Иминме дим торган җирем—**
**Иделем, Казансуым.**
**Чамалыйм җилнең, һаваның**
**Көчен, дымын, басымын.**

**Циклоннар ерак булса да,**
**Күңелем тыныч түгел.**
**Пәйда була туган җирем—**
**Авылым, Агыйделем.**
**Җилләрнең анда исмиме**
**Афәтле, ачылары?**
**Акмыйммы кушылып агу,**
**Сафмы эчкән сулары?..**

**Әй, сез, җирдәш-судашларым,**
**Дусларым, туганнарым,**
**Сезнең шатлык—минем сөенеч,**
**Кайгыгыз—минем кайгым.**
**Туган җирем, торган җирем—**
**Язмышның ике яры.**
**Бер үк елга, бер үк йөрәк**
**Икегә аерыламы?**

Гел саф түгел эчкән сулар,
Гел тыныч тормый һава.
Мәгълүм тарафлардан килеп,
Яман хәбәрләр ява...
Ярлар тигез сакланачак,
Калмасак әгәр каушап.
Аю ашый алмаячак,
Әгәр без аерылмасак.

Кыялар какшамаячак,
Әгәр без каушамасак.
Иделләр имин агачак,
Әгәр без аерылмасак.

*

Гомерләр үттеләр, аналар көттеләр
Сугыштан кайтмаган улларын.
Сагышка манчылды сәгате, минуты
Имин дип саналган елларның.

Сугышлар юк сыман, офыкта күк томан
Һәм озын әле дә минутлар.
Гомерләр үтәләр, әбиләр көтәләр,
Исән-сау кайтсын, дип оныклар.

Балалар киттеме азатлык яуларга?
Кирәкме хакимлек аларга?
Кемгә дан, мал килә сугыштан?—
Үзләре түкми яшь, коймый кан...

Шул хакта уем да, хисем дә,
Шул теләк өнемдә, төшемдә:
Әниләр, әбиләр тын йоклар,
Сау кайтса балалар, оныклар.

## Мизгел

Өлгергән алма рәвешле
Эленеп тора мизгел.
«Өзелмә!»—дип иелә гөл.
«Өзел!»—диеп исә җил.

Күз иярми, кай арада
Өзелеп төшә алма.
«И гомер!»—дип бөгелә гөл.
Тик исүен белә җил.

*

Август мине уйландыра,
Үзе—җәй ул, үзе—көз.
Бүген көлгән, сөйгән була,
Иртәгәсе... билгесез.

Бүтән айлар—туры сүзле,
Гадәтләре—хәйләсез.
Җәйләре—җәй, кышлары—кыш,
Боекмыйм, булса ямьсез.

Август—матур, август—юмарт,
Гөрләп бара бар эше.
Җилләр белән килә ләкин
Сагышларның сарысы.

Бер сәбәпсез борчылулар,
Сәбәпсез кайгырулар,
Шатланмый яуган яңгырлар,
Көен эзләгән моңнар...

Мин белмәгән көйсез көннәр
Сизелмәсен дип ялгыш,
Күз яшергән гөл төсендә
Көйри билгесез сагыш.

Август мине моңландыра...
Түгел, ахры, җил белән—
Сәбәпсез борчу, кайгылар
Килә... күңел төбеннән.

## Исемсез кошлар

Җылы илләргә китеп барышлый,
Туктала кошлар безнең якларда.
Кунак кошларга эндәшәм сорап:
«Сезне кем диеп, ничек атарга?»

Канатларыгыз—яшел, ал, сары...
Мөмкиндер әйтү: «Оҗмах кошлары!»
Исләр китмәле гүзәллекләрне
Үз җирегездә күрүче бармы?

Танылмаганнар юклык иленә
Оча да китә, кайтмаска бүтән.
Иясез калган риясыз эшләр,
Исемсез хисләр... алар юк күптән.

Төшендем моны соңгарып бик тә:
Билгеле булсын дәрәҗәң, затың.
Күрә белмәсә үз илең, халкың,
Чит җирләр ничек бәяли алсын?

Кунак кошларым, тыйнак дусларым,
Танышып шундый киңәштә калыйк:
Җылы яклардан кайтып барышлый,
Сезгә исемләп эндәшә алыйк.

*

Гыйнвар суыгында агач чатный,
Очмый тора кошлар һавада.
Дөнья туңып талган тын арада
Бәллүр чәчәк ата абага.

Тәрәздәге чәчәк бәйләмнәре
Күңелләрне язга чакыра.
Ышанасы килми һич салкынга,
Гүя яшьлек—алда, якында.

Гәрчә Гыйнвар көнне калтырата,
Зәһәрлеген гәрчә арттыра,
Юккамы тик көннәр озыная,
Юккамыни көннәр яктыра?

Ышанасы килә: абагалар
Чәчәк аткан көннәр килерләр!
Озыная барган кебек көннәр,
Озыная барыр гомерләр...

## Кышкы яңгыр

Тышта—Гыйнвар... Тынгы бирми
Тамчылар, шыбырдашып.
Адаштыргыч ак бураннар
Калды кайда адашып?

Туды, ахры, җылы уйлар
Гыйнвар картның җанында.
Бер яшьнәп, күкрәп аласы
Килде бугай аның да.

Июль белән очрашырга
Хыяллана торгандыр.
Юккамыни кар урнына
Төн буе койды яңгыр?!

Төн буе яшь койды Гыйнвар
Күкри белмәс тынлыкта.
Иядәшүләр кыен шул
Чал чәчле олылыкка...

Яшьни алмау рәнҗешеннән
Кузгатыр ул өермә.
Яшь Җәй әйтер: «Әй, өермә,
Син мине күрә күрмә!»

*

Ак болытлар йөзгән су буенда
Күрдем аны, суга керешли.
Су кызыдыр... Йә булмаса, күктән
Иңгән кыз булырга тиештер...

Әй, чибәр кыз, сине күпме гасыр
Иҗат итте икән табигать?
Буын саен яңа рәвеш эзләп,
Үзгәрткәндер бизәп, кадерләп.

Һәр буынга төшкән яңа бизәк
Табигатьнең бөек серләдер.
Осталыкның инде син чигедер,
Гүзәллекнең соңгы сүзедер.

Табигатьтә ләкин бөтен нәрсә
Үзгәрергә дучар лабаса.
Ничек аны кичерербез, шушы
Әсәрне дә саклый алмаса?..

*Хисам Камалга*

Сабантуйга бергә барган идек,
Хәзер менә кайтып киләбез.
Булды җиңү, булды җиңелүләр,
Сынатмадык бугай иллә без.

Сабантуйлар узса, бар ярминкә,
Юл тотарбыз шунда иртәгә.
Язсын анда—алдау-алданусыз—
Тагын бергә бәйрәм итәргә.

## Хакимлек тәме

Хакимлек тәме бар, диләр.
Белмәгәч, нәрсә әйтим?
Хаким була язганда да,
Булдым мин һаман... ятим.

Гадилекнең галилеген
Шәйли язган икәнмен:
Риясызлар арасында
Тойдым яшәүнең тәмен.

Әгәр мине көннәр алдаса,
Кичләремдә өмет каралса,
Ал шәфәкъләр яна алмашка:
«Бу дөньяда әле эшең бар,
Сагына белә торган кешең бар».

Аера таулар, еллар дисеннәр,
Таралыплар китсен зиһеннәр.
Таулар, еллар аша җил сөйләр:
«Синең әле җирдә эшең бар,
Сине сагынучы кешең бар».

Онтылгандай хисләр, исемнәр,
Шәфәкъ сүнсен, утлар сүнсеннәр.
Таныш йолдыз таңда сер сөйләр:
«Синең әле җирдә эшең бар,
Сагындыра алган кешең бар».

Әгәр көннәр, кичләр алдаса,
Төнnәремдә күкләр каралса,
Таныш йолдыз яна таңгача.
Мин кабатлыйм: «Әле эшем бар,
Төн йокламый уйлар кешем бар».

*2000–2002*



**Мөсәгыйт Хәбибуллин**

## ЙӨРӘККӘ ТАМГАН ЯЗГЫ ТАМЧЫЛАР

хикәя

Сугыштан соңгы зарыгып көтеп алган беренче яз килде. Кичтән һавада дымсулык артты, энгер инүгә, күк йөзен куе болыт томалады. Ишегалдында йөргән Фатыймага күрше карчыгы әйтә салды:

—Язгы ләйсән янгырына бу, килен,—диде.

Күрше карчыгының колак очына эләгеп калган бу сүзе, иртән күзен ачкач, Фатыйманың янә хәтеренә килде. Чынлап та өй кыегыннан тып-тын тамчы тама иде. Бераздан тәрәзә башына кунарга кергән чыпчык кыштырдарга тотынды. «Нигә инде хет сина йокламаска, ни кайгын бар?—дип уйлады Фатыйма. Аннары:—Нигә алай дим әле мин аңа? Бәлкем, анын да яз килүен сизүедер, саласы сипкелле күкәйләрен, борын төртеп чыгачак сары томшыклы кошчыкларын күз алдына китерәдер. Ихтимал, әле күрше өйнең кыегында гомер иткән күксел-кара бүрекле чыпчыкның былтырларны нәкъ шул вакыт житкәч үзе тирәсендә чыркыл-тый-чыркылтый уралуын исенә төшерәдер. Чыпчыклар яз кавышалар, көз житеп, балаларын очыруга, янадан төрлесе төрле якка таралалар, ди бит».

Фатыйма, гәүдәсен турайтып, киерелеп-сузылып алды, теләсә-теләмәсә дә:

—Их-ма!—дип куйды.

Мәгънәсе Фатыймага билгеле дә, билгеле дә булмаган әлеге хикмәтле сүзне Харис бигрәк тә иртән уянгач һәм бер тын дөнья хәлләрен сөйләшеп яткач әйтер иде... Шулай дип әйтер иде дә, төн үтеп сүрелеп житмәгән Фатыйманың кайнар битләреннән үбеп алыр иде... Алар нибарысы елга якын бергә торып калдылар. Харис кебек ирләр сугыш башланыр көннәрдә печән чабарга йөрделәр, хатыннар печәнне чүмәләгә куйдылар. Әле булса күз алдында Фатыйманың, сугыш хәбәре килүгә, кырыклап ир-егет, печән өстеннән диярлек, колхозның «полуторка»сына утырып Бөгелмәгә китте. Хатыннар ирләрен хәтта станцага хәтле булса да озата бара алмадылар. Ирләрнең күпләре шул китүдән әйләнеп кайтмады. Ике атна үткәч, Харисның: «Смоленск шәһәре тирәсендә сугышабыз»,—дигән

беренче хаты килде. Ай үтүгә килеп төшкән икенче хат Харис кулы белән язылмаган иде...

Фатыйма ул көнне кырга эшкә килгәч, үзе сөргән кара җир өстенә ятып, үксеп-үрсәләнеп елады. Сабанчы хатыннар аны юатмадылар, сугышка киткән ир турында: «Эзсез югалды» дигән хәбәр алу җинел түгел икәнне беләләр иде. Сабанга җиккән атлар гына, гаҗәпләнгәндәй, пошкырып, башларын чайкап тордылар.

Шул хәлдән соң өч ел гомер узды, дүртенче яз, җиңү язы килде. Сугыштан берән-сәрән авылга ирләр кайта башлады. Сугышта югалу хәбәреннән гайре Харис турында һичнинди хәбәр алмаган Фатыйманың күнеле, язгы ташкынга эләккән йомычкадай, бәргәләнде дә тулганды. Ахыр, өметен өзмәскә теләп: «Азмы анын кебек хат-хәбәрсез сугышта югалучылар һәм көтмәгәндә исән-сау әйләнеп кайтып төшүчеләр»,—дип үз-үзен юатты. Ә үзе һаман көтте, сабыр итте. Харисы салып калдырган өйдә берьялгызы яшәде. Кайчагында ана өерләре белән солдаткалар килеп керде, җыелышып моңсу җырлар җырладылар, аннары ялгызлыкларыннан зарлана-зарлана, фашистларны, бәдбәхет Гитлерны каргадылар.

Беренче тынычлык язынын чалт аяз көнендәге кояш мул итеп җылы нурларын сипте. Нурлы, якты иде дөнья. Әйтерсен илдә фаҗига да булмаган иде. Фатыйма, тәрәзә пәрдәсен күтәреп, урам якка күз салган иде—йөрәге җу итеп китте: урам тутырып әсир немецларны куалар иде. Аларны әйдәүче яшь солдат әсирләргә кычкыра, мәгәр немецлар алҗыганнар, солдатнын кычкыруына игътибар итмәстән, бер көйгә атлый бирәләр. Әсирләр артыннан, адым да калмый диярлек, яланаяк авыл малайлары ияргән, кулларын болгый-болгый нидер сөйләнәләр, кычкырышалар. Ә немецларны озатучы солдат шау-гөр килеп торган балалар төркемен куа, ләкин малайлар бераз гына тукталып калалар да янә әсирләр артына тагылалар.

Фатыйманың тере немец солдатларын әле беренче күрүе иде. Немецлар барысы да сары чырайлылар, ямьсезләр кебек күренде ана. Кая куалар икән үзләрен?

Ул арада, сулышы кабып, каршы капка Камилә килеп керде.

—Ахирәткәем, Фатыйма, күрдеңме, әсир нимечләрне куалар. Бездә эшләячәкләр, ди. Актауга әсфәлт юллар салдырачаклар, ди, үзләреннән. Барак житештергәнче фатирга таратасылар, ди.

—Шул гына житмәгән иде! Өемә нимеч кертәм ди! Бәлкем ул минем Харисымны үтергән нимечтер. Мин ул кабахәтне үз кулларым белән буып үтерәчәкмен...

Фатыйма, бармакларын тырпайтып, Камиләгә таба кузгалды.

—Китче, тиле, нишләвен бу? Ниемә шулай күзләрең купты? Нимечме әллә мин сина?!

Камилә чыгып киткәч, Фатыйма морҗа буендагы эскәмиягә утырды да, хәлсезләнеп китүен тоеп, күзләрен йомды.

Шул чакта тәрәзәдән бригадир:

—Фатыйма, бүген фермага салам ташырга барырсын!—дип кычкырып, эшкә чакырды.

Фатыйма юынды-киенде дә, беренче эше итеп, чиләк-көянтәләрен алып, суга китте. Бизәкле көянтә-чиләкләрне ана Хариска чыкканда әтисе алып биргән иде. Харис чишмә суын ярата иде, шуны белгәнгә, Фатыйма, ераграк булса да, суга чишмәгә йөрде. Чишмә тау астыннан тибеп чыга, кояш чыгышына каршы торгангамы, аны Таң чишмәсе дип йөртәләр. Таң чишмәсенен суында чәй әйбәт чыга, хуш исле була. Харис яратыр иде Таң чишмәсе суыннан кайнатылган куе-кара чәйне баллап эчәргә...

Фатыйма Әхнәфләр тыкрыгыннан борылды да инеш буена төште, кечкенә күперчекне чыгып, тау итәгенә таба юнәлде. Чишмә өстендә сыек томан тулгана, томан эчендә әкият кызлары биидер сыман. Юк, алар

салкын чишмә суы белән алсу битләрен юалар, алай да түгел, көянтәчиләкләр белән чәчләрен юарга чишмә суына төшкәннәр, имеш. Таң чишмәсе суы белән чәчләрен юса, Фатыйманың да ефәк шикелле була торган иде чәчләре. Харис Фатыйманың шул чишмә суы белән юган чәчләренә борынын төртер иде дә:

—Тукта, зинһар, китми тор. Бу чәчтә, билләһи дип әйтәм, мең төрле хуш ис бар,—ди торган иде, җүләркәй...

Чишмәгә якыная төшкәч, абайлады Фатыйма: Таң чишмәсе янында әкият кызлары түгел, ә бая урамнан куылып барган әсирләр утырышканнар, ят телдә гөжләшәләр, яшел кәтилүкләренә су алганнар да тәмләп чишмә суы эчәләр, арада берәүсе чишмә янындагы зур таш өстенә менеп урнашкан да тырышып-тырышып авыз гармуны уйный.

Инбашы аша көянтә салган, бизәкле туй чиләкләрен кулына тоткан Фатыйма килеп чыгуга, әсирләрнең барчасы да шым булдылар, күктән төшкән алиһә күргәндәй, бөтенесе дә аңа текәлеп катып калдылар. Фатыйманың гүя аяклары җиргә ябышты. «Кая китте икән теге яшь солдат? Нигә болар үзләре генә, Таң чишмәсе янында, Актау халкы өчен изге урынны пычратып?!»

Фатыйманың миеннән мизгел эчендә әнә шундый уйлар узды. Әсир немецлар һәммәсе диярлек ак кашлылар, су күзлеләр, ач яңаклылар иде. Күрче, нәкъ шундые Фатыймага таба атлый түгелме?!

—Фройлейн...

Фатыйма чак кына кычкырып җибәрмәде, шул мәлдә кемдер:

—Сидеть!—дип боерды.

Фатыйма ялт итеп тавыш килгән якка борылып карады һәм җилкәсе аша автомат аскан, таш өстендә утырган солдатны күреп, тынычлана калды. Солдат уңып беткән гимнастеркасының якаларын ычкындырып җибәргән, бармак арасында «кәҗә мөгезе» көйри.

—Йә ходаем, куркуларым ләгънәттән.

—Курыкма, апа. Ал суыңны. Әй, Ганс, булыш әле чибәркәйгә су алырга!—дип боерды солдат әсиргә, Фатыймага таба ым кагып.

Ганс дигәне авыз гармуны уйнаучы булды, күрәсең. Үз исемен ишетүгә, авыз гармунын кесәсенә салып, Фатыймага каршы кузгалды.

—Бирмим. Кит, ягылма, фашист!

Фатыйма шундый иттереп карады әсиргә, тегесе әпен-төпен артка чикте. Фатыйма, башын чөя төшеп, чишмә янына килде, чиләкләрен мөлдерәмә тутырып су алды да чиратлап көянтәсенә элде һәм, авызларын ачып торган немецларга күтәрелеп тә карамыйча, жай гына, иплe генә адымнар белән кузгалып китте. Чиләктә мөлдерәп торган суның тамчысы да түгелмәде, ә Фатыйманың зифа сыны, авыр эш эшләп күнеккән гәүдәсе чиләкләрне сизмәде дә, тик юанрак балтырларының елтырап китүе генә, янбашларының уйнаклап баруы гына аның чишмә янынна китүен раслый иде. Әсир немецның авыз гармунында ят та һәм гаҗәеп төстә таныш та көй уйнавын ишетеп, Фатыйма үзе дә сизмәстән туктап калды, уйнаучыга борылып карады, шул чагында чиләге чайпалып куйды, зөбәрҗәттәй елтырап торган су тамчылары итәгенә тамды. Ул атлаган җайга китереп, аңа су алып бирергә теләгән немец авыз гармунында Штраус вальсын өздерә иде. Фатыйма, яман эштә тотылган кеше шикелле, йөзгә балкып, кайту ягына борылды.

Икенче көнне аңа авыл Советы председателе килде дә:

—Бараклар салганчы, ике әсир синдә торыр,—диде.

—Кертмим. Шул гына житмәгән тагын,—дип каршы килде Фатыйма.

—Карарны үтәми хәлең юк, алар безгә юллар салачаклар,—дип, китә башлады авыл Советы председателе.—Бер сиңа гына фатир кертмибез...

—Барыбер кертмим,—дип сүзен сүз итәргә маташты Фатыйма.

Кичке якта аның капка төбенә яшел шинель кигән ике әсир килеп туктады. Кече капканы төртеп карадылар, ачылмады: Фатыйма шудыргычны чөйләп үк куйган иде. Ят телдә нидер кычкырдылар, үтенделәр, әмма

Фатыйма капканы ачмады. «Күтәрсез-күтәрсез дә китәрсез әле»,—дип үртәлде. Ләкин әсирләрнең барыр җирләре юк иде, күрәсең, бөкшәйгән килеш капка төбендә тора бирделәр.

Шулай бер сәгатьләр чамасы вакыт узды, Фатыйма әсирләрне онытырга теләде, бәйләм бәйләп карады, чынын гына әйткәндә, йөрәгендә әсирләргә карата мыскал да кызгану хисе юк иде, берәүсе вакыт-вакыт кулындагы кәгазь кисәген капка аша күтәреп, тәрәзә ягына күрсәтеп, болгап ала.

Энгер инде, сибәләп янгыр яварга тотынды. Әсирләр һаман китмәделәр. Фатыйманың бу хәлгә ачуы килә башлады. «Ни хаклары бар ялгыз хатын янына әсирләр кертергә. Үтереп китсәләр? Фашист фашист инде».

Карангы төште. Шул вакыт берәү кече капканы шакыды, ул шундый иттереп шакыды ки, Фатыйма, инбашына шәлен салырга да онытып, ишегалдына йөгереп чыкты.

—Апа җаным, мин бу, ач әле капкаңны. Керт инде шуларны, күшегеп беткәннәр бит.—Курыксаң, үзем дә кунармын...—Капканы шакучы көндез күргән яшь солдатны шундук таныды Фатыйма.

—Үзең кунсаң гына.—Фатыйма капканың шудыргычын тартты.—Әйтәм бит, куркам мин алардан.

—Иң юашларын сезгә китердем. Әнә тегесе, озыны—антифашист. Исеме—Ганс, кечкенә буйлысының исеме—Вольф.

—Барыбер фашистлар,—диде Фатыйма.

—Йә инде, апа җаным, чын фашистларны без фатирга кертмибез, иске мәктәпкә урнаштырдык. Болар безнекеләр дим ич. Ганс,—дип немецка дәште солдат.—Уйна әле гармуныңны.

—Ни-ихт, замерзал Ганс,—диде немец. Ул күшегеп беткән кулларын солдатка күрсәтте.

—Ярый, бар кер. Җылынгач уйнарсың,—диде ана солдат.

Фатыйма әсирләргә алгы якка урын җәйде, баш асларына мендәр ташлыйм дигән иде, тукталып калды, мич арасыннан иске пальтосын чыгарып салды. Немецлар дәшми-тынмый гына чишенделәр һәм, өсләренә яшькелт шинельләрен ябынып, йокларга яттылар.

—Син алардан курыкма, тузаннары коелган инде аларның. Аннары болары безнекеләр. Гансның әтисен төрмәдә черетеп үтерә Гитлер. Коммунист булганы өчен.

—Нигә соң монысы безгә каршы сугышкан?

—Сугышмаган ул, музыкант, торба өреп йөргән.

—Әтисе коммунист булгач, Гитлер армиясендә музыкант булырга да хакы юк аның.

—Яшисе килгәндер...

—Яшисе...—дип кабатлады Фатыйма.—Түземлеләр үзләре. Китмиләр дә китмиләр.

—Приказ. Китәләр икән—баш долой,—диде солдат.—Карале, апа җаным, мин башкаларның ничек урнашуларын карап чыгыйм инде. Бәлкем, синең кебек кертмәүчеләр бардыр?

—Бик дөрес эшлиләр, тапкансың тансык кунак. Бел аны, энекәш, үзең кайтмыйсың икән, кисәү таягы белән куам да чыгарам үзләрен.

—Әйтәм бит, юашлар алар, әүлиялар,—дип көлемсерәде солдат.

—Әүлиямы, әүлия түгелме, анысын син дә, мин дә белмибез. Кайтмыйсың икән, нимечләрең тышта куначак. Ипи тотып ант итәм менә.

—Йә хода, булса булыр икән, кайтам бит инде, тикшереп кенә чыгам үзләрен.

Шулай диде дә солдат, чыгып китте, Фатыйма түр якның ишеген барып япты, келәсен төшерде, бераздан, ишек тоткасына аркылы китереп, кисәү агачы тыгып куйды. Шуннан соң гына тынычланып, урынына барып ятты. Сөян бүрәнәсеннән буралган стена аша агач башларын шаулатып җил йөгергәне ишетелә, тәрәзә пыяласына кыеклап язгы ләйсән янгыр ява, урамны уятып, майламаган тәгәрмәчен шыгырдата-шыгырдата атлы

уза, тәгәрмәч шыгырдавы күнелгә әллә ниткән шом сала, болай да курка-курка яткан Фатыйманың йөрәген ялкынсындыра. Вакыт-вакыт Фатыймага өй эчендә кемдер йөри кебек тоела башлый, гүя кеше әле стенага килеп сөяләә, әле ишек янына барып баса, әле мыштым гына бусагага утыра. Аның һәр аяк тавышы йөрәккә үтеп керә, арка буйлап салкын боз булып ага. «Шушындый чакта күрше Нәсимә әби дә килеп керми ичмасам. Кая олакты соң бу солдат? Нигә һич югы автоматын биреп калдырмады?»—дип уйланып ятты Фатыйма.

Алгы якта кайсысыдыр йөткереп куйды, Фатыйма шым булды. Немецлар үзара акрын гына сөйләшә башладылар. Бераздан алар да тынып калдылар, Фатыйма үзенең йөрәк тибешен колак янында ук ишетә иде. «Их, бу солдатны. Исемен дә сорамадым ичмасам, рәхәтләнеп исемен әйтеп тә сүгә алмыйм мөртәтне. Хәзер кайтам, дигән булды да бит... Һич югы автоматын калдырсын иде,—дип янә уйланып алды Фатыйма. Ләкин икенче мәлдә инде бу уеннан да курка калды.—Кереп кулыннан суырып алырлар иде дә китәрләр иде бөтен Актау халкын кырырга. Аз кырганнардыр безнекеләрне, эттән яралган нәстәләр. Солдатын да әйтер идем, әллә антифашист дигән була. Алай булгач, нигә әсир булып йөриләр?! Мылтык бирсәләр, ике дә уйлап тормас идем, кырыр идем үзләрен. Харисым өчен, Камиләнен Идрисе өчен...»

Алай да ару үзенекен итә икән, Фатыйма тәрәзәгә кыеклап сибәләгән янгыр тавышына, агач башлары шаулавына йокымсырап китте.

—Апа дим, апа! Ач! Мин бу—солдат!

Фатыйма әүвәл һични аңламый ярсынып сикереп торды, йөрәгә ашкынып тибүен тоюдан гаҗиз калып, тавышка колак салды. Солдат икән. Алай да, тәрәзә пәрдәсен сыдырып, ишегалдына күз салды. Янә солдат икәнәнә инангач кына, иңенә шәлен салып, ишек ачарга чыкты.

—Кайттым. Әллә инде ятып та өлгердегез?

—Кер әйдә, түр якка ятарсың. Мич кырындагы сандык өстенә урын җәйдем үзенә.

Солдат ана ияреп түр якка керде, плащын чөйгә элде, сүзсез генә итекләрен сала башлады. Фатыйма солдатның мыш-мыш килеп чишелүен сагаеп тынлап торды.

—Авырмы, солдат, хезмәт итүләре?

Солдат дәшми, әллә аруы житкән, әллә Фатыймага ачуы чыккан. Тик, ятып, бераз торгач кына:

—Тыныч йокы, апа,—диде.

Аның шулай диюенә Фатыйма бөтенләй тынычланып китте, күзләрен йомды. Сонгы мәлдә ул тәрәзә кыегындагы чыпчыкның кыштырдавын ишетеп калды.

Немецлар бик иртә уяндылар, акрын гына сөйләшәләр, шыбыр-шыбыр яуган янгырга сукрануларымы... Фатыйма, уянса да, урыннан кузгалмый ятты. Агачлар шаулый, җил тагы да көчәйгән булса кирәк, янгыр кайта-килә тәрәзәне чыбыркылый. Тәүлеккә якын ява бит, юл өзелгәндер. Бригадир Чулак Галиәкбәр кушуынча, кичәгенәк саламга ике ураганнар иде, бүген, мөгаен, барып та булмастыр.

Фатыйма ашыкмый гына торды, киенде, солдатның өстеннән сыдырылып төшкән юрганын рәтләп япты. Солдат изрәп йоклый, кымшанып та карамады, борын астындагы аксыл-сары мыегы, өлгергән тарыдай, бөтерелеп тора. «Сабый гына, ә үзе бер өер нимечне куып йөртә»,—дип көлемсерәп уйлап куйды Фатыйма, шунда солдатның кылган чәченә кагыласы, күпереп торган яңагыннан сөясе килеп китте. Шул ният белән ул кулын да суза башлаган иде, мәгәр шундук тартып алды. Акрын гына ишек ачыла башлады.

—Комрад.

—Нәрсә кирәк сина?

Ишек ярыгында немецның су сыман күзләре елтырады.

—Будить... Комрад.

—Тор әле, солдат, әнә сина нимечең дәшә,—диде Фатыйма, жинелчә генә солдатның жилкәсенә кагылды.—Нимечләрең уянды дим, нидер сорыйлар, уян инде!

Солдат күзләрен ачты, ишектәге әсирнең су күзләренә төбәлде.

—Йөреп керергә исәпләре, чыгар үзләрен,—диде солдат һәм икенче ягына әйләнеп ятты.

Фатыйма немецларга тышкы ишекне ачып бирде. Үзе алгы өйгә чыгып, ике толымга чәчен тарап үрде, кулын-битен юды. Аннары баздан ярты чиләк бәрәңге алып куйды. Бераздан, мичтә ут дөрләп янып киткәч, немецлар керделәр, утка каршы утырып, кулларын жылыта башладылар. Алар сөйләшмәделәр, Фатыйма мич янына килгән саен читкә тайпылдылар, үзара алар күзгә-күз карап кына аңлаштылар. Ганс дигәне, Фатыйма күрмәгәндә генә, аңа күзен алмый карады, хатын аның күз карашын үзендә тойса да, немецны гел күрмәгәнгә салышты. Мич каршында утыра-утыра битләре алсуланды, әсирләргә дә кеше төсе керде.

Мичтәге бәрәңге кайный башлады, чуен читеннән күбекләнеп су ташып чыкты. Моны күреп, немецлар икесе берьюлы:

—Картоф!—диештеләр.

—Анысы бар, менә әпекәй генә юграк,—диде немецларның ни сукалауларын абайлап алган Фатыйма. Хатын самовар куйды, өстәл хәстәрләргә кереште.

Солдат уянды, аякларын сузыбрак жибәрде, күзләрен ачты.

—Карале, солдат, мин бу нимечләреңне ашатырга да тиешме?

—Һә,—диде солдат.

—Аруың житкән икән әсирләр көтүен кәтә-кәтә. Тор инде,—диде Фатыйма.—Янбашыңа тоз төшәр.

—Яңгыр явамы?

—Ява. Төн буена яуды.

—Димәк, беркая да бармыйбыз. Ял!

—Тор әйдә, бәрәңге пешә хәзер, ашап алырбыз. Башка нәрсәм юк, чәй куйдым әнә.

—Рәхмәт, Фатыйма апа. Безнең паек кисәге бар. Әсирләргә әпекәй бирәбез. Ә бәрәңгең жәл булмаса, әйдә, ашат үзләренә. Әнә тегесенә, озын бармаклысына күбрәк бирсәң дә жәл түгел. Әйтәм бит, антифашист улы, музыкант. Искитмәле итеп уйный. Авыз гармуның уйнап жибәрсә, жаннарны актара, сары шайтан. «Интернационал»ны белә, «Катюша»ны сыздырып жибәрсәме!..

—Каян белдең минем исемне? Кем әйтте?

—Исполкомда әйттеләр. Мин үзем Дима. Коми егете. Күрәсең, татарча да сукалыйм. Бу вакытта кыш әле бездә, шулай да кояш карый инде, түбәләрдән тамчылар тамадыр...

—Әйдә тор, юын да ашап алырбыз.

Фатыйма мичтән бәрәңге алды, коштабакка салып, өстәлгә куйды. Әсир немецларга да салып бирде. Савыт тулы бәрәңге кулга эләгүгә, тегеләр алгы якка чыгып киттеләр. Ул арада Дима да, юынып, өстәл янына килеп утырды.

—Минем дә ипи-май бар, кичкә китерермен.

—Алдыңа куйганны һәйбәтләп кенә аша әле. Синдәйләргә ризык жәлме, солдаткаем. Ни сөйләп утырган буласың тагын. Ят кешеме әллә син. Солдат ул бар кешегә дә кардәш кеше.

—Рәхмәт, Фатыйма апа. Бәрәңгең тәмле, күптән ашаган юк иде инде. Сыерың бармы соң?

—Юк, Дима.

—Ирең ни яза?

—Смоленскидан килде соңгы хаты. Хәбәрсез югалган...

—Анысы шәп түгел икән. Әйе,—диде Дима, олыларча фикер йөртеп,—бу фашистларны жинүләре жиңел булмады.

—Синең үзеңә ничә яшь соң?

—Унсигез. Карт солдат инде мин. Минем яшьтәшләрнең сугышта катнашканнары булды. Мине әнә шул хәсрәтләргә бәйләделәр дә... Бер авыз сүз русча белмиләр...

—Ә син үзең немецчә беләсенме соң?

—Нигә кирәк ул миңа? Мин аларда әсир түгел, алар миндә әсир. Өйрәнсеннәр. Җиңүчеләрне хөкем итмиләр. Хәер, музыканты бераз сукалый сукалавын.

—Кайчанга хәтле тотарга исәбең миндә боларны?

—Бараклары салынып бетү белән, алырбыз.

—Күрәселәрем бар икән әле. Антифашист булсалар да, мин барыбер куркам алардан, солдат.

—Курыкма. Фатир тоткан өчен акча түләрләр үзенә, ике йөз грамм ипи бирерләр.

—Тамагыма тыгылмасмы соң ул ике йөз грамм әпәй? Әпәең дә кирәкми, алып кит немечләреңне!

—Мин урнаштырмадым аларны, исполкомыгыз. Сез Совет властен таныйсызмы, юкмы?

—Йа ходаем, авызыңнан җил алсын.

—Ну вот, димәк, бараклары салынганчы яшиләр булып чыга.

—Солдат кына димәссен үзеңне.

—Генерал буласы кеше мин, апакаем. Мөнә ишетерсең әле Димка Сорокин дигән генералның батырлыкларын.

—Әй ходаем, сибә борчакны бертөрле итеп бирәүләр. Җитеп тормасмы, әйдә чәеңне эч тә... Әнә шикәрен дә сал, тартынма...

Солдат чыгып китүгә, алгы яктагы немецлар буш савытларын керттеләр, икесе беравыздан рәхмәт әйттеләр. Алар чыгуга, ишектән Камилә килеп керде.

—Ахирәт, Фатыйма, сиңа да икәүне керттеләрмени? Миндә дә икәүләр. Сөяк тә тире бичараларда. Карап-карап тордым да бәрәңге пешереп бирдем әле үзләренә. Берсе, дүрт балам бар, ди. Дүрт бармагын тырпайтып күрсәтә, малакаем. Икенчесенең авызында сөте кипмәгән. Иртән торды да лышык-лышык жылый башлады. Ничә яшь соң үзенә, дип сорыйм. Унҗиде дип язып бирде. Маңка көенә сугышып йөргән бит, эт җан.

Алгы якта немец авыз гармунын уйнап җибәрде. Ят булса да моңсу көй иде.

—Минекеләр юашлар, авыз ачып сүз әйткәннәре булмады.

—Савыт белән бәрәңге биргәндә, кулым үбәргә үрелде әнә теге гармун уйнаганы, беләсең килсә. Чак кына авызына сугып җибәрмәдем.

—Куй инде. Саламга барабызмы соң?

—Һай алла, көне көн булса икән. Димка солдат әйтә, мондыйда әсирләрне дә чыгармыйбыз, дигән була.

—Алар чыкмасалар да, безгә чыкмыйча ярамас, Фатыйма,—диде Камилә кисәк житдиләнеп.—Көнне төнгә ялгый-ялгый эшләгәнгә җиндек без аларны, ахирәткаем, беләсең килсә.

Фатыйма анын сүзләрен куәтләп, ияк кагып торды. Солдаткалар арасында Камилә агитатор кебегрәк кеше иде, җыелышларда актив катнаша, ял сәгатьләрендә кычкырып газеталар укый, ул бар нәрсәдән дә хәбәрдар иде.

—Әйдә алайсам,—дип, күтәрелде Фатыйма һәм киенә дә башлады.

Ул арада Димка солдат кайтып керде.

—Әллә эшкәме? Шундый көндәме? Өстән янгыр явып торгандамы?

—Без тылда көн-төн эшләгәнгә җиндегез бу немечне, туганкаем,—диде аңа чыга-чыгышлый Фатыйма.

Солдат ни әйтергә белми авызын ачты да калды.

Урамга чыккач, Камилә:

—Ә синен ул музыкант әсирең бераз кешегә охшаган, нур кисәге бар сыман йөзендә,—диде.

—Сөйлә тагын.

—Ай ахирәткәем, әсир кеше—кол кеше, бәйле эткә тиң кеше, бирәсе җәзасын биргәннәрдер инде үзләренә, сөйләмә тузга язмаганны. Ир-атны сиңа гелән сугышыр өчен генә туган дип беләсеңме? Беләсең килсә, табигать аларны безне сөяр өчен яраткан, мал табар өчен... Ә син бик алай һаваланма, егерме биш яшьлек хатынга кемнең күзе төшмәс. Карасын, күзенең агы ларып чыкканчы карасын. Гомер бакыена йөрәге янып йөрсен онытa алмыйча, җаны көеп.

—Алла диген, малакаем, әйтмә алай, Камилә. Идрисен рәнҗер.

—Рәнҗемәс, Фатыймакаем. Кичерер. Без алар эшләгәнне барысын да эшләп карадык, барысын да күрдек. Менә ничә көн инде сул як җилкәм сызлый, сәнәк тота алмый башладым. Әллә Нәсимә әбигә кереп төн якка тигәнәк яфрагы яптырасы инде? Теге вакытта май сөртеп шуны яптыргач, гелән җиңеләеп киткән иде.

Көньяк-көнчыгышта күк йөзе ачылды, дөньяга мул булып яктылык тула башлады. Хатыннар колхоз утарына килеп керүгә, бригадир:

—Катыннар, Фатыйма, Камилә, бүген саламга барып булмас, абзардан тирес чыгарырбыз,—диде.

Кичке якта эштән кайткач, Фатыйма яңгырда чыланган сырмасын мич башына җәеп салды, шәльяулыгын мич каршындагы киштәгә элде, аннары иске пинҗәген киде дә мунчага су ташыды, утын кертеп, мичкә ут төртеп кайтты. Мунча узгач, Фатыйма Камиләгә керде, ахирәтен мунчага дәште. Ул да түгел, тышта эңгер инде. Ябалдашларын мунча түбәсенә салып үскән талның күләгәсе өй тәрәзәсенә хәтле сугылды. Фатыйма бәрәңге әрчеде, аш салды да тәрәзә янына килеп утырды. Уйга чумды. Күзе карт өянке күләгәсенә төште, шул күләгә аны хатирәләр дулкынына алып кереп китте. Шушы йортка төшкәч, атна үтүгә, ул беренче тапкыр мунчаны үзе ягарга килде. Мунчага сөялеп диярлек үскән карт өянкене күргәч, Фатыйма шаклар каткан иде. Өянке шундый карт, шундый карт иде ки, көнчыгыш ягындагы ботакларының күбесе корыган, кәүсәсе киртләч-киртләч килеп кантарланып беткән, бил тирәсенәрәк уралган тимер чыбык тәнен ертып кергән, шул төштә өянкенең кәүсәсе буынланып тора. Мунчаны Харисның әтисе салган, мунча янында үскән яшь талны әтисе кисеп ташларга иткән дә, әнисе ирек бирмәгән, үссен безнең бәхеткә дигән... Өянке янына килдеме Фатыйма, әле булса таң кала, карт тал аңа кем беләндер сөйләшә, кемгәдер зарлана шикелле тоела. Өянкенең яфраклары шыбырдап тора, җил каты искәндә, кемгәдер ачуланыпмы, карт тал ябалдашлары белән мунча түбәсен чәбәкләргә керешә. Мунчаны ачуланамы шулай, үгетлиме, өйрәтәме, һич аңламассың. Нәкъ менә үлем түшәгендә яткан картлар инде: яшәп-яшәп тә дөньяви хәлләрнең асылына төшенеп җитә алмаган, әмма үзе ясаган хаталарны бала-оныкларыннан ясатмаска тырышыпмы, акыл өйрәтергә, үгетләргә яратучан була бит ул картлар. Өянке дә шулай кылана. Чынлап та, кеше дә бит бер картайдымы, кысылмаган җире калмый, барысын да күрә, барысына да өлгерә, һәммәсен белә, аңлый сыман.

Фатыйма якты күздә мунча керергә яратмый, тәне ояла, ул караңгы төшкәч кенә мунчага килә. Бу вакытта аны карт өянкедән башка берәү дә күрми, ә өянке шул хәтле картайган ки, төннәр буена сукранып чыга. Караңгы төндә агач әллә ниткән карачкыга охшап кала, җил чыктымы, котны алып, шыгырдарга тотына, шундый вакытта Фатыйма аны кызганып куя. Җил туктауга, карт өянке авыр итеп сулыш ала, җиргә чүгеп, кемнәндер мәрхәмәт сорый кебек.

Фатыйма инде икенче тапкыр чабына, ә Камилә һаман килми дә килми. «Әллә ут алмаганга килмәвеме моның?»—дип уйлый Фатыйма, ә үзе караңгыда, эссе мунчаның ләүкәсендә изрәп утыра бирә. Бик эсселәнә башласа, алгы якка чыга, чүмеч белән салкын су алып, коену исәбе. Аның чыкканын сизгәндәй, карт өянке ябалдашлары белән мунча башын чәбәкләргә тотына. Фатыйма аны гүя ишетми, ул почмактагы ләгәннән чүмеч тутырып салкын су ала да кайнар тәненә коя, салкын су тәнен җилкендереп, татлы итеп кытыклый-кытыклый, култык асларына коела,

түбән ага, шул мәлдә Фатыймага кемдер аны йомшак кына сөя, иркәли, назлыйдыр сыман тоела. Фатыйманың шундый уйларын сизгәндәй, карт өянке мунча түбәсен тагын да зәһәрләнебрәк чәбәкләргә керешә. Фатыйма эссе мунчага керә, парларга куйиган себеркесен алып, ләүкәгә менә һәм кайнар себеркене йөзенә каплый да тирән итеп сулыш ала, әчкелтем-татлы каен исе күкрәгенә тула, Фатыйманың күңеле сафланып кала. Хатын үзенең йөрәк тибешен ишетә. Шул мәлдә аңа мунчада чынлап та берәү бар кебек тоела. Йорт иясеме шулай әрсезләнеп йөри, әнә ул тәгаен ләүкәгә таба киләдер шикелле, менә-менә үрелеп Фатыйманың аягыннан эләктерер кебек. Шунда хатын:

—Ах!—дип, киерелеп, себерке белән аркасына суга. Мизгел эчендә күңелдәге шом юкка чыга, хатын үзалдына сөйләнә-сөйләнә, ахылдый-ухылдый чабынырга керешә.

Бераздан ул, хәлсезләнеп, астагы сәкегә төшеп утыра һәм шунда тыштагы өянкенең янә мунча түбәсен чәбәкләвен ишетә. Фатыйма чүмеч ала да, һичнигә игътибар итмәстән, Таң чишмәсенең суы белән чәчен юа башлый.

—Ахирәт, ахирәт дим! Менә мунча пәрие димәсән,мунча пәрие инде! Ут алмый утырасыңмы әллә, тилекәй?—дип кычкыра алгы яктан Камилә.

Мунчага ахирәте Камилә килеп керә, аның кулында сукыр ут. Сукыр ут дерелдәп, курка-курка гына як-ягына карана. Камилә аны почмактагы шәмдәлгә утырта. Урын табылуга сөенеп, сукыр ут, солдат кебек, тураеп баса, сузылып-үсеп китә һәм шым була.

—Беләсеңме, ахирәткәем, ни ди теге Димка солдат? Синдәге Гансны татарча көйләр уйнарга өйрәтәм, ди, аккордеон табып биргән үзенә. Синең Ганс дигәнеңнең түбәсе күккә тигән. Менәтерәк, ышанмасаң, үзең кайтып кара. Җибәрик үзләрен мунчага.

—Алардан соң бу мунчага мин ничек керермен?!

—Үзем юып чыгарырмын мунчаңны. Керсеннәр, ахирәткәем. Алар да кеше бит. Җитмәсә синдәгеләр дә, миндәгеләр дә антифашистлар, ди. Безнең яклы кешеләр ул антифашист дигәннәре, бик беләсең килсә.

—Мина алар барыбер немечләр. Керсәләр дә башта солдатны җибәрәбез...

—Ярый-ярый, шулай итәрбез,—дип сөйләнә-сөйләнә, Камилә җитез генә ләүкәгә менеп, ташка су бөркеде.—Һә-һә, яккансың бертөрле итеп, ахирәт. Монда өч бөртек кеше түгел, бер полк солдат кереп чыгарлык...

—Бик җилпенмә, утны сүндерерсең.

—Сина аның барыбер хаҗәте юк, синең янда мин дә курыкмыйм, беләсең килсә.

Мунчадан кайтып керүгә, Фатыйма Димканы җибәрде. Солдат, рәхмәт әйтә-әйтә, чыгып йөгерде. Фатыйма белән Камилә чәй эчәргә утырдылар. Фатыйманың Таң чишмәсе суы белән юган, һәйбәтләп тараган кара чәчләре иңбашларына сибелеп төшкән, битләрендә мунчадан соңгы алсу нурлар биешә.

—И-и, ахирәткәем, бу Харисымны төшемдә күрүләр бер бетәр микән, юкмы икән... Көнаралаш янымда йоклый сыман. Ул сөя, ул ярата, ул назлый, әллә ниләр инде шунда. Саташумы икән әллә? Уянып китәм дә котларым алынып ятам, әллә, мәйтәм, исән микән үзе? Исән булмаса, төшләремә шулай ап-ачык булып кермәс иде, дим. Беркөн Җәмилә әбигә сөйләгән идем: үзе булмаса да, җаны килә аның, балам, ди. Хәер биргәлә, ди. Килүдән туктар, ди. Ә минем аны күргән саен күрәсем килә.

—Сугыш бетүгә күпме булды бит инде. Исән булса, хаты килмәсә дә хәбәре килер иде, юктыр, шулай хәбәрсез югалуларыдыр бахырның, ахирәт. Әй, ахирәт-ахирәт, ни әйттең иде дә бит таштай-тукмактай кайтып төшсә. Һай яратадыр иден үзен бертөрле итеп, әй! Син бит Харисыңны бигрәкләр яратадыр иең, Фатыйма.

—Син Идрисеңне яратмый идеңмени, җүләрем. Әле булса хәтеремдә: бер тапкыр мунчага дәштек үзегезне. Ис тигәнме үзенә шунда, бермәлне

сине күтәреп алып килеп кирә бу. Ир башы белән жылый бит, мескенкәем. Үлде бит, мине ташлап китте бит, жанкисәгем, дип өзгәләнә. Нашатыр иснәтә-иснәтә исенә килгәч, әй куана, бичаракай...

—Юк инде, Фатыйма, синең Харисыңа житмәс. Көнләшеп бетә алмыйдыр ием гөрләшеп яшәвегездән...

Фатыйма күзләрен идәнгә текәде, башына салган яулыгын иненә сыдырып төшерде. «Күр әле бу күнел дигәнен,—дип уйлады хатын.—Гел юкка куанып утырам, ә рәхәт булып китте».

Әйе, Харисны яратты ул. Аның сөюләрен онытып буламы. Бер тапкыр алар югары болында куна калдылар. Харис чалгысын печән чүмәләсе өстенә ташлады да:

—Йә, Фатыймакай, кабарга ниең бар, ашыйк та ятыйк,—дип, урын хәстәрләргә кереште. Ашап-эчеп алгач, алар яңа чапкан печәннән жәйгән «түшәккә» яттылар.

Әңгер иңеп килә, кичке тымызык һавада чапкан печән исе. Әле анда, әле монда йолдызлар кабына, бераздан күк йөзе алтын тәңкәләр сипкәндәй чуарланып калды. Елга ягыннан томан канат жәйде. Сарут койрыклары муенны кытыклый. Харисның иреннәре битне пешерә. Шул төндә Харис аңа багышлап жыр жырлады. Ык суыдай талгын, саф, моңлы көй иде ул. Төнлә Фатыйма төш күрде. Имеш, күккә ашкан икән һәм йолдызларны уятып йөри, үзе Харис жырлаган жырны жырлый икән. Йолдызлар нигәдер сүнгәннәр, әмма Фатыйманың килеп кагылуы була, йолдыз зыңлап китә һәм, гөлт итеп кабынып, нур чәчә башлый. Ул да түгел, Фатыйма болынга төшә, бәйләм-бәйләм чәчәкләр жыя, чүмәлә төбендә йоклап яткан Харис янына килә. Ләкин чүмәлә төбендә Харис юк, имеш, аны кемдер алып киткән. Фатыйма күз яше белән еларга тотына.

Ул шунда чынлап та елап уянып киткән иде. Караса, Харисы янында ята. Фатыйма иренең куенына кереп, ире уянып китә дә хатынын кысып-кысып кочаклый.

«Жүләрем, кысма шул тиклем, үтерәсең бит Фатыйманы... Карале, Харис, Таһир белән Зөһрә дә шулай яратышканнар микән?»

«Без алардан кимме».

«Харис, нигә шул тиклем татлы микән ул?»

«Ятратканга».

«Их, элегрәк белгән булсам, берәр ел алданрак чыккан булыр идем үзеңә».

«Ә нигә чыкмадың соң? Сорадым ич мин».

«Курыктым. Гармунчы. Янында кызлар сырпаланалар».

«Ә мин сине генә яраттым. Күрүем булды, менә ул минем дигән кыз, дип юрадым...»

—Күрче, күрче берәүне, әллә гел йокыга китеп утыра инде. Фатыйма дим, тилекәй, уян,—диде Камилә.—Хәзер солдатын кайтыр, самавырын яңарт. Мин чыгыйм инде...

Камилә чыгып киткәч, Фатыйма урын жәйде, кипшерә башлаган чәчен тарады. Шунда үзендә берәүнең карашын тойды. Башта ул аны күрмәмешкә салышты һәм шундук үзенең сылу гәүдәсен күз алдына китерде. Әйдә карасын, тонсын күзе. Фатыйманың өстендә биленә сыланып торган алсу ситсы күлмәк, балтырларына чаклы кара чәчләре сибелеп төшкән. Озын иде чәч Фатыймада. Харисы аның толымнарына уралыр иде дә иләсләнеп: «Мин синең әсирең, чәчләреңә әсир»,—дияр иде.

—Фройлейн!

—Ни кирәк сиңа?—Фатыйма башын чайкап, чәчләрен тузгытып жибәрде.

Әсир Ганс ишарәләр белән нидер сорый иде. Кулында иске аккордеон.

—Энструмент...

Немец бармагын бармакка ышкып күрсәтте. «Кораллар сорый, ахры»,—дип Фатыйма чәчен баш түбәсенә өеп куйды да тасма белән бәйләде, аягына чүәк элеп, алгы якка чыгып, Харисның кораллар әржәсен табып бирде.

Немец телне аңламады, әмма хатынның күз карашыннан төшенде булса кирәк, тиз генә аккордеонга барып ябышты.

—Музыка, гу-гу...—дип сөйләнә-сөйләнә, рәхмәт әйтә-әйтә, эшкә керешге.

—Яса инде бик теләгәч.—Фатыйма почмактагы иске киез өстендә йокымсырап утырган икенче әсиргә күз төшереп, алгы якка узды да көзге каршына барып басты. Күрер күзгә юантыграк гәүдәле, җәлпәгрәк борынлы иде Фатыйма; күзләре гүя як-якка йөгерешеп китәргә торалар, тулы иреннәрендә әйтелмәгән сүз калган сыман, елмайганда бит очларында кәҗә бәтие тоягы хәтле генә чокыр хасил була.

Солдат кайтып керде, ах-ух килә-килә чәй эчәргә утырды. Димка өстәл тутырып чәй-шикәр куйды, букчасыннан бер бөтен ипи чыгарды, тушенка ачты.

—Фатыйма апа, әйдә чәй эчәбез.

—Рәхмәт, мин эчтем инде,—диде Фатыйма чаршау артыннан.—Нимечләреңне мунчага җибәрәсеңме соң?

—Бара күрсеннәр.—Димка солдат алгы якка чыгып, немецларга нидер әйтеп керде.—Башлары күккә тиде. Ә син... Кин күңелле хатын икәнсең. Өйләнсәм, мин дә, боерган итсә, синдәй хатынга өйләнәм. Матур, таза булсын, күзләре җете кара, мәченеке кебек янып торсын.

—Бик теленә салынсаң, чүәк янда гына, алдым салдым башыңа берне.

—Һм-м, бетте, бетте, апаҗан, аты-башы шул булыр. Гафу... Бер йомыш бар иде, Фатыйма апа. Моннан ике өй аша гына бер кыз бар, Валя исемле. Киләм дип вәгъдә иткән иде.

—Бар инде, бар, алып кер,—диде Фатыйма. Ул күрше авыл кызы Валяны белә иде. Кыз кибеттә сатучы булып эшли. Телгә җор Димка, күрәсең, кыз белән танышып та өлгергән иде.

Күп тә үтмәде, Димка әйләнеп тә кайтты, артында бусагадан узарга оялыбрак, кибетче кыз Валя басып тора.

—Узыгыз инде, узыгыз. Кич утырыргамы? Рәхим генә итә күрегез.

—Э-э, әйдә, Валечка, түргә узып утыр,—диде Димка кинәт дәртләнеп һәм кыюланып.—Хәзер музыка да булдырам. Фатыйма апа, сез каршы түгелдер бит?

—Каян алмакчысың ул музыканы?

—Һә!—солдат ишекне ачып, Ганска дәште.—Ганс, кер әле.

Немец керде, аккордеонын тез өстенә куйды, тупсага утырды.

—Сыздыр әле бер татар көен.

—Нет. Плохо знай.

—Аны өйрәнерсең. Әйдә соң белгәнеңне, Штраус вальсын.

Фатыйманың күптән мондый моңнарны ишеткәне юк иде инде. Әллә нишләтә күңелне, һәр аһәң бөтен тән буйлап чымыр-чымыр йөгерә. Күрче, күрче бу Гансны, бармакларын гына күрче, ни тамаша йомшак итеп баскан кебек, ә көе тәмам күңелне айкый. Өй эченә моң тулды, ул бер ишеккә килеп бәрелде, тәрәзәләргә чиртте, почмакларга ташланды, ахыр килеп, чыгар урын табылмагангамы, өй тутырып янгырарга керешге. Штраус. Харис уйнарга ярата иде шул вальсны. Гансның кылган чәчләре маңгаена төшкән, аккордеон көенә сихерләнгән бер кыяфәттә почмакка төбәлгән дә уйный да уйный. «Туган илен исенә төшерәме икән әллә, мескенкәем? Йөргән кызынмы? Аның белән кулга-кул тотынып, урман аланнарында йөрүләрен хәтерләвеме?»—дип, кул эшен бер якка куеп, дөньясын онытып тыңлап утырды Фатыйма. Көй аның йөрәген кузгатып җибәрде, хәтта күңелендә әсиргә карата кызгану хисе кузгалды. Ганс кинәт кенә «Катюша»га күчте. Димка белән Валя күзгә-күз карашып алдылар да беравыздан диярлек җырлап җибәрделәр. Фатыйма башына япкан яулыгын иңнәренә төшерде, белгән кадәр җырга кушылды.

Расцветали яблони и груши,
Поплыли туманы над рекой...

Күр инде бу жырны тагын, ничек шул тиклем күзгә күренә сурәте. Язгы бакча, иртәнге томан, бакча башында Харис басып тора, кул изи, үзенә дәшә иде. Йә инде, нишләвен бу тагын; Харис та Харис! Күмү тигән булса, сөякләре череп барадыр инде Харисыннын...

—Фатыйма апа, әллә елап утырасыз инде?—диде Валя.—Минем әни дә елый шул көйне ишетсә...

—Юк, Валя, болай гына ул, монсурак булып китте.

Гансның уйный-уйный бит очлары алсуланды, сары кашлары уйнаклаштырды, күзләре елмайды. Ул да күрде Фатыйманың күзенә яшь тулуын һәм нигәдер тагын да дәртләнебрәк уйнарга кереште.

Жыр беткәч, Димка Фатыймага:

—Әйдәгез, бер татар көен дә жырлыйбыз. Ну, Валя, син беләсенме теге ничек әле?..

—«Галиябану»нымы?

—Әйе,—диде Димка, югалткан әйберен тапкандай шатланып. Ганс, Фатыйма апа жырлый, син, давай, жайлаш. Булдырасың син аны.

Немец, жырның сүзләрен аңламаса да, Фатыйма жырлый башлауга, дикъкать белән тыңларга керешге.

Тәрәзә төбе каты бал,
Ашыйсың килсә ватып ал...

Ганс чынлап та көйне шундук тотып алды, икенче мәлдә инде ул, башын кырын сала төшеп, уйнап та жибәрде. Өйдәгеләр тын калдылар. Гажәпләнмәслек тә түгел иде, немец бик үк жиренә житкермәсә дә «Галиябану» көен уйный иде. Гансның бармаклары аккордеон теленә баскан саен моң да нәфисләнә бара. Гүя ул шул озын бармаклары белән тоткынлыкта яткан моңнарның әле бер капкасын, әле икенчесен ача, ирекә чыккан моң исә йөрәкләргә былбыл булып килеп куна, бәгырьләрне телә. «Күрче бармакларын, шүрәле бармакларыннан бер дә ким түгел»,—дип уйлады Фатыйма, немецның уйнавына соклануын яшермичә. Ул да түгел, яшьләрнең ни теләүләрен аңлапмы, гармунчы вальска күчте. Димка белән Валя күзгә-күз карашып алдылар да биергә керештеләр, ду килеп бөтерелә башладылар...

Төнлә ул берьялгызы калды, Димка солдат Валяны озата чыкты. Фатыйма ишекне эчтән келәгә салды, тотка аша үткәреп, кисәү таягы тыгып куйды. Ни күңеле тынычланып ятса да, икеме-өчме сискәнеп, уянып киткәләде. Моңарчы гамьсез генә йөри бит әле, Диманың Валя белән ду килеп биюе, кылган чәчләрен туздырып, як-якка селкенә-селкенә Гансның дәртләнеп аккордеонда «Галиябану» көен уйнавы күңелгә әллә ниткән шик-шом салды да куйды.

Гансның болай кылануын иптәше өнәми, ачулана, көннәр буе сөйләшми иде. Аның шулай турсаюына Ганс бөтенләй игътибар итми, алданрак кайткан булса, Фатыйманы күреп, йөгереп килеп кече капканы ача, чиләкләр алып, чишмәгә суга китә иде. Кич белән ул капка каршына чыга, урамда жырлап йөргән егетләрнең көйләрен отып ала һәм икенче көнне шул көйне сыздырып уйнап утыра иде. Беркөнне «Шахта» көен откан. Шундый иттереп килештереп, бар жирен-жаен китереп уйнап жибәрде ки, Фатыйма тамагына төер тыгылып, идән юган жиреннән туктап калды. Харис өздерер иде шул көйне, күңелләр айкалып китәр иде шул көйне уйнап жибәрүенә. Күр әле моны, гел килештерә бит бу да.

Фатыйма түзмәде, түр якның ишеген ачып куйды, көй алгы өйгә керде, йөрәкләрне жилкендерә, бәгырьләрне телә башлады. Гансның өстендә яшькелт гимнастерка, ул аны атна саен юып тора, шуңамы, әсирнең гимнастеркасы уңган ситсыга охшап калган. Йөзендә язып та, әйтеп тә бетермәслек житдилек. Сталинград шәһәрен алырга теләп, жилкә аша аскан автоматыннан кургаш уты коя-коя безнең солдатлар өстенә килгәндә дә аның йөзе шулай куркыныч булдымы икән?.. Юк, ул гынамы, үлем турында онытып, күзләре тулы дәһшәт, йөрәге тулы нәфрәт белән безнең солдатлар окобына килгәндер. Ә хәзер Фатыйманың күңелен күрер өчен «Шахта»

көен өздерә, солдатканың болай да әрнүле йөрәгенә көлтә-көлтә ут сала, ут өсти, мөртәт немеч.

Фатыйма шапылдатып ишекне яба, түшәмнән туфрак коела, тәрәзә пыялалары зыңлап ала. Ганс уйнаудан тuктый, аккордеонын сак кына агач караватка куя да өстенә иске яулык яба. Шунда ул яулыкка борынын төртә, озак итеп, иләсләнеп сулый, иптәше моңа карап тора-тора да:

—Җүләр!—ди.

Ганс аның ягына күз сирпеп тә карамый, ул яулык япкан аккордеонны ала да, ишекне ачып, мунчага чыгып китә. Иптәше белә: ул анда «Галиябану», «Шахта» һәм аңа таныш булмаган әллә ниткән татар көйләрен төне буе өйрәнәчәк. Ә иртән, таң беленер-беленмәс кайтыр һәм шыпырт кына кереп, ятып йоклар.

Кичке якта Фатыйма эштән кайтуга, яңа көй өйрәнгән булыр, сыздырып-сыздырып уйнар. Аның шулай уйнавына мөкиббән китеп, күрше карчыгы Нәсимә әби коймa аша тыңлап торыр һәм яулык очын күзләреннән алмас. Икенче көнне Фатыйманы күрсә, карчыкларга хас кызыксыну белән:

—Татарлармы әллә синең ул солдатың? Татар булса, чык та куй үзенә! Күзләренә уй төшкән, тикмәгә түгел бу, балам. Уеңны уй итмәсәң, гомер бакыеңа бәхет күрмәссең. Ирсез хатын—канатсыз кош ул, балакай,—диде.

Фатыйма нәзек кыйгач кашларын җыерды, шомырт кара күзләрен кыса төште дә, ни әйтергә белмәүдән тәмам чарасыз калып, тулы иреннәрен бөрештереп бераз торгач: «Мәнсез карчык, убырлы кортка, ни сөйли тагын, ни булсын минем уемда?»—дип ярсына-ярсына, китеп барды. Өенә кергәч, караватына капланып, тамагына килеп тыгылган төерне үткәреп җибәрә алмый ятты. Шунда аңа үз-үзенә карата кызгану хисе уянды, аяз көндә яшен сукса гына, ятларга күз салса салыр ул. «Юрама юкны, Нәсимә әби. Рәнҗетмә болай да кимсү күңелле солдатканы»,—дип үртәлде ул.

Нәкъ шул чакны кыштыр-кыштыр күрше карчыгы үзе ияреп керде. Карчык, түкереген йотып, башына бәйләгән француз яулыгын рәтләп торды, аскы ияген күтәрә төшеп, юка иреннәрен елмаюга җәйде:

—Япа-ялгыз хатын янында япа-ялгыз ир яшәми, балакай. Сөләйман пәйгамбәр әйткән, ди, зат янында зат ятканда таң атмас, таңнар атса да, җан атмас, дип әйтеп әйткән, ди, җүләркәем. Ике гомер яшәрмен дип беләсеңме, гүргә кереп чермәс сөякләрең бармы әллә?! Зифа сының, кайнар каның бар икән, хафалы уйлар бар да бар инде ул синдә, балакай... Күзең әйтә, йөзең әйтә, йөрәгең купкан, күңелең ятмаса—саклан, ятса—баш тартма. Чык та куй шул солдатка. Кырык хатынга бер ир кайтты, ир янында хатын үлмәс, ил өстендә ир үлмәс, бала... Ул да гомер буена әсир куып йөрмәс.

Фатыйма уңып калган яулыгын башыннан сыдырып алды, битенә каплады һәм үртәлеп-үксеп елап җибәрде. Аның тынычланырга исәбе югын абайлап, күрше карчыгы дәшми-тынмый гына чыгу ягын карады.

Кемдә юк ул самимилек, нәүмизлек! Әсирнең үзендә яшәве Фатыймага башта кызык тоелды, булдыра алган кадәр аңа татарча сүзләр өйрәтте. Ә күрше карчыгы әнә ни сөйли.

Кич белән шулай тел өйрәнеп утырганда, Фатыйма Ганстан сорап куйды:

—Кем идең син сугышта?

Татар телен шактый тиз сукалый башлаган, аш-суны гына түгел, өйдәге һәр әйбернең исемен-затын үзенчә сакаулап әйтә башлаган Ганс әүвәл бу сорауны аңламый торды.

—Бүләм. Сугаштэ.—Ганс самавыр торбасын алды.—Пум-пум,—диде. Аннары бер тәлинкәгә ике кашык белән суккалап торды.—Музика.

«Димәк, син рәтләп сугышмагансың да икән, музыка уйнап кына йөргәнсең,—дип, үз-үзен тынычландырырга тырышты Фатыйма.—Нәсимә әби мине солдат белән тора дип уйлый, ахры. Чит кеше күңелләрен белеп кенә бетереп булса икән ул...»

Яхшылык эшләү, изгелек кылу, кызгану-җәлләү Фатыйманың холкына сыймаган нәрсә түгел, хатын-кыз буларак кешегә инәлеп бәйләнә белмәде,

юк-барга кычкырынмады, күрше-тирә белән бер тапкыр да җәнҗалга кермәде, әйткән белән күнсә—күнде, күнмәсә—юк, мәгәр кешегә авыз ачып каршы сүз әйтмәде. Бик тә ачуы килсә дә, кешегә ишеттерми генә: «Кадалып кит!»—ди торган иде. Бу сүзне дә ул Харистан отып калган иде. Күп вакытта ул үзен мескен вә нәүмиз хәлдә итеп тоя, аның бу халәтен сизеп алган ахирәте Камилә:

—Ишен югалткан дуадак каз сыман йөрмә әле, күпме сагынсаң да, күпме зарыксаң да, үлгән артыннан үлеп булмый, аеграк акыл белән яшәргә вакыттыр инде сиңа да, ахирәткәй,—диде.—Мине әнә аксак Төхфәтулла димли. Килде беркөнне, ярты кыстырган. Бордым да җибәрдем үзен. Күчеп киләсең икән, яртысыз гына кил, дидем. Ап-аек көе килде. Күндем әнә...

Шул сөйләшүдән соң бер атнадан аксак Төхфәт Камиләгә күчеп килде. Гөрләшеп яши башладылар, ике көнгә бер Фатыйманың мунчасын яктылар. Фатыйма мунчага алардан соң төн канат яргач кына барды. Караңгы мунчада йорт иясе белән генә сөйләшеп, озак итеп, хәлдән тайганчы мунча керде. Шулай иткәндә төш күрергә дә өлгерми йоклый торган иде.

Беркөнне Камилә белән Төхфәтулла Фатыйманы ашка дәштеләр. Ичмасам гармунын уйнар дип, Камилә Ганска да әйткән булды. Ганс, рөхсәт сорагандай, Фатыймага карады. Аннары түр якта китап укып утыручы Димка солдатка карады.

—Керсен,—диде Димка солдат.

Камиләгә Төхфәт белән бергә булу килешкән, күрәсең, табын белән мич арасында җил-җил килеп йөри. Ир дә барысын да тапкан берәүдәй өстәл янында кәпрәеп утыра. Төхфәт киң кашлы, зур борынлы, каракучкыл чырайлы, аксаганда аның бер җилкәсе түбән төшеп китә, җиргә җитмәгән аягын тотып алырга теләгәндәй, кинәт сул якка үрелеп куйгандай итә. Язмышын шул инвалид белән бәйләвенә Камилә дә үкенми, ахры, кияүгә чыкканнан соң хатынга тәмам канат үсте: күзләре елтырый, күкрәкләре тулышып китте, йөрешенә кадәр үзгәрде. Фатыйма кебек, ир-аттан бер дә тартынып тормый, үткәндә дә, сүткәндә дә Төхфәтнең йә чәчен туздыра, йә агач аягына баса.

—Бас-бас, барыбер сизмим,—ди Төхфәт һәм тәмле итеп, үз итеп Камиләсенең йомшак җиренә шапылдатып сугып ала.

Ганс өстәлнең бер читендә көлемсереп тик утыра бирә, бер чокыр әче бал эчкәннән соң аның какча сары йөзенә алсулык йөгерә, кылган чәчләре тырпаебрак китә, әсир юк-юк та монаеп Фатыймага күз ташлап ала. Әмма Фатыйма, аңарда гамьнәре бөтенләй булмагандай, Харисы белән сөйләшә иде. Ләкин соңгы вакытта күкрәк түреннән үз язмышына әрнүсыкрау чыга башлады. Бераз утыргач, җырларга тотындылар. Ганс гармунын тартты, ул шул тиклем бирелеп уйнады ки, кылган чәчләре маңгаена төште, күзләренә нур өстәлде. Харис шулай дөньясын онытып уйный торган иде. Фатыйма Ганс янына күчеп утырды да «Галиябану»ны уйнарга кушты.

—Казер.

—Карале, моның Гансы татарча сөйләшә башлаган бит,—диде Камилә, ингә-ин орынып утырган Төхфәтенә төртеп.

Фатыйманың күкрәк челтәрендә нидер чатнап куйды, ул серле үтергеч карашы белән ахирәтенә карады, торды да ялт кына чөйдәге шәлен элеп алды һәм ишеккә ташланды.

Бу төнме? Бу төн көзнең ямьсез вә шыксыз бер төне иде. Тискәре төн ягыннан ачы җил исә, карлы яңгыр ява, аяк астында мәте лыжырдый. «Аh бу Камиләне, күрче, үзенә ир табып алган да кеше җанын кыйный, үтереп мыскыл итә, кеше мәсхәрәли...»

Кайтты да түр якка кереп бикләнде (Димка солдат Валясы янына киткән иде) һәм караватына капланып туйганчы, күз кабаклары әчеткәнче елады.

Шуннан соң ул Камиләләргә бер тапкыр да кермәде, эштә дә аңардан бер читтәрәк булырга тырышты. Камилә эчтән көя, үкенә, үртәлә иде,

күрәсең, гел аның тирәсендә уралды, хәл-әхвәлен сораштырган булды, әмма Фатыйманың аңа барыбер жаны эремәде.

Беркөнне Ганс эштән берүзе кайтып керде.

—Иптәшең кая?—дип сорады Фатыйма, ул немецка ачулана алмады, бу көннәрдә жаны бер Камиләгә әрнүле иде.

—Госпиталь ята,—диде Ганс.—Чүрли.

Көн кичке якка авышып килә, күк йөзе чалт аяз, салкынча, карлы яңгыр яуганнан соң янәдән аяк астын катырып, туңдырып жибәрде, тәрәзәдән кояш үрелеп карый, табын хәзерләгән өстәлгә төшә, күңелләргә жылы өреп, әллә ниткән өмет чаткылары өсти. Ганс алгы якта гармун тарта, Харис Фатыймага багышлап жырлаган көйне уйный. Берме, икеме генә жырлаган иде Фатыйма югыйсә, отып алган тагын үзе. Гажәеп жинел итеп уйный, Фатыйманың йөрәге сулкылдап, ярсынып тибеп-тибеп куйгалады. «Ниләремә болай ярсуланам соң әле? Димкасы да кайтмый ичмасам!»—дип үз халәтенә үзе төшенә алмас бер хәлдә, өстәлен жыештырды Фатыйма, ут алды, Диманың китабын табып, укырга кереште. Ләкин укый алмады. Йокларга ятты. Тәрәзә башындагы чыпчык кыштыр-кыштыр килә, шылт итеп, өй бүрәнәләре утырып куя, өй кыегына кагылып, жил йөгереп уза... Хәтеренә бәхетле чаклары килә...

Бер чиратып, бер йомшартып торган яз көне иде, Харис аны кич клубка спектакльгә алырга килде. Дәшми-тынмый гына жыена башлаган кызына әнисе:

—Йөрмәсәң дә ярар иде инде, кызым,—диде. Фатыйма белә: «Барбар, кызым, тик ипле йөр»,—дигән сүзе иде бу әнисенең.

Капка төбендә аны Харис көтеп тора иде, Фатыйманың чыгуы булды, егет аны кулына күтәреп алды да йөгерә-атлый олы юлга алып чыкты.

—Жүләрем, егасың бит. Беләсеңме мин ничә пот?

—Жил син, мамык син минем өчен, Фатыйма. Мин синең белән күккә оча алам,—диде Харис, сулышына кабып. Сер бирергә яратмый иде, бахыр...

Төн бик акрын уза, башка әллә ниткән уйлар тула, Фатыйма талгын гына йокыга китә, зиһенен йокы пәрәвезе ураганда: «Ишекне бикләдемме?»—дигән уй керә, ләкин йокы сөреме көчлерәк тәэсир итә. Шундук төш күрә, ул гүя көймәдә икән, Ыкның аръягына йөзеп чыкмакчы, жил дә юк, кулда ишкәк тә юк, агымсу көймәне түбәнгә агыза. Фатыйма курыкмый, көймә аккан жайга бара бирә. Шунда көймәнең койрык очыннан Харис күтәрелә, көймә төбендәге йомшак печәнгә сузылып яткан Фатыйма янына килә. Тик нигәдер ире ап-ак чәчле, кашлары да ак. «Нишләдең син, Харис?»—дип сорый Фатыйма. Харис жавап бирми, бармаклары белән Фатыйманың күкрәген капшый, иңнәреннән ала, түшенә башын салып, тынып кала. «Картайдыңмы шулай, чәчләрең гелән ап-ак булган, Харис жаным?—дип сорый Фатыйма.—Күзләрең дә уңган сыман. Картайгач, күзләр дә уңа микәнни, Харис? Нигә дәшмисең?! Китче, кая йөрдең моңа кадәр, нигә туры Ак Тауга кайтмадың?.. Әсир төшсәң соң. Әнә миндә дә торалар бит әле, тиздән аларны да кайтарып жибәрәләр, ди. Соң шулай дими, исән булгач, менә кайттың бит әле... Кысма мине, үпмә шул тиклем, көймә капланса, нишләрбез, жүләрем...»

Фатыйма сискәнеп уяна. Тын. Күкрәгендә кемнеңдер кулы ята сыман, куркынып куя. Ныклабрак караса, юрган бөкләнгән икән. Тынычланып, стенага таба әйләнеп ята һәм кинәт ана караватт янында берәү басып торадыр шикелле тоела. Зиһене сафлана, әйләнеп карый.

—Кем бар монда?

«Беркем дә юк. Нишләвем бу? Саташам инде әллә?»

Әкрен генә тора, шәлен жилкәсенә сала, тышка чыгарга жыена, Гансны уятмас өчен ишекне сак кына ача. Алгы якта караңгы, иске агач караватт шыгырдап куя. «Ул мина тимәс, жүләр түгел бит. Мина кагылса, аны атарлар»,—дип уйлый Фатыйма баскычтан төшкәндә.

Ләкин әйләнеп кергәндә аның Ганска дәшәсе килеп куя, ул хәтта

бер мизгелгә ишек янына туктала, салкын корычтан ясалган ишек тоткасына кулын салгач кына, айный да, кабаланып, түр якка уза, ишек келәсен төшерә. Йөрәге дөп-дөп тибә, колак янында нидер гөжли, дулкынланудан шулай бу. «Тиле дә сон үзем, башы ике мәллә анын мина тияргә!» Фатыйма тынычлана, урынына ята...

Иртән ул торганда, Ганс эшкә киткән иде инде. Фатыйма яулык япкан аккордеонга кагылып алды һәм нишләптер бөтен тәне кымырҗып куйды. «Уф аллам, нигә шулай куркам сон әле мин бу немечтән? Миндә гаме дә юк ич анын!..»

Кич эштән кайткач, аш пешерде, ашады, Ганска бер тәлинкә аш чыгарды. Аккордеон шыгырдатып утырган немец, ашны күрүгә, ни әйтергә белми аптырап калды.

—Мингә?

—Әйе, сина, аша,—диде Фатыйма.—Әпәен бармы? Иптәшен кая сон?

—Баг-баг. Казер кайта.

—Баг түгел, бар.

—Баг, барр,—диде Ганс, нечкә бармаклары белән кашыкка тотынды. Сәер итеп тота иде немец кашыкны, авыр көрәк тоткан сыман, учлап, йомарлап.

«Кашык та тота белми, бигрәк ят инде, бичара». Холкына сыймаган нәрсә булса да Фатыйма көн үтә көн немецка гадәтләнә башлады. Дима ике көнгә бер генә куна кайта йөрде.

—Син начур йуклады, әйе?—диде беркөнне иртән Ганс Фатыймага.

—Саташтым. Син тиледән куркып яттым.

—Син түкел, мин курка синнән.

«Курка, куркытырсын син мөртәтне»,—дип уйланды Фатыйма.

Ашагач, Ганс ишегалдына чыгып китте, мунчага таба юнәлде, ул анда бик шакылдый башлагач, Фатыйма да шунда килде.

—Нишлисен син монда?

—Ишек егыла. Ясау кәрәк...

Чынлап та ишекнен бер күгәне суырылып чыккан, шунамы, әйбәтләп ябылып житми иде. Ганс ишекне күтәреп алды да, күгән тишегенә агач кисәге ярып тыкты, күгәнне балта түтәсе белән сак кына кагып куйды, аннары ишекне әлде, ябып карады.

—Гуд. Якшы булдын...

Фатыйма үз-үзен тирги-тирги өйгә атлады. Бу тырыш кеше егәренсәләтен кая куярга белми интегә, мин, тиле, анын артыннан аптырапйөдәп йөрим. Өйдә эш беткәнме?

Бүген ул кырга сабанга баргач, тургай сайраганны ишетте. Атларын туктатып, кошчыкнын монын акылы-һушы китеп тынлады. Зенгер-зенгер кояр да кояр монын кыр өстенә мескен кошкай. Кемгә шулай дәртләнепөзгәләнеп сайрый, кемне чакыра икән? Бәлкем, ул да минем кебек япаялгыздыр, сайрый-сайрый парын эзлидер? Ә тегесе еракта-еракта, кайтмый да кайтмый. Бер тапкыр көлтә бәйләргә килгәч, шушы басуда Харис аны утыртып куйган көлтәләр арасына алып кереп үпкән иде. Лабогрейкада эшләгәнгәме, Харистан тир исе килә, сулышы кайнар, иреннәре каты иде. Шундагы көлешү, үртәшү-шаяртуларны, яшерен генә каш сикертүләрне, күз кысуларны, кибән артына качып, мыштым гына иреннәрне көйдергәнче үбешүләрне онытасы буламы, онытырлык хәлләрме алар...

Кичке ашка ул Гансны үз өстәле янына дәште. Итле аш иде, Ганс ике тәлинкә ашады, аннары бер чокыр чәй эчте.

—Бу ишек ясаган үчүн, әйе?—диде ул, көлемсерәп.

Ипи, тоз, чәй, савыт, кашык, пычак, балта кебек сүзләрне Ганс нәкъ татарча итеп әйтә иде инде. «Әйе»не ул сүз саен кыстыра: «әйе» анын өчен килешү дә, сорау да, тагын әллә нинди мәгънәләрне анлата иде, күрәсен.

Аннары ул аккордеон уйнады, татарча жырларга тырышып карады. Фатыйма, ана карап, бәйләү бәйләп утырды.

Урын җәя башлауга, Ганс чыгып китте, бик озак алгы якта йөренде.

Фатыйма ятты. Йокыга китәр алдыннан тагын: «Ишекне әллә бикләдем, әллә юк»,—дип уйлап алды. Мәгәр торып карарга көче-дәрманы житмәде, аруы тәмам житкән иде, бүген ул гектарга якын жир сөрде. Учетчик Аксак Төхфәт:

—Беренче урын синдә, Фатыйма күрше!—дип мутланды.

Эштән кайтканда идарәгә керде, күзенә ташлануы сәбәп булдымы, күптәнге нияте идеме, күкрәгенә орденнар, медальләр таккан яңа председатель Галләм Кыямов Фатыйманың терсәгеннән алды да:

—Фатыйма, без сине сыерлар саварга күчерергә булдык бит әле,—ничек уйлыйсын?—диде.—Сабан сөрүне тракторларга, ирләргә бирергә вакыт житте кебек.

—Ярый соң,—диде Фатыйма килешеп. Сабан сөрү аңа чынлап та бик авыр иде.

Фатыйма һичкайчан зарлану-сыктану дигән нәрсәне белмәде, сугыш елларындамы, соңыннанмы, нужа арбасын иң төпкә жигелеп тартты, олысыкечесе аны хөрмәт итә, яхшы яктан гына телгә ала, яманлыгын күрүче булмады. Юантыграк балтырлы, ирләргә хас зур куллы, карсаграк гәүдәле, тулы янбашлы, кыскарак билле хатында чынлап та көч-гайрәт мөлдерәп тора шикелле иде.

Күзләрен йомуы булды—тагын шул көймә. «Нигә көймә?—дип уйлады Фатыйма.—Бит алар Харис белән печән эчендә йоклаганнар иде, нигә тора да бу көймә күз алдына килә икән?»

Ни генә булмасын, көймә эченә ятып йокыга китүе рәхәт иде. Тиздән янына Харисы килер, кочар, иркәләр, назлар, сөяр. Аннары рәхәт-рәхәт булып китәр. Тик чәчләре генә нигәдер ак бу Харисның, кашлары да уңган сыман саргайган, тырпаеп торалар.

Көймә чайкала, су тавышы, Фатыйма янына янә Харисы килә.

«Харис, нигә син болай бик озак кайтмый йөрдең? Мин бит сине бик тә, бик тә сагындым, жанкисәгем... Әй, белсәң икән ялгыз яшәүләрнең кыенлыкларын, Харисым... Кочакла, кочакла, нык кысып кочакла... Их, Харис!.. Бу кадәр булмастыр инде... Кай арада кайттың соң әле син?.. Камилә әнә Аксак Төхфәткә кияүгә чыкты, ә мин сине көттем. Көттем дә көттем. Кайта икән ул ирләр, бик көткәч... Менә кайттың бит... бераү дә күрмәсә ни, иртәгә үк ишетерләр, күрерләр... Хәтерендәме, бер тапкыр печән чүмәләсе төбендә кунган идек... Шул мәлләрне сагыныпмы. Кочак...»

Фатыйма үз тавышыннан үзе куркынып уянды. Куллары белән юрганны бөтәрләп кыскан, бөтен тәне дерелди, аркасында салкын тир.

«Әй, ходаем, бу нинди төш инде тагын?»

Өй эче тыныч, әмма алдагы өйдә кемдер йөренә кебек. Бер тын яткач, күргән хәлләре бары тик төш кенә икәненә инангач, Фатыйма торды, юынды, киенде дә казан астына ут салды. Шул вакыт тәрәзә башындагы чыпчык уянды һәм кыштырдарга кереште. Хәсрәт кош бик озак тынычлана алмады.

Иртән кояш чыгып, ишегалдына аяк басуга, Фатыйма нигәдер өй кыегында утыручы чыпчыкка игътибар итте. Чыпчык тырыша-тырыша үзенчә сайрый, кемнедер үз янына дәшә иде. Ә инде бүрекле кошчык янына килеп кунгач, канатларын жәеп, йоннарын кабартып, чыр-чыр килеп кинәнә башлады, ахыр килеп, ни кыланырга белми иптәше тирәсендә бөтерелергә тотынды.

Фатыйма көянтә-чиләк алды да чишмәгә суга барырга чыкты. Урамга аяк басуы булды, югары очта әсирләр төялгән машина күренде. Машина кемнеңдер өй каршына туктаган иде. Фатыйманың нишләптер йөрәге жу итеп китте.

Әржәдә әсир немецлар. Алар арасында Ганс күренде. Ул Фатыймага кул болгый, туктарга кушамы, әллә ни шунда. Әмма Фатыйма туктап тормады, тиз-тиз атлап, чишмәгә юнәлде.

Жай гына, көйле генә чиләктәге суларны мыскал да чайкалдырмыйча чишмәдән кайтып килгәндә, өе каршына туктаган машинаны күрүгә,

Фатыйма үзе дә аңлап бетермәгән тәэсир хафасында адымын тизләтте.

Ни булыр бу? Нигә аның капка төбендә тора ул машина?! Әллә соң? Ходаем!..

Фатыйма килеп җитүгә, Димка солдат капкадан чыкты.

—Фатыйма апа, коткарабыз үзенне немецлардан, илләренә озатабыз. Котыласын...

Фатыйма көянтә-чиләкләрен җиргә куйды да, ни әйтергә белми, катты да калды. Аның янына Ганс килде.

—Эчү ярый,—диде ул Фатыйманың күзләренә туры карарга тырышып.

Фатыйма сизелер-сизелмәс кенә ияк какты. Ганс җиргә тезләнде, чиләкне чак кына аудара төшеп, салкын һәм саф Тау чишмәсе суын эчте. Озак эчте, бәлзәмдәй тәмләп эчте.

—Монда су тамлы, дөньяда юк! Сыйн да дөньяда бераз гына, Фатыйма. Мин сыйне йурагымда алп китам...

—Рәхмәт сезгә, Фатыйма апа. Мең яшәгез,—диде Дима һәм Фатыйманың кулын кысты. Ганс та аңа таба бер адым ясады. Әмма Фатыйма чак кына артка тайпылгандай итте. Немец моны сиздеме, машина әрҗәсендә бөкшәеп утырган иптәшләреннән яхшысынмадымы, китәргә дип борылды, мәгәр ике адым ясамады, каерылып:

—Сыйн айтсаң, мин кала, Фатыйма, әйе,—диде.

Ул арада шофер машинасын кабызды. Әрҗәдәге немецлар шаулаша башладылар. Фатыйма, Ганс аңларлык кына итеп, сизелер-сизелмәс кенә башын чайкады.

Менә машина кузгалды, ул ерагайганнан-ерагая барды, ә Фатыйма һаман бер урында басып торды. Бары тик йөрәге генә, күкрәк челтәрен ташлап китәргә җитешеп сикеренде, ни кылырга белми бәргәләнде:

«Харисым-бәгырькәем дә шулай каңгырап йөри микән?»—йөридер, исәндер... Исән булмаса, бу тамаша төшләремә кереп интектермәс иде...—дип, көянтәсен иңенә салды, җирдәге чиләкләренә үрелде.

*1975 ел*

РЕДАКЦИЯДӘН: *Бу көннәрдә Татарстанның әдәби җәмәгатьчелеге күренекле язучы Мөсәгыйт Хәбибуллинның 75 яшьлеген билгеләп үтә.*

*Мөсәгыйт Мөдәррис улы Хәбибуллин 1927 елның 25 декабрендә Оренбург өлкәсенең Абдуллин районы Габдрахман авылында игенче гаиләсендә туган. Аның хезмәт юлы бик иртә, әле сугыш елларында ук башлана. Ыналты яшендә туган якларыннан чыгып киткән егет һөнәр мәктәбендә укый, токарь, бораулау мастеры, инженер-механик, шофер булып эшли. 1971 елда читтән торып Казан дәүләт университетын тәмамлый.*

*Мөсәгыйт Хәбибуллинның әдәби иҗатта ярты гасырдан артык стажы бар. Аның беренче әдәби язмалары район газетасында илленче елларда күренә башлый. Хәзер аксакал әдип дистәләгән очерк, хикәя, повесть һәм романнар авторы.*

*Язучы буларак, М. Хәбибуллин чынбарлыкны фәлсәфи һәм тарихи тасвирлау юнәлешендә үсте. Соңгы елларда тарихи темаларга язылган дистәләп романы исә аны ("Кубрат хан", "Илчегә үлем юк", "Иван Грозный һәм Сөембикә" h. б.) халкыбызның олуг әдипләре сафына куйды.*

*Редакция хезмәткәрләре һәм каләмдәшләре Мөсәгыйт аганы юбилее белән чын күңелдән тәбрикли, аңа бетмәс-төкәнмәс иҗат дәрте, ныклы сәламәтлек тели.*

# Şigriət
# Шигърият



## Рәшит Шиһап

### МОҢНАР ЯШИ ҖИРДӘ

«Моңсызлар да була», диеп яздым
Күңел кырыс мәлдә, җырымда.
Фикеремнән бүген кире кайтам,
Изге Китап тотып кулыма.
... Йолдызлардан моңнар килә Җиргә,
Ерак булса да бик арасы.
Галәм моңсызларны тудырмый ул,
Юк,
Моңсыз булмый адәм баласы.
Бишегендә сабый елаганда
Үзәк өзгеч моңнар тоям мин.
Кешеләрнең зарын тыңлаганда
Йөрәгемә моңнар коям мин.
Мәхәббәт тә хистән, моңнан тора,
Ярату ул—
Янар хисле моңнар тарата.
Ә бу җирдә һәркем сөеп-сөелә,
Моңсыз булса, ничек ярата?
... И, мин моңсызлар дип атаганнар!
Миңа үпкә саклый күрмәгез.
Тик гозерем бар сезгә: хаталанып
Җырга гына барып кермәгез.

### Бәйсезлек

Тудым... Дәрәҗәне күтәрергә
Бераз гына алдым елап та.

Рәшит ШИҺАП *(1938)—шагыйрь, «Заман өчен бәхәс», «Җан авазы» һ. б. китаплар авторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Лениногорск шәһәрендә яши.*

Кендек әби миңа бәхет юрап,
Әфсен укып өрде колакка.
Мин ирекле! Бишек-җир минеке!
Беркем дәгъва итми бит аңа.
Нинди рәхәт бәйсез булып яту,
Тавыш бирү азат дөньяңда.
Бурыч, вазифа юк. Синдә бары
Яшәп калу өчен талпыну.
Имезлектән иңгән кара икмәк,
Ана сөте көченә табыну:
Тормыш юлына баскач... үзгәртәләр...
Бәйсез булып калу бик авыр.
Сүрәнләнә хөрлек кояшың да,
Көннәр, еллар була болгавыр.
Язмыш дигәнең гел бәйлелектә
Иленә дә, хәтта хуҗаңа.
Ил яклый ул! Хуҗаларның гына
Исе китми синең нужаңа...
Аһ, ул бишек-җиһан бәйсезлеге!—
Кайнар каныма минем сеңгәндер...
Мин үз фикерем белән гомер сөрәм,—
Башкача бит яши кемнәрдер...

Китә кеше... Җаның сызлап кала,
Язмышка без бик зур үпкәдә.
Ни аяныч, кирәклеләр китә,
Алар кирәк ахры Күктә дә.
Пәйгамбәрдәй затлы җаннар сүнә,
Ачынудан йөзләр саргая.
Әллә инде Тәңре тирәсендә
Пәйгамбәрләреме азая?
Иртә сүнә шагыйрь, әдипләре,
Намус, вөҗданлысы сыкрап.
Шундый исәненең үкчәсенә
Заман басып килә җан сорап.
Кала бирә вәхши, миһербансыз—
Тормаганы хәтта чүпкә дә.
Андый кавем кирәк түгелдер ул
Җирдә генә түгел, Күккә дә...
Китә кеше... Яхшылары китә,
Гүя йөрәк тамырын актарып.
Кирәкленең гомерен озайтыгыз,
Сүнгәч булмый Аны кайтарып.

## Акчарлаклар үкси һаваларда

Кама өсләрендә күксел моңнар,
Күрсенәләр генә чал дулкыннар.
Ак пароход уза моңны ерып,
Эзе асларында бар упкыннар.
(Шуннан менә җаның моңнар булып,
Һәм тарала—яшьле шомнар булып...)
Чыгасыңдыр төнлә мин югында,

Ә мин синсез—дөнья тәмугында.
Кинәт кенә моң сарыла ярга,
Сизәм, ул—Син, килдең сүзең барга:
«Дулкыннарда ник юк миңа чәчәк,
Кая ярда без кабызган учак?»
Чәчәкләрдән
Такыя үрдем Сиңа—сөйгәнемә,
Элеп куйдым Кама күкрәгенә.
Һич борчылма, безнең учак яна!—
Күчердем мин аны йөрәгемә...
Акчарлаклар үксе һаваларда,
Канатына моңны алалар да.
Күңелемне сызлатып ла—сызып
Яшисең син минем яраларда...

Акчарлаклар үксе һаваларда.

## Эзлим

Ничә еллар менә эзләп йөрим
Ялгызак каз сыман каңгырап.
Күңел тавышым җирдә, һаваларда,
Йолдызларда китә яңгырап,
Эзлим аны инеш буйларыннан,
Чишмәдәге аккан сулардан.
Син арышын урган басулардан,
Йөрәк маең тамган кырлардан.
Туган нигеземнән эзлим аны
Син калдырып киткән язында.
Ул—язлардан да бит якты иде
Һәм җылырак иде тагын да.
Күпме мәдхияләр язылса да,
Аз әйтелгән аның хакында.
Никадәр ул кирәк тормышымның
Һәрбер борылышы чатында!
Аһ, нәрсә ул каурый болытлардан
Миңа таба карый иелеп?..

Рәхмәт, әни!
Мин әнә шул җылы карашыңны
Ничә ел эзлим бит тилмереп...

*2002*

*Татар хикәяләре хәзинәсеннән*

# Әмирхан Еники

## ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ

*Баязит Бикбайга*

### I

Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй битгән сөя... Рәхәт, һай, рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, монсу башкорт даласында!

Әнә көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән, алъяпкыч бәйләгән, күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы арык кына бер әби кизәк җыеп йөри. Сул беләгендә аның иске чиләк, уң кулында нечкә таяк. Шул таягы белән ул кизәкне чирәмнән куптарып әйләндерә дә аннары иелеп алып чиләгенә сала. Тагын як-ягына каранып эзләп китә. Тагын кизәкне, чирәмнән куптарып, чиләгенә алып сала... Шулай да бу авыл кырындагы чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла, колхоз терлекләре монда йөрмиләр, ә бәләкәй генә авылның үз бозаулары салып калдырган «беленнәр» күпме генә соң алар! Далада утын дигән нәрсә бик кадерле булгач, ялгыз әби, ике-өч көндә бер чыгып, иске чиләге тулар-тулмас шул «беленнәр»не җыеп кайта. Борыннан килгән бер гадәт. Аннары кизәк казан астына бик килешә, ашны әкрен генә кайната, ә үз җае белән әкрен генә кайнап пешкән аш бик тәмле була ул. Әйтерсең, чирәм исе керә ашка.

Тик соңгы вакытта әбинең хәле бик үк әйбәт түгел әле. Картлыгы җиткәнме, берәр чир зәхмәтеме шунда, ләкин гел менә бөтен тәне авырап, кул-аяклары сызлап, йөрәгенең хәле китеп тора. Ара-тирә өшетеп тә җибәрә яки тиктомалга яндыра да башлый. Үзенчә, мәтрүшкәсен-нчен эчкәләп, ятып караса да, бер дә юнәеп китә алмый. Менә бүген дә, кояш шактый нык кыздыруга карамастан, аның зәгыйфь тәне, эчендә боз яткандай, гел туңып тора; аркасы буйлап әледән-әле салкын кымырҗу йөгереп уза, шул ук вакытта күз төпләре яна, иреннәре бөрешеп кибә, һәм ул гер таккандай авыраеп киткән аякларын көчкә генә сөйрәп йөри... «Булмас ахрысы, кайтырга кирәк»,—ди ул үз-үзенә иренеп кенә һәм, чиләге кизәк белән тулмаса да, авылга таба борыла.

Читән буйларында котырып кычыткан үскән тар тыкрыктан узып, бәбкә үләне түшәлгән киң урамга килеп чыккан чакта гына, аңа Минлебай карт очрый. Торна шикелле нечкә озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабайны, авылның иң карт кешесе, диләр. Туксанның өстендә

үк түгел микән? Хәер, тәгаен ничә яшьтә булуын ул үзе дә белми. Былтыр гына аның житмештән узган Миңлегәрәй исемле улы үлеп киткән иде. Хәзер бабай Миңлегәрәйнең зур улы Миңлегалидә тора. Миңлегалинең дә өйләнгән улы, кияүгә чыккан кызлары бар. Миңлебай карт менә шуларның балаларын, ягъни үз токымының дүртенче буынын күрде. Дүртенче буын әкәмәт икән ул, бер дә бабай дигәнчә түгел. Ул хәтта аларның исемнәрен дә отып ала алмый. Вилне Вилдан дип, Эмманы Әсмабикә дип тик йөртә бирә...

Дөньяда чамасыз озак яши торгач, кайчандыр паровоз тавышын да ишетмәгән бабай тракторын да күрде, автомашинасын да, самолетын да, радиосын да күрде; алар аның авылына һәм өенә килеп керделәр, ләкин картның берсенә дә исе китмәде. Чөнки бу заманның барышына ис китеп өлгерерлек түгел иде.

Ләкин былтырмы икән, өченче ел микән, кемнәрнендер бу тирәләргә очып килеп, самолеттан бүре атып йөрүләрен ишеткәч, картның моңа шулай да исе китте. Кара син аны. Бүрене самолеттан гына «сугалар» диген, ә?.. Кайчандыр, бик күптән инде, ул үзе ир-егет чагында камчат бүрек, ак чикмән киеп, билен кызыл билбау белән буып, камыт күрмәгән сөлектәй яшь айгырга атланып далага чыгып китә иде дә, йөри-йөри бүренең эзенә төшкәч, аны уктай сузылып очкан бурзаеннан өсләтеп һәм ун-унбиш чакрым куа барып, озын саплы чукмары белән сугып ала торган иде. Менә бу ичмасам бүре сугу иде! Ә хәзер һавадан атып йөриләр, имеш. Моның ни кызыгы да, ни комарлыгы бар? Юк, әллә нишләде бу замана! Машина да машина, ә кешенең үз йөрәгенә, үз кулына ни кала?!

Миңлебай картның дөньяда да, колхозда да хәзер бер эше дә юк. Ул какланып беткән тәнендә бары жан асрый. Алдына куйганны утырып ашый, ястыгын тәгәрәтә дә ятып йоклый, шулай итеп гомерен суза да суза. Аның хәзер бер генә эше бар—ул ялан таптарга ярата. Һәр көнне иртәнге чәйдән соң ул, озын карагай таягын тотып, торнаныкыдай нечкә аякларын сыгылдырып кына буш урамнан уза, кырга чыга һәм юлсызнисез күзе караган якка таба китеп бара. Берәр түбә жиргә менгәч, озын таягын ике учлап, ерак кырларга тик кенә һәм озак кына карап тора. Бу күз житмәс Юлкотлы яланының бөтен ягын, андагы түбәләрнең, үзәннәрнең, чокырларның барысын да исемнәре белән белә. Хәзер инде ул исемнәрнең күбесе онытылып бара. Хәзер, мәсәлән, Каракош басуы яки Атчабар кыры дип түгел, ә фәләненче бригаданың да тәгәненче бригаданың участогы дип кенә йөртәләр. Юлкотлы яланнарын тоташтан сөреп бетерделәр. Иске чикләр, иске исемнәр барысы да күмелеп калды шунда...

Карт түбәдән төшеп китә, үзәнлекләрдән уза, иген басуларын буразна буйлап кисеп чыга, шулай итеп әллә никадәр жир әйләнеп, күп вакытта авылның икенче очыннан кайтып керә. Юлында очраган кешегә үзе башлап дәшми, ә берәрсе: «Саумы, Миңлебай бабай?»—дип дәшсә, «Ару але» яки «Шөкер!» дип кенә узып китә. Ни уйлап, нәрсә карап йөри торгандыр карт—белүче юк.

Менә бүген дә карчык, йөзгә-йөз очрашкач дәшмичә китүне килештермичә, үзе башлап аңа:

—Нихәл, арумы, Миңлебай агай?—диде, авызын учы белән генә каплый төшеп.

—Ә, синмени әле бу, Акбикә килен? Шөкер!—диде карт тукталып.

Житмештән узган карчык аның өчен һаман да килен иде әле, Акбикә дип тә бары ул гына дәшә, югыйсә, авыл халкы карчыкны күптән инде Акъәби дип кенә йөртәләр.

—Каян кайтып киләсең болай?—диде карт.

—Менә кизәк жыярга чыккан идем.

—Ә, ярый, ярый... Казан астында утның өзелмәве яхшы. Йә, үзең ару гынамы соң?

—Шөкер иде әле, тик менә бу көннәрдә генә әллә нишләп хәлем китеп тора,—диде карчык һәм тирләгән битен яулык очы белән сөртеп алды.

—Авырма инде, син—ялгыз кортка, карар кешең юк.

—Алладан вакыт җитмәгән булса, үтәр әле.

—Үтәр, Алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек,—диде карт, ияк очында гына ябышып торган берничә бөртек ап-ак кылдай сакалын селкетеп.—Ярый, кортка, юлыңда бул!

Һәм карт, озын аякларын сыга биреп, китеп тә барды. Ул карчыклар белән күп сөйләшеп торырга яратмый иде.

Акъәби, үзенең жил капкасына килеп житкәч, туры читән алачыкка узды. Бу эчтән балчык белән сылаштырылган жир идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда аш-суы да пешә иде. Жирдән аз гына күтәртеп салынган, калай моржасы туры гына кыектан чыгарылган учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты. Казанына өч-дүрт чүмеч су салды да учагына күп кенә итеп чыбык-чабык сындырып тыкты, ут төртеп җибәрде. Чыбыклар күмерләнеп төшкәч, алар өстенә иплəп кенә кизәкләр өештереп куйды. Аның исәбе башта су жылытып, табак-савытын юу, аннары әзер казанда үзенә бер-ике генә уҗау буш умач пешереп алу иде. Нигәдер күңеле бүген сызык йөгерткән буш умачны корот катып кына ашарга теләп тора иде. Ләкин карчык сизә, пешерә дә, ашый да алмас кебек; хәле бөтенләй бетеп бара, көчкә генә йөреп азаплана, гәүдәсе менә гел ятарга гына сорап тора... Ахырда түзмәде, казан астыннан кизәкләрне алгарак тартып, учагын сүрелтә төште дә бераз ятып торырга булды. Алачыктан өенә узышлый күрше ишек алдында йөргән яшь хатынга читән аша гына дәште:

—Гарифә кызым, минем казан астын гына кереп караштыра тор әле, әз генә ятып алмакчы булам, бер генә дә хәлем юк.

—Ә, ярый, ярый, Акъәби, карармын, борчылма, ят!—диде унган хатын, әбинең төсе качкан чыраеннан авыру булуын шунда ук чамалап.

Акъәби урам тәрәзәләре ябык, әрем себеркесенең исе аңкыган салкынча өенә керде, сәке түренә бөкләп куйган ястыгын җәйде дә, бисмилласын әйтеп, сырган юрган белән ябынып, бөгәрләнеп кенә ятты. Аның бик жылынасы килә иде. Ятып күзләрен йомуга, ул, салкын бер чоңгылга баткандай, башта туңып китте, кымыржып, акрын гына калтырана башлады. Күпмедер вакыттан соң бераз гына жылынган кебек булды, ләкин тәмам эреп, изрәп китә алмыйча, ярым уяу, ярым йокылы хәлдә һаман бөрешеп кенә ята бирде. Бераздан Гарифә кереп хәлен белде, ашыйсын-эчәсен килмиме, дип сорады. Әби: «Локма да кабасым килми, кайнар чәй генә эчәр идем»,—диде. Гарифә алачыктан утлы көл өстендә генә пешергән куе чәй китереп, чынаягына карлыган кагы салып, шуны сыек бал белән генә аңа эчерде. Әбинең жыерчыклы ябык куллары һәм кипкән иреннәре калтырый иде. Шулай да ул тәлинкәне үз кулы белән тотып эчте, Гарифәгә күп итеп рәхмәт әйтте, тирләп бер йокласам, иртәгә, Алла боерса, аякка басармын, диде, тик бүген инде көтү кайткач, кәжәсен савып, сөтен баз өстенә генә куярга кушты. Гарифә барысын да эшләргә булды, тыныч кына ятарга кушты һәм карчыкның өстен әйбәтләп ябып чыгып китте.

Ләкин карчык икенче көнне дә, өченче көнне дә аягына баса алмады. Күрәсең, авыруы аның болай бер-ике көн генә ятып үткәзеп җибәрерлек түгел иде. Ниндидер житди чиргә охшый. Карчык үзе алай дип уйларга тырышмаса да, әллә ходайдан вакыт житүе шушы микән, дип шомаланып та куйгалый иде.

Күршеләре кереп аның хәлен һаман белә тордылар, Гарифә исә ашау-эчүен кайгыртып, йорт-жирен һаман карый йөрде. Шулай да карчыкның хәле бер дә алга бармагач, аңа, әллә улларына, кызларына хәбәр итикме, болай яту ярамас бит, дия башладылар. Ләкин Акъәбинең өмете зур иде әле, ерак каладагы балаларын бер дә борчыйсы килми иде.

Аннары болай да берәрсе кайтып китмәсме дигән өмете дә юк түгел иде. Кайткалыйлар иде әле аның уллары яки кызлары, инәләрен онытып бетермиләр иде, исән генә була күрсеннәр инде.

Карчыкның соңгы еллардагы гомере шул балаларының кайтып китүләрен көтеп яшәү белән генә уза башлады. Дөрес, моннан ун ел элек, карты үлгәннән соң, балалары карчыкны калага тартып караганнар иде дә каравын, ләкин Акъәби гомер иткән нигезен ташлап китәргә теләмәде инде. Шушы Юлкотлыда туган ул, үскән ул, шушы Каһарман карт өенә килен булып төшкән, шушында илле биш ел яшәгән, уллар-кызлар үстергән. Шушы Юлкотлы туфрагында аның атасы, анасы, күпме туганнары, яшьли үлгән сабыйлары, гомер иткән карты ята—йә, ничек шуларның барысын да ташлап китәсең?.. Күп торасы да калмагандыр, ят җирнең туфрагына барып ятканчы, шушында үзенең ата-анасы, карты, сабыйлары янында булыр—шулай уйлаган иде карчык ул чакта. Һәм, һичнигә карамастан, хәзергә чаклы ул шушы ниятендә нык торды.

Шулай да карчыкка җинел түгел иде. Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зыяратта ятучы әрвахлар нихәтле генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлыгын җиңеләйтә алмыйлар иде. Ялгыз башын монда асраса да, күңеле белән ул һаман шул балалары янында иде. Шуларны уйлап, шуларны сагынып, шыксыз озын көзләрне дә, салкын кышларны да уздырып җибәрә; сабыр гына җәйне көтеп ала, ә җәен берәр улымы яки кызымы балалары белән кайтып китәргә тиеш аның... Шулай көйләнде инде карчыкның тормышы: асылда җәйнең бер атна-ун көне өчен генә яши ул һәм ел буе диярлек тик шуна әзерләнә. Маен-күкәен дә шул көнгә дип җыя, итен-казылыгын да балаларым өчен дип каклый, шомыртын, эремчеген, коротын да шулар өчен киптереп куя. Бигрәк тә оныкларын бик сагына карчык. Шулар кайтса инде, куанычы эченә сыймый, бөтен дөньясын оныта, үзе дә бер бәйрәм итеп кала, бичара. Тик бу бәләкәчләрнең әти-әниләре карчык янына гадәттә бик кыска вакытка гына кайталар. Алар, ни хикмәттер, гел ашыгалар. Кайсы-ның эше көтә, кайсының курортка китәсе була, аннары, балаларыбыз авыл җирендә авырып-нитеп китә күрмәсен, дип куркалар да булса кирәк, кыскасы, бер атна торгач та, карчыкның бик тилмереп соравына карамастан, юатыр өчен кулына мул гына акча тоттырып, вәгъдәләр биргән булып, китеп тә баралар. шулай итеп, ел буе көтеп алган санаулы көннәр төш кебек кенә үтә дә китә. Аннары тагын шул кыска гына тансык төшнең яңадан инүен көткәндәй, озын йокыга охшашлы ялгыз гына яшәү башлана.

Нишлисең, заманасы шулай туры килде инде. Акъәбинең сабый чактан исән калган балалары үсә тордылар, күрше авылның урта мәктәбен бетерә тордылар, һәркайсы, канат чыгарган кош кебек, Юлкотлыдан еракка оча торды. Хәзерге вакытта бер улы белән бер кызы Өфедә яшиләр. Тагын бер кызы, врач булып чыкканы, Пермь өлкәсендә тора, ә иң кече малае, институтны бетергәч, Казакъстанга җибәрелгән иде, шунда, исеме дә билгесез бер шәһәрдә, кемдер булып эшли.

Өфедәге иң зур улы Суфиян хәзер инде отставкага чыккан полковник, ә кызы Гөлбикә фәнни институтларның берсендә гыйльми эштә, кияве исә аның, Чакмагош башкорты, зур җаваплы урында утыра. Кыскасы, барысы да зур кешеләр булып беттеләр. Кайсы галим, кайсы инженер, кайсы врач... Борын заманда бер ата-анадан түгел, бөтен өязеннән бу кадәр укымышлы башкортлар чыкмагандыр. Акъәби үзе кыз чагында башкорттан яки татардан доктор барлыгын ишеткәне дә юк иде. Әле дә хәтерли, элек авылда берәрсенең теше сызласа, моннан унсигез чакрымдагы чуваш авылына, тәмәке алып кайтыр өчен, ат мендереп кеше чаптыра торганнар иде. Булган заманнар. Юк, аның балаларына килде инде бәхет, килде, әйтәсе дә түгел!

Тик менә бик бәхетле булып киткән балалары аңардан ничектер

шактый ераклаштылар. Зарланса язык булыр, карыйлар, ярдәмнәреннән ташламыйлар, рәхмәт үзләренә, тик шулай да карчык борчылып уйламыйча булдыра алмый: туган җирләрен дә, кечкенә Юлкотлыны да, аталарыннан калган нигезне дә алар бөтенләй онытып баралар кебек. Уйлары да, күнелләре дә бүтәндә булса кирәк... Менә зур улы Суфиян. Күпме ил гиздe, нинди зур дәрәҗәгә иреште, олайды, үзенең дә ул-кызлары үсеп житте, инде хәзер беркайда да эшләми. Зур пенсия ала, машинасы бар—ана бит Юлкотлыга ешрак кайтса да була хәзер... Ләкин, нишләтәсең аны, һаман вакытым юк дип зарлана, ниндидер комиссияләрдә эшләп йөри, кышын бер-ике айга курортка китә, йә булмаса үзе кебек погоннарын салган полковниклар белән төннәр буе карта сугып утыра, ә җәйгә чыккач, машинасына хатынын, бала-чагаларын утырта да йә Кырымга, йә хатынының урыс туганнарына—Саратовка китеп бара. (Суфиян сугышка чаклы ук әле, Саратовта хезмәт иткән чагында маржа кызына өйләнгән иде, һәм Акъәбинең ул чакта мона күнеле бик тә сыкранган иде.) Ә каладан йөз егерме чакрымда гына торган Юлкотлы читтә кала, әнисе-карчыкның алар өчен генә дип саклаган казлары келәтендә шул килеш эленеп тора. Полковникның кереп туган авылын күрергә һәм әнисен куандырырга вакыты да, җае да табылмый. Ничек монда күнел сыкранмасын, ди.

Шулай да былтыр җәй Суфиянның житкән улы Геннадий үзләренең машинасында «бабушканы» күрергә дип кайткан иде. Өч көн торды, өч көн Акъәби бер кәлимә башкортча белмәгән оныгы алдына барлык сыйларын куйды, сүзсез генә ана монсу һәм назлы итеп карап утырды. Егет җирән чәчле иде, таза иде, физкультурник иде; урам буйлап чыгып киткән чакларында карчык анын чуар күлмәк кигән кин аркасына читән аша гына карап кала иде. Егет бер көн эчендә Юлкотлының бөтен тирәягын йөреп чыкты; машинасына ыбыр-чыбыр балаларны төяп, әллә кайлардан үзләрен йөртеп кайтарды, аннары колхоз келәтендә аунап яткан ике потлы гер ташын табып кайтты да иртә-кич гел шуны күтәрепчөеп уйный башлады.

Кечкенә авылда егеткә аралашыр өчен үз тиннәре бөтенләй юк диярлек иде,—кызлар җәйләүдә яталар, егетләре каядыр таралышып беткәннәр,—һәм Акъәбинең мона бик эче поша иде. Оныгының күнелен табар өчен, ул әледән-әле ана башкортча нидер әйткән була, ләкин Геннадий, берни анламыйча, «бабушкасына» бик юмарт елмаеп карый, җавапсыз калмас өчен генә:

—А, да-да, точно!—дип баш кагып куя иде.

Әби белән оңык арасында бер кызык хәл дә булып алды. Шулай иртәнге чәй янында оныгын сары майда гына йөзгән әче коймак белән сыйлаган чакта Акъәби «безнең башкорт халкы...» дип нидер сөйли башлаган иде, Геннадий, шуны үзенчә анлап булса кирәк, көтмәгәндә генә баш бармагы белән күкрәгенә төртеп:

—Я—башкирин, бабушка, башкирин!—диде, һәм, житмәсә әле «борчылма!» дигәндәй, әбисенә күз дә кысып куйды.

Акъәби уйчан гына ана карап торды, үзалдына гына көрсенгәндәй итте, аннары монсу-назлы итеп кенә елмайды: нишлисен, бу җирән чәчле егеттә анын каны, башкорт каны ага иде шул!

Менә шулай Акъәби ялгыз башы шушы көнгә чаклы улларын, кызларын көтеп, оныкларын сагынып, алар турында үзенең күнелле һәм күнелсез уйларын эченнән генә уйлап, исән-имин генә яшәп килде. Җәйгә чыгу белән, һәрвакыт өметләре уяна торган иде, бәйрәм көннәрен көткәндәй рухланып, шуна бер дә иренмичә әзерләнә башлый иде. Әмма быел, ходайдан вакыт житкәнме, җәйгә аяк басу белән, үзен начар сизә башлады һәм бирешмәскә тырышып йөрде-йөрде дә ахыр чиктә менә урынга ук ятарга мәҗбүр булды.

Башта торып китәрмен дигән өмет белән ятты, күршеләренең калага улларына хәбәр итик дигән сүзләрен дә кире какты, әмма ләкин хәле

аның отыры начарлана барды. Биш-алты көн эчендә ул күзгә күренерлек булып суырылды, саргайды, ашаудан калды. Күршеләре, карчыкның болай начарлана баруын күреп, хәвефкә төштеләр, нишлик икән, дип үзара киңәшеп тә алдылар, ахырда Юлкотлыдагы колхоз бригадиры Сәетгалигә хәбәр итәргә булдылар.

Колхоз идарәсе моннан алты чакрымдагы Сыртлан авылында иде, шунлыктан Сәетгали кечкенә Юлкотлыда бердәнбер хуҗа һәм баш кеше. Һәр көнне иртән иртүк ул, мотоциклының сиртмәле биленә атланып, такыр юлдан пырылдап, тирбәлә-тирбәлә Сыртланга китеп бара, ә кич белән тагын шулай җен кебек машинасында тумырылып кайтып җитә иде. Гарифә барып әйткәч тә, Сәетгали икенче көнне үк, Сыртланга узышлый, үзенең мотоциклында пырылдап, Акъәбинең капкасы төбенә килеп туктады. Акъәби шунда ук кем килгәнен белеп алды һәм, ни өчен икән бу, дип борчылып уйлап куйды. Ул арада ишектән, иелә биреп, тузанлы күн итекләрдән, бригадир белән председательләр өстендә генә очрый торган, капчыкланып беткән зәңгәр пинжәктән Сәетгали үзе дә килеп керде.

—Саумы, Акъәби?—диде ул, таза кешегә дәшкәндәй юри кычкыра биреп.—Бәй, ни булды, әллә авырып калдыңмы?

—Авырыйм шул, Сәетгали,—диде карчык, гаепле кеше сыман итеп.

—Куй, юкны сөйләмә, гомердә авырмаганны... Синең кебек корткага килешәмени ул!

Сәетгали, килеп, сәке кырыена гына утырды, карчык юрганын үзенә таба җыя төште.

—Килешми дә бит, нишлисең, ходайдан вакыт җиткәч...

—Җиткән ди сина... Болай гына, салкын-фәлән генәдер әле... Кай җирең авырта соң?

—Авырткан җирем дә юк кебек... Тыным кысыла, сулавы авыр...—диде Акъәби, бугазын һәм күкрәген сыйпап.

Сәетгали карчыкның суырылган, саргайган йөзенә беравык сынап карап торды.

—Йә, нишлибез, Акъәби, доктор чакыртыйкмы?

—Кирәкмәс, Сәетгали улым, иншалла болай да үтәр әле...

—Үтә күрсен!—диде Сәетгали, карчыкка тагын да сынабрак карап. Юк, шулай да карчыкның хәле бер дә шәпкә охшамый, йөзе лимон кебек сары, күзләре тоныкланып тора.—Әллә, мин әйтәм,—диде бригадир сак кына,—калага хәбәр итикме? Суфиян агай, йә булмаса, Гөлбикә апай килеп китсә, зарар итмәс... сөйләшерсез...

—Юк, кирәкмәс, сабыр итик әле, алар да эшле кешеләр,—диде карчык, эченнән генә үзенекен уйлап.

—Анысын куй,—диде Сәетгали, урыныннан торып,—бер әсәйләре өчен вакыт табарлар әле. Ярый, идарәгә баргач, мин Гыйльман агай белән сөйләшермен. Берәр чарасын күрербез. Ә син, әбекәем, тыныч кына ят. Терел.

—Иншалла!.. Рәхмәт керуеңә, Сәетгали улым.

Сәетгалигә ияреп, Гарифә дә өйалдына чыкты. Алар анда пышын-пышын гына нидер сөйләшеп тә алдылар. Аннары мотоциклның каты гына пытыр-пытыр итеп кузгалып китүе ишетелде, һәм озак та үтмичә, аның тавышы ераклашып, ниһаять, бөтенләйгә тынды.

Ә берничә көннән соң Сыртлан ягыннан Юлкотлыга таба тузан уйнатып килгән өр-яңа яшел «Волга» машинасы күренде. Һәм, киң урамның күк үләнендә ярылып яткан кара эз калдырып, Акъәбинең капкасы төбенә килеп тә туктады. Машинадан җәйге габардин пальто, күк эшләпә кигән зур, таза гәүдәсе бер ир белән ефәк плащ кигән, зәңгәр косынка бәйләгән озын буйлы ябык кына бер хатын чыктылар. Болар Акъәбинең кызы белән кияве иделәр.

Алар урам тәрәзәләре ябык карангырак өйгә килеп кергәч һәм кызының: «Әсәем!»—дип дәшүен ишеткәч, йокылы-уяулы хәлдә яткан

Акъәби сискәнеп күзләрен ачты, бер мәлгә өнемме, төшемме бу дигәндәй аптырап, каушап калды, аннары куанычыннан онытылып китеп, капыл гына урыныннан тормакчы булды.

—Кызым, Гөлбикә!—диде ул, өзелеп.

Кызы шунда ук килеп, аның өстенә иелде, мангаеннан үпте, һәм алар тотынышып икесе дә елап җибәрделәр. Мәһабәт кияве дә, килеп, карчыкның кипкән ябык кулын зур, таза кулларына алды, иелә төшеп, күтәренке тавыш белән: «Нихәл, әби җаным, авырып киттеңмени? Ничево, ничево, берни дә булмас!»—диде һәм, пальто чабуын кайтарып, аз гына читкәрәк, сәке кырыена утырды. Кызы да чәжлап торган плащы белән әнисенең аяк очына чүкте. Алар икесе бертавыштан карчыкка кузгалмаска куштылар. Ләкин карчыкка кияве белән кызы алдында болай авырып ятуы гаҗәп унайсыз иде, һичнигә карамыйча, аның тизрәк торасы, кадерле кунаклары өчен әүвәлгечә бөтерелеп йөрисе килә иде, әмма тик, нишләсен, ятарга чарасыз мәҗбүр иде. Шулай да ул түшәк өстенә торып утырды һәм Гарифәгә урам тәрәзәсен чыгып ачарга, тизрәк самовар куярга кушты.

Тәрәзә капкачы ачылгач, өй эче яктырып китте. Акъәби шәһәрчә бик пөхтә киенгән кадерле кызы белән кадерле киявенең чиста, шома йөзләрен күрде. Күрде дә үз хәленнән тагын бер унайсызланып, елыйсы килеп, авыр сулап куйды. Үз нәүбәтләрендә алар да бик ябыккан, тәмам кечерәеп калган әниләренең зәгъфрандай саргайган, сулган йөзен күрделәр. Күрделәр дә, сүзләрен оныткандый, бер мәлгә тынып калдылар һәм яшерен генә карашып алдылар. Болай ук булыр дип көтмәгәннәр иде алар. Хәер, колхоздан калага шалтыраткач та, алар карчыкның чынлап авырып китүен белеп, башта ук тәгаен бер ният белән юлга чыкканнар иде. Хәзер исә ике төрле сүз булырга мөмкин дә түгел. Эшләре тыгыз, вакытлары юк, шуңа күрә сүзне озынга сузмыйча, карчыкка шул ниятләрен әйтергә булдылар.

—Әсәем,—диде кызы, әнисенә үрелеп.—Без сине үзебез белән алып китәргә дип килдек. Калада докторларга күрсәтербез, әйбәтләп карарбыз, анда тизрәк терелерсен.

Кияве дә шунда ук өстәде:

—Дөрес, әби, бездә сиңа әйбәтрәк булыр, монда доктор да юк, караучы да юк, ялгызың нишләрсең?

Карчык тиз генә җавап кайтара алмады, аның кинәт күңеле тулды, шул ук вакытта нигәдер бик борчылып та куйды.

—Рәхмәт инде, балалар!—диде ул, бераздан әкрен генә.—Юкка мәшәкатьләнгәнсез, үз өемдә дә терелер идем әле ходай насыйп итсә.

—Юк, әсәем, сине хәзер монда калдырып китеп булмый,—диде кызы, кабаланып.—Алып китәбез. Яхшылап дәваларга кирәк сине...

—Өй ялгыз кала бит.

—Калсын, берни дә булмас, күршеләрең карый торырлар.

Карчык бүтән бер сүз дә әйтмәде, сулап кына куйды, монда доктор каравыннан башка, мәтрүшкә-фәлән эчкәләп кенә терелеп китмәсен үзе дә аңлый иде булса кирәк. Аннары япа-ялгыз яту да аны шомландыра иде. Ә тегендә, калада, бөтен балалары диярлек, ходайдан вакыт җитеп, алай-болай булып китсә, алар аның янында булачаклар. Әмма шул ук вакытта нәкъ менә шушы «алай-болай булып», ягъни үлеп китүен уйлап, ул үзенең гомер иткән почмагыннан чыгып китәргә дә теләми иде. Чит җирдә үлү, чит җир туфрагында ятып калу аны һәрвакытта куркыта иде. Юк, аның шушында, карты җан биргән кечкенә өендә үләсе, авылдашлары кулы белән кечкенә авыл зыяратына—карты һәм яшьли үлгән сабыйлары янына куеласы килә иде. Ләкин ничек итеп менә хәзер ул алырга дип килгән кызы белән киявенең ихтыярына каршы тора алсын? Чыкмаган җанда өмет бар, дигәндәй, бәлки, алып китеп, чынлап та терелтеп, аякка бастырып кайтарырлар, шуның өчен килгәннәр бит. Юк, авыр иде карчыкка бу төенне чишү, бик авыр иде!

Чәй урынын карчык янына, сәке өстенә әзерләделәр. Карчык яткан җиреннән генә, Гарифәгә кушып, үзенең сыйларын—баздан сөтен, маен, чоланнан кәрәзле балын, каклаган казылыгын табынга китертте. Ярлырак та бит, нишлисең, таза чагы булса, үзе тиз генә берәр кайнар аш та өлгертер иде, ә болай кешегә кушып кына буламыни ул. Аннары кызы белән кияве дә: «Борчылма, әсәй, бик әйбәт, бик житкән»,—дип кенә торалар. Ашыгалар, күрәсең. Алып китәргә дип килгәч, алар үзләре дә бу юлы күчтәнәчләр төяп кайтмаганнар иде. Шулай да кызы берничә лимон белән бер кап шоколад конфетлар китергән икән, шуны табынга чыгарып куйды. Лимон авыру карчыкның нәфесе бик теләп торган нәрсәсе иде, ул аңа бик сөенде, хәтта кулына алып иснәп-иснәп тә карады.

Табын әйләнәсенә утырыштылар. Гарифә чәй ясый башлады. Карчыкка берьюлы рәхәт тә, күңелле дә булып китте. Менә ходаның рәхмәте, кәтмәгәндә генә ул иң кадерле якыннары белән бер табында утыра бит әле. Аның өчен елына бер генә килә торган бәхет бит ул, гел шуны көтеп яши иде бит ул, тик менә, кызганычка каршы, урын өстендә каршы алырга туры килде үзләрен. Шуңадыр ахры, бу минутта аңа никадәр генә рәхәт булмасын, нечкәргән күңеле нидер сизенгәндәй ирексездән ямансулап та, шомланып та куйгалый иде. Хәерлегә була күрсен иде...

Чәй янында сүз дә гел киту белән бәйләнгән эшләр турында барды. Карчыкка авыр иде бу сөйләшү, китүенә бер дә ышанасы килми иде, шикелле, шуңа күрә күбрәк кызы бу турыда кайгырып утырды. Аның соравы буенча карчыкның кәҗәсе белән тавыкларын Гарифә карап торырга булды. Келәтнең үз йозагы бар икән, өйне бикләргә дә бер иске богау йозагы бар икән әле, Гарифәгә шуның белән өйне бикләп, ачкычын үзендә сакларга куштылар. Боларны тыңлап утырганда, карчыкның рухы акрынлап һаман сүнә барды. Ахырда түзмәде, өзелергә торган тавыш белән еламсырап әйтте:

—Ходаем, гомер иткән өемә йозак салып китәрмен, дип уйлаган идеммени мин...

—Әсәем, бу ниткән сүз?—диде кызы, гаҗәпләнгән булып.— Бөтенләйгә ташлап китмисең бит, менә тиздән терелеп, үзең дә кайтып житәрсең.

Карчык: «Юат инде, кызым, юат!»—дигәндәй, үзалдына моңсу-загыйфь кенә көлемсерәп куйды, әмма кайтарып бүтән бер сүз дә әйтмәде.

Чәйдән соң юлга да әзерләнә башладылар. Кияү кеше ашыга иде, аңа ниндидер бер кичке җыелышка кайтып житәргә кирәк икән. Ул машинасы янына чыгып китте. Тузан кунган яшел «Волга»ны бала-чага сырып алган иде. Аягына чак тәпи басканы да ава-түнә килеп житкән. Зурраклары машинаның бөтен ялт иткән нәрсәләрен тотып-сыйпап, әйләнеп йөриләр, тик түбәсенә генә менеп китмиләр. Зур, таза абзый чыккач, алар башта куркып читкә сибелделәр, ләкин тиз үк янадан машина тирәсенә җыела башладылар. Аларның тынгысыз елтыр күзләре бу шәп агайга, машинасында бер йөртеп килмәсме, дигән ышанычлы өмет белән, гел чекрәеп карап кына торалар. Хәтта бер кап-кара башлы малай әрсезләнеп һәм юмаланып сорап та куйды:

—Агай, ә, агаем, безне анавы очтан гына бер йөртеп килсәң инде!

Мәһабәт агай башын кагып, телен шартлаткан булды:

—Юк шул, малайлар, булмый хәзергә, ашыгабыз. Менә Акъәбиегезне китерә килгәч, мин сезне рәхәтләнеп бер йөртеп кайтарырмын, ярыймы!

Малайлар, Акъәби дигәнне ишеткәч, шунда ук тындылар, артык бәйләнеп тормадылар. Кайчагында алар мәсьәләнең житдилеген зурларга караганда да тизрәк аңлый беләләр иде.

Шул арада читтәге капка төпләрендә җыелышып торган корткалар, хатын-кызлар да акрынлап килә башладылар. Акъәбине алып китәләр, дигән хәбәр кечкенә авылга бик тиз таралып өлгерсә дә, хатын-кызлар каладан кайткан кадерле кунакларга ашап-эчкәндә комачауламас өчен

шулай әдәп саклап, күтәребрәк торганнар иде. Хәзер инде менә килделәр, олыраклары өйгә үк кереп киттеләр. Акъәби аларга бик якын кеше, гел бергә яшәгәннәр, ана бик ияләшкәннәр, шуңа күрә аны ерак юлга, билгесез сәфәргә озату алар өчен шактый зур вакыйга иде. Йөзләре дә аларның житди-уйчан иде, нидер сизенәләр иде, ахрысы, һәркайсында корткабызны янадан инде күрә алмабыз дигән уй ята иде шикелле... Гажәп бит ул,—кеше берәүнең дә үлүен теләми, әмма шул ук вакытта ничектер ихтыярсыздан шул үлемнең буласын сизеп, көтеп тора кебек...

Бераздан кара бишмәтен, оек-калушын кигән, чәчәкле зур шәлен ябынган Акъәбине кызы белән Гарифә ике ягыннан култыклап, акрын гына өйдән алып чыктылар. Алар артыннан бер хатын зур мендәр күтәреп чыкты.

Кияү машина ишеген ачты. Карчыкны ипләп кенә утырттылар, мендәрен, таяныр өчен, янтыгына салдылар. Кызы янәшәсенә кереп утырды. Машина тәрәзәсенә хатын-кыз башлары иелде.

—Акъәби, жаным, хуш, сау бул инде!

—Акъәби, бәгырем, терелеп кайта күр!

—Хуш, безне онытма, без көтәбез сине!—диделәр ана.

Ә таякка таянган бер корткa:

—Хуш, яшьтәш, бәхил бул, ахирәттә күрешергә насыйп итсен!—диде, бик тыныч, әмма чын күнелдән бик ихлас итеп.

Гөлбикә иренә тизрәк кузгалырга кушты. Машина алдында торучыларга кыска гына бер гудок бирде дә шома гына кузгалып китте.

Аз гына китүгә, Акъәби кинәт урыныннан кузгалып:

—Һай, кәфенлегемне оныткамын лабаса!—диде, нишләргә белмәгәндәй бик борчылып.

Кызы бу көтелмәгән сүздән сискәнеп киткәндәй булды һәм чыраен сытып:

—Куйсана, әсәй!—диде, үпкә катыш рәнжү белән.—Таптың искә төшерер нәрсә!

Карчык дәшмәде, күзләрен йомып, хәлсезләнеп башын гына иде.

Яшел машина йомшак кына тирбәлеп һәм тузан уйнатып, Юлкотлыдан зур калага таба чыгып китте. Кечкенә өйнең капкасы төбендә жыелышып калган хатын-кызлар бөтерелеп тузан сузылган юл буена, машина күздән югалганчы, тик кенә карап тордылар.

## II

Менә Акъәби ялгызы кечкенә бер бүлмәдә, сиртмәле тар караватта, ак түшәмгә карап һәм каяндыр түбәннән тоныкка ишетелгән зур кала гөрелтесенә колак салып, тыныч кына ята. Урыны йомшак, астында чип-чиста ак җәймә, өстендә сатин юрган—ипле, рәхәт аның арык-жинел гәүдәсенә... Рәхмәт инде киявенә дә, кызына да,—аны менә шулай кадерләп, аерым бүлмәгә урнаштырдылар. Дөрес, ул аларны бер дә тыгызлыйсы килмәгән иде килүен, ләкин кияве белән кызы бу хакта авыз да ачтырмадылар. Хәтта элек бу бүлмәдә торган асрау кызларын да кухняга чыгардылар. Тик бераздан гына сизде карчык: монда авыру кешенең яткан жире генә түгел, ашаган-эчкән савыт-сабасы да аерым булырга тиеш икән.

Гомумән, карчыкка башта игътибар бик зур булды. Беренче көнне үк шәһәрнең икенче читеннән отставкадагы полковник улы белән килене дә аны күрергә килеп життеләр. Чүкечтәй нык, базык гәүдәле, зур йомры башлы, кыска имән муенлы полковник Суфиян, әйтергә кирәк, кәкре аякларындагы тар кунычлы хром итекләре белән генә түгел, бөтен кыланыш-гадәтләре белән дә чын «янарал» булырлык, беткәнче хәрби бер кеше иде. Кычкырып, кырт кисеп сөйләшә ул, берәүдән дә тарсынмыйча киерелеп, шаркылдап көлә һәм, иң мөһиме, үзен бик хаклы рәвештә дөньяның хуҗасы санап, бернигә исе китмичә, рәхәтләнеп

яши иде. Квартир менә диган, машина бар, пенсия җитәрлек, шуның өстенә аучылар җәмгыятендә нидер эшләп тә шактый акча төшергәли, кыскасы, әле чак иллесен тутырган полковникның тормышы бал да май, ал да гөл иде.

Әнисе карчык янына күрешә килгәч тә, ул карлыккан тавыш белән бүлмәне яңгыратырга тотынды:

—Һай, әсәй, әсәй, әсәем!—диде, әнисенең кипкән кулын каты учларына алып.—Ни булды сиңа, авырып киттеңмени, ике күзем?.. Ну, ничево, түлке син паникага бирелмә. Безнең генерал әйтә торган иде: солдатны пуля түгел, паника үтерә, дип...

—Нәрсә соң ул... пәникә дигәнең, улым?

—Улмы, ул ни... курку, әсәем!

—Мин бер дә курыкмыйм, улым,—диде карчык тыныч кына.—Тәкъдирдән узмыш юк, барысы да Алла кулында.

—Һи, әйттең тагын! Барысы да безнең кулда!—диде полковник, һаман шаулап.—Менә мин сиңа докторның иң шәбен үзем алып килермен, әсәй!..

—Рәхмәт, улым, рәхмәт!

Карчыкның килене, өч башкорт бичәсенә торырлык юан, мәһабәт, ап-ак Мария Васильевна, каенанасы белән ике куллап, бик җитди итеп күреште. Карават карыена урындык алып утырды да, авыруның хәленә керергә теләгәндәй, аңа чын кызгану белән карап тора башлады. Юрган астында бала шикелле сизелер-сизелмәс кенә яткан бу каенана дигән сап-сары йөзле карчыкка аның нидер әйтәсе дә, кайгыртып нидер сорыйсы да килде, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, тел юк—карчык бер кәлимә русча, ә килен бер авыз башкортча белми иде. Шулай да Мария Васильевна ире аркылы булса да берничә сорау бирде.

—Әсәй, киленең менә синнән кай җиреӊ авырта дип сорый.

Карчык уйчан-моңсу гына әүвәл улына, аннары килененә карады.

—Тыным кысыла,—диде ул, күкрәген күрсәтеп.—Хәлем бер дә юк.

—Күптәнме?

—Тыным бетүен кыштан ук сизә башладым. Ә хәлсезләнүем күптән түгел...

Суфиян карчыкның сүзләрен русчага әйләндергәч, Мария Васильевна иреннәрен мәгънәле генә кысып, башын селкеп торды. Аннары ашыкмыйча гына нидер әйтте.

—Әсәй, киленең әйтә,—диде Суфиян,—опасный берни дә булмас, бронхлары ниткәндер, борчылмасын, ди.

Карчык дәшмәде, тик күзләре белән генә рәхмәтен белдереп, килененә бер тутырып карап алды.

Икенче көнне карчык янына күрешергә дип Суфиянның зур улы Геннадий да килде. Геннадий инде Юлкотлыга барып, әбисендә кунак булып кайткан егет, шуңа күрә ул карчык белән бик үз булып: «Ха, бабушка!»—дип шатланып күреште һәм, урындык алып, караваты янына утырды. Акъәби сөенеп-яктырып, башкортча: «Улым, килдеңмени, рәхмәт төшкерем!»—диде, ә егет аның ни әйткәнен аңлагандай, елмаеп башын какты. Әйе, карчык бу дәү, сары егетне, үз нәселенә һич охшамаса да, чынлап ярата иде—барыбер аның токымы ич, аның каны!.. Нишлисен, якын шул, бик якын!.. Тик егет үзе «бабушкасының» йөрәгендә аңа карата нинди тирән һәм газаплы мәхәббәт ятканын сизәме икән?.. Юк, сизәргә тиеш, әнә килгән бит әле ул, әнә елмаеп әбисенә нидер әйтә дә бит әле... Ах, бу тел юклыгы!.. Карчыкның тел өйрәнер вакыты күптән үткән шул инде, әмма нигә бу Суфиян, юньсез, балаларына, ичмасам, әбиләренә дәшә алырлык кына үзебезчә берничә дистә сүз өйрәтмәде икән соң?!

Егет әдәп кушкан кадәр утырганнан соң кузгала башлады, торып, әбисенең кипкән ябык кулын сыйпады һәм: «Пока, бабуся!»—дип баш какты да чыгып китте. Карчык аңардан бик шат, риза булып калды.

Шул ук көнне тагын Суфиянның өч кызы—Татьяна, Светлана,

Рита белән кече малае Борис та әбиләре янына килделәр. Кызлары да суеп каплагандай әниләренә охшаганнар, әниләре кебек барысы да эре сөякле, жирән чәчле, зур соры күзлеләр... Тик Боря (Борис) гына атасына охшаган, атасы кебек зур башлы, зур битле, арыш чумарыдай кап-кара бер малай иде. Бусын инде бер дә икеләнмичә Суфиян малае Шәяхмәтов дип йөртергә була.

Кызлар әбиләрен сырып алдылар, шаулап: «Здравствуйте, дорогая бабушка!»—дип күрештеләр, алып килгән чәчәкләрен карават янындагы тәрәзә төбенә утыртып куйдылар, урындыгына шоколад конфетларын салдылар һәм, инде ни әйтик, дигәндәй, күзләрен елтыратып, әбиләренә карап тора башладылар. Шушы икән инде ул папаларына мама тиешле әби-карчык! Үзе кечкенә, үзе арык, өстенә кин җинле әкәмәт кенә күлмәк кигән, башына вак кына чәчәкле сары яулык бәйләгән, в общем, типичная башкирка икән.

Ә Акъәби үз нәүбәтендә житеп килгән бу таза, зифа кызларга уйга калып, исе китеп, селкенмичә карап ята. Аннары зәгыйфь кенә елмая, иреннәрен кыймылдатып куя—нидер әйтергә тели, ахрысы... Менә ул күзләрен Боряга төби, әкрен генә кулы белән ымлап, аны якынрак килергә чакыра. Боря курыккандай башын сөзеп, каш астыннан гына карап, кузгалмыйча тора, тик апалары «иди, иди» дип аркасыннан этәргәч кенә әбисенә якынлаша. Карчык бердән яктырып, малайның аркасыннан сөеп: «Бәбкәчем, ди,—зур егет бул, Алла тәүфыйк бирсен үзенә!»—ди... Малай берни аңламыйча, кызарып, әбисе яныннан тизрәк китә, ә кызлар, нидер әйтеп, шаулап көлешәләр... Карчык исә һич үпкәсез, әмма боек-сагышлы итеп, тирән генә бер сулап куя. Әйе, бу балалар, никадәр ят-сәер күренмәсеннәр, аның үзенеке шул, үзенеке!.. Улының кемгә өйләнүенә, ничек яшәвенә бәгыре күпме генә сызланмасын, әмма оныклары ана бик якын, бик газиз шул!.. Минем байлыгым, дип кенә йөртә ул аларны...

Бер-ике көннән соң кызы Гөлбикә доктор чакыртып китерде. Урта яшьләрдәге таза, мөлаем хатын доктор Акъәби белән бик ачык сөйләште, күп сорашты, аннары күкрәген алдан да, аркасыннан да әйбәтләп тыңлады, тик ни өчендер карчыкның үзенә авыруы турында бер сүз дә әйтмәде. Кызы белән залга чыгып, шунда икәүдән-икәү генә сөйләштеләр.

Әкъәби күңеленә нәрсә генә килсә дә, сабырлыкка өйрәнгән гадәте буенча артык борчылмыйча, шомланмыйча, тыныч кына ята бирде. Ләкин докторларны озатканнан соң янына кергән кызының бик житдиләнеп киткән йөзенә карап, ул эшнең серен сизенгәндәй булды. Дөрес, кызы ана берни әйтмәде, әмма бу киеренке хәрәкәтсез чырай, бу юри ана карамаска тырышкан борчулы күзләр хәлнең ничек икәнлеген һәртөрле сүздән дә ачыграк әйтеп торалар иде кебек... Ә хәлләр чынлап та бик шомлы-куркыныч иде: докторлар карчының үпкәсендә яман шеш (рак) таптылар. Алар фикеренчә, житмештән узган карчыкка операция ясап торудан мәгънә юк, иң яхшысы—үзенә әйтмичә юатып, тыныч кына яткыру да авыру газабын төрле дарулар белән җиңеләйтергә тырышу—бары менә шуны гына эшләргә мөмкин. Хәер, үзенә әйтмәсәләр дә, карчык бу авыруның әҗәленә тигән авыру булуын күптән инде сизеп тора иде. Күпме яшереп маташмасыннар, монда ул бары вакытлы мөсафир гына...

Докторлар килеп киткәннән соң, карчыкка игътибар һәм тәрбия тагын да көчәя төште. Кызы белән кияве генә түгел, улы белән килене дә башта әсәйләренә бик йомшак булдылар, гел кайгыртып кына тордылар. Кирәк даруларын да табып китерделәр, күңеле теләгән ризыкны да алдыннан өзмәделәр. Гүя алар көннәре санаулыга калган әсәебез алдында соңгы бурычыбызны үтик дип тырышалар иде. Һәм шушы хәл үзе генә дә инде карчыкка күп нәрсә турында сөйли иде кебек... Билгеле, ул балаларыннан бик риза, күңеленнән аларга рәхмәтен укып кына тора, әмма шулай да аларның бу соңгарак калган яхшылыклары вакыт-вакыт

карчыкка аны фани дөньядан юатып озатыр өчен генә эшләнгән шикелле булып тоела, шуңа йөрәге сызланып куя, һәм, чыкмаган жанда өмет бар, дигәндәй, иң элек бер Алласына сыенып, тыныч кына ята бирә иде.

Акъәби калага килеп урынга яту белән, Казакъстандагы кече улын һәм Пермь өлкәсендәге зур кызын чакырып язуны үтенә башлады. Аны менә язабыз, инде язабыз дип гел юатып тордылар, ләкин шулай да язарга ашыкмадылар. Бу шактый читен мәсьәлә иде. Карчыкның кече малае кайтып-китеп йөрмәслек бер жирдә эшләгәнгә күрә, аны, гомумән, чакырып маташудан мәгънә юк иде. Ә зур кызы Пермь өлкәсенең эчкәре бер районында балалар врачы булып эшли, жәй көне эше аеруча тыгыз була, шуңа күрә аны да вакытлы-вакытсыз борчырга ярамый иде. Кыскасы, карчыкның хәле бер көерәк торган чакта чакыру белән ашыкмаска булдылар.

Көннәр үтә, гүя алар зур каланың түбәндәге шау-шуы кебек тоңык кына гүләп, читләтеп үтә. Колакка сеңгән бу шау-шуның башы-ахыры булмаган кебек, үтеп торган көннәрнең дә исәбе һәм билгесе юк. Ә рәхимсез авыру карчыкны астыртын гына кимерә, акрынлап кына ул эри-сыза...

Озакка сузылган өметсез авыруның бик күңелсез бер ягы бар: авыручы үзе дә, аны караучылар да акрынлап ялыга башлыйлар. Бигрәк тә соңгылар өчен бу бик читен хәл: алар, үз-үзләренә икърар итәргә курыксалар да, ничектер ихтыярсыздан «ахырын» көтә башлыйлар. Акъәби моны әле сизми иде, элекке кебек игътибар да бар, карыйлар да үзен, әмма шулай да нәрсәдер, жан жылысымы, борчылып торумы, кимеде кебек. Һәрхәлдә, кайгырту-карау гадәткә кергән мәжбүри бер мәшәкать төсен алды шикелле. Аннары кызы да, кияве дә бик эшле кешеләр, һәркөнне үзләренең хезмәтләренә йөриләр, шулай булгач, аларның авыру әсәйләренә бөтен игътибарларын биреп бетерә алмаулары бик табигый иде.

Карчыкның берәүгә дә зары юк, ул барысын да аңлый, һәммәсеннән риза-канәгать, тик ул көне буе ялгыз ятудан бик туя һәм берәрсенең кайтып керүен зарыгып көтә. Кеше тансык, кеше кирәк аңа. Бигрәк тә кызының ике баласын—алты яшьлек Равиле белән дүрт яшьлек Гүзәлне бик сагына иде ул. Аларны балалар бакчасына йөртәләр—иртән илтеп куялар, кичкә табан алып кайталар. Алар кайткач, зур квартир тулып, жанланып киткәндәй була. Бүлмәдән бүлмәгә йөриләр, такы-токы нидер сөйләнәләр, һәм Акъәби ишектән күзен алмыйча аларны көтеп ята. Равиле—малай кеше—әбисе тирәсендә күп чуалырга яратмый, керсә дә, тизрәк чыгып китү ягын карый, әмма Гүзәле, кыз бала булганга ахры, авыру әбисеннән бер дә ятсынмый, аңа гел сырпаланып кына тора. Бары шушы бала гына аңа бик матур, бик мөлаем итеп: «Әбекәем!»—дип дәшә. Бичара карчыкның күзләре яшь белән тулып китә бу жанга якын, тансык, кадерле «Әбекәем»не ишеткән чакта. Бик ярата, өзелеп ярата ул шушы түм-түгәрәк битле, кап-кара күзле йомшак, пакь, татлы оныгын! Үз йөрәгедәй якын ул аңа.

Хужаларга кунаклар да еш кына килгәлиләр иде. Өйдә, билгеле, ыгы-зыгы башлана. Гөлбикәнең кадак үкчәле туфлиләре белән шак-шок басып, ашыгып йөргәне ишетелә, тәлинкә, чәнечке-пычак, рюмкалар чыңлавы ишетелә, шуннан залдагы кунакларның шаулап сөйләшүләре, көлүләре ишетелә башлый. Карчык шуларның барысын да ничектер балаларча кызыксынып тыңлап ята.

Кызы Гөлбикә, вакыты тыгыз булса да, кергәләп: «Әсәй, хәлең ничек, бер-бер нәрсә кирәкмиме?»—дип сорап чыга. Карчык, күңеле булып:

—Рәхмәт, кызым! Кунакларыңны кара, кунакларыңны!—ди ана.

Ә залда мәжлес матур гына дәвам итә. Сөйләшеп-көлешеп арыгач, берәрсе пианинода уйный башлый, аңа кушылып, кемдер жырлап та жибәрә. Ә кайчагында исә кунакларның тавышы бөтенләй тына, аның урынына ят бер хатын-кызның ашыгыбрак сөйләгән ясалмарак тавышы ишетелә. Бу инде телевизор дигән нәрсә булырга тиеш. Карчыкның аны әле күргәне юк, ләкин шундый әкәмәт бер әйбер барлыгын, өйдәгеләрнең аны бик көтеп, бик яратып карауларын ул инде белә. Вакыт-вакыт шул «тилевәзир» дигән нәрсәдән бик моңлы курай тавышы да, бик борынгы башкорт жыры

да янгырый... Шул чакта карчык ишекләрне ачарга куша һәм жанына тансык бу жыр-моңны тәмам эреп, хыялларга китеп тынлый. Гүя ул ефәк кылганнар йөгерешкән даласына, авыр чулпыларын чыңлатып йөргән кыз чакларына кайткандай була.

Әмма кайвакытта бу «тилевәзир» бик әкәмәт нәрсәләр дә күрсәтеп куя, ахрысы. Шундый әкәмәтләрнең берсен өйдәгеләр «футбол» дип атыйлар. Нәрсәдер инде ул футбол дигәннәре, Хода белсен!.. Ләкин шуны күрсәтә башласалар, хужалар да, килгән кунаклар да ашау-эчүләрен дә, дөньяларын да оныталар. Бервакытны шул хәерсез футбол аркасында Акъәби бичара чак жаныннан аерылмады. Тик кенә уйланып ятканда, залдагы бер ханым кинәт:

—Керде!—дип чыйнап жибәрде.

—Гол!—дип үкереп салды житмәсә тагын бер ир кеше.

—Әстәгъфирулла, тфү, тфү!—диде карчык, тәмам агарынып.

Кунакларның күбесе читтәге кечкенә бүлмәдә авыру карчык ятканны белмиләр дә иде шикелле... Һәрхәлдә, авыру бар дип борчылучы яки аның хәлен белергә керүче булмый диярлек—утыралар, көләләр-шаулыйлар, ашыйлар-эчәләр дә таралышалар... Шулай да ешрак килеп йөрүче бер кунак Акъәби янына кергәли торган иде. Бу—тәбәнәк буйлы, ашыкмыйча, елмаеп кына сөйләшүче, исеме шактый билгеле булган олы яшьтәге бер шагыйрь иде.

Залда кунаклар шаулап утырган чакта гына, ул карчык янына мыштым гына килеп керә, керә дә: «Саумы, әбекәем!»—дип ике куллап күрешә, аннары урындык алып, караватк кырына утыра. Ул күп сөйләшергә яратмый иде, күбрәк тезләренә таянып тик кенә утыра һәм ара-тирә берәр хикмәтле сорау гына биреп куя торган иде. Карчык аның әчкәнме-түгелме икәнен дә аера алмый, чөнки шагыйрь һәрвакытта гел бертөсле була торган иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, ул бу уйчан, сәер кешене көтеп ала иде. Ничектер алар, аз сөйләшсәләр дә, бер-берсенә бик тиз ияләшеп киттеләр.

—Акъәби, Акъәби!—ди шагыйрь, үзалдына әйткәндәй әкрен генә.—Ә ни өчен Акъәби, ни өчен Кара әби түгел?

—Минем исемем Акбикә,—ди карчык, бу көтелмәгән сораугa бераз пошынып. —Кыз чагымда мине Аксылу дип йөртәләр иде, кияүгә чыккач, Аккилен булдым, аннары Акжингә, ә хәзер менә Акъәби...

—Димәк, син гомереӊ буена ак кеше булгансың икән. Ак күңелле, пакь күңелле кеше.. Менә мина да шундый әсәй кирәк иде.

—Ни сөйлисен, улым, синен үз әсәең бардыр бит?

—Юк шул, юк... Күптән ожмахта инде ул... Ә әсәйсез авыр, әсәй сабый балага гына түгел, менә минем кебек сакалы агарган кешегә дә кирәк икән ул!

—Рәхмәт, улым!—ди карчык, нигәдер ирене калтырый башлап.

Шагыйрь, тезләренә таянган килеш, бераз уйланып утыра, аннары тагын сорап куя:

—Юлкотлыны сагынасынмы?

—Сагынам, улым!

—Әйе, халык матур уйлаган, авылына, жиренә, суына матур исемнәр бирә белгән. Юлкотлы! Юлың котлы булсын, Акъәби!—дип әйтәсе килеп тора.

—Безнең ерак бер бабаебызның исеме Юлкортлы булган диләр. Аның кышлавын «Юлкотлы кышлавы»[1] дип йөрткәннәр. Тора-бара авылга да шул исем күчкән.

—Ә, шулаймыни?—ди шагыйрь, кызыксынып, һәм карчыктан иплэп кенә аның кыз чакларын, кайчан, ничә яшендә кияүгә чыгуын, туйларның ул заманда ничек узуын, шул чактагы йолаларны, уеннарны, жырларны сорашырга тотына. Әкъәби, еш кына тыны кысылса да, үзенең истәлекләрен, күргән-белгәннәрен иренмичә сөйли, ә шагыйрь аны бик игътибар

---

[1]К ы ш л а у дип борын күчмә башкортларның жәйләүдән соң кыш уздырыр өчен тукталган жирләренә әйткәннәр. *Автор.*

белән тынлап утыра... Карчык сөйләп бетергәч тә әле, ул ни дә булса әйтергә ашыкмый, тик бераздан гына үзенең берәр эчке уен раслагандай әйтеп куя:

—Ийе... узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да!.. Шулай ди жыр, сулар үргә акса да, ди, усал әйтә! Берсе дә—узган гомер дә, үтеп киткән тормыш та кире борылып кайтмаячак. Син дә, әбекәем, моның белән килешә торгансыңдыр?

—Килешмичә нихәл итәсең инде...

—Юк, син дөресен әйт, син олы кеше, бәлки, борынгы тормыш сиңа кадерлерәктер, син аны сагына торгансыңдыр?..

—Хәзергесе начар булса, сагыныр идем,—ди карчык, уйланып кына.—Хәзергесе, Аллага шөкер, әйбәт бит.

Шагыйрь ана күзләрен тутырып карый.

—Шулаймы?!. Син дөньяны таный беләсең икән, әбекәй, янә, яшә!.. Ләкин сагыныр нәрсәләр дә юк түгел бит. Әнә шул син сөйләгән халыкның матур йолалары—бәйрәмнәре-туйлары, уеннары-жырлары—берсе дә онытылмаска тиеш, минемчә... Халыкның буыннан-буынга күчеп килгән рухи байлыгы бит алар барысы да... Дөрес, яңа заман яңа байлыклар тудыра, ләкин искенең дә яхшысын саклый белергә кирәктер ләбаса!

—Борчылма, улым,—ди карчык, сабыр гына.—Халыкныкы халыкта саклана, югалмас, Алла бирсә!

—Гажәп сүз әйттең, әсәй бәгырем, гажәп сүз!... Һәм шагыйрь, кинәт кенә тураеп, бер аягы белән идәнгә акрын гына суга-суга жырлап та жибәрә:

> Аппак микән, йомшак микән
> йәнкәемнең куллары,
> Салавап күпере кү-ү-үк
> суга барган юллары.

Онытып кара син бу жырны, онытып кара, мөмкинме соң!..

Шагыйрь тавышы өзелгәндәй шулай ук кинәт кенә тынып кала, башын артка чөя һәм күз төбендә аның тәгәрәп төшә алмаган яшь бөртекләре күренә. Тик бераздан тынычлангач кына, гафу үтенгәндәй әйтеп куя:

—Син мине тилегә санама инде, яме!.. Нишлим, мин шагыйрь кеше, халык жырын, бөек Тукай әйтмешли, рәсүлнең тырнагыдай йөрәгемдә саклап йөртәм.

—Ә мин Тукайны беләм,—ди карчык һич көтмәгәндә.

—Китче!—ди шагыйрь, шаккатып.—Кайдан беләсең син аны?

—Суфияннар мәктәптә укыган чакларында: «И туган тел, и матур тел»,—дип бер жыр ятлап йөриләр иде, шуннан хәтеремә кереп калган.

—Суфиян агай туган телне жырлап йөрдеме?.. Кызы-ык!—Һәм шагыйрь, бөгелә төшеп, тавышсыз гына көләргә тотына:—Их, генерал, генерал!..

Ләкин Акъәбинең житдиләнеп китүен күргәч, ул көлүеннән шунда ук туктый, иелеп чәчләрен сыпыра, аннары баладай юаш кына әйтә:

—Син мине кичер инде, әсәй, синнән бернәрсәмне дә яшерә алмыйм шул...

—Бик яхшы, улым,—ди карчык тыныч кына.—Күңелең кешеләргә көзгедәй һәрвакыт ап-ачык булсын!

—Рәхмәт, әсәй, рәхмәт!.. Жиңел, рәхәт миңа синең янда... Тик күп лыгырдап ялыктырам бугай үзеңне... Ярый, кузгалыйм булмаса, син дә ял ит инде, ял ит, безгә карама, без—әрсез кунаклар!..

Һәм шагыйрь, торып, карчыкның юрган өстендә яткан сап-сары кулын йомшак кына сыйпый да исерә төшкән кешедәй аз гына чайкала биреп чыгып китә.

«Сәер кеше!—дип уйлана карчык, аның артыннан.—Ләкин әйбәт кеше үзе, кече күңелле, тик күңелендә ниндидер сызлавыгы бар шикелле, жанына урын таба алмыйча, шуңа сызланып йөри, ахрысы, бахыркаем!» Һәм күп вакытта ул аны ятим баладай күреп, чын ихластан кызгана торган иде.

... Бер ике-өч атна үтүгә, карчыкның хәле шактый авыраеп китте. Бик ябыкты ул, тамагына бернәрсә капмас булды, шуның өстенә тавышы да бетә башлады. Янадан врачлар килде, карадылар, юаткан булдылар, тагын ниндидер яңа дарулар язып калдырдылар. Хәер, карчык өчен боларның берсе дә кирәкми иде инде. Ул барысын да белеп ята. Шулай ук аның хәлен уллары-кызлары да бик яхшы белеп торалар... Һәм эчләреннән генә куркып, шомланып үлемне көтәләр. Карчык хәзер моны үзе дә сизә, карчыкның сизгәнен алар да беләләр.

Ләкин шуңа карамастан һаман: «Әсәй, борчылма, үтәр, терелерсең!»— дип аны да, үзләрен дә алдарга тырышалар.

Карчык соңгы көннәрдә бик уйлана башлады. Көндезләрен барысы да хезмәтләренә китеп беткәч һәм асрау кыз да, карчыкның өстеннән бикләп, базарга китеп баргач, Акъәбигә ялгызы ак түшәмгә карап, теләсә күпме уйланып ятарга мөмкин иде. Уйлар күп, уйлар төрле-төрле, өзлексез килә торалар, китә торалар... Башта ул чынлап та Юлкотлысын сагынып йөдәде. Бөтенесе—яланы-кыры, авылы-урамы, кешеләре, малайлары—бер генә минутка да исеннән чыкмый... Бөтенесе—өе, алачыгы, келәте, кәҗәсе, тавык-чебешләре—күз алдында тора, бөтенесен ап-ачык ишетә, күрә... Менә кәҗәсе көтүдән кайткач, ишек төбенә килеп, Акъәбине дәшкәндәй, тавышын калтыратып кычкыра торгандыр. Җавап булмагач, тык-тык басып, өйалдына ук керә башлыйдыр... Тавыклары да тибенеп йөргән җирләреннән туктап: «Нигә әле безнең әбиебез күренми?»—дигәндәй, башларын кырын салып, җелт-җелт карана торганнардыр. Казлары да, күл буеннан кайткач, ишек алдында озак кына каңгылдаша торганнардыр да, чыгучы, дәшүче булмагач, боек кына чирәмгә чүгәләшеп, башларын сыртларына салып, йокыга талалардыр... Әйе, алар барысы да әбинең юклыгына гаҗәпләнә торганнардыр, күңелсезләнеп, боегып, монаеп йөри торганнардыр... Шуларны уйлагач, Акъәбигә гаять авыр булып китә, алар да, үзе дә ана бик кызганыч булып тоела һәм ихтыярсыздан кайнар яшьләре мөлдерәп агып төшә... юк, күрмәс инде ул аларны—туып-үскән Юлкотлысын да, гомер иткән өен дә, күршеләрен дә, терлекләрен дә берсен дә янадан күрә алмас инде!

Шушы котылгысыз аерылышуны сизеп торганга күрә дә булса кирәк, карчыкның күңеленә еш кына башка уйлар—җитдирәк, тирәнрәк уйлар да килә башлады. Әйе, аның көннәре санаулы, соңгы сәгате якынлаша... Ул курыкмый, ул тыныч көтә бу серле, рәхимсез сәгатьне, тик бер ходаеннан җан бирү газабын җиңеләйтүне генә сорый... Ул әзер булып торырга тиеш, әйе, зиһене ачык, теле бар чакта үл үзенең соңгы теләген, соңгы васыятьләрен әйтеп калырга тиеш. Аннары инде... китәргә дә була.

Иң элек аның уен, билгеле, үлгәннән соң ничек итеп күмәрләр дигән нәрсә гел борчып тора. Ул белә: кайда, кемнәр кулында ятуын, әмма ул, гомере буена башыннан яулыгын салмаган мөселман карчыгы, Алла хозурына барам дип ышана, шуңа алдан әзерләнеп килгән һәм бөтен керсез күңеле белән үлгәннән соң гәүдәсен бары мөселманча итеп җирләүләрен тели: «Инде, мулла-мәзин чакырып, тәхлил әйттерү кебек зур мәшәкатьле эшне сорамыйм да, анысын эшләмәсәләр дә ярый. Әмма ләкин гәүдәмне әйбәтләп юып, ак кәфенгә төреп, ләхетле каберга куйсыннар иде. Аннары, берәр карттан гына булса да, баш очымда Коръән укытсыннар иде...» Авылында булса, аны шулай күмәрләр дә иде, аның алып куйган кәфенлеге дә, чәчеме өчен җыеп тоткан тәңкәләре дә, гәүдәсен ләхеткә куючылар өчен саклап килгән сөлгеләре дә бар иде, ләкин, нихәл итмәк кирәк, барысы да сандыгында торып калды шул... Ничек кенә булмасын, улы-кызы аның бу үтенечен тыңларга тиешләр. Үзләре ышанмасалар да, кирәксез нәрсә дип тапсалар да, ул кушканча эшләргә тиешләр—бу бит газиз аналарының соңгы васыяте! Васыятьне үтәмәү мөмкинме соң?!

Һәм кызы бер кичне аның хәлен белергә кергәч, Акъәби аңа якынрак килеп утырырга кушты.

—Гөлбикә кызым, сиңа сүзем бар,—диде ул, чак ишетелерлек зәгыйфь тавыш белән.—Алладан вакыт җитә шикелле, шулай сизәм... Менә исемдә

чакта әйтеп каласым килә...—Аңа сөйләве авыр иде, әледән-әле тыны кысыла, авызы белән көчкә генә өзеп-өзеп сулышын ала.—Йә Аллам, җиңеллек бир... Э-э, әйе.. кызым, ишетәсеңме, мин үлгәч, гәүдәмне берүк...

Гөлбикә, кызганудан йөзен чытып, шунда ук аның сүзен бүлде:

—Әсәй, әсәем, нигә ул хакта сөйлисең әле... Куй, кирәкми, борчылма, уйлама ул турыда...

—Һай, кызым, ничек уйламыйсың ди, килә бит ул әҗәл, килә, күрмисенмени?... Ух, уф... Соңгы сүземне әйтеп калыйм...

—Әсәем, бәгырем, ярамый сиңа сөйләшергә,—диде кызы, кат-кат башын селкеп.—Хәлең юк, тавышың беткән, нигә үзеңне азаплыйсың... Тыныч кына ят, кирәгеңне генә сора!..

Карчык бераз күзен йомып торды, аннары ничектер хәл кергәндәй тыныч кына әйтте:

—Мин, кызым, нәкъ менә иң кирәген сорыйм да шул... Сез, яшьләр, шәригать йолаларын белмисез, үзем әйтеп калдырмасам, кем мине мөселманча җирләр?.. Яшьнеккә салырсыз да илтеп куярсыз...

Кызы урыныннан ук торды—ул, гадәтенчә, каядыр ашыга иде.

—Юк хәсрәт төшкән башыңа, әсәй!.. Ярар, бу хакта сүзне бетерик... Врачлар киңәшен тыңларга кирәк. Хәзер менә шушы даруыңны эч, бераздан Фатыйма кайнар чәй кертер... Онытма, ямьсез уйларга бирелеп яту синең өчен бик зарарлы ул... Ярый хәзергә, сөйләшербез, минем барып киләсе җирем дә бар иде...

Карчык дәшмәде, тик «бар!» дигәндәй башын гына каккандай итте. Һәм бик озак күзләрен йомып, берни уйламагандай, тын гына ятты. Әмма аның зиһене бер генә секундка да эшләүдән туктамаган иде. Нәрсәнедер, үзе өчен бик мөһим, бик яңа бер хакыйкатьне аңларга тырышып ята иде кебек... Алай, әнә ничек икән ул!.. Үләсе кеше белән каласы кеше тиз генә уртак тел таба алмыйлар икән! Бик кыен икән аларга сөйләшүе... Ни өчен соң бу шулай? Бөтенләй кирәксез, юк нәрсә турында кайгыртып ятамыни ул—дөньядан китәсе ана кеше? Балалары белән аның арасы шулай бик ераклашты микәнни? Алай дисәң, карыйлар, дәвалыйлар, кызганып, борчылып та торалар кебек, ә менә әсәйләренең соңгы сүзен, соңгы үтенечен тыңларга, йөрәген аңларга теләмиләр. Нидән соң бу болай?

Әлбәттә, карчыкка моның җавабын табу бик читен иде. Тик ул күңеле белән генә сизелә: балалары аның бүтән кешеләр, бик нык үзгәргән кешеләр. Авыр ана, ямансу аңа, ничектер кинәт бик ятим, бик ялгыз калгандай хис итә ул үзен... Ләкин шулай да аның балаларына үпкәлисе, рәнҗисе килми. Җәнлек үзенең ярасын ялап төзәткәндәй, ул да җәрәхәтле йөрәген сабыр акылы белән тизрәк тынычландырырга, юатырга ашыга: ярамый болай, язык булыр, ди, балаларымны бәхилләп, ризалыкларын алып китәргә тиешмен, ди. Шәт, алар да мине аңларлар, сүземне тыңларлар, кадерләп озатырлар... Әйе, аның өмете зур һәм әйтер сүзе дә күп әле, күп...

Җитмеш алты ел буе дөньяда яшәгән карчык бит ул. Гомер иткән нигезе бар, нужа белән тапкан күпме-азмы мал-мөлкәте бар, яшь килен чагыннан ук саклап килгән үзе өчен бик кадерле кием-салымнары бар—шуларның барысын да ул бик теләп, бик куанып балаларына калдырып китә. Өен, абзар-курасын, кәҗә-сарыкларын соңыннан теләсә нишләтсеннәр, колхозга бирәләрме, сатып акчасын бүлешәләрме—алар эше.

Ләкин кайбер бик кадерле нәрсәләрен ул балаларына исемләп, атап биреп калдырырга тели. Сатар өчен дә түгел, чит кешеләргә бирер өчен дә түгел, ә аның төсе итеп, саклап тотар өчен бүләк итәргә тели. Мәсәлән, үзенең ак ука тоткан, якут каптырмалы сары бәрхет камзулын Гөлбикәсенә, вак мәрҗәннән җыеп эшләнгән, әдрәс астарлы кашмау белән чәчкабын Пермьдәге олы кызы Сылубикәсенә, картыннан калган камчат бүрекне улы Суфиянга билгеләп тора. Аннары бик борынгы тәңкәләр һәм төрле төстәге ташлар белән бизәлгән беяте (хәситәсе) бар, шуны, кабул итсә, марҗа килененә бүләк итәр иде. Улының хатыны булгач, ул ана да якын бит, бәлки, Мария килен дә каенанамның төсе дип беятне үзендә саклар иде.

Билгеле, кызы—кашмаулы, килене бөятне киеп йөрмәсләр, ул кадәресен генә Акъәби аңлый инде. Ләкин бит аларны бер әсәйләре генә түгел, әсәйләре кебек бик күп башкорт кызлары, башкорт җиңгәләре кигәннәр. Шуның өчен генә булса да, алар ул киемнәрне ничектер сакларга тиешләр. Югыйсә бетә бит инде барысы да, югала, онытыла... Ярый, шушы көнгә кадәр ул, Акъәби дигән кортка, яшәп килде. Ул менә аларны монарчы туган җирләре белән, андагы тормыш, андагы кешеләр белән бәйләгән бердәнбер җеп булды. Хәзер шушы бердәнбер җеп тә өзелә инде... Нишлисең, тәкъдирдән узып булмый шул, узып булмый!.. Ләкин, ни кызганыч, тере җеп өзелү белән бергә туган-үскән илгә юл да киселәчәк. Кылганлы далада утырган Юлкортлы үзе дә, аның кешеләре дә акрынлап онытылачак. Әмма киселергә тиешме соң, Раббым, туган илкәйгә юл, онытылырга тиешмени соң ата-бабадан килгән андагы тормыш, андагы кешеләр? Юк, Акъәби үзе мондый хәл белән һич тә килешә алмый. Аның өчен туган ил—туган туфрак дигән сүз. Шул туфракта ата-бабаларының сөякләре ята, шунда аның гомердәшләре Миңлебай картлар, Минҗиһан корткалар, шунда аның күз алдында үсеп җиткән яшь ирләр, яшь киленнәр, шунда аның тирәсендә чуалган бала-чагалар, һәм ул аларны, кая гына китмәсен, актык сулышына чаклы онытачак түгел. Менә шул хакта аның үз балаларына да бик нык әйтеп каласы килә:

«Суфиян улым, Гөлбикә кызым, балакайларым! Сез икегез дә укыган, белемле, дәрәҗәле, зур кешеләр булдыгыз. Икегезнең дә түгәрәк кенә тормышыгыз бар, бер-бер артлы балаларыгыз үсеп килә, үзегез дә инде олыгаеп барасыз. Аллаһы Тәгалә барыгызга да тигез гомер биреп, шул балаларыгызның игелеген күрергә насыйп итсен! Амин!.. Ләкин сезнең дә сабый чакларыгыз бар иде. Сез «Аслы күл» әйләнәсендәге киң, тигез балада утырган Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылында тудыгыз. Сөттәй йомшак, көмештәй саф сулы «Аслы күл» Юлкотлыдан өч кенә чакрымда... Аның шифалы суында коендырыр өчен атагыз мәрхүм сезне, арбага тезеп утыртып, еш кына шунда алып бара иде. Ә «Аслы күл»нең Нора тавына менсәң, шуннан инде еракта ялгыз утырган, нәкъ түбәсенә куш каен үскән Балкан тавы да күренә. Сезнең «Зыятүләк белән Сусылу» әкияттен ишеткәнегез бар инде, шул көзгедәй уйнаклап яткан күл белән еракта басып торган биек таудан туган әкият ул, ә тауның түбәсендәге куш каенны Зыятүләк белән Сусылуның кабере диләр, каеннар төбеннән бәреп торган чишмәне Сусылуның озын, кара толымнарыннан саркып чыккан су диләр. Әнә шулай әкиятләргә кергән гаҗәеп якты, иркен, матур җирләр бит ул безнең «Аслы күл» яклары! Һи, ниләр генә сөйләп булмас иде безнең башкорт илләре, башкорт җирләре турында!..

... Мин бераз читкәрәк киттем шикелле, балалар! Әйтәсе килгәнем бүтән иде... Зиһенемне азрак җыйыйм әле... Әйе, менә шул... Сез Юлкотлыда тудыгыз, аның киң урамында чабышып йөрдегез, чирәмендә ятып аунадыгыз... Үсә төшкәч, сез Юлкотлының ак кылганлы яланнарында, тау-чокыр буйларында йөрдегез, бозау көттегез, кизәк җыйдыгыз, әрлән кудыгыз... Бүтәннәрдән бер аермагыз да юк иде, бүтәннәр шикелле үк сез дә ситсы күлмәк, бөрмәле ыштан киеп, ялантәпи йөрүче кап-кара балалар идегез, үскәч кенә менә кем булып киттегез!

...Җиде-сигез яшегездән Юлкотлының кечкенә мәктәбенә сабакка төштегез. Шунда тел ачкычы таптыгыз, шунда күңел күзегез ачылды... Икешәр-өчәр көн рәттән котырган кышкы бураннарда үзем сезне җитәкләп мәктәпкә илтә торган идем... Атагыз Әлшәй базарыннан, куенына кыстырып, сезгә китаплар, дәфтәрләр алып кайта торган иде... Бик ипле, бик бала җанлы кеше иде ул, мәрхүм!.. Бервакытта да сезнең теләгегезгә каршы килмәде... Юлкотлы мәктәбен бетергәч, Сыртлан мәктәбенә йөреп укыдыгыз... Аны да бетергәч, калага китәбез, дидегез—каршы тормадык. Гәрчә сезне бер-бер артлы яныбыздан җибәреп тору авыр булса да, уку—изге эш, без күрмәгәнне балаларыбыз күрсеннәр, безгә насыйп булмаган аларга насыйп булсын, дип, хәлебез җиткәнчә һәркайсыгызның өс-башын юнәтеп, акчасын да аннан-

моннан табып, сезне ерак юлга озаттык. Сездән аерылгач, безгә бик ямансу була иде, атагыз, ир кеше, сиздермәсә дә, минем ашарга утырган саен кашыгыма яшьләрем тәгәрәп төшә иде... Сез киттегез, әмма ул чакларда әле сез Юлкортлыны онытмый идегез, Юлкотлыны сагына идегез, бала кошлар шикелле очып-очып кайткалый идегез... Ләкин ни өчен сез аны соңыннан оныттыгыз?.. Чакырып-дәшеп тә еллар буе кайтмый башладыгыз?.. Ике сүзнең берендә «туган ил» дисез, ә Юлкотлы нәрсә соң? Туган илнең сезгә иң якын, иң кадерле бер өлеше түгелмени ул?..

... Сез бик еш кына «халык» дисез, ләкин Юлкотлыдагы кешеләр дә халыктыр бит инде. Бер тамырдан чыккан, бер ыруттан үрчегән халык, шуңа күрә ул сезгә якынрак та, туганрак та булырга тиештер ләбаса!.. Кайчандыр сезнең башыгыздан сыйпап узган агайларның, апайларның кайберләре хәзер дә әле исәннәр. Менә кайтып, шулар белән ике куллап бер күрешсәгез, олылап бер жылы сүз әйтсәгез, сез аларны күпме сөендерер идегез. Һәм күпме рәхмәт, күпме изге теләк сез алардан ишетер идегез. Һай, ярата безнең халык зур укыган кешенең кече күңелле булуын, мактап бетерә алмый, ә тәкәббердән кача, тәкәбберга бервакытта да йөзен дә, телен дә ачмый ул...

Яки атагыз мәрхүмне исегезгә төшерегез. Ул да бит халыкның бер бөртеге... Сезгә жан биргән, сезнең өчен тир түккән, сездән күпме өметләр көткән ата кеше бит әле ул сезгә! Йә, сез аның алдында бер дә бурычлы түгелмени соң?.. Авыл читендәге канау белән генә әйләндереп алган кечкенә зыяратта аның гәүдәсе ята. Баш очында ташы юк... Аның каберен мин дә, тагын берничә авыл карты гына белә. Бездән соң белүче булмаячак, кабер жир белән тигезләнәчәк... Йә, сезнең жаныгызны бер дә борчымыймыни бу нәрсә?.. Машиналар сатып алырга хәлегездән килә торып, атагызның каберенә бер ком таш кына яздырып куярга сезнең кулыгыздан килмимени? Килә, бик килә, тик күңел саранлыгыннан котылырга кирәк, тик кемгә бурычлы булуыгызны онытмаска кирәк!.. Имештер, яшь чагында көтү көткән, соңыннан бик баеп киткән Өфенең бик зур бер куписы үзенең шул кайчандыр киеп йөргән иске чабаталары белән озын чыбыркысын намаз бүлмәсендә генә элеп тоткан, ди. Күрәсез, ул да, бахыр, намаз укыган саен шуларга карап, элек кем булуын онытмаска тырышкан. Менә сезгә гыйбрәт!

Әйе, сез зур кешеләр булдыгыз, илгә, дәүләткә кирәкле, файдалы кешеләр булдыгыз, хәзер шуның әжерен күрәсез, рәхәтен чигәсез!.. Ләкин сезне менә без, Сәлимжан белән Акбикә дигән гади башкорт кешеләре, дөньяга китердек, Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылы сезне үзенең туфрагында үстерде, башкорт халкы сезне бүгенге югарылыкка күтәрде,— сез шуны онытмагыз, балаларым, ишетәсезме? Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы?.. Бу минем күңелем түреннән чыккан иң кайнар, иң зур, иң соңгы васыятем сезгә!»

Һәм шушы васыятен әйтеп калырга Акъәби берничә тапкыр омтылып карады. Бу аның өчен бик тә кирәк иде, әйтмичә китәсе килми иде, хәтта үлгәннән соң да әйтә алмыйча калган васыяте өчен каберендә борчылып ятыр кебек иде. Ләкин ул авызын ачты исә, аңа: «Һәй, әсәй, юкка борчылма әле син, кирәкмәгән нәрсәләр уйлап ятма әле»,—диделәр. «Сиңа күп сөйләргә ярамый, фрачлар кушмый»,—дип гел тыйдылар һәм аны юатыр, тынычландырыр өчен тамчылап даруын эчерделәр, лимонлап чәен китерделәр, тәлинкә тутырып алмасын, чиясен китереп куйдылар.

Аптырап-уйланып ята торгач, кайчагында Акъәбинең үзе янында сырпаланган кечкенә Гүзәлгә нидер әйтәсе килә, бик сак кына, бик гади сүзләр белән генә күнелендәге шул сабыйга аңлатасы килә. Шул ук вакытта баланың йөрәгенә шом салмыйм дип тә курка ул... Ничек кенә дип әйтергә аңа? Бераз икеләнеп ятканнан соң, баланың аркасыннан сыйпап, гүя болай гына әйтеп куйган була:

—Бәләкәчем, мин тиздән китәрмен инде...

—Китәсен... Кая китәсен?—ди бала, зур күзләре белән әбисенә тутырып карап. (Ә берни сизә, берни төшенә белмәгән, бары тик ышана яки курка

гына белгән сабый күзләреннән дә бәгырьне телгәләрлек нәрсә бар?!)

—Ни инде... үзебезнең Юлкотлыга,—ди карчык, көчкә генә телен әйләндереп.

—Юк, китмисең, китмисең!..—ди бала, шунда ук үпкәли дә башлап.

Акъәби үксеп җибәрмәс өчен иреннәрен кыса һәм озак кына дәшә алмыйча тора. Бары бугазына килгән төер кире киткәч кенә, тагын әйтеп куя:

—Мин сиңа, кошчыгым, аннан бүләк җибәрермен.

—Бүләк? Нинди бүләк, әбекәем?

—Сиңа билгеләп куйган бик матур чулпыларым бар, шуларны җибәрермен.

—Ә нәрсә ул чулпы? Нигә син аны алып килмәдең?

—Онытканмын.

Бала ышаныргамы-юкмы дигәндәй әбисенә карап тора-тора да, нидер сизенгәндәй, башын селкеп куя.

—Син алдыйсың,—ди ул, сузып кына.—Бездән китәр өчен генә әйтәсең...

Акъәби йөзен тизрәк читкә бора. Юк, булмый, сөйләү мөмкин түгел... Сабыйның күңеленә кагылырга ярамый, ярамый, аярга кирәк аны, аярга!.. Кем белә, бәлки, соңыннан бу әйткәннәрне исенә төшереп, әнисеннән: «Әбекәем кая китте, нигә миңа чулпы җибәрми?»—дип сорап йөдәтер. Һәм карчык сабыйны тынычландырыр өчен, аның күңелендә берниндн шик-шөбһә калдырмас өчен, көлгән булып, баланы юатырга ашыга:

—Юри генә әйттем, бәбкәчем, юри генә! Сине калдырып китәмме соң?!. Юк, юк, беркая да китмим, күз нурым!..

...Гаҗәп хәл! Бала белән шушы гөнаһсыз гына сөйләшүдән соң Акъәби гомумән васыятьләрен кемгә дә булса әйтергә тырышудан шактый вакыт тыелып торды. Әллә ничек шунда һичнәрсәгә исе китмәстәй, һичнәрсә турында уйлыйсы килмәстәй булып калды. Тик өзлексез җанын борчыган бер генә нәрсә аны һаман уйландыра иде. Һәм бары шуны гына ул үз янына ашыгып кына кереп чыккан улы Суфиянга ишетелер-ишетелмәс тавышы белән тагын бер тапкыр әйтеп карады:

—Улым, үтенәм сездән, мине зинһар үзебезчә, мөселманча җирли күрегез инде.

Улы Суфиян уйлап та тормыйча:

—Һи, әсәй, обязательно шулай эшлибез аны!—диде гаҗәеп бер җиңеллек белән:—Менә әйтте диярсең, мөфти хәзрәтнең үзен чакыртам янына... Только син, әсәем, үләргә ашыкма әле, яме! Торыйк әле, торыйк, Алласына, мулласына үч итеп, дигәндәй...

—Көфер сүз сөйләмә, улым!—диде карчык, сабыр, җитди генә.

Ләкин Суфиян авыру кешегә бердәнбер кирәк нәрсә, ул да булса (үз сүзе белән әйтсәк), бодрость дип белә иде. Шуңа күрә ул һәр сүзне уенга бора, үзенчә шаяртмакчы-көлдермәкче була. Һәм күп вакытта утырып та тормыйча, авызына ни килсә шуны сөйләп, бүлмәне бер шаулатып, тизрәк чыгып та китә иде. Ә карчык, бичара, ни уйларга да белмичә, аның артыннан башын гына чайкап кала. Чынлап әйттеме ул, юри генә әйттеме, нигә утырып, әйбәт кенә сөйләшмәде соң, кая ашыга, кая чаба ул? Гаҗәп бу шәһәр халкының гадәте—барысы да каядыр ашыгалар, ашыгалар, ашыгалар!..

Үлем дә ашыга иде шикелле. Соңгы көннәрдә карчыкның хәле бөтенләй мендәреннән бер дә аерылмас булды. Бала шикелле тәмам кечерәеп калды, күзләрен дә инде йортә алмый башлады.

Врачлар кызы белән киявенә карчыкның тиздән өзелеп китү ихтималын әйттеләр,—торса, тагын бер атна-ун көн генә тора алыр, диделәр. Бу хәбәр аларда зур борчылу тудырды. Димәк, әсәй карчык китә!.. Һәм бик ачык, котылгысыз булып алларына килеп баскан бу гаять авыр, хәсрәтле үлем аларны тәмам аптырауга төшерде. Хикмәт шунда, үлем дигән нәрсә аларның өенә беренче мәртәбә керә әле, монарчы аларның мондый фаҗигале хәлне күргәннәре дә, кичергәннәре дә юк иде әле... Борчылмыйча, уйланмыйча һич мөмкин түгел. Иң элек карчыкның үлеме балаларга бик авыр тәэсир

итәчәк, куркытачак бу нәрсә аларны... Аннары мәетне юу бар, жыештыру бар, озату бар, ә алар үзләре бу эшләрнең тәртипләрен һич белмиләр. Кемнән эшләтергә, ничек эшләтергә боларны? Түбәндәге дворник хатыны Сәрбиҗамал апага әйтсәң, ул бик теләп боларның барысын да оештырыр иде... Юарга, кәфенләргә карчыкларын да табар иде, бәлки, мулласын да чакырып китерер иде. Ләкин болар барысы да гаять мәшәкатьле эш бит, әллә ничек күнелсез эш. Кияве, бу хакта сүз чыкса, теше сызлагандай, чыраен сыта башлый. Мөселманча булсын, дип әллә нинди карчыкларны, муллаларны үзенең квартирасына бер дә китерәсе килми аның... Килешми аның хәлендәге кешегә бу нәрсәләрнең берсе дә. Ничектер бүтән юл, бүтән чара табарга кирәк бу положениедән чыгар өчен...

Кияве белән кызы арасында шушы хакта берничә көн буена сүз барды. Гаять четерекле мәсьәлә турында алар мөмкин кадәр әдәп, такт саклап сөйләштеләр, ләкин шулай да ара-тирә үпкәләшеп, талашып та киткәләделәр. Хәер, асылда аларның фикерләре бер иде: карчык квартирда үлсә, бик авыр, бик күнелсез булачак.

Ахырда кияве әйтте: «Гөлкәй, бүтән чара юк, әбине больницага салырга кирәк,—диде.—Больницада әле аңа яхшырак та булыр, урын-жире чиста, врач көн дә карап тора, сестралар һәрвакыт янында, үзебез дә чиратлашып янына баргалап торырбыз... Аның каравы, балалар кадерле әбиләренең үлемен күреп, тетрәнеп калмаслар, куркып елашмаслар... Аннары больницада мәетләрне әйбәтләп юындырып, киендереп озатучы махсус кешеләр дә бар. Ә без үзебез монда нишли алабыз?.. Юк, иң яхшысы—больницага салу инде...».

Гөлбикә бу эшнең күнелгә авыр, оят, килешмәгән ягын сизсә дә, уйлый-тора ахырда риза булды. Шулай сөйләшеп килешкәннән соң, алар үзләренең бу карарларын, унайсызланыбрак булса да, Суфиян белән Мария Васильевнага да әйттеләр. Башта Суфиян бик кайнарланып каршы төште:

—Што сез,—диде кычкырып,—кадерле әсәебезне өйдә үлмәсен өчен генә больницага илтеп салмакчы буласыз! Оятын ничек күтәрерсез, хурлыгын кая куярсыз?.. Юк, юк, мин мона асла риза түгел!

Ләкин кияү кеше кызмыйча гына, әйбәтләп кенә аңа төшендереп бирде:

—Каенагай, оят мәсьәләсендә синең безгә бер сүз әйтергә дә хакың юк. Әсәебезне авылдан без барып алдык, без аны өебездә ай ярым буена кулыбыздан килгән кадәр тәрбияләдек, карадык, терелмәсме дип бөтен чараларны күрдек... Әсәй үзе моның өчен безгә рәхмәтен әйтер, дип ышанабыз. Инде больницага салу мәсьәләсенә килгәндә, бу синең өчен авыр икән, тотасың да үзенә аласың... Сиңа да ана бит ул!.. Әмма мин әсәйнең үлгән чагын балаларга күрсәтеп, аларның йөрәкләрен жәрәхәтләргә теләмим.—Һәм шунда ук, каенагай тагын дулап китмәсен, дип булса кирәк, ипләп, йомшартып улына әйтте:—Без, Суфиян, дәү кешеләр, мәсьәләгә айнык карарга тиешбез. Авыруны больницага салуның һичбер гаебе юк. Беркем бер сүз әйтмәячәк. Инде анда үлеп китә икән, без әсәебезне шуннан гына бик әйбәтләп, бөтен шартын житкереп, соңгы юлына озатырбыз. Ә өйдән мәет озату бик авыр, бик мәшәкатьле эш ул, син безнең хәлебезне аңларга тиешсең, Суфиян!

Бу сүзләрдән соң Суфиян шактый аптырауга төшеп, үзенә терәк эзләгәндәй, алмашлап бер сенелесенә, бер хатынына карады. Ире артына посыбрак, бөрешеп кенә утырган сенелесе гүя бөтен кыяфәте белән: «Миңа карама, мин арыдым, мин берни дә эшли алмыйм»,—дип әйтеп тора иде. Ә юан ак беләкләрен зур күкрәкләре өстенә кушырып салган хатыны, бу мәсьәләгә ана һич кагылмагандай, йомык бер битарафлык саклап утыра иде. Суфиян акрын гына жилкәсен кашырга тотынды.

—Шулай, каенагай!—диде кияве, аның хәлен жиңеләйтергә теләгәндәй.—Борчылырлык урын юк, барысы да бик әйбәт булыр, менә күрерсең!

Һәм Суфиян бу мәсьәләдә үзенең ялгыз калуын гына түгел, бигрәк тә көчсез булуын сизеп, ниһаять, килеште.

Инде моны карчыкның үзенә житкерергә кирәк иде. Кияү, билгеле, бу эштән читтә калырга теләде, чөнки ул, нинди генә якын кеше булмасын, карчыкның үз баласы түгел... Шуңа күрә улы белән кызы әйтергә тиеш булдылар: «Әсәй жаным,—диделәр алар ана иплән кенә,—докторлар сине бер атна-ун көнгә больницага салып торырга куштылар, анда дәвалап карамакчы булалар. Син борчылма бер дә, хәлең яхшыргач та, кире алып кайтырбыз үзенне...»

Акъәби моның чын сәбәбен сизгәндерме-юктырмы, әмма «болнис» дигән сүз үзе генә дә аның котын алды, бәгырен телгәләп жибәрде. Тәмам куркып, рәнжеп һәм ялварып ул: «Балакайларым, зинһар кузгата күрмәгез, шушы жылы урынымда тыныч кына үлим, миңа берни дә кирәкми вакытым житте, аңлагыз шуны!»—диде.

Ләкин улы белән кызы, ташка әйләнеп булса да, аны үгетләп, юатып, хәтта азрак кына көчләп тә урыныннан кузгаттылар, киендереп чыгардылар һәм «Волга» машиналарына кырын яткырып, алдан кияве сөйләшеп куйган бер больницага илтеп салдылар.

... Өч тәүлек үтүгә, төнлә белән Акъәби шул больницада вафат та булды. Жан биргәндә, янында кеше булмаган. Берәүне дә борчымыйча, күбәләктәй тавыш-тынсыз гына киткән дә барган. Әйтерсең, үзенең Юлкотлысына...

Иртән иртүк әбинең үлгәнен телефон аша кызына хәбәр иттеләр. Кызы белән кияве шунда ук машинага утырып больницага киттеләр. Алар килгәндә, Акъәбине үлекләр ята торган цемент идәнле таш бүлмәгә төшереп куйганнар иде инде. Тиздән улы Суфиян белән килене Мария Васильевна да килеп життеләр. Ак жәймә астында яткан әсәйләренең йөзен ачып карадылар. Йөзе бер дә бозылмаган иде, киресенчә, ничектер авыр газапларыннан котылып, тынычланып калган кебек иде. Әмма күзләрендә ни торып калгандыр, анысын күрмәделәр—күзләрен кемнеңдер бармагы сак кына йомдырып куйган иде.

Аннары больница бакчасына чыгып, шунда гына карчыкны ничек итеп жирләү турында үзара киңәш корып алдылар. Мулла чакыру, женаза укыту кебек нәрсәләрне эшләмәскә булдылар. Шулай да әсәйләренең Аллага ышанган карчык кеше булуын исәпкә алып һәм аның үзенең дә бик үтенеп соравын исләренә төшереп, гәүдәсен кәфенгә төреп күмәргә булдылар. Ләкин, гонаһ шомлыгына каршы, больницадагы мәетне юып, киендереп озатучы маржалар кәфен дигән нәрсәне бөтенләй белмиләр дә икән. Ә читтән кеше чакыртып, дини йолага бәйләнгән нәрсәләрне эшләтү монда рөхсәт ителми икән. Шулай итеп, чарасыздан, Акъәбине «заманча гына» әзерләргә мәжбүр булдылар. Бер чиста күлмәген китереп өстенә кидерделәр, башына «мөселманча» итеп ак батист яулык бәйләделәр, шуннан соң гәүдәсен кечкенә кызыл табутка салдылар. Табут әйләнәсенә чәчәкләр тезделәр, күп итеп исләмәй сиптеләр, һәм Акъәбиебез хәйран матураеп китте. Ул, бичара, хәтта көләмсерәп яткандай күренә башлады.

Зыяратка табутны машинага куеп илттеләр. Озата баручылар күп түгел иде: иң якыннары да аларның кайбер дус-ишләре һәм шулар арасында әлеге кечкенә буйлы шагыйрь дә бар иде. Ләкин ул бүген дә кызмача иде шикелле.

Табутны кабергә төшергәндә, кызы Гөлбикә бик каты елады, килене Мария Васильевна да елады, аның кызлары да «бабушкаларын» кызганып елашып алдылар. Ләкин ирләр түзделәр... Кияве, иреннәрен кысып, читкәрәк китте. Ә улы Суфиян, әсәен озату шәрәфенә, бөтен орден-медальләрен өр-яңа кителенә тагып килгән, башына соры папахасын сындырыбрак кигән полковник, кабер кырыенда таш сыныдай басып торды. Үлемне күп күргән, елауны күптән онытkan кеше булуына карамастан, аңа бу минутта яшьләрен йотып калу гаять авыр иде шикелле.

...Күмеп бетергәч тә, борылып китү ничектер кыен иде, шуңа күрә шагыйрь ак балчык өеме янына басып, мәрхүмә турында берничә сүз әйтергә булды:

—Кадерле дуслар, без менә шушы биек тау башындагы, инде үләннәре дә корыган, чәчәкләре дә шиңгән җир куенына Акъәбиебезне бирдек,—диде ул, ашыкмыйча, салмак кына.—Ак күңелле, пакь күңелле әсәебездән мәңгегә аерылдык... Әйе, ул барыбызның да уртак әсәебез иде. Алай гына да түгел, мин, һич икеләнмичә, аны башкорт халкының изге җанлы анасы дияр идем... Әмма нәрсә беләбез без анын хакында?.. Күрә белдекме без анын шул изге җанын, пакь күңелен, ак уйларын!.. Менә сез, анын уллары, кызлары, кияүләре, нәрсә генә әйтә аласыз гомере буе сезнең өчен өзелеп яшәгән бичара әсәегез турында?.. Юк бит, әйтә алмыйсыз бит...

Шунда ук Суфиян кычкырып анын сүзен бүлде:

—Син ни сөйлисең, ә?! Ташла, кирәкми...

—Безобразие бу!—диде кияве дә, кызарып-бүртенеп.

Шагыйрь аларга һич игътибар итмичә тагын нидер әйтә башлаган иде, шул чакта кемдер аны беләгеннән эләктереп, кабердән җилтерәтеп читкә алып китте. Телгә батыр булса да, гәүдәгә бик җиңел иде шагыйрь...

Бу күңелсез тамаша аркасында озата килүчеләр янә гына кабергә куелган Акъәбине ничектер онытып җибәрделәр. Берәүләр шагыйрьне тиргәргә тотындылар, икенчеләр, киресенчә, аңа әһәмият бирмәскә, сүзне уенга борырга тырыштылар. Һәм үзара сөйләшә-шаулаша кабер янынннан тарала да башладылар. Иң ахырдан кузгалган Гөлбикә зират капкасы төбендә утыручы карт-корыларнын учларына тиз-тиз генә акча салып чыкты...

Киттеләр. Агыйдел, Дим буйларына караган биек тау башында Акъәби берүзе генә торды да калды.

Әмма ләкин Акъәби биек тау башындагы зыяратта әнә шулай ялгызы гына торып калса да, үзенең фани дөнья белән аерылып бетмәвен тагын бер тапкыр балаларынын исенә төшерде. Хикмәт шунда, кызы Гөлбикә Юлкотлыда карчык өен карап торучы әлеге күрше хатыны Гарифәгә кыска гына хат язып, әсәйләренең август ахырында вафат булуын хәбәр иткән иде. Озак та үтми, Гарифәдән дә Акъәбинең үлүенә бик хәсрәтләнеп, күрше-тирәнең аны бик кызганып елауларын әйтеп, инде бахырның өе ятим калды, аны нишләтергә уйлыйсыз, дип борчылып язган хат килә. Хат артыннан ук колхоз машинасына салып җибәргән карчыкның иске яшел сандыгы да килеп төшә. Күрәсең, яхшы күңелле Гарифә үзенчә бер изгелек эшләргә теләгәндер инде, ләкин монда ул сандыкны берәү дә әле көтми иде. Яна гына кичергән кайгы-мәшәкать аркасында, гомумән, Юлкотлыда калган өй-нигез турында да, башкасы турында да уйлашырга өлгермәгәннәр иде. Инде менә әсәйләренең үзе белән бергә картайган, буявы да уңып беткән иске сандыгы: «Мин сезнеке, мине нишләтәсез?»—дигәндәй, Гөлбикә квартирына килде дә керде. Гөлбикәгә бу сандык бик таныш иде, кайчандыр анын шушы сандык өстендә курчак уйнаган чаклары да бар иде, кинәт күргәч, әллә нишләп китте, бер мәлгә аптырап-каушап калгандай булды. Аннары исенә килеп, тиз генә агасы Суфиянга шалтыратты. Шул ук көнне кичкә табан агасы белән җингәсе Мария Васильевна, зур уллары Геннадийны да ияртеп, аларга килеп тә җиттеләр.

Барысы да җыелып беткәч, сандыкны идән уртасына куеп ачтылар. Ачып җибәрүгә, алар өстә генә яткан ак бәз кәфенлекне күрделәр. Һәм, күреп, берәр сүз әйтү түгел, хәтта бер-берсенә күтәрелеп карарга да ничектер кыймадылар, тик ак материяне сак кына бер читкә алып куйдылар. Аннары бөкләп салган кием-салымнарны чыгарырга тотындылар. Менә әсәйләренең тәнкәле кара җиләне, читләренә ука тоткан сары хәтфә камзулы, алтынга манган тәнкәләр һәм төрле ташлар тагылган бөяте (хәситәсе), вак мәрҗәннән эшләнгән кашмавы белән чәчкабы, беләзек, муенса, чулпылары, кыз чагында үз кулы белән чүпләп суккан кызыл башлы сөлгеләре килеп чыкты. Шулай ук аталарынын кызыл сәдәпле кара кәзәкие белән камчат бүреге дә килеп чыкты—карчык шушы көнгә кадәр аларны да саклап торган икән, бичара!.. Актарына торгач, тагын бер хикмәтле әйбер табылды: бу аталарынын яшь чагында тотып йөргән кыска саплы, күн чуклы, өч җәпле, һәр җәбенен очына көмеш пластинка бөкләп кидерелгән бик шәп камчысы иде.

Хикмәтле камчы шунда ук барысын да бик кызыксындырды.

—Һай, атаемның төлке куганда тотып чапкан камчысы бит бу!—дип кычкырып ук җибәрде Суфиян һәм элмәгеннән киеп селтәнеп тә, бот буена сугып та карады.

—Да-а, менә бу ичмасам реликвия!—диде кияве дә, сокланып.—Тик кем саклар аны?

—Ә аның хуҗасы бар,—диде Суфиян катгый рәвештә һәм улы Геннадийга борылып, тантаналы итеп әйтте:—Мә, улым, Гена, ал бабаңнан калган чуклы камчыны... Белеп тот, Шәяхметовлар кулында йөргән камчы булыр бу!..

Һәм Геннадий Шәяхметов баш кагып, елмаеп кына өч җәпле камчыны кулына алды.

...Инде калган әйберләрне нишләтү, ничек бүлешү мәсьәләсе кузгалды. белгәнебезчә, әсәйләренең бу хактагы теләген алар тыңламыйча калдылар. Шулай да һәркайсы үзенә ошаган нәрсәне алырга хаклы иде. Ләкин бу тәнкәле җилән, хәтфә камзул, бөят, кашмау, чәчкаплар белән алар нишләрләр икән?.. Төс итеп кенә саклаудан башкага ярамый инде боларның берсе дә, аунап йөри торгач, череп-тузып кына бетәрләр... Шул чакта кияүләренең башына бик шәп бер идея килде. Ул болай диде:

—Менә нәрсә, Гөлбикә, каенагай! Без бу әйберләрне бүлешеп, әрәм-шәрәм итеп бетермик. Барыбер файдаланып булмаячак бит... Без лучше тотыйк та бөтенесен театр гардеробына тапшырыйк. Анда мондый нәрсәләрне саклый беләләр, борынгы тормышны уйнап күрсәткәндә, киеп файдаланырлар, ә безнең тарафтан театрга бу бик әйбәт бер бүләк булыр. Чын, уйлагыз әле!

Бу фикергә шунда ук Мария Васильевна да кушылды:

—Бик дөрес әйтәсез, Сәхип Карамович, безгә нигә алар, артистлар кисеннәр.

Ләкин Суфиянга да, Гөлбикәгә дә мондый тәкъдим белән тиз генә килешүе авыррак иде. Ничектер күңелләре тартып бетерми иде. Әллә ничек менә әсәйләреннән яхшы түгел кебек—алар өчен саклаган, аларга, дип калдырып киткән бит әле ул... Инде тот та бөтенесен кочагы белән театрга илтеп ташла! Килешерме, оят булмасмы?

Шул ук вакытта кияүләренең сүзендә дә дөреслек бар: бүлешеп алсалар, әрәм-шәрәм булып кына бетәчәк: нишлисең, тәнкәле җиләннәр, укалы камзуллар заманы үтте шул инде!.. Ахырда, уйлаша торгач, башта Суфиян, аннары Гөлбикә дә яшел сандыктан чыккан бөтен кием-салымны театрга илтеп тапшырырга риза булдылар. Гөлбикә шулай да әсәенең төсе итеп, уртасына кызыл якут куеп, саф көмештән челтәрләп эшләнгән ике зур чулпыны үзенә алып калды.

Көннәр уздылар. Хәсрәт иртәнге томандай бик тиз таралды. Эш, мәшәкать белән тулы иркен, мул тормыш үзенең иске эзеннән ашыгып һаман алга таба тәгәрәде. Акъәбинең балалары өчен бу кызу чапкан тормыш бик тансык та һәм бик мавыктыргыч та иде.

Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә... Куыша-куыша йөгергән кылганнар арасыннан, озын карагай таягын җир үлчәгәндәй алга ташлап, Миңлебай карт кайтып килә. Ыштан балагын энкә тыгып кигән ак оекбашларына чәчәк тузаны кунып, билчән уралып, бакра сырышып беткән—әйтерсең, Юлкотлы яланнарын үзе белән ияртеп кайта ул...

Авылга кереп, Акъәбинең тәрәзәләре кагылган өе янына җиткәч, карт күрше Гарифәдән гел кычкырып сорап уза:

—Аккилен кайтмадымы әле?

Гарифә ни дип җавап бирергә дә белми—ул бит инде аңа былтыр ук берничә мәртәбә Акъәбинең калада вафат булуын әйткән иде. «Балалар акылы керә башлаган ахрысы бу картка»,—дип уйлый ул эченнән генә һәм, аптырагач, ачуланып биреп әйтә:

—Куй, Миңлебай бабай, үлгән кеше кайтамыни, ничек телең барып сорый.

Ләкин карт аның сүзләрен гүя колагына да элми.

—Алдама,—ди ул, таягының башын селкеп.—Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр, насыйп булса, кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен.

Һич анламассың, әллә чынлап, әллә үчекләп, әллә саташып әйтә бу бернигә исе китми торган әҗәлгә дә күптән кулын селтәгән, ялан таптаучы йөз яшәр Минлебай карт!

## Искәрмә

Аксылу. Аккилен. Акҗиңгә. Акбикә.

Хәзер инде аны, Акъәби, дип олылыйлар.

Болар—бер кешенең исемнәре.

Озын гомер кичергән Акъәбинең сандыгында пөхтәләп төрелгән кәфенлекләр генә түгел икән. Аның бәяләп бетергесез хәзинәсе мулдан: сөлгеләр, камзул, кәзәки, камчат бүрек, хәситә, чулпылар, кашмау, чәчкап, муенса, беләзек... Ә күңеле сандыгы чагыштыргысыз бай икән. Халыкны үзгә-үзенчәлекле иткән әйберләренә өстәп, Акъәбинең туган ил турында, кендеге өзелгән туган җире турында васыяте бар икән! Балаларына һәм оныкларына әйтәсе шушы васыяте турында көн-төн дигәндәй уйлана, башкорт иленә, башкорт язмышына бәйле һәр нәрсәне ишетүенә һәм хәтерләвенә куанучы да, кайгыручы да башкорт әби:

«... Сез киттегез, әмма ул чакларда әле сез Юлкотлыны онытмый идегез, бала кошлар шикелле очып-очып кайткалый идегез... Ләкин ни өчен сез аны соңыннан оныттыгыз?.. Чакырып-дәшеп тә еллар буе кайтмый башладыгыз?... Ике сүзнең берендә «туган ил» дисез, ә Юлкотлы нәрсә соң? Туган илнең сезгә иң якын, иң кадерле бер өлеше түгелмени ул?..»

Ишетмиләр Акъәбинең болай ачыргалануын балалары. Оныкларын инде әйткән дә юк.

«... Сез бик еш кына «халык» дисез, ләкин Юлкотлыдагы кешеләр дә халыктыр бит инде. Бер тамырдан чыккан, бер ыругтан үрчегән халык, шуңа күрә ул сезгә якынрак та, туганрак та булырга тиештер ләбаса!»

Акъәбинең өзгәләнүе балаларына һаман ишетелми. Оныкларын әйтәсе дә юк.

«Яки атагыз мәрхүмне исегезгә төшерегез. Ул да бит халыкның бер бөртеге... Сезгә җан биргән, сезнең өчен тир түккән, сездән күпме өметләр көткән ата кеше бит әле ул сезгә! Йә, сез аның алдында бер дә бурычлы түгелмени соң?.. Аның каберен мин дә, тагын берничә авыл карты гына белә. Бездән соң белүче булмаячак, кабер җир белән тигезләнәчәк... Йә, сезнең җаныгызны бер дә борчымыймыни бу нәрсә?..»

Акъәбинең рухи газабын балалары һәм оныклары барыбер ишетмиләр.

Ходай ла! Үзгәлеген-үзенчәлеген югалтучы халык, барыбызның да Анасы-Әсәе булган изге Акъәбинең васыятен кабул итү түгел, ә тыңларга да теләмәгәч, югалтуга бара түгелме соң?!.

Юк, һич тә алай түгел икән!! Ялан таптаучы йөз яшәр Миңлебай карт Акъәбинең күршесе Гарифәдән гел сорап уза:

«—Аккилен кайтмадымы әле?..

—Куй, Миңлебай бабай, үлгән кеше кайтамыни...

—Алдама... Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр, насыйп булса, кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен.»

Әйе, өзекләр Әмирхан абый Еникинең әле генә сез укыган «Әйтелмәгән васыять» исемле хикәясеннән (1965 ел) китерелде. Өзекләрнең күбрәк һәм озынрак китерелүе минем Әмирхан абыйдан уздырып әйтә алмаячагымны ихластан тануымнан булды. Соңгы җөмләгә игътибар итегез—«Учагында ут сүнмәсен». Инде халыктагы бер гыйбарәне искә төшерик. Авылның һәр ихатасында өч төтен күтәрелеп торырга тиеш икән: өй, мунча һәм самавыр

торбаларыннан. Кунаклар килүенә барысы да әзер булыр ягъни. Ә кунакчыллыгыбыз бетмәгәч, халкыбыз бетми дә бетми инде!

Шулай шул—сүзне оста сайлаганда гына әдип укучысына фикерен төгәл җиткерә ала. Әмирхан абый исә сүз сайлауга—әдәби әсәрнең теленә бик тә таләпчән, хәтта талымчан иде. Егерменче гасырның җитмешенче елларыннан соң мин аның белән шактый аралаштым, әңгәмәләребез әдәбият-сәнгать турында иде, әлбәттә, тормыш барышына еш кагылгалый идек, гайбәт тирәсенә төшмәдек. Шахмат уйнаган чакларыбыз булды, хәтта сабан туенда (аңа инде алтмыш яшь иде) бил дә алыштык.

Бервакыт ул миннән кинәт:

—Хәситә...—диде дә, гадәтенчә тукталып уйлангач:—Нәрсә ул? Каян беләсең син аны?—дип сорады.

Бу, шиксез, Әмирхан абыйның мине сынавы иде. Шул чакта басылган бер хикәямдә «хәситә» сүзе кулланылган иде. Көмешчеләр-коемчылар авылы тумасы булуымны, бала чагымнан һөнәрмәндләр ясаган бизәнү әйберләренең күбесен туган авылымда күреп калуымны, әмма коемчы һөнәрен белү миңа килеп җитмәвен әйттем.

—Алай икән...

Аксакал соравының ни өчен бирелүен шәрехләмәде, ләкин бу бәя минем өчен зур иде.

Икенче вакытта—1997 елның 22 февралендә Әмирхан абыйның өенә баргач, мин аңардан «шәриктәш» сүзенең дөрес кулланышы ничек булуын сорадым. Хикмәт шунда—бер хикәямә әлеге сүз керүен әйттем, бу сүзне аңламауда мине гаепләүче булды, дидем. Әмирхан абыйның «Казан утлары» журналының шушы бүлегенә әзерләнүче «Матурлык» исемле бик мәгълүм хикәясендә дә бар иде бу сүз: «Әнә шундый сәер генә, серле генә һәм сөйкемле генә бер егет иде безнең Бәдретдин шәриктәшебез!»

—Дөресе «шәрик» булмыймы икән...

—Шулаймы... Ялгыштым микән...—дип чәй яныннан акрын гына кузгалды Әмирхан абый һәм береаздан икенче бүлмәдән кечкенәрәк форматлы, әмма шактый ук калын китап күтәреп керде.—Карыйк әле без шул сүзне.

Сүзлегенең тышлыгы таушалган ук иде, исеме күренмәде, ахрысы гарәп әлифбасында иде бу китап. Мин исә нинди һәм кем төзегән сүзлек икәнлеген сорарга базмадым.

—Монда «шәриктәш» диелгән,—дип иркен сулады Аксакал язучыбыз.—Төзәтмибез. Язылганча калсын.

Бу кечкенә деталь дә Әмирхан абый Еникинең әдәби телебезне камилләштерүдәге олпатларча өлешенә бер дәлил булып тора, әлбәттә.

Өч сәгать чамасына (артыграк та бугай) сузылган шушы очрашуда ук мин Әмирхан абыйга бер хатының күчермәсен бирдем. Унынчы класста—1948 елда язылган хикәя сыман нәмәрсәкәйгә аның кыскачарак анализы иде бу. Мактап та күрсәткән иде соң Әмирхан абый минем «Тимерче эше» исемле иҗат җимешемне!.. Шөкер, аның турыдан һәм гадел тәнкыйтендә мин әдәби иҗатның олпатлыгын аңлый башладым кебек. Ә моны аңларга тырышу хәзергәчә дәвам итә...

Әмирхан абый, хатының күчермәсен укыгач, үзенә генә хас булганча йомшак кына елмайды, аннары кеткелдәп куйды... Һәрчак дөресен язуына—мәсләгенә тугры булуына сөенүе иде аның! Олпат Аксакалның сөенүе исә миңа да сөенеч булды.

Мондый тәэссораты да аның кеше буларак та олпатлыгы булып тоелды миңа. Әйе, Олпат шәхес, әдәбиятыбызны тотучы Әзмәвер әдипләрнең берсе иде Әмирхан абый Еники.

«Әйтелмәгән васыять» хикәясе әдипнең ике томлык «Сайланма әсәрләр»енең икенче томыннан (1971 ел) алынды.

*Әсәрне журналда бастыруга*
**Мәгъсум ХУҖИН** *әзерләде.*



## Гөлчәчәк Галиева

# БАРСАМ

ЧЫН ХИКӘЯТ

*Ирем Әхмәт сөйләгәннәрдән*

*Кара юрга аткаем,*
*Йомшак иде ялкаең.*
*Күңелемнән китәсе юк*
*Тугрылыгың, малкаем!*

**1942** елның февраль башлары иде. Мин өченче сыйныфта укып йөрим. Көннәрдән беркөнне, дәрес вакытында, безнең сыйныф ишеген кинәт кенә кемдер шакыды. Сискәнеп киттек. Укытучы апабыз ашыгып ишеккә юнәлде...

Бераздан ул безгә:

—Балалар, колхоз рәисебез Ахун абый килгән. Аның сезгә әйтер сүзе бар икән. Басып каршы алыгыз,—диде.

Сугышка кадәр Ахун абыйны без барыбыз да яхшы белә идек. Алыптай баһадир гәүдәле, төз сынлы, бик тә сөйкемле кеше иде ул...

Бүген исә каршыбызга без яраткан, якын иткән Ахун абыебызга бөтенләй дә охшамаган ят бер кеше килеп басты. Аның йөзенә күтәрелеп туры карарга да әллә ничек кенә уңайсыз иде: сул яңагының буеннан-буена чыбыркы очы сыман нечкә-озын, күкле-зәңгәрле җөй сузылып төшкән. Ул җөйнең бер очы күз кабагының аскы ягын тарттырып, күзен йомылып бетә алмаслык иткән... Аскы ирененең яртысы юк, теш казнасы имәндергеч булып, ыржаеп күренеп тора... Элек арыш тулы капчыкны баш очына кадәр көчәнми-нитми күтәрә алган сул кулы урынында хәзер... буш җин...

Без хәтта утырырга тиешлегебезне дә онытып, баскан көйгә тораташтай катып калдык. Каршыбызда коточкыч сугыш афәтенең ни-

Гөлчәчәк ГАЛИЕВА—*язучы; «Тулгак» китабы авторы. Язучылар берлеге әгъзасы.*

нәрсә икәнен миләребезгә, вөҗүдебезгә сендерергә теләгәндәй, бу сугышның тере шаһиты басып тора иде. Аның куркыныч рәвешкә кереп гарипләнгән йөзе, шыксыз булып асылынып торган җиңе бу каһәр төшкере сугышның әле кешеләр өстенә янә дә мең вә мең бәхетсезлекләр яудырачагын сүзсез дә сөйли иде.

Ул, исән кулы белән гарип авызын каплабрак, безгә болай диде:

—Утырыгыз, балалар... Мине күргәч тә аптырап калганыгызны аңладым... Нишлисең, сугыш бит. Аннан кем генә исән-имин кайтыр икән, белмим... Ыжгырып килгән фашистны атарга мылтыгы да җитми бит аның. Ярый, балалар, фронт хәлләрен икенче юлы сөйләрмен. Ә хәзер бер гозеремне тыңласагызие. Анда, конюшнидә, янарак кына туган бик матур ике колыныбыз үлем хәлендә ята. Әнкәләре дә шул ук хәлдә. Күтәрәмгә калганнар, бичаракайлар. Әгәр дә кайсыгыз да булса шул колыннарны өенә апкайтып исән калдыра алса, гел үзегезнеке булачак. Сүз бирәм! Ату үләләр бит бичаралар. Калхуз аларны барыбер саклап кала алмый. Уйлап карагыз әле, йә, кайсыгыз тәвәккәлләр икән?!.

Тынлык... Башлар иелгән... Сугыш бит ул үзе белән бергә ачлыгын да алып килә. Өендә бер уып салырдай булса да умачлык оның калса ярый әле ул... Бу балаларның байтагы үзләреннән туйганчы ашаган чакларын инде хәтерләмиләр дә бугай. Югыйсә, кырык беренче елны игеннәре дә үкереп уңган иде лә. Әмма дә... Әмма дә халыкка аның бөртеге дә эләкмәде.

—Абый, берсен мин алып карыйм әле...—дип әйткәнемне сизми дә калдым. Сафура апам мәктәптә директор булып эшли. Әнием дә үтә мәрхәмәтле зат. Шуларга ышанганмын, шуларга таянганмындыр инде...

—Бәрәкалла! Ялгышмасам, син Кәшифәттәй малае бит әле, име? Сыер тота аласызмы соң?

—Әйе, Ахун абый, сыерыбыз бар. Сөтен дә ишле бирә.

—Сөт эчерә алсагыз, колын исән калачак, Аллаһы боерса!

Өйгә кайтып керү белән, әнигә барысын да ашыга-ашыга сөйләп бирдем.

—И-и, бала, ат жене кагылган шул сиңа, ат жене... Барсаң өстеннән егылып төшеп, беләгеңне бер тайдырганыең инде, югыйсәм...—диде әни.— Күз алдымнан һич кенә дә китәсең юк: Барсанны сугышка озатканда жылый-жылый шешенеп беткәниең. Әтиеңне йөрткән ат булгачтын, бөтен яшәве бездә ие бит инде ул малкайның. Бигрәкләр дә мал жанлы бала шул син, улым... Йә, бар инде, бар, олы чананы лапастан ал да, йөгер!

* * *

Конюшнигә килеп керсәм... Бетәшеп беткән ябык, тире дә сөяккә генә калган (әмма дә тиресе-йоны сокланып туя алмаслык чем кара матур!) бер колын үләксә шикелле сузылып ята, мин синайтим. Маңгаенда ап-ак кашкасы да бар. Күзләре йомык. Җан әсәре тамчы да сизелми. Эчем жу-у итеп китте, тыным кысылды. Җылап җибәрдем. Үлгән колынны җәлләп җылавымны ишеткәнме, әллә каян гына ат караучы Сәттар абый килеп чыкты.

—Сәттар абый, икенче колын кайда? Монысы үлгән бит, үлгән. Ахун абый: «алар икәү», дигән ие...—дим, ә үзем әле һаман да җылавымнан туктый алмый сулкылдыйм.

—Юк, олан, исән әле, исән ул!—ди Сәттар абый.—Җә инде, жегет кешегә яшь агызып җылап тору бер дә килешми. Әнәтерә, жегет булгач, колын да үлемгә бирешмәскә тырыша. Ә менә син сораган икенчесе үлде. Анысы да матурые, бә-әк матурые. Әйдә, балакай, чанаңны мондарак китер, икәү күтәреп салмый булмас: яңа туган булса да, авырлыгы житәрлек монын, ат токымы бит... Һай, әгәр дә исән-имин үстерә алсаңмы?!— Нәселле айгыр булачак бу! Сәттар абый әйткәние, диярсең әле менә, боерган булса!

Колынны күтәреп маташканда, ничектер, күзем әнкәсенә төште. Йә Ходаем, күзләрен зу-у-ур итеп ачкан да, әле безгә, әле колынына карый. Башын да күтәрмәкче була үзе, тик хәле генә юк... Капылт кына торырга теләгәндәй, бөтен гәүдәсе белән талпынып та карый, бичаракаем...

—Саттар абы-ы-й! Күр әле, әнә безгә ничек итеп тилмереп карый. Күзеннән мөлдерәп яшь ага. Нишләп икән, ә?

—Бала—кемгә дә бала шул инде. Кадерле. Колыны күздән югалуга ук үләчәк инде ул, бичара...

—Саттар абый, ат күзеннән нишләп мөлдерәп яшь ага икән ул, ә? Әти җигеп йөри торган теге Барса исемле атны сугышка озатканда да шулай булганые. Әллә атлар да кешеләр шикелле җылый микән ул?

—Һы, ничек кенә җылыйлар әле! Тик алар тавышсыз гына, атларча гына җылыйлар...—диде Саттар абый, көрсенеп.

Шулай, икәүләшеп чана тарта-тарта, сөйләшеп кайта-кайта, өйгә җиткәнебезне сизми дә калганмын. Капканы ачуга, Моряк атылып килеп чыкты. Безнен эт ул. Аптыраган кыяфәт белән әле миңа килеп сырпалана, әле чанага карап йомшак кына өргәләп ала, әле: «Син кем соң?» дигәндәй, Саттар абыйга да өргәләп куя.

Колынны идәнгә кертеп салдык. Әни җылымса гына итеп сөт әзерләп куйган. Сөтне олы кашык белән колынның авызына сала башладык. Әмма колын аны йотмады, сөт авыз турысына куйган җамыякка агып төшә торды, төшә торды. Мин колынның башын бераз гына күтәреп торам, ә Саттар абый ике кулы белән аның авызын ачып, әни исә олы кашык белән сөт салып тора. Сөт идәнгә ага... «Булмас ахры бу»—дигән шомлы уйдан өметем киселеп барганда, менә тәрә вәйт, Ходайның рәхмәтле бирмеш көне, колыным беренче йотымын йотмасынмы! Озак та үтмәде, күнелләребезгә шатлык өстенә шатлык өстәп, күзләрен дә ачып җибәрде бу! Менә сөенеч кайда икән ул!

Бераздан Саттар абый:

—Аллага шөкер, болай булгач, монысы исән калды, дигән сүз. Ярый, мин кайтыйм инде,—дип, саубуллашып чыгып китте.

Озакламый мәктәптән Сафура апай да, энекәшләр дә кайтып керде.

Озын-озак уйлап тормадык, колыныбызга Барса дип, әти җигеп йөргән атның исемен куштык.

—И-и, балакайларым,—диде уйларыннан айнып-арынып киткән әниебез.—Әле генә шуны уйлап утыра идем... Барса диген... Элекке Барсабыз да ап-ак кашкалы, нәселле ат иде бит. Монысы тагын да матуррак булырга охшаган, тик әтиегез генә юк...—диде дә, күз яшьләрен безгә күрсәтмәскә тырышып, битен яулыгы белән каплады. Әнинен йөрәгеннән чыккан ачы сагыш, моң тулы бу сүзләрен без ул чагында анлап та бетермәгәнбездер. Исән калган колын шатлыгы биләгән иде безне ул чакта. Ул шатлыкның иге-чиге юк сыман иде. Әллә инде безнен бу халәтне анлап, боларның куанычларын тагын да арттырыйм әле, дигәндәйме, колыныбыз да нечкә, озын сыйракларына басарга талпына башлады. Нәзир энем белән мин, аңа торырга булышмакчы булдык. Колынның корсак астыннан тоткан Нәзир кинәт кенә чырыйлап кычкырып җибәрмәсенме:

—Карагыз әле, пес итә бит бу, пес итә! И, Алла, кулларымны буяды бит, әни, тизрәк астына ләгән куй инде!

Ачуым килде моңа.

—Улым, тыныч кына тор, песе буленмәсен. Соңыннан үзем сөртермен дә алырмын—диде ана әни. Ләкин энем мырлавыннан туктамады.

Ачуым тулышты, түземем төкәнде.

—Бигрәкләр дә өф-өф инде син, Нәзир. Чебен тисә чер иткән кызлардан бер дә ким түгел. Харап булган, кулына колын сидеге чәчрәгән икән, үлә күрмә инде тагын...

—Нигә бу төшеннән үзең тотмадың соң алайсам, мина куштын? Хәйләкәр төлке, өстәвенә әле ачуланган була тагын. Ачуымны бәк

китерсән—киттем-бардым... Үзең тот!—диде дә Нәзир, авызын турсайтып, китте дә барды. Ә колын, маладис, сыйраклары бераз калтыраса да, сер бирмәде, аягында калды һәм... һәм идәнне чылатуын дәвам иттерде.

Атна-ун көн эчендә Барсабыз тәмам ныгыды, тернәкләнде бит, әй! Шаянлыгына, арт сикертеп чапкынлавына, кыланмышларына түзәр әмәл калмагач, тоттык та, җылы абзарга чыгардык үзен. Апай үзенең күз карасыдай карап торган тегү машинасын каядыр илтеп, ике капчык солыга алыштырып кайтты. Әле тагын каяндыр бер капчык арыш көрпәсе дә юнәтте.

Мин Барсаны әкренләп өйрәтә башладым. «Сыйлавын» да камчы-чыбыркы белән түгел, шакмаклап туралган шикәр чөгендере белән генә сыйлыйм инде анысы. Хәер, Барсага чыбыркы-камчының бервакытта да йомышы төшмәде. Акыллы иде ул, зирәк иде.

Шулай бер-бер артлы атналар, айлар үтте. Торган саен зирәкләнә баруы белән колыным күрше-күләнне дә гаҗәпкә калдыра башлады. Ул үзенең шатлыгын да, үпкәсен дә, рәхмәтле булган чакларында хәтта «рәхмәт»ен дә матур итеп аңлата, кешеләрнең тел белән әйтүенә караганда да үтемлерәк итеп аңлата белә иде. Үзенә генә хас кешнәве, дәү күзләре, бар килеш-килбәте белән ничектер нәзакатьле, затлы итеп «сөйләшә» иде ул безнең белән.

* * *

**1944** ел. Ул елларда безнең якларда бүреләр бик ишәйде. Әйе, 1944 елның салкын марты иде. Шундый көннәрнең берендә, шабыр тиргә батып, саташып уянып киттем. Әллә нинди шомлы иртә. Иртә дә түгел әле бу, иртәнең яралгысы кара төн чатыры эчендә әле тыпырчына гына башлаган чак.

Ишегалдына чыктым. Чыксам... Минут эчендә түгел, бер мизгелдә минем янга койрыгын болгап килеп җитә торган Морягым юк! Күренми... Оясына якынрак килеп карасам, өнсез калдым: ап-ак кар өстендә кан тамчылары, йолкынган йоннар, бүре эзләре... Бөтен тәнем куырылып китте. «Моряк бәгърем, син кайда, нишләттеләр сине?!» дип, әллә кайларга кадәр ишетелерлек итеп кычкырасым, бөтен дөньяга аваз саласым килде, әмма тавышым чыкмады. Кинәт кенә: «Абзардагылар ни хәлдә икән?» дигән уй йөрәгемне өтеп алды. Карыйм: шөкер, ишекләре ябык, аларга аркылы салган нык аралар да үз урынында. Бүре дигән зәхмәтнең түбәдән төшә торган гадәте дә бар, Аллам сакласын! Атылып абзарга керсәм... башка чакта ишек янында ук басып, иреннәре, янаклары белән битләремне назлап каршы ала торган Барсам хәзер исә миңа арты белән баскан да, пошкырынгалап тик тора. Юк, юк, бу гадәти пошкыруы түгел аның. Кай җире дә булса авыртудан, шуңа чыдый алмыйча гасабилы ыңгырашуы, уфылдавы бу аның. Башын бормыйча гына, үзе күз кырые белән мине күзәтә. Карашында тирән үпкә сизелә кебек. Морягымны кызганудан йөрәгемнең әле дә булса сулкылдап әрнегән бер мәлендә бахбаемның бу аңлаешсыз сәер халәтен күрүдән мин, ни уйларга да белмичә, гаҗиз калдым. Өстәвенә, алгы аякларын чиратлаштырып, тезеннән бөгеп, миңа таба боргалап та ала. Һич аңламыйм... Ни булган? Нигә үпкәләдең? «Их, Морягым өчен йөрәгемнең ничек итепләр сыкранганын-сызлаганын белмисең шул син, югыйсә, миңа болай артыңны куеп тормас идең»—дим. Шулай дип Барсамны муеныннан кочаклап алуым булды, аның күтәребрәк торган аягына күзем төшүе булды... Малкаемның ике аягында да канлы җәрәхәт иде. Йә Хода, бүре-зәхмәт әллә монда да үтеп кергәнме? Абзарның бөтен җирен: идәнен, түшәмен, ян тәрәзәләрен карап-тикшереп чыктым. Тик шикләнерлек урын тапмадым. Атымны яктыда җентеклəбрәк карамакчы булып, абзар ишеген киңрәк итеп ачып җибәрдем. Таң сызылып килгәндәге ак кар яктысында ишектәге сузылып-сузылып киткән кан эзләре шәйләнде. «Ah!» иттем.

Аннары, ниһаять, барысын да аңладым: әй, бичаракаем, Морякны коткарам, диеп, жан көчләре белән тибенгән икән. Аяклары канаганчы тибенеп, ишекне ачмакчы булган, күрәсең. Үпкәсен тел белән әйтә алса: «Их, син, нигә уянмадың? Моряк бит безне ничекләр итеп чакырды, мин дә бит сине чакыра-чакыра кешнәдем, нишләпләр генә уянмадың, югыйсә, мылтыгың да бар иде бит»—дигән булыр иде ул. Мин исә абзар ишегенең калын такталардан ясалуына, аратаның да нык булуына сөенеп бетә алмадым. Әй, Барсакаем—җүләркәем минем, ярый әле чыга алмагансың! Бер көтү бүре үзеңне дә ботарлап ташлаган, харап иткән булыр иде. Синең хәсрәтеңне мин дә, әни дә күтәрә алмас идек. Аның бит хәсрәте болай да башыннан ашкан: әтине җирләдек, Гаяз абыем сугышта, ут эчендә. Инде кайчаннан бирле хәбәре-хаты юк. Җизнинең хаты килгәли хәзергә дә, ләкин сугыш үз корбаннарын чүпләп кенә тора бит. Безнең авылга гына да кемгә—«үлгән», кемгә—«хәбәрсез югалды» кәгазе никадәрле килде бит инде. И, гөнаһсыз малкаем! Син бездән акыллырак шул, сөйләшә генә алмыйсың...

Таң атты. Әни дә уянып чыкты. Аннары без икәүләп Барсаның аякларын юып, җәрәхәтләренә киптерелгән бака яфрагын уып сиптек тә, йомшак чүпрәк белән кысып бәйләп куйдык. Аяклары авыртуын, шәт, баса алганбыздыр, әмма хәсрәтен баса алмадык, күрәсең. Ул көнне Барсабыз ни ашамады, ни эчмәде. Гел яратып каба торган шикәр чөгендере кисәкләрен дә биреп карадым,алмады, капмады, башын гына борды. Озак, һай, озак онытa алмады ул урак койрыклы шаян нәни дустын. Аптырагач, эт оясын юкка чыгарырга туры килде. Шуннан соң гына нәни дусты Моряк яшәгән ул урыннан, туктап калмыйча, тыныч үтә башлады.

* * *

Бервакыт Барса апай белән икебезне коточкыч бәладән (бәлки әле үлемнәндәдер) саклап калды.

1944 елның зәмһәрир салкын кышы иде. Сабадан укытучылар өчен декабрь аена бирелгән хезмәт хакы акчасын алып кайтып киләбез. Юлның шактый өлеше урман кырыеннан уза. Шул урман кырыена житәрәк, күрәм: ике ир заты урманнан чыгып, нәкъ юл уртасында безгә каршы басып, туктап торалар. Берсенең кулында мылтыгы да бар. Эчкә шом керде, курку төште. Апай хәтта агарынып китте.

—Энем, бу урманда сугыш качкыннары яши икән, дип сөйлиләр иде. Мөгаен, шулардыр. Безнең акча апкайтканны беләләр инде болар, нишлибез?..—ди.

—Апай, син сузылып ят, түлке чана башына ныгытып ябыш, ныклап! Төшеп калырлык булмасын. Курыкма, Барса бирешмәс!—дигән булам.

Барса да, нидер сизендеме, әсәренеп, колакларын торгызды. Пошкыруында да шом сизелә. «Нишлик?»—дигәндәй, башын үзе безнең якка да боргалап куя. Ә тегеләр—торалар. Кузгалмыйлар да. Атны туктатачакларына ышаналар, күрәсең. Инде болар турына килеп житәбез, дигәндә генә, минем: «Әйдә, на-а, Барса!» дип, бар шәпкә дилбегәне каты итеп кисәк кенә тартып җибәрүем булды, Барса жаный дүрт аяклап чабып боларның өсләренә ташланмасынмы! Өстәвенә, әллә нинди бер усал, дәһшәтле-кыргый тавыш белән көтмәгәндә кешнәп җибәрде! Бу хәл тегеләрнең бөтенләй котын алды бугай: икесе ике якка (ничек тайпылып өлгергәннәрдер?) юл читендәге кар көртенә мәтәлеп кенә килеп төштеләр. Артыбыздан атып карадылар каравын, шөкер, соң иде инде. Коштай очкан Барсабыз безне бу кәбихләрдән шактый ук еракка алып китеп өлгергән иде инде. Бераздан, йөзеннән кан качкан, акбурдай агарынган апай да телгә килде:

—Э-э-э-нем жа-аным! Исән калдык бит! Барсабыз тегеләрнең жүнсез кешеләр икәнен бездән элегрәк сизенгән икән бит, әй! Ул синең команданы гына көткән булып чыга бит. Сөбханалла! Атлар кешеләрдән

дә зирәгрәк була, дисәләр, бәлки ышанмаган да булыр идем—диде дә, сәер генә тынып калды апаем. Борылып карасам, апаем ике кулы белән дә йөрәк турысын тоткан, бөгелеп төшкән...

Шул вакыттагы куркуыннан имгәнеп калган йөрәге озак чыдый алмады анын. 1953 елның мартында, бары тик утыз өч яшендә чагында, берсеннән-берсе кечкенә кызлары Алия белән Алисәне ятим калдырып, дөнья куйды ул...

* * *

Барсам турындагы иң авыр сәхифә—кызганыч хатирә—ул аерылышу, мәңгегә аерылышу тарихы... Күнелемә гомер буена житәрлек әрнүле жәрәхәт салган бу вакыйгаларны күз алдына китерү мина әле хәзер дә жинел түгел...

... Нигәдер, ул көнне иртәдән үк эчем пошты. Сәбәбе дә юк төсле. Мәктәпкә дә теләр-теләмәс кенә киттем. Дәресләр беткәнен көтеп тормыйча, озын тәнәфестә тиз генә өйгә кайтып килергә уйладым.

Кайтып киләм шулай, күрәм: безнең капка төбендә тарантаска жигелгән ат тора. Капканы ачып керсәм, ишегалдында ике ят ир-ат, кулларын болгый-болгый, минем апайга нидер аңлатып маташалар. Абзарның ачык ишегеннән чыгар-чыкмас боларны күзәткән Барсага да карап-карап алалар. Бахбаем, мине күргә, гадәтенчә—биегәнсыман вак-вак атлап яныма килеп житте. Мин анын маңгаен кашыдым, муенын сыпырдым. Шунда тегеләрнең берсе:

—О! Какая походка! А осанка, осанка какая! Это же не конь, а чудо!!!—дип, атыма соклануын белдерде.

Барсамның боларда эше юк: ефәк төкле йомшак иреннәре, янаклары белән ул минем битләремне назлый, иркәли...

Шул рәвешчә бераз басып торгач, икенче ир заты да телгә килде:

—А какой ласковый, настоящий джигит!—дип, Барсаның елкылдап торган янбашыннан сөеп куйды.

Апай мине ымлап кына өйгә дәште...

Бу кешеләрнең атымны алып китәргә килүләрен белгәч, бугазыма утырган төердән сулышым капланды. Сүзсез калдым. Авыр иде мина. Әйтеп бетергесез авыр иде. Мин, үз-үземне белештермичә, йодрыкларым белән ишек яңагын төйдем.

—Бирмим! Бирмим!!! Үзем ач кала-кала, үз өлешләремне ашата-ашата үлемнән саклап калдым мин аны. Ә сез ул вакытта: «Нигә ябыга бу бала, тәмам сөяккә калды бит»—дип аптырый идегез. Ни хаклары бар аларның?! Әйдә, Ахун абыйга әйтик: «Мәктәпне атсыз калдырасыз бит» диик...

Апай сүземне әйтеп бетерергә дә бирмәде, нинди дер куркынган-серле тавыш белән ишетелер-ишетелмәс кенә:

—Тукта, энем, шаулама. Хәзер безгә Ахун абыең түгел, обком үзе дә ярдәм итә алмаячак, болар бит НКВД кешеләре. Закон алар кулында, ни телиләр—шуны эшлиләр. Энем, жаным, мине саклыйм дисәң, зинһар өчен, үзең булыш инде. Берүк кире дәшә күрмә! Барыбер алардан котылып булмаячак, «алабыз» дигәч, алалар да алалар инде болар.

Апайның шушы сүзләреннән соң, Барсага үз кулларым белән йөгәнен киертеп, капкадан үзем алып чыктым. Күземә яшь тулды. Теге кешеләрнең берсе атланган арада атымның ялларыннан, янакларыннан сыпырам, үбәм, ә күзләремнән мөлдерәп яшь ага...

Урам буйлап бераз ияреп бардым да, кинәт кенә борылып, атыма: «Сау бул!» дип тә әйтә алмыйча, бугазыма тыгылган төерне йотарга тырышып, өйгә чаптым. Кайттым да, чак-чак тыеп торган яшьле күзләрем белән мендәремә капландым.

Әмма, озак та үтмәде, берзаман, шактый ерактан ук Барсамның ярсып кешнәгәне ишетелде. Атылып-бәрелеп урам якка караган ачык тәрәзәгә

ташландым. Карасам-күрсәм... Бахбаем бар булмыш көченә чаба-чаба, сырт сикертеп өйгә кайтып килә!

Ишектән чыгу юк—тәрәзәдән генә сикердем. Әле анда да чак-чак кына өлгердем. Капканы ачуым булды—ялт Барсам! Миңа күзен дә салмыйча, янымнан выжлап кына үтеп кереп китте бу мин сиңа әйтим! Шул чагында муены буйлап сузылып төшкән озын камчы эзен күреп алдым. «Аh, фашист тәреләр!»—дип кычкырганымны сизми дә калдым. Аннары, муеныннан кочып назламакчы булып, янына килдем. Әмма ул, капылт кына борылды да, абзарга кереп китте һәм миңа арты белән басты. Инде ни генә, ни-нәрсә кылсам да Барсамның мине үзенә якын җибәрмәячәге көн кебек ачык иде. Әйе, аның үзен бу рәвешле тотуы хыянәтем өчен үпкәләве генә түгел, ә бик тә, бик тә нык рәнҗүен белдерүе иде.

Икенче көнне барысын да күреп-күзәтеп торган бер дус малаем миңа менә нәрсәләр сөйләде: «Башта тыныч кына барган бахбай авылны чыккач та кисәк туктап калды. Бер адым да кымшанмый бу, мин сиңайтим. Куган саен киреләнә, пошкыра-пошкыра таптанып, бер урында тик әйләнеп тора. Атланган бәндәнең дә берзаман тәмам түземе төкәнде: оятсызларча сүгенеп, камчысы белән Барсаның муенына сыздырып җибәрүе булды, бахбай ыргылып китеп чаба да башлады. Арт сикертеп чаба, хитри! Менә бер заман кисәк кенә арт санын шундый итеп күтәрде бу—теге мөртәтҗан атның башы аркылы җиргә очып та барып төште, Барсаң да кире авылга сыпырды, вәт! Аяклары җиргә дә тимәде бугай, очты гына, малай!»

Инде бер атнадан соң, ниһаять, Аллага шөкер, атыбыз үзебезгә калды бугай, дип куанып кына йөргән бер мәлдә безнең капка төбенә җигүле ат белән тагын бер ят кеше килеп туктады. Матур гына ишеккә шакып, өйгә килеп тә керде бу. Матурын матур да, әмма дә йөрәк барыбер «»жу-у! итеп китте. Күнел дигәнең сизенә бит ул, тиз генә өйдән чыгып шылдым. Башымда бер генә уй бөтерелә: ничек итеп атны шыпырт кына абзардан чыгарырга да, төнгелеккә урманга сызарга...

Өйалдыннан да чыгарга өлгермәдем:

—Карале, кем, энекәш, минем атка да инешегездән су эчертеп менсән яхшы булырые. Туарып биримме атны, әллә үзең дә булдыра аласыңмы?—дигән тавышка сискәнеп, имәнеп киттем. Теге абый шыпырт кына артымнан ук чыккан икән, карак мәче диярсең...

—Ат та туармаска...—дип, төксе генә җавап кайтардым да, ирексездән, теләр-теләмәс кенә атлап урамга чыктым. Капка аратасына бәйләп куелган, елкылдап-тупылдап торган яшь алмачуар бияне күрүгә, һәммәсен дә онытып, онытылып, күреп туймаслык бу затлы гүзәлгә текәлдем. Бу сылубикәгә соклану тәэсиреннәнме, күнелемә бер уй килде: «Нигә соң әле шушы алмачуар белән бергә Барсамны да инеш буена алып төшмәскә ди?!» һәм шулай эшләдем дә.

... Бахбайлар, бер-берсен күргәч тә, башларын нәзакатьле генә чайкап, тыйнак кына кешнәшеп, пошкырынгалап алдылар. Аннары Барса, вәкарь белән генә сөлектәй сыгылмалы сынын уйнатып, кияү егетедәй көяз атлап, кунакның янәшәсенә үк килеп басты. «Кунак кыз» исә, һич тә көтелмәгән бу бәхетле очрашудан нишләргә дә белмичә, әле биегәнсыман иттереп зифа аякларын тыпырдаткалый, әле елкылдап торган гәүдәсен дулкын-дулкын дерелдәтеп, уйнаткалап ала...

Менә бер мәлне болар йомшак иреннәре белән бер-берсен назларга керештеләр. Вакыт-вакыт кешнәшеп тә куялар. Халык телендәге: «Кешеләр сөйләшеп, атлар кешнәшеп табыша» дигәннәре менә шушы була торгандыр инде ул.

«Егет» белән «кыз»ның су буендагы матур кыланышларын сүз белән генә язып бетерә торган түгел, аны үз күзләрең белән күрү кирәк. И-и, уйнап та карадылар инде Моряк үлгәннән бирле Барсамның болай шаярганы, болай куанганы юк иде әле. Хәтта ул янәшәләрендә минем басып торганымны, барлыгымны да онытты. Аның бөтен кыяфәте: «Күрәсезме, мин нинди бәхетле!»—дигән шикелле иде.

Мин бу ике гашыйкның шушы бәхетле халәтенә сокланып туймадым, хәтта көнләшеп тә куйдым бугай әле. Үземнен дә Зәйтүнә исемле бик тә чибәр, сөйкемле бер кызга гашыйк булып та, хисләремне белдерергә җай таба алмыйча гаҗизләнеп йөргән чагым иде лә...

Зәйтүнәкәем янында, нишләптер, гел өлкәнрәк егетләр чуала иде шул. Көннәрдән-беркөнне шуларның берсе: «Карале, Зәйтүнә, нишләп әле юеш борынлы бу салага синен тирәндә бөтерелә?»—димәсенме! У-у-ф-ф, шул чактагы гарьләнүләрем, хурлануларым... Ачуымнан шартлардай булып, хыялым белән тегенен ипи шүрлеген шундый иттереп «җимереп» ташладым! Зәйтүнәгә: «Нишләп салага булсын ул, менә дигән егет ич! Ул мина бик тә ошый!»—дип кенә әйтсә бит инде, югыйсә...

Менә хәзер, бу гүзәл җаннарның сөю-сәгадәтле халәттә мәхәббәттә анлашуларын күзәткәндә, янымда Зәйтүнәкәй булса, ул минем хәлемне анлар иде, дип уйлаганым әле дә хәтеремдә. Һай, самими-садә, гүзәл сабыйлык елларым...

Һич тә көтмәгәндә: «Әхмәт! Әхмәт!»—дип дөнья ярып кычкырган тавышка сискәнеп китеп, борылып карасам, йөзе качкан энем Ирек йөгереп килеп тә житте.

—Әхмәт абый! Әхмәт абый жаным, атларны апкайт инде. Теге кунак абый ашыга! Беләсен килсә, ул бит Барсабызны апкитәргә килгән! Теге вакытта килгән кешеләрнен ин зур нәчәлникләре икән ул, исеме Шамил абый...—дип, тыны кысылудан, бу хәбәрне көч-хәл белән анлатты.

Шылды. Анлашылды. Әйе, барысы да анлашылды. Бу юлы инде Барсамның үзе теләп китәсе көн кебек ачык иде. Минем атыма хуҗа булыр өчен менә нинди хәйләле, мәкерле юл эзләп тапканнар... Көчсезлегемнән, чарасызлыгымнан күнелем тулышты. Мин, ачы күз яшьләремә буылып, яр буена сузылып ятып, үкси-үкси еладым...

Капка төбендә безне көтеп торган теге юньсез кеше:

—Сөбханалла! Кара боларны, ничек килешкәннәр, ә! Безнен Иркә егетне сайлый белә шул ул. Егет тә бик канәгать күренә, шулай бит, Сафура ханым?—дип, янында басып торган апайга күзен кысты.

Бу бәндәнен кыланмышларыннан косып җибәрерсен, билләһи! Ун фашистны жыгып салырлык гәүдәсе белән, сугышка китмичә, монда гына илнен тынычлыгын саклый имеш. Авыл халкы ачлыктан интегә, ачтан үлә, ә ул—аяклы әбрәкәй, корсагын киереп, монда мин үстергән атны алып китәргә килгән... Шул вакыттагы кичерешләрем, уйларым, нәфрәтем миндә гомерем буена сакланып калды. Онытa алмадым, һай, оныта алмадым мин Барсамнан мәнгегә аерылган ул көнне.

Аннан сон байтак вакытлар дәвамында ак кашкалы колынымны төшемдә күреп, уянып китә торган булдым. Колынымның күзләре йомык икән. Жан әсәре дә сизелми... Эчем жу-у итеп китә, тыным бетә... Жылап жибәрәм... Шунда әллә каян гына ат караучы Сәттар абый килеп чыга... «Исән әле ул, исән!»—ди имеш Сәттар абый.—Жә, инде, жылама, жегет кешегә жылау бер дә килешми...—ди икән имеш... Ә мин үлгән колынымны кочам... Анын нәни гәүдәсенә ингән боз салкыны мина да күчә, минем бар вөжүдемне биләп ала һәм мин, шабыр тиргә батып, туңып уянып китәм...

Сәттар абый да юк инде. Сугыш ачлыгын күтәрә алмыйча вафат булды. Урынын жәннәттән әйләсен. Ни дияр иде икән? Барсанын үзенә икенче гомер биргән, авызыннан өзеп, азыгын ана жәлләмәгән ин якын дустын шулай жинел генә ташлап киткәнен күргән-белгән булса, ни генә дияр иде икән? «Дуслык кына түгел, мәхәббәт дигән нәрсә дә бар әле бу дөньяда. Ул дуслыктан өстенрәк була. Ә син борчылма, олан. Барсан сине беркайчан да онытмас»—дияр иде, мөгаен...

✻

*Һәр төбәктә—безнең каләмдәшләр*

# УЗЫП БАРУЧЫ ЕЛДАН ШИГЪРИ БӘЙЛӘМ

*Халкыбыз күңелендә узып баручы 2002 ел—күп һәм җуелмас истәлекләр, хатирәләр елы булып калачак дип уйлыйбыз.*

*«Казан утлары», димәк, безнең 80 еллык юбилеебыз тантаналары белән башланып киткән III Татар Конгрессы корылтае, аннары Рәсәй буенча җанисәп—халык санын алу көннәре...*

*Тагын башка күп бәйрәмнәр һәм дәүләтчелегебезне—Казанны югалтуга 450 ел тулу уңае белән моңлы Хәтер көне...*

*Егерменче гасыр азагында кабат алдык дип ышанган суверенлыгыбызны да акрынлап җую куркынычы, сәясәттәге төрле афәтләр, янаулар, касәфәтләр... Болар бар да шигырь теленә дә күчте, рухи бер активлык тудырды: шагыйрьләр күп яза, яңа исемнәр дә күренә тора... Һәм иң мөһиме, төрле төбәкләрдән, бигрәк тә Башкортстаннан хатлар, шигырьләр еш килә. Гомумән, Башкортстан халкы язмышы, андагы татар шагыйрьләре иҗаты белән журналыбыз даими таныштырып бара: юбилейларын да билгеләргә онытмыйбыз, яңа исемнәрне дә күрсәтә киләбез. Бу санда тәкъдим ителә торган бәйләмдә Уфадан Лилия Сәгыйдуллина—әнә шундый, шиксез, сәләтле яңа шагыйрә дип уйлыйбыз. Ул—Шаран районы кызы, бүгенге көндә Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укытучы. Доцент, фәннәр кандидаты. Татарча бер китап бастырып чыгарган безнең авторыбыз, «Азатлык» радиосының Уфадагы үз хәбәрчесе Мөнир Вафинны да укучыбызга мәгълүм исем дип уйлыйбыз. Берничә китабы булган, Яңавылда яшәүче Фәрит Суфияров та...*

*Чыңгыз Мусин атлы шагыйребез—Әгерҗедә туып-үссә дә, иҗади мәйданы—Ижевскида, шундагы газета, әдәби көчләр мохитендә. Аның да берничә китабы бар, ул—Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Ә Алабугада яшәп иҗат иткән мәрхүм Фазыл Шәехнең бу бәйләмдә—инде аның васыяте булып, соңгы шигырьләре тәкъдим ителә. Бу шагыйрь—күңелендә чын шигырь һәм матурлык, сөю короны йөрткән икән...*

*Чаллыдан Мансур Сафин—шулай ук укучыга билгеле; русча һәм татарча шигырь китаплары авторы. Ул—тәрҗемә дә итә, публицистика өлкәсендә дә актив эшли. Журналыбызда әлегә сирәк күренде ул.*

*Питрәчтә яшәп иҗат итүче керәшен кардәшебез Павел Апушев та—берничә шигырь китабы авторы. Проза да яза. Ул—милли җанлы, чын татар рухлы шагыйребез.*

*Бу бәйләм—яңа 2003 елга кергәндә иске елдан шигъри саубуллашу хатлары, «утырып уйлар уйладым» дигәндәй, халкыбыз, хәлебез һәм киләчәк турында гамьнәребезнең бер елъязмасы булыр, укучы аны нәкъ шулай кабул итәр дигән өметтә калабыз.*



# Чыңгыз Мусин

## Мәхәббәт

Кичке эңгер җиргә иңгән.
Хуш исле серле алан.
Мин хыял аргамагында
Үткәнгә кайтып барам:

Очрадың да юлларымда,
Күңелне сихерләдең.
Әле дә яшьлектә табынган
Мәхәббәт хисендә мин.

И... серле гүзәл нәфислек,
Кемне әсир итмәгән?
Тәүге сихри тойгыларны
Йөрәгемнән үткәрәм.

Моны тою зур бәхеттер,
Иң гүзәл саф хистер ул.
Мәхәббәтең—җанга хуҗа,
Бер илаһи көчтер ул.

Гомеремнең гүзәл гаме,
Шигъри гамь ул—хислелек.
Иң бөек хис—мәхәббәт ул,
Яши җанга көч биреп.

Тик офыкта куе томан
Иртәләрдә, кичен дә.
Ирексездән чайкаламын
Шул томаннар эчендә.

Гамьсез яшьлек узган инде
Давыл белән, җил белән.
Ә мин аны куа-куа
Юлларымда сөрлегәм...

Яшьлегемә йөгереп кенә
Кайтып буладыр кебек.
Ул мине үрләр артында
Көтеп торадыр кебек.

## Соңладым

Мин тормышны соңрак белдем, ахры.
Йә туганмын җиргә иртәрәк.
Тик нигәдер язмыш кануннары
Юлларымны торды киртәләп.

Йөрәгемдә гүя тоям кебек
Бәхет гөлләренең сулганын.
Хыял үрләренә җитәлмамдыр,
Соңладым шул, ахры, соңладым.

Һәр кылганның җирдә үз сәгате,
Тормыш җырым кайчан язылыр?
Гомер көзләренә килеп кердем,
Ә бу, бәлкем, бәхетем языдыр?

*Ижевск шәһәре.*



# Фазыл Шәех

## СОҢГЫ ШИГЫРЬЛӘРЕННӘН

### Кояш

Кояшның мин күрмим яктылыгын,
Тоям бары аның җылысын.
Ләкин яшим нурлы хозурында,
Рәхмәтемнең әйтеп олысын.

Караңгыдан, кара күләгәдән,
Буш төннәрдән саклыйм акылны.
Кояш килә миңа—кешеләрнең
Якты күңелләре аркылы.

Минем җанга, димәк, һәрбер кеше
Таңнар, көннәр, кояш китерә.
Юк, кояшсыз яши алмый сукыр,
Нуры белән һаман ул бергә.

Ләкин сукыр—кара күңелләрнең
Нурсызлыгын тоеп интегә.
Җаны кала аның рәхәтләнеп,
Айсыз төннәр үтеп китүгә.

Сукыр кеше дөнья киңлегендә
Нинди юллар капшап бармасын,
Тоеп яши хәтта күкләрдәге
Йолдызларның моңсу карашын...

Белмәсә дә сукыр—газапларның
Язмышына язган иң дәвен,
Әллә нигә тора сулышы да—
Аңа ярдәм иткән берәүнең!

### Көн яктысы белән хушлашканда

Җирнең яме белән инде күптән
Хушлаштым мин көзге көннәрдә.
Кояш, йолдыз, ай нурларын күрәм...
Төшләремә генә кергәндә.

Ак күңелләр кыйбласында яшим,
Ямен тоеп бөтен Галәмнең.
Шуңа салкын кара төннәрдә дә
Ару белми кайнар каләмем.

Ә ул тормыш давыллары аша
Әйди мине алга юл алып.
Битараф һәм гамьсез күңелләрнең
Йөрәгенә очкын, ут салып.

Ничек риза булыйм, мин сукыр дип,
Шигъри җаным эшсез торсынга?!
Бурычым бар—газиз халкым өчен
Наз булырлык җырлар тусынга.

Кояшның мин нурын күрмәсәм дә,
Җылысы бар итә йоламны.
Юк, барыбер җиңел булмас миңа
Ташлап китү якты дөньяны.

## Мәхәббәт хаҗы

Күзге гөлбакчада йөргән чакта,
Берән-сәрән өзәм гөлләрен.
Әүвәл шул гөлләргә гашыйк булып,
Йокы күрмәдем мин төннәрен.

Хәзер алар назланырга әзер,
Күкрәгемә кат-кат үрелеп.
Җаныма ут салган чәчәкләрне
Үбәргә дә булмый өлгереп.

Ул гөлләрнең инде хуш исләре
Сүрелсә дә кырыс җилләрдә,
Алар гүя үкенечләр аша
Яшьлегемә сәлам җибәрә.

Вакыт әфәнденең сихри көче,
Күрәсең, үз эшен эшләгән.
Яшьлекнең тик кайтавазы килә
Күз яшьләрен түккән төшләрдән.

Баш иям мин күзге гөлбакчаның
Чәчелеп калган чәчәк таҗына,—
Кайнар мәхәббәткә юл сайлаган
Йөрәгемнең сөю хаҗына.

—Саумы, Мөхәммәт?!—ди күршем, күреп
Кулымдагы алсу гөлләрне.
—Ару,—дим мин,—Мөхәммәтнең әле
Хаҗи булып киткән көннәре...

*Алабуга шәһәре.*



# Павел Апушев

## Яшәү белән үлем талаша

Җиргә киләбез бит
Яшәү, Тормыш, диеп,
Яшәү белән үлем талаша.
Бу дөньяда ни рәхәтем, диеп,

Кешнәп куя бер карт алаша...
Яшәү белә үлем киләчәген,
Чөнки яшәү бит ул акыллы.
Белми үлем кемне йотачагын
Чиксез явызлыгы аркылы.
Кояш якты, кояш мәрхәмәтле,
Алып килә матур, алтын көн.
Ай да көмеш төстә, һаман истә,
Тик юлдашы аның—кара төн...
Көнгә көндәш төн дә инде әнә
Алсу офыклардан авышкан.
Уртак авазларны ишетәбез
Чишмәләрдән килгән тавыштан.
... Нәни чишмәләр бит, ага-ага,
Олы елга белән кавышкан.

## Ялгыз чакта

Көзге кич. Өйдә берүзем.
Тәрәзәмә җил шакый:
—Керт мине, дустың булырмын,
Ялгыз утырма бакый...

—Гомер буе яшим сине,
Җил дускаем, яратып.
Юлдашларым-уйларымны
Китәрсең шул таратып.

... Җил артыннан килеп кунды
Тәрәзгә сары яфрак:
—Керт мине,—ди, серләшербез,
Утырмачы аптырап.

—Яфраклар—минем сердәшем,
Барсы да якын таныш.
Сине кертсәм, уйларыма
Сарылыр сары сагыш.

—Исәнме!—дигән шикелле
Тәрәзәмнән ай карый.
—Яктырып китәр уйларым,
Сиңа керсәң дә ярый.

## Җан бөреләрем

Җилләр япса, үзең ач син
Тәрәзәләрең иртән.
Мин бит сөю-сәламемне
Шул җилләр аша илтәм.

Керсен алар өй эчеңә
Сөйләргә хисләремне.
Исеңә ал, җаныңа сал
Сагынган кичләремне.

Калмасын бөре эчендә
Шытасы яфракларым.
Җаным бөреләрендә ич
Өзелеп яратканым.

## Җибәрә күр фәрештәңне

Читлеген ваткан җанвар күк,
Сындырып кыршауларны,
Эзләп китәселәр килә
Ачмаган утрауларны.

Җилкәнне шашкын җилләрнең
Иркенә куясы да
Барып чыгасы иде лә
Бәйсезләр дөньясына.

Пушкин да килгән кунакка
Үз итеп чегәннәрне—
Торагы чатыр булса да,
Табигать сөйгәннәрне.

Аерма ләкин, и Тәңрем,
Сизгер, сак күзләреңнән.
Читләшсәм туры юлымнан,
Бастыр үз эзләремә.

Тыя бел җилләр иркен дә
Иң кирәкле чагында.
Юлдаш итеп, фәрештәңне
Җибәрә күр яныма.

Шикле гамәлем булганда,
Ул мине күреп торсын.
«Болай ярармы икән?!»—дип,
Бер акыл биреп куйсын...

## Кайт үзеңә

Мин бәхәстә үткен итеп
Карамасам дус күзенә,
Рухым дәшә: син бит хаклы,
Чигенә күрмә, кайт үзеңә.

Хәсрәтемнән башым иеп,
Тезләнсәм мин пар теземә,
Дәшә рухым: син бит горур,
Нишләвең бу, кайт үзеңә.

Ят арбага утырып мин,
Тап төшерсәм үз йөземә,
Дәшә рухым: син пакь кеше,
Ю кереңне, кайт үзеңә.

Онытылып әгәр бер көн,
Читкә тайсам үз эземнән,
Рухым дәшә: юлың туры,
Адашмачы, кайт үзеңә.

Вәгъдә биреп, үтәмәсәм,
Торалмасам мин сүземдә,
Рухым дәшә: туры бит син,
Таш ярырсың, кайт үзеңә.

Бер ялгышып, бер төзәлеп,
Дөрес юлны эзлим менә.
Рухым дәшә: тайпылмассың,
Иманлы бул, кайт үзеңә.

*Питрәч.*



## Мансур Сафин

## Иләһи мизгел

Кем кабызган бу кояшны,
Бу галәмгә җан өргән?
Яралдырган бу язларны,
Язмышларга моң үргән?

Кем офыкка Өмет утын
Иртә-таңнарда салган,
Гашыйк нурларына төреп,
Безне назларга манган?

Әйе, кем ул?
Кем иң бөек
Вә мөкатдәс, иң изге?
Ул—дөньяны Дөнья иткән,
Безнең күңелләргә җиткән
Тәүге Илаһи Мизгел!..

*Газиз Кашаф-Үзилегә*

Үзен-үзе яндырды ул
Иҗат учакларында,
Күбәләктәй бәргәләнеп
Илһамлы чакларында.

Гөл-учаклар мәңге дөрли,
Мәңге үзенә тарта:
Җан-күбәләк янган саен—
Дөньяның яме арта...
Үз-үзеңне корбан итү—
Бер дә яңалык түгел.
Беләм!..
Тик мин дә күбәләк шул—
Мине дә көтә күгем.

*Мин—Ватанчы!*
М. Гафури

Мин—Ватанчы! Табигатьче!
Милләтче генә түгел.
Каеннар кебек яратам
Туган ягымның күген.

Сандугачлардай инанам
Язның ал вәгъдәсенә!—
Мәҗүсидер күңелләрем—
Илаһи моңнар сеңә.

Җир-ананың җыр-баласы
Булып яшим галәмдә,
Шуңа күрә бар әйтәсем—
Кулымдагы каләмдә.

Мин—Ватанчы! Табигатьче!
Сулышларыбыз—бергә.
Канатым канап, егылсам—
Җирләгез җилле үргә:
Җирсүем булсын түрдә...

## Кызыл карлар

«Кызыл карлар» ява таң атканда:
Сөенечкә? Тылсым-сихергә?
Әллә инде Тәңре бүген килгән
Кыш турында изге фикергә?

Яз сулышын сизә бугай Ул да—
Елмаюлар чыга битләргә:
Бәлки менә бүген,
бәхет юрап,

Безнең яктан бүтән чикләргә
Мәҗбүр итәчәк ул
моң-зарларны
Кызыл буран булып китәргә?!.

❁

*Кадыйр Сибгатның юбилей
кичәсендә туган уй-шигырь*

Дусларым китә баралар:
Каерылып артка карыйм—
Әллә инде мин үзем дә
Алар артыннан барыйм?

Киек казлар кире кайта,
Язгы һаваны ярып,—
Нигә соң әле сагышлар
Күңелне ала сарып?

Ап-ак күбәләк-хисләрем
Яна япан шомлыкта:
Дусларымның китүләре—
Качу микән коллыктан?

Караңгы шул—күз төртерлек...
Дөнья тулы тозаклар...
Әле тагы ничә гасыр
Явыз Иван газаплар?

Дусларым китә баралар...
Кайгыдан—тик бер чарам:
Сагыш догаларын укып,
Мин дә шул юлдан барам.

*Чаллы шәһәре.*



# Фәрит Суфияров

## Йолдызларга карап

Караш җитми галәм чикләренә,
Йолдызларга карап сокланам:
Миллион еллар буе кешелеккә
Үз яктысын-нурын саклаган
Изге исем булып яңгырый алар
Планетада барлык телләрдә,
Зәңгәр төндә якты нурлар сибеп,
Күк өстендә алар тирбәлә...
Яз сулышын җиргә өрә сыман
Ерактагы йолдыз җилләре.
Яшьлек ямен, гүзәллеген күрәм,

Бу назларның юктыр тиңнәре.
Йолдызларның балкып елмаюын—
Күңелемдә калсын—күчерәм.
Сандугачлар сайрый, сихри төн бу,
Татлы хисләремә исерәм.
Күзләремә төшә якты нуры,
Кешеләргә шуны өләшәм:
Авыр минутларын җиңеләйтеп,
Елмаямын, көлеп эндәшәм.

## Хәтер китабы

Мин актардым хәтер китабымны,
Узган вакытларга карадым.
Йөгереп кенә кайтып бала чакка,
Болыннарны чыгып урадым.

Дусларымны күреп, барлап чыктым,
Мәҗлесләрнең булдым түрендә.
Бер ваемсыз үткән балачагым,
Кайгы болыты юк күгемдә.

Хәтер китабымны актарганда,
Мин тап булам шомлы елларга.
Кайгыларым кара шәлен бәйләп,
Чыгып баскан йөргән юлларга.

Ерак калган еллар кайтавазы,
Ялгыз калсам, килеп чаң кага.
Тетрәнә дә күңел кинәт кенә,
Диңгез дулкынылай чайкала.

Хәтер китабына бар да сыйган,
Күп югалту күрдем гомердә.
Язмышыма ятлар сөенмәсен:
Зарланмадым үзем мин бер дә...

## Поездларны юлга озатам

Поезд чаба, вагоннары зыңлый,
Тәгәрмәчләр җырын көйләде.
Моңсу чакта мин дә китәр идем,
Әллә ничек җае килмәде.


Газиз башны бирәр якка илтим,
Борчу-мәшәкатьне калдырып.
Авыр кичерешләр белән яшим,
Йөрәк утларымны яндырып.

Җир тетрәп калтырана сыман.
Гаделсезлек җанны өттерде.
Яңа көнгә күзләремне ачтым,
Кайнар яшьләремне түктерде.

Офыкларга караш тартылганда,
Поездларны юлга озатам,
Моң-сагышларымны алып китсәң,
Өнсез булып торам азактан.

Гәйбәтчеләр тынар, этләр өрмәс,
Китәм әле мин дә еракка,
Куанычлар, юанычлар юллыйм,
Бер тынгылык эзлим йөрәккә.

*Башкортстан. Яңавыл шәһәре.*



## Мөнир Вафин

### Тарту көче

Ник күкләргә тартылу соң
Һәр баланың эше?
Көчле буладыр, күрәсең,
Күкнең тарту көче.

Каурый кебек кала алмый,
Авырая кеше.
Һәм шул чакта бөгеп сала
Җирнең тарту көче.

Бала чакның хыяллары
Тәки чынга аша:
Күкнең тарту көче белән
Җан галәмгә аша.

Милләт дигән сүздә
Ми сүзе бар!
Бер күрсәтер әле ул үзен.
(Миле милләт булса!)
Тиле милләт булса
Ул бу сүздә
Таба алмас һич тә Ил сүзен.

Кеше туа.
Карыннан чыкканда ук
Күзләр шәрран ачык.
Тугыз айлык тоткын—дөньялыкка
Бер караштан гашыйк.

Кеше үлә.
Җан гәүдәне ташлый,
Газраилдән качып,
Бу дөньяны күреп туялмаган
Күзләр кала—ачык...

Кемдер балда, майда йөзә,
Тормышын оҗмах итә.
Икенчеләр ул оҗмахны
Ахирәтлектән көтә...

Монда оҗмахта яшәгән
Тәмуг көтәсен таный...
Адәмнәрне тигезләргә
Әл дә дөньялар—фани!

Дөнья куласа,
Әйләнә дә бер баса
Диләр.
Их, куласа
Тизрәк дуласа!
... Кыен ул аста.

Бу урында Алып батыр
Күккә карап яткан, диләр.
Аннан торып чабатасын
Рәхәтләнеп каккан, диләр.

Кеше әйтеп ышанмаслык:
Чабатага тулгач-тулган!—
Дөбер-шатыр аккан туфрак
Мәгърур-горур таулар булган.

Ул тауларга кешеләрнең
Карашлары төбәлгәннәр.
Кайберәүләр гомер буе
Атлап чак-чак менәлгәннәр.

Уңыш телим мин дә бакый—
Кеше атлы туганнарга:
Җан-тир түгеп, үрләгәндә
Миннән калган... тузаннарга.

*Уфа.*



## Лилия Сәгыйдуллина

### ҖИР БЕЛӘН КҮК АРАСЫ

Синсез үткән көннәремнең
Саннарын санамадым.
Йөрәктәге яраларның
Исәбен алалмадым.

Нух пәйгамбәр чорындамы
Без бергә булган идек?—
Туфан киләсен белмичә
Уй-теләк корган идек...

Кирәк булгандыр да шул чак
Көймә ясап каласы!..
Бүген исә безнең ара—
Җир белән Күк арасы.

Туфаннан соң гасыр түгел,
Күпме дәверләр үтте...
Яңа туфан кирәктер ул
Кушарга Җиргә—Күкне!

Болытлар төньякка ага,
Иссә дә саба җиле.
Табигатьтә иләслекме?
Әллә мин тиле-миле?

Тормыш үренә үрмәлим.
Әйтерсең, бер альпинист.
Шул үрне ала алмасам
Яшәү мәгънәсез, имеш...

Һәрбер адым—олы җиңү.
Бәлки шулдыр җиңелү.
Таң чыгыдай Күккә ашып,
Күк боз булып сүрелү.

Инде Күккә якынайдым.
Тик җитми сулар һава-а-а!..
... Саба җилләре иссә дә
Болыт төньякка ага.

Тегермән ташлары.
Тегермән ташлары...
Алтыннан кадерле
орлыклар ташланды.
Алтыннан кадерле
орлыклар вакланды.
Алтыннан кадерле
булмышлар таркалды,
он итеп тартылды
һәм камыр басылды.
Әй! Орлык затлары-ы-ы?!.
Эх, орлык чаклары!..

### Чәчәк-тау

Исеме бар—Чәчәк-тау, дигән.
Шау чәчәкле чагы булгандыр.

Хәтер булып исем калгандыр.
Бүген монда—ап-ак кылганлык.

Тауның зарын тыңлый тик җилләр,
Сыйпый-сыйпый кылган башларын.
Ни кичкән тау кыя вакытта?
Вакланып ук беткән ташлары.

Җыерчыклар баскан тау битен.
Кечерәеп калган шул тавым...
Тау булып тау үтә алмаган
Тәкъдир куйган вакыт сынавын.

Ялкын ялмый алтын яфракларны.
Күзгә яфрак—күзгә учакта!
Сүзләр кирәксездер бу чакта...

Учак өсләрендә—ак-ак төтен.
Хушлашулар шулдыр—Күз яна!..
Төтен исе. Төтен—дөньяда...

Синең янга төтен булып барсам!..
Тик ул бәхет кемгә эләгә?!
Мин—төтеннән калган күләгә...

## Гөнаһлы мин...

Гөнаһлы мин Ходай каршында:
Барлыгына аның инанмый,
Башка аллаларга ялындым,
Үзем ясап, сынга табындым...

Гөнаһлы мин атам каршында:
Мәңге яшәр, диеп, ышанып,
Әйтер сүзләр саклап йөрткәнмен.
Миңа рәнҗеп—анда киткәндер...

Гөнаһлы мин анам каршында:
Безгә бәхет теләп Ходайдан,
Үзен онытып, гомер кичерә,
Чәчләренә бәсләр төшерә...

Гөнаһлы мин сөю каршында:
Сөю йөзен таный белмичә,
Үземнекен күрми үткәнмен,
Башканыкын—мин үз иткәнмен...

Гөнаһлы мин синең каршыңда:
Сабыйларча, ихлас ачылып,
Ахры, сине артык яраттым.
Һәм шуңадыр—сине югалттым...

Гөнаһлы мин тормыш каршында:
Корылмаган йортым алдында,
Утыртмаган агач алдында,
Туылмаган бала алдында...

Гөнаһлы мин тормыш каршында!

*Уфа.*

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Харис Закиров

### ЛӘХЕТ

хикәя

Май аенын тымызык киче. Агачлар гүя йокыга талып килә. Ник бер яфрак селкенсен дә, ник бер үлән кымшансын. Ел фасылы ягыннан май яз ае саналса да, керсә дә җиһанда чын-чынлап җәйгә күчеш бара. Әнә агачлар гына түгел, җир өсте дә көннән-көн үзгәрә, яшеллеккә күмелә. Яшисе килә! Дөнья матур, дөнья киң ул, мәгълүм шагыйребез әйтмешли.

Балконнан карап, хозурланып торган Алмазны уйларыннан телефон шылтыравы бүлде. Ләкин ана илтифат итмәде. Чөнки оныгы укырга кергәннән бирле шылтыратучыларның күбесе ана түгел, оныгына була иде.

—Дәү әти, сине сорыйлар. Тавышы Хәсән абыйныкына охшаган.

Телефонда, чыннан да, Хәсән иде. Тавышы үзенә хас булмаганга карлыгып чыкты:

—Безнең сабакташ Азат үлгән бит. Иртәгә күмәләр, Самосырово зиратына. Соңгы юлга озатырга барабыздыр бит инде? Син нишлисең?—Баш редакторының киңәш сорагандай әйтүе—ул ярымбоеруга, күрсәтмә бирүгә тиң.

—Барабыз, барабыз, ул турыда сүз дә юк,—дияргә ашыкты Алмаз.—Нәрсәдән үлгән ди соң, белмәденме?

—Өйдә җан биргән. Нидән икәнен хатыны да төгәл генә әйтми. Замана чиредер инде... Йөрәк... Соңгы көннәрдә, түшенкелеккә бирелеп чамасыз эчкән бугай...

Берничә җөмләдән торган шушы сөйләшүдән соң, ул бөтенләй тынычлыгын җуйды. Азат белән бергә укып йөргән вакытларны исенә төшерде.

Алмаз, Хәсән, Азат—өчесе дә бергә укыдылар, алар Казан университетының татар матбугаты өчен әзерләнгән төркеменнән иде.

---

Харис ЗАКИРОВ *(1942)—журналист, прозаик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Керпе мыегы» исемле хикәяләр китабы авторы. Казанда яши.*

Азат эшләп килгән егет. Яшь аралары бер чама булгангамы, дөньяга карашлары туры килгәнгәме—алар Алмаз белән бик тиз уртак тел тапты, алай гына да түгел, дуслар ук булып киттеләр. Хәтта каникулларның берсендә Азатлар авылына кайтырга да җыенып йөргәннәр иде. Ләкин өченче курсны тәмамлар-тәмамламас көннәрдә аларның юллары аерылды: Азатны армиягә алдылар.

Укуы бүленүгә көенсә дә, тулай торакның кысан бүлмәләреннән котылып, хезмәт итү дигән романтикага сөенгән иде ул.

Армия дигәннән, Азат төзелеш батальонына эләкте. Ватанны яклау, хәрби романтика дип алгысынган егет кулына көрәк тоттырып, измә ясарга куйсыннар әле! Илдә сәяси хәлләр үзгәреп, бар нәрсә турында ачыктан-ачык сөйли-яза башлагач кына беленде: сигез миллион халкы булган Мәскәү үзеннән ике тапкырга кимрәк Татарстанга караганда азрак солдат бирә икән. Азат әнә шул тигезсезлеккә эләккән булып чыкты.

Сабакташы, югары чинлы командирларга дача йортлары салышып, арзанлы солдат хезмәте белән таш йортлар торгызуда катнашып йөргән арада, Алмазлар университетны тәмамлап төрлесе төрле якка таралышып, эшли башлаганнар иде инде. Шулай да Азат белән күрешергә насыйп булган икән.

Казан артындагы якын районда гына урнашканга күрә, Алмаз шәһәргә еш йөри иде. Бер килүендә алар Ленин урамындагы элек үзләре ашап-эчеп йөргән студентлар ашханәсендә очраштылар. Азат та, ниһаять, укуын тәмамлаган, өйләнеп өлгергән, телевидениедә эшли икән. Ул көнне хәл-әхвәл алышып кына калмадылар, Азатларга кунарга ук кайттылар.

Сабакташының торган җире, кайчандыр бакчачылык ширкәте саналып, тора-бара шәһәргә йотыла башлаган урында салынган йорт булып чыкты. Анысын да аларга хатыны ягыннан танышлары табып биргән, аңлашылганча, Азат Казан кияве икән.

—Бу өйдә кыш чыгып булмый инде. Ул ике такта арасына пычкы чүбе тутырып салынган куыш кына. Без бит әле бәби дә көтәбез,—диде Азат, зур серен әйткәндәй сөенеп. Ләкин сөенеч төсмерен бик тиз югалтты.—Фатир бирүче берәр оешма булса, моннан башларымны алып качар идем.

Азатның бу сүзләре Алмазны сагаерга мәҗбүр итте. Сабый чагыннан ук татар дөньясына омтылган, Казанны үзенең кыйбласы дип санаган һәм беренче теләгенә—журналист булуга ирешкән кеше шул шәһәрдән башын алып качарлык хәлгә житсен инде...

Күрешкән мәлдә сынатырга теләмәсә дә, сөйләшеп ачылып киткәч, Азат үзенең тормышында бик тә авыр хәлгә калганын әйтми булдыра алмады. Вакыт-вакыт алар хатынының әтисе йортына да барып торгалыйлар икән. Ләкин озаклап түгел. Бабай кешенең, тол калып яшәве өстенә, күзләре дә сукырайган, болай да тормыш кыерсыткан кеше, билгеле инде, яшьләр белән сыеша алмый. Шуның өстенә, Азат хатынының кияүдән кайткан апасы, фатир яшьләргә кала дип куркып, әтисен һаман-һаман аларга каршы котырта икән.

Болай караганда, фатир ягыннан Алмазның да мактанырлыгы юк, тулай торакта көн күрә. Аерма шунда гына: ул әлегә ялгыз. Ә ялгыз башка кайда да бер дигәндәй...

—Беләсеңме яшьти, сина фатир бирердәй бер оешма бар. Тик, Казанда түгел. Теләсәң, киләсе ялда бергә барып кайтабыз,—диде ул дустының күзләренә карап.—Чаллыга күч син!—Анда бер танышым бар. Ул кодалаган иде. «Теләсәң мина, теләсәң башка газетага урнашырсың. Баштарак кошчылык фабрикасына урнашып торырсың, анда чиратны озак көтмиләр. Урнашырга үзем булышырмын»,—дигән иде.

Бу сүзләрдән соң Азатның күзләрендә очкын кабынгандай булды. Аның «башларымны алып качар идем» дигән сүзләре чын күңелдән булган икән.

—Ярдәм итәргә әзер булуың өчен рәхмәт анысы,—диде Азат көрсенеп, шунысын гына аңламыйм, мин китәм, син киләсең булып чыга бу Казанга.

Озакламый Алмаз сабакташ дустының Чаллыга барып урнашуын һәм ике ай эчендә фатир алуын да ишетте. Күп тә үтми ул үзе дә Казанга

күчеп, балалар газетасында эшли башлады. Сирәк-мирәк булса да районнарга, шәһәрләргә командировкаларга чыккалады. Ә бер көнне ана Чаллыга барырга, шәһәргә һәм КамАЗ заводына нигез салган кешеләр белән очрашырга, аларның истәлекләрен язарга куштылар.

Сабакташы мул табын әзерләп көтә иде. Тавык итенең кыздырганын да, ысланганын да юнәткән. Хезмәт кенәгәсенә ярыш оештыручы инженер диеп язылса да, асылда кошчылык фабрикасының партия оешмасын җитәкли иде Азат. Әллә дустының килерен белгәч, сынатмас өчен, өстәлгә соңгысын чыгарып куйганмы? Болары хакында Алмаз төпченеп тормады, дустының тормышы рәтләнә башлаганга сөенеп кенә утырды. Тик менә фатир ягын бөтенләй үк хәл ителгән дип әйтерлек түгел икән әле. Утыз квадрат метрдан торган ике бүлмәле фатирның Азатка берсен генә биргәннәр, икенчесендә башка гаилә яши. Шунлыктан кухня, ванна, туалет кебек нәрсәләр тирәсендә еш кына чират барлыкка килә икән.

Юл мәшәкатьләре кичеп, очерк геройлары артыннан йөреп, шуның өстенә әле, очрашу хөрмәтенә бераз кабып та куйгач, Алмазны йокы басты.

«Фабрикага—төнге дежурлыкка барасым бар»,—дигән булып, хатынын ияртеп чыгып киткән Азатны сизмәде дә кунак, җыелмалы креслода изрәп калды. «Төнге дежур» дигән сүзләрнең мәгънәсен аңлар өчен уникe квадрат метрлы бүлмәдә гаилән белән яшәп, кунак кабул итеп карарга кирәк.

Халык әйтмешли, җыласаң да, җырласаң да үтә торган гомер Алмаз өчен генә янача була алмады—елларны ашыктырып үтә торды. Эш, гаилә, командировкалар, семинарлар, очрашулар... Шундый очрашуларның берсе аеруча хәтерендә уелып калган.

Журналистлар семинарына яшь хәбәрчеләр алдында чыгыш ясарга Алмазны да чакырганнар иде. Мөнбәр артына үткәч залга күз төшерсә, үз күзләренә үзе ышанмады, алдагы рәтләрнең берсендә Азат утырмасынмы!.. Менә сиңа яшь журналист! Хәер, ник гаҗәпләнергә? Семинарларга тегe яки бу белгечне яшенә карап түгел, хезмәт стажыннан чыгып чакырганнары билгеле инде. Димәк, Азат фатирга хуҗа булып калу өчен таләп ителгән уникe елны фабрикада эшләп, ниһаять, яшьтән үк омтылган эшенә—журналистикага күчкән булып чыга.

Алар лекциядән соң күрештеләр. Әмма күрешүләре салкын, бик салкын килеп чыкты. Хәтта хәл-әхвәл дә сорашып тормадылар. Азатның үз-үзен тотышы, сөйләшкәндә гел читкә каравы, күзгә-күз текәлгәндә исә үч алырга җыенган кешедәй нәфрәт сирпүе салкынайтты бугай ул күрешүне. Ике ел элек Азат фатирын алыштырып, Яшел Үзән шәһәренә күчкән икән. Әлеге соңгы очрашуда шунысы мәгълүм булды. Аның фатир хакына әрәм үткән уникe ел гомере өчен Алмаз үзен гаепле санады...

... Алмазлар Самосырово зиратына билгеләнгән вакыттан иртәрәк килделәр. Май кояшы шактый күтәрелергә өлгергән. Талгын җилдә сизелер-сизелмәс кенә чайкалган агачлардан кала, бу тирәдә бүтән хәрәкәт чалымнары сизелми. Яңа зират турында ишеткәне булса да, аны килеп күргәне юк иде Алмазның. Казанның башка зиратларыннан нык аерылып тора икән бу. Барыннан да элек зурлыгы, иркенлеге белән.

Зур, бик зур икән бу интернациональ зират. Күрәсең, җирле хакимият халык сүзенә колак сала башлаган. Югыйсә, иске зиратларда мәет өстенә мәет күмелә, кабер казыганда кеше сөякләре чыгу кемгә генә мәгълүм түгел соң...

Сул якта татарлар, уңда урыслар күмелә икән. Хәер, кайсы милләтнең кайда күмелгәнен төшерелгән ташлар һәм тәре баганалары әллә кайдан күрсәтеп тора.

Әнә—яңа казылган кабер. Чү! Нишләп бу кадәр озын, буйдан-буйга сузылган ул? Игътибар беләнрәк карагач, Алмаз зиратның читендә, урманлыкка терәлеп диярлек торган урында, экскаваторны шәйләп алды. Соңгы елларда, каберне экскаватор белән казыйлар дип ишеткәч ышанмаган иде. Менә үз күзләре белән күрде инде. Бер-ике генә түгел, дистәләгән мәет өчен траншея-кабер (!)

Мәрхүмнең гәүдәсен автобустан алып кабер янына китерү, кирәк-яракларны бушату күп вакытны алмады. Килеш-килбәте, төсе-бите, үз-

үзен тотышы белән муллага охшаган карт килеп баскач, Алмазның күңеле булды, димәк тол хатын Азат мәрхүмне шәригать кушканча, олылап күмәргә тели...

Яшьрәкләрдән икәү ләхет сайгагын әзерләргә кереште. Ләкин бу эш шома гына башланмады. Чөнки берәүләр сайгакларны буйга тезәргә тәкъдим итте, икенчеләр аркылы тезелә дип фараз кылдылар. Өзеп, тәгаен генә берәү дә әйтә алмады. Хәтта, теге муллага охшаган карт та дәшмәде. Ул арада кемдер сайгакларның берсен кискәләргә өлгергән иде инде.

Беренче карашка мәшәкатьсез булып күренгән бу эш шактый озакка сузылды. Нарат сайгакларны кискәләргә алынган ир, әллә көче җитмәде, әллә пычкысы үтмәде—бик акрын кисте. «Авыл җирендә бу эшне кабер казучылар алдан ук башкарып куя шул»,—дип, Алмаз икенче пычкы белән әлеге иргә булышырга тотынды. Хикмәт чыннан да пычкыда икән. Тешләре ашалып беткән, шуның өстенә, тәмам үтмәсләнгән. Берничә кеше тотынгач, бу эш тә тәмамланды. Инде мәрхүмнең гәүдәсен кабергә индерергә вакыт җитте. Алдан өч кеше кабергә төшеп, йөзләре белән кыйблага карап басты. Мәетне сөлгеләр белән сак кына аска төшерделәр.

Шулчак ләхеткә индерүчеләрнең: «Кирәк бирегез әле! Ләхет бик кечкенә алынган бит»,—дигән сүзләрен ишетеп, бәхилләшергә килүчеләр өнсез калды. Әйе, ләхетенә сыймый иде Азатның гәүдәсе. Китап әйтә, кеше бакый дөньядагы төп йортына күчү белән, күмүчеләр кабер яныннан кырык адым ара киткәч мәет торып утырыр ди. Торып утыру түгел, баш калкытырга да чама юк монда.

Азатның гәүдәсен өскә күтәрми генә ләхетне зурайтыбрак алуга керештеләр. Сайгак кискәндәге кебек, бу да шактыйга сузылды. Чөнки ләхете тар булган кебек, кабер үзе дә кеше сыяр-сыймас, шуның өстенә траншеяда Азатка кадәр җирләнгән кеше каберенең туфрагы да ишелергә генә тора иде.

Шуннан соң мәрхүм рухына багышланган соңгы йола—Коръән Шәрифтән сүрә укып, дога кылынды. Сүрәне шул ук мулла кыяфәтендәге кеше укыды. Сүз ни хакында баргандыр—аны беркем дә, хәтта заманында дәрелфөнүндә гарәп телен өйрәнеп маташкан Алмаз да аңламады. Коръән гарәпләргә Аллаһы тарафыннан аларның туган телләрендә индерелгән. Үзенең телен дә оныта башлаган татарга кая инде ул гарәпчә аңлау, кая инде ул аять кәлимәләренә төшенү! Алай да дога кылу, дөресрәге, ике кул белән битләрне сыпыру күмәк рәвештә башкарылды.

Сәдака өләшенгәч, «Әсгатов Азат (1945—2000) дип язылган тактаны кабер өстенә урнаштырасы гына калды. Чүкеч белән кадак дигән нәрсәләрне онытканнар булып чыкты. Шуңа күрә бу әйберләрне Алмаз үзе юлларга тотынды. Кылка сырма киюе белән башкалардан аерылыбрак торган бер ир кирәкләрне җыеп алган иде. Азат шуңарга дәште. Әмма бу адәмнән кадак, чүкеч сүзләре чыкканчы: «Что-что, говори по-русски», җавабы алданрак яңгырады.

Ул әйберләр чыннан да әлеге кешедә бар иде. Алмаз аның кабер казучы икәнен аңлады. Аңлады, әмма еллар буена газетада эшләп чарланган—теге яки бу әйбер хакында ахыргача ачыкларга өйрәнгән гадәтенә хилафлык итмичә:

—Значит, могилу вы копали?—дип сорап куйды.

—Да, мы. А что?

—Нишу не так сделали, знаете нишу—куда кладут покойника?

—Знаю, знаю. Мы же с Ахмедом копали. Не я дык, он знает.

Алмаз башка нәрсәләрне сорашмады. Кабер казучыдан аңкыган аракы һәм сарымсак исе болай да күп нәрсәне аңлата иде.



**Сәвия Михайлова,**
Казан университеты профессоры,
Халыкара Төрки академиясе академигы

# XIX ГАСЫРДА КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНДА ШӘРЫК ТЕЛЛӘРЕН ӨЙРӘНҮ

2004 ЕЛДА Казан дәүләт университеты ачылуга 200 ел тулачак. Шул уңай белән аның эшчәнлеге турында хәзердән үк төрле тикшеренүләр алып бару, әле моңа кадәр ачылып бетмәгән мәсьәләләрне яктырту сорала.

Безнең үзебезне исә шәрык илләре халыкларының тарихын, мәдәниятен, әдәбиятын һәм телләрен өйрәнүнең, ягъни ориенталистика фәненең торышы кызыксындыра.

XIX гасырның беренче дистә елларында Россиядә ориенталистика фәненең түбәндәге үзәкләре барлыкка килә: Мәскәүдә университет һәм Лазарев институты; Казанда университет, Духовная академия һәм гимназия; Петербургта университет, Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты һәм Азия музее; Одессада Ришелье лицее каршындагы Шәрык институты һәм Харьков университеты. Шәрык илләрен өйрәнүне нигездә университетлар өйдәп бара.

Россиядәге ориенталистика фәненең язмышы XIX гасырда, бигрәк тә, аның беренче яртысында Казан белән нык бәйләнгән. Казан шәрык илләрен өйрәнүдә дөньядагы төп үзәкләрнең берсе булып санала. Шәрыкны өйрәнү-тикшерүне киң җәелдереп җибәрү өчен Казанның барлык алшартлары да була, моңа аның Көнбатыш белән Көнчыгыш илләре арасындагы сәүдә эшләрендә товар йөртү-алмашу үзәге булуы, беренче чиратта, татар сәүдәгәрләренең Иран, Төркия, Урта Азия, Монголия һәм Кытай белән тыгыз бәйләнешлары, иң зур губерналарның берсенең административ-сәяси үзәге булуы; губерна халкының күпмилләтле этник составы; ул чордагы Россиянең иң сыйфатлы мануфактурасын җитештереп торуы аркасында яхшы социаль-икътисади хәле ярдәм итә. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 1804 елдан башлап университетлы Казан үз эченә ундүрт губернаны туплаган гаять зур уку-укыту округының да үзәгенә әверелә, аңа Кавказ белән Себернең күпмилләтле төбәкләре дә керә. Ә 1800 елдан шәркый Россиядә берденбер азиат

типографиясе дә эшли башлый, анда гарәп, төрек, татар, фарсы, монгол, калмык, тибет, санскрит һәм башка телләрдәге әдәбият басыла. Менә шулар барысы бергә Казанда ориенталистика фәненең эре тармаклары барлыкка килү өчен шартлар тудыра. Алар әүвәл Казан университетында мөстәкыйль шәркый кафедралар кысасында оешып, аннары философия факультетының шәрык бүлегенә әверелә.

Казан университетында шәрык илләрен өйрәнүнең шактый зур тарихы бар, ул Казан гимназиясе һәм анда татар классы булу белән бәйләнгән. Казанда беренче гимназия 1758 елда ук, «Мәскәү университеты белән Петербургтагы кадет корпусыннан кала, бөтен Россиядә дөньяви уку йортында белем алу мөмкинлеге юк вакытта оештырыла» *(Владимиров В. В. Историческая записка о Первой Казанской гимназии. XVIII столетие.–Казань, 1867.–Стр.3).* Мәскәү университеты җитәкләгән Беренче Казан гимназиясе төбәкнең рус телле һәм төрки телле төп халыклары өчен күренекле мәдәни үзәк булып тора. 1769 елда гимназиядә, Россиядә беренче буларак, гарәп һәм төрек телләре нигезләре укытыла торган татар классы ачыла. Ул класс алга таба университетта шәрык телләрен системалы өйрәнү һәм белгечләр—шәрык телләреннән тәрҗемәчеләр, фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлек буенча кадрлар әзерләү өчен җирлек була. Шәрык белгече академик Н. И. Веселовский (1848—1918) гимназиядә, аннары университетта шәрык телләре укыту «чик буе һәм чит илләр белән аралашу, башка милләтләр яши торган төбәкләрдәге администрация өчен кирәк ихтыяҗдан» килеп туганлыгын бик урынлы искәртеп үтә. *(Веселовский Н. И. Сведения об официальном преподавании восточных языков.–СПб., 1879.–Стр. 5).*

В. В. Владимиров исә «Казан гимназиясе бездәге урта белем бирү тарихының миниатюр чагылышы ул» дип, бик төгәл билгеләп үтә. *(Владимиров В. В. Описание празднования 100-летнего юбилея в I Казанской гимназии.–Казань, 1867.–Стр. 37).*

Екатерина Икенченең («Әби патша»ның) 1769 елгы 12 май указы белән беренче татар теле укытучысы итеп Казан Адмиралтея конторасы тәрҗемәчесе тылмач Сәгыйть Хәсән улы Хәлфин (1732—1785) билгеләнә, гимназиядә ул 1769 елдан алып 1785 елга—вафат булганчыга кадәр укыта. Аның эшен улы Исхак Хәлфин дәвам итә, анысы Екатерина Икенченең «Учреждения для управления губерний Российской империи», «Устав управы благочиния» дигән эш кәгазьләрен—документларын русчадан татар һәм кырым татар телләренә тәрҗемә итүче була. Исхак Хәлфиннең үлеменнән соң, гимназиядә 1800—1829 елларда татар, төрек, гарәп, фарсы телләрен үз чиратында Ибраһим Исхак улы Хәлфин (1778—1829) укыта. Ул исә татарлардан Казан университетының беренче адъюнкты (кече гыйльми дәрәҗә) була.



*Сәгыйть Хәлфинның «Татар теле әлифбасы»ның титул бите.*

Шул рәвешле, Хәлфиннәр династиясе өчен Казан университетында шәрык телләре укыту, буыннан-буынга күчә килеп, алтмыш ел буена дәвам итә. В. В. Владимиров үзенең «Историческая записка о I Казанской гимназии» дигән хезмәтендә Хәлфиннәр турында болай дип яза: «Алар мәктәбеннән дәүләт хезмәтенең төрле баскычларында хөкүмәтнең өметен аклаган бик күп татар телен белүчеләр чыккан». Хәлфиннәр Россиядә татар теле буенча беренче уку-укыту ярдәмлекләре төзүчеләр дә булганнар. Инде 1778 елда ук Мәскәү университеты типографиясендә гарәп хәрефләре белән беренче «Татар теле әлифбасы» басылып чыга, аннары кулдан гына язылган «Татарча сүзлек һәм кыскача татар грамматикасы» дигән ике томлык хезмәт дөнья күрә, ул үз эченә 25000

сүзне алган була. Менә ул хезмәтләрнең тулы исемнәре: «Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов, сочиненная Казанских гимназий учителем и Адмиралтейской конторы переводчиком Сагитом Халфиным»; «Татарский словарь и краткая грамматика в пользу обучающегося при Казанских гимназиях юношества татарскому языку». Ч. ч. I—II.—Казань, 1785. *(Ч. I 44+653 стр. Ч. II—874 стр.)*

Шунысын да әйтеп үтик, Хәлфин сүзлегенә кадәр XVII—XVIII гасырларда кулдан язылган уникс сүзлек булганы да мәгълүм. Ләкин аларның берсенең дә 600 сүздән артканы булмаган. Шулай итеп, Хәлфин сүзлегенә ул элгәрләрдәге барлык сүзләр дә тупланган була.

Танылган шәрык белгече, төрки телләр галиме А. Н. Кононов Хәлфин сүзлегенең Россиядә төрки телләрне тирән белгәнлеккә бер дәлил һәм төрки лексикография өчен кыйммәтле истәлек икәнлеген искәртеп уза.

С. Хәлфин «Әлифбасы» да бик вакытлы дөнья күрә. Басылып чыгуга ук ул, тәрҗемәчеләр өчен ярдәмлек буларак, губерналарның чик буе идарәләренә, Әстерхандагы солдат балалары мәктәбенә, Тышкы эшләр министрлыгына таратыла. 100 нөсхәгә якыны Мәскәү университеты типографиясеннән Казан гимназиясенә уку ярдәмлеге итеп озатыла. Шунысын да онытмаска кирәк, XVIII гасырның икенче яртысында Россиядә һәм Көнбатыш Европада шәрык телләрен өйрәнүчеләр билгеле кыенлыклар кичерә. Немец шәрык белгече И. Фюкның әйтүенчә, XVIII гасырның азагында Австрия шәрык академиясе бары тик «Төрек лексиконы» дигән бер китап кына бастырып чыгара. Парижда исә 1696—1779 еллар аралыгында гарәп телендә бер генә китап та дөнья күрми. Бары тик Парижда 1795 елда гарәп, төрек, фарсы, кырым татар телләре кафедралары булган махсус уку йорты ачылгач кына анда дәреслекләр языла башлый. Аерым алганда, 1810 елда Парижда Сильвестр де Сасиның «Гарәп грамматикасы» беренче мәртәбә басылып чыга.

Әйтеп киткәнебезчә, гимназиядә шәрык телләрен укыту университетта да ориенталистика фәненә җирлек әзерли, чөнки татар теле буенча беренче уку ярдәмлекләре, сүзлекләр, әлифбалар инде төзелгән була, алар күп кенә шәрык телләрен өйрәнүдә беренче баскыч булып санала. Шәрык белгече, рус академигы В. В. Бартольд (1869—1930) татар теле «дипломатик мөнәсәбәтләр теле булып хезмәт итә» дип бик дөрес яза *(Бартольд В. В. История изучения Востока в Европе и России.—Л., 1925,—стр. 182).*



*Ибраһим Хәлфин. Эрот Зарипов рәсеме.*

1804 елгы беренче университет уставы нигезендә Казан, Мәскәү, Харьков университетларында шәрык телләре кафедралары оештырыла. Ул кафедраларга караган телләр арасында гарәп, фарсы, яһүд, сүрия телләре дә санала. Казан университеты исә, шул ук уставка нигезләнеп, татар телен укыту хокукын да ала, аның беренче укытучысы итеп Хәлфиннәр династиясенең иң талантлы вәкиле—татар мәгърифәтчелегенең башында торган И. И. Хәлфин раслана. Ул рус, татар, фарсы, гарәп һәм төрек телләрендә иркен сөйләшә, латин һәм немец телләрен дә өйрәнә. Рус телен яхшы белүе аңа чит ил шәрык белгече—профессорлар алдында өстенлекләр бирә, чөнки тегеләр баштарак бары тик латин телендә генә аңлаша ала. И. Хәлфин үзен татар һәм башка шәрык халыкларының тарихын, мәдәниятен һәм тормыш-көнкүрешен һәрьяклап тирән белүче итеп таныта. 1809 елдан Казан университетына караган Азия типографиясендә аның татарларны үз теле һәм тарихын тирәнтен өйрәнергә, балаларын Казан һәм Әстерхандагы халык училищеләренә, гимназияләренә укырга өндәгән мөрәҗәгатьләре вә белешмәләре басылып чыга тора. И. Хәлфин ул уку йортларында «шәрык телләрен сезнең арадан үсеп чыккан бик мөхтәрәм шәхесләр укыта» дип искәртә.

Ибраһим Хәлфинның бу тырышлыклары нәтиҗәсез калмый. XIX гасырның 20-30 елларында ук татар, кыргыз (элек, Россиядә казакъларны шулай атап

йөрткәннәр), калмык, бурят һ. б. милләтләрдән укучылар һәм студентлар күренә башлый. Алар өчен әле 1809 елда ук И. Хәлфинның «Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения» дигән дәреслеге университет типографиясендә 1200 данә бастырылып таратыла, аннары 1822 елда аның «Жизнь Джингиз-хана и Аксак Тимура с присовокуплением разных отрывков, до истории касающихся, коих все слова обучающихся расположены по алфавиту в пользу воспитанников Казанского императорского университета» дигән татар хрестоматиясе дөнья күрә. Бу хезмәтләрнең һәр икесе уку-укыту ярдәмлекләре итеп тәкъдим ителә. Соңгысы, шундый «катлы-катлы көбесте кебек» исемдә булса да, җәмәгатьчелек, бигрәк тә мөселманнар тарафыннан зур кызыксыну белән кабул ителә, чөнки анда бик борынгы һәм сирәк очрый торган кыйммәтле чыганаклар урнаштырылган була—шуның белән дә бу хезмәт фәнни әһәмиятле санала.

Танылган шәрык белгече М. Х. Френ (1782—1851), Ибраһим Хәлфинның бу хезмәте белән танышкач, андагы борынгы төрки авторларның аерым тарихи өзекләрен сайлап ала, аларны үзенең Болгар дәүләте һәм Биләр шәһәренә багышланган фәнни мәкаләсенә кертеп җибәрә. Ул мәкалә Көнбатыш Европа шәрык белгечләренә киң танылган «Fundgruben des Orients» журналында 1816 елда ук Венада басылып та чыга.

И. Хәлфин М. Френ белән берлектә шул ук журналда Тимер Котлыгның тарихи ярлыгын да шәрехләп бастыра. Билгеле шәрык белгече, тарихчы немец Йозеф Гаммер-Пургшталь (1774—1856), бу тарихи ярлыкны журналга бастырганда, мондый бәяләмә бирә: «Әлеге ярлык уйгур вә иске татар рәсми кәгазьләренең бик сирәге, шунлыктан чын мәгънәсендә әдәби вә сәяси кыйммәтле җәүһәрдер». Гаммер ул ярлыкның кульязмасын Френга «үзенең Казандагы дусты Хәлфин җибәрде» дип әйтергә дә онытмый.



*Ибраһим Хәлфин дәреслекләре.*

Бу ярлык әле хәзерге галимнәр тарафыннан да өйрәнелә. Тарихчы Ш. Ф. Мөхәммәдьяров: «И. Хәлфин Тимер Котлыгның 1397 елгы ярлыгын бастырып чыгарып, Алтын Урда, Кырым һәм Казанның ярлыкларын бүген фәнни өйрәнүгә нигез салган, шуның башлангычы булган»,—дип искәртә. *(«Мухамедьяров Ш. Ф. В кн., Новое о прошлом страны.—М.—«Наука», 1967, стр. 104).*

И. Хәлфиннең татар телендә язылган «Монголлар вә татарлар турында Әбелгази Баһадур хан тарихы» (1825) дигән хезмәте дә зур фәнни кызыксыну тудыра. М. Френ да аңа югары бәя бирә. И. Хәлфингә бер хатында ул: «Бу хезмәт күптән көтеп алынган, Азия турындагы әдәбиятта татарча язылган беренче тарихи әсәрдер, ул Казанның данын күп тапкырлар арттырачак әле»,—дип яза.

Инглиз галиме А. Давидс белән немец галиме Й. Гаммер-Пургшталь да И. Хәлфин хезмәтләрен тарихи чыганак итеп файдаланалар. Британ музеендагы төрки манускриптлар коллекциясен теркәгәндә шәрык белгече Ч. Рей шулай ук аның хезмәтләрен искәртеп уза.

Немец шәрык белгечләреннән XIX гасыр ахырында В. Перч һәм XX гасыр уртасында Б. Шпулер татар һәм шәрык чыганакларының күпчелеге Россиядә сакланганлыгын, шунлыктан Көнбатыш Европа ориенталистлары һәм бигрәк тә монгол яулары чорын өйрәнүчеләр өчен И. Хәлфиннең фәнни хезмәтләре төп нигез булып торганлыгын раслыйлар.

Шул рәвешле, И. Хәлфин хезмәтләре Көнбатыш Европада татар тарихи чыганакларының басыла башлавына юл яра.

И. Хәлфиннең сәләтле шәхес булуы, аның белем дәрәҗәсе һәм фәнни эрудициясе замандашлары-теләктәшләре арасында үзенә ихтирам-хөрмәт тудыра. Ул Россиядә һәм Көнбатыш Европада үз чорының күп кенә галимнәре белән таныш була, алар белән аралашып тора.

Мисалга, И. Хәлфин белән М. Френ арасында озак елларга фәнни-иҗади хезмәттәшлек урнашканлыгын әйтеп үтәргә дә була. Бу хакта В. Владимиров: «... Френның фәнни хезмәтләренең әһәмиятен һич киметмичә, шуны искәртеп үтәргә тиешбез: аның Алтын Урда нумизматикасына караган хезмәтләренең һәм ул бастырып чыгарган борынгы татар тарихи истәлекләренең күп өлеше, бәхәссез, И. Хәлфиннән алынган, чөнки Френ Россиягә килгәнче әле татар теле белән бөтенләй таныш булмаган».—дип яза.

И. Хәлфиннең тормышында-язмышында профессор-табиб Карл Фукс (1778—1846) белән дуслыгы да зур урын тота. Аларны һәр икесенең дә һәм тарих белән, һәм телләр белән тирәнтен кызыксынулары берләштерә. К. Фукс үзен татар, чуваш, мордва халыкларының тормыш-көнкүрешен фәнни дәрәҗәдә өйрәнүче галим итеп таныта. Ул чувашларның тарихын, гореф-гадәтләрен, йолаларын тикшеренү өчен махсус рәвештә чуваш телен өйрәнә. «Татарлар,— дип яза ул,—минем игътибарымны бик тиз җәлеп иттеләр. Мин аларның дини йолаларын, бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен һәм гаилә тормышларын бик тырышып өйрәндем, шуларны кәгазьгә төшерә бардым». *(Фукс К. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношении.—Казань, 1844, стр. 38).*



*И. Хәлфиннең «Монголлар вә татарлар турында Әбелгази Баһадур хан тарихы» исемле хезмәте.*

Шунысын да онытмаска кирәк, И. Хәлфиннең алдынгы карашлары хакимият тарафыннан һәрвакытта да хуплап каршы алынып тормаган. Шулай булуга да карамастан, ул үзенең фикерләрен «Любопытное соображение И. И. Хальфина» (1819) исемле хезмәтендә теркәп калдырган. Хезмәт русча язылганлыгы исеменнән үк аңлашыла булса кирәк, автор моны рус хакимияте вәкилләре дә укысын өчен махсус шулай эшләгәндер дип уйларга җирлек бар. Ул болай дип яза (татарча тәрҗемәдә бирәбез): «...студентлар, күпмедер вакыт татар бистәләрендәге халык арасында яшәп, анда сөйләм телен камилләштерергә, татарларның гореф-гадәтләрен, ырым-йолаларын өйрәнергә һәм шул рәвешле мөселманнарга аң-белем бирерлек сәләткә ия булырга тиешләр».

Казан укыту округының опекуны-кайгыртучысы итеп билгеләнгән М. Г. Магницкий (1778—1855) фикерләренә капма-каршы мөнәсәбәттә торган И. Хәлфинны университетның ул чордагы ректоры Г. Солнцев һәм университет советы әгъзалары яклап чыга, аның бу фикерен куәтләп, шуны гамәлгә ашыруны сорый. Әмма М. Магницкий бу үтенечләргә бик каты каршы чыга. Ул болай дип яза: «Бу тәкъдимнең бөтенләй мәгънәсе юк. Мин хәтта укымышлы шәхесләр җыелышында Император университеты студентларын татарларга укыту өчен бирү һәм шуны кемнәрнеңдер бердәм яклауларын һич аңлый алмыйм, бары тик гаҗәпләнәм генә. Кызганыч, бу тәкъдимгә каршы бер генә тавыш та бирелмәгән... Бу тәкъдимне кире кагарга кирәк».

И. Хәлфиннең күпьеллык мөгаллимлек һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеге эзсез югалып калмый. Дистә еллар дәвамында студентлар аның хезмәтләре буенча укый, танылган шәрык белгечләре аның фәнни-гыйльми тикшеренүләренә таянып эш итә.

Патша фәрманы белән Казан университетына шәрык телләре профессоры итеп философия фәннәре докторы һәм иректе фәннәр магистры Мартин Христиан Френ (1782—1851) билгеләнә. Ул Казанга Ростоктан 1807 елның август аенда килеп төшә. Бик зур кыенлыклар булуга карамастан,—уку әсбаплары юк, Френ үзе ни урыс, ни татар телен белми!—студентларга лекцияләрен бары тик латин һәм немец телләрендә генә укыган Френ, әле җитмәсә, гарәп һәм фарсы телләрен дә укытып маташа! Шуның өстенә, теләге булганнарга яһүд телен, Иран-фарсы һәм гарәп илләре тарихын һәм әдәбиятын да укыта. Бу нинди гыйлем-белем бирү булганлыгын шуннан үзегез аңлагыз инде!

Шулай да университетта ун ел укыту дәверендә М. Френ, немецларга хас эшчәнлек-үҗәтлек белән, нумизматика, гарәп филологиясе, археологиясе һәм шәрык палеографиясе өлкәсендә күп эшләр майтарып калдыра. Билгеле булганча, ул Россиядә беренче фәнни-гыйльми гарәп белгече буларак таныла. Аның хакында П. С. Савельев болай дип яза: «Френ Россия белән бөтенләй туганлашып беткән, үз фәненнән башка бернәрсә дә эзләмәгән, хәтта бик кызыксындыргыч башка вазифа һәм урыннардан да баш тарткан». (Савельев П. С. О жизни и ученых трудах Френа.—СПб., 1855. стр. 54). Нәкъ менә Казан университетында «ул Көнбатыштагы Германиядән килгән гадәти семитологтан Европада бары тик атаклы Сильвестер де Сасига тиңләрлек беренче дәрәҗәдәге гарәп телләре белгече булган»,—дип яза галим И. Крачковский аның турында. *(Крачковский И. Ю. Избранные сочинения. М.–Л., Т. V, 1958. стр. 5).* М. Френ Казан университетының хезмәтләрен бик югары бәяли. Казан укыту округы опекуны С. Руммовскийга бер хатында: «Шәрыкны төрле яклап өйрәнү юнәлешендә Казаннан да яхшырак урын юктыр»,—дип яза. Ул шәрык телләрен белмичә, үзләштермичә торып, даими эшләп булмаганлыгын аңлаган икән. Шәрык телләре кафедрасында М. Френ лекцияләрен беренче булып тыңлаучылар Семен Кручинин, Федор Риттау, Иван Попов, Алексей Пятов, Сергий Гроздовский һәм Януарий Ярцевлар була. Алар арасында М. Френның фәнни эзләнүләрен дәвам иттерүче Я. Ярцев (1792—1861) Россиядә иранистика фәненә зур өлеш кертүче булып таныла.

Казан университетында ун ел эшләгәннән соң, М. Френ Петербургка китә һәм 1817 елның сентябрендә Фәннәр Академиясенең борынгы шәрык бүлегенә академик итеп раслана. Азия бүлеге музее ачылгач, аны карап-саклап торучы итеп билгелиләр. Ул анда шәрык кульъязмаларын өйрәнү белән шөгыльләнә, аларны тәрҗемә итә һәм бастырып чыгара. Казаннан киткәч тә М. Френ университет белән элемтәләрен өзми, Казан шәрык белгечләренә кулыннан килгән кадәр ярдәм итә, яңа шәрык кафедралары ачылуга да булыша. Казан университеты тарихчысы Н. П. Загоскин: «... аның хезмәтләре барлык фән дөньясының казанышы булып тора»,—дип яза *(Загоскин Н. П. История Императорского Казанского университета.–Казань, 1902, том I, стр. 224).*

М. Френның Петербургка күчеп китүе һәм Казан укыту округы попечителе М. Магницкийның консерватив эшчәнлеге университетта шәрык фәненең үсешен күпмедер вакытка тоткарлый. Ул, 1819 елда инспекция-тикшерү үткәргәч, университетны фетнә оясы дип атый һәм аны «җимереп ташларга кирәк» дип таләп итә. Патша Александр Беренче аның рапортына: «Нигә җимерергә, төзәтергә мөмкин»,—дигән тамга сала. Шуннан соң казарма режимына әверелдерелгән Казан университеты күбрәк «монахлар орденына» охшап кала.

Магницкийның үҗәтләнеп тыкшынуы аркасында хөкүмәт, нинди дә булса яшерен сәяси оешмалар барлыкка килүне кисәтү максатыннан, профессорлар һәм укытучылардан кул куйдырып, «алар бернинди дә масон ложаларына һәм башка яшерен җәмгыятьләргә кермиләр» дигән ышаныч язуы ала. Магницкий чорында, ышанычсыз яки укытырга яраклы түгел дип табылып, университеттан унбер профессор куыла. Укыту процессы да тамырдан үзгәртелә. Этнография фәне, «бары тик инородецларны тикшерү белән генә шөгыльләнә» дигән тамга сугылып, шулай ук ышанычсыз фән дип игълан ителә. Махсус чыгарылган инструкция-кулланма шәрык телләре укытучыларны шәрык халыкларының күп гасырлык тарихларына һәм мәдәниятләренә кагылмаска мәҗбүр итә. Күпсанлы күрсәтмәләр бары тик бер максатка гына яраклаштырыла, «азатлык-ирек рухы ачыктан-ачык та, яшерен рәвештә дә православие чиркәве тәгълиматын йомшартмаска тиеш» диелә *(Мельгунов.–С. Из истории студенческих обществ в русских университетах. 1907. стр. 23-24).*

Ориенталистика фәненең яңа үсеш чоры 1827 елда университет ректоры итеп фәнни эшләрне алдан күреп оештыру сәләтенә ия Н. И. Лобачевский (1792—1856) сайлангач кына башлана. Фән дөньясында ул үзе күбрәк нәэвклид геометриясенә нигез салучы буларак билгеле, әмма аның тулаем гуманитар фәннәрне, шул исәптән шәрыкны өйрәнүне үстерүгә керткән өлеше дә чиксез зур. Атаклы шәрык бүлегенең (1835—1855) аякка басуы һәм үсеше нәкъ менә аның эшчәнлегеннән аерылгысыз.

Аның катнашында 1828 елда шәрык телләре кафедрасы икегә бүленә:

татар-төрек телләре кафедрасы (анысын И. Хәлфин җитәкләргә тиеш була, әмма ул вакытсыз үлеп китә) һәм гарәп-фарсы телләре кафедрасы, аны Ф. И. Эрдман (1793—1863) җитәкли, аны бу вазифага М. Френ тәкъдим итә. Френ мәктәбен үткән Эрдман гарәп һәм фарсы телләрен укытудан тыш, шәрык илләренең борынгы тарихы һәм нумизматикасы буенча да лекцияләр укый, университетте шәрык телләрен укытуны киңәйтү турында чыгышлар ясый. Иранның иң борынгы чорыннан XIX гасырга кадәр булган тарихы, гарәп әдәбияты тарихы фәннәрен ул, нигездә, латин һәм немец телләрендә укыта. Эрдман төрле фәнни җәмгыятьләрнең—Париждагы Азия җәмгыяте, Копенгагендагы борынгы төньяк җәмгыяте, Мәскәүнең борынгы рус тарихы җәмгыяте, Курляндиянең тел-әдәбият һәм сәнгать сөючеләре җәмгыяте әгъзасы була.

Шул елда ук татар-төрек телләре кафедрасына Мирза Касыйм улы (Александр) Казем-Бәк (1802—1870) эшкә килә. 1826 елны христиан динен кабул иткәч, аңа Александр исемен кушалар. Россиядәге ориенталистика фәненең күтәрелеш чоры аның исеме белән бәйләнгән. Казем-Бәк бик тирән мөселман һәм Европа белеме ала, Европаның галимнәре белән таныш була.

Укыту округының яңа попечителе Н. М. Мусин-Пушкин үзенең 1831 елдагы тәкъдимнәренең берсендә аның турында менә нәрсәләр яза: «Казан университетына Казем-Бәкнең килүе бәхет булды, гарәп, фарсы, төрек, татар телләре белгече, соңгы өчесендә иркен сөйләшә, шул телләрне грамматик һәм синтаксик кагыйдәләргә туры китереп укыта, гарәп һәм фарсы әдәбиятын белеп кенә калмый, ул фәннәр турында Европа язучылары әсәрләре белән, бигрәк тә инглиз әсәрләре белән яхшы таныш, ул телдә сөйләшә һәм яза, рус телен белә, шулай ук иркен сөйләшә һәм укыта».

Казем-Бәк әле 1829 елда ук Бөекбритания короле Азия җәмгыятенең әгъзасы итеп сайлана. Аны күп мәртәбәләр Көнбатыш Европага эшкә чакыралар. Шул ук Мусин-Пушкинның мәгариф министрына шәхси хатларының берсендә ул: «Тәкъдимнәремдә әйтелгән сәбәпләргә өстәмә рәвештә, аңа адъюнкт дәрәҗәсе бирүне соравымны раслаучы тагын бер хәбәр шулдыр—Казем-Бәк әгъза булып торган Лондон Азия җәмгыяте аны Лондонга күчеп килергә чакыра. Бу хәбәр миңа рәсми булмаган чыганаклар аша килеп иреште. Мин Казем-Бәкне Казанда саклап калуны бик тә телим, чөнки ул магометаннарны укыту өчен аеруча файдалы булачак».

Казем-Бәк бик тә үзенчәлекле шәхес була. Ул ачык зиһенле, искиткеч ораторлык сәләтенә ия, укытуда һәрвакыт камил методика куллана. Аның замандашларыннан берсе: «Казем-Бәк дәресләренә хәтта башка кафедра студентлары да йөри иде»,—дип искә ала (Казанские вести. 1891, N 66). Ул хезмәт сөючәнлеге, тегәллеге, зыялылыгы һәм тирән белеме белән аерылып тора. Төрек-татар грамматикасын ул үзенең Демидов премиясенә лаек булган хезмәтеннән укый, бу хезмәт төрек һәм татар телләре укытыла торган барлык училищелар, гимназияләрдә зур абруй казана.

1832 елда ректор Н. И. Лобачевскийның зур ярдәме белән А. К. Казем-Бәк редакциясендә һәм аңлатмалары кертелеп, «Кырым тарихы» (кульязма татар телендә) басылып чыга. Аны әле 1826 елда ук И. Хәлфин сатып алган була. «Әссаб-ас Сәйяр яки Җиде планета» дигән ул әсәрне тарихчы Мөхәммәд Сәед Риза иҗат иткән. Кырым ханнарыннан атаклы җидесе хөрмәтенә Сәед Риза әлеге тарихны шулай атаган. Бөек математик Н. И. Лобачевский Мөхәммәд Сәед Риза иҗатын өйрәнү өчен оештырылган Советның башында шәхсән үзе торган. Бу хезмәтне эшкерткәндә зур кыенлыкларга очраргa туры килә. Казем-Бәк әсәрнең авторы турында мәгълүматлар туплар өчен Әстерхан, Таврия, Уфа, Казан мөфтиләре белән хатлар алыша. Ул «Дербент-намә» кульязмасын эшкерткәндә дә, мөселман кануннары тупланган «Мөхтәсерель викгает», ягъни «Кыскартылган викгает» дигән капиталь хезмәтне бастырып чыгарганда да үз вафизасына бик җитди карый, дистәләрчә вариантларын чагыштыра һәм манускриптлардагы йөзләрчә хаталарны төзәтә, чыганакларның үзләрен генә түгел, ә соңгы тикшеренүчеләрнең дә хезмәтләрең тәнкыйди күзлектән карап өйрәнә-тикшерә.

Казем-Бәк рус тарихы өчен шәрык телләрен өйрәнүнең мөһимлеген искәртә килә. Ул: «... руслар өчен шәрык телләрен өйрәнүнең әһәмиятле икәнлеген Европа белгечләре дә әйтә»,—дип яза *(Казем-Бәк А. К. О появлении и успехах восточной словесности в Европе и упадке ее в Азии.*

*Журнал Министрства народного просвещения. 1836, № 8, стр. 248).* Күрәсең, ул патша хөкүмәтенең шәрык гыйлеменә булган чын мөнәсәбәтен күз алдында тоткандыр, «русларның шәрык телләре белән кызыксынуы бик кечкенә» дип борчыла ул шул ук язмасында.

Казем-Бәкнең тикшеренү лабораториясендә сакланып калган чыганакларга карап бәяләгәндә шуны билгеләп үтәргә кирәк, борынгы заманнарда фарсы телле ыру-кабиләләр яшәгән төбәкләрдәге тарихи-мәдәни тормышны өйрәнүнең төп чыганаклары мондый булган: Иран чыганаклары (Авеста, чей язулары, мифология, эпос, «Шаһ-намә» һәм Иран тарихчыларының әсәрләре), яһүдиләрнең һәм христианнарның изге китабы—Тәүрат, грек-юнан чыганаклары, Византия тарихчыларының һәм Европа галимнәренең мәгълүматлары. Казем-Бәк, зенд теле санскритның бер сөйләше—ул, Зороастра турындагы мәгълүматлар шикелле үк, Иранга Һиндстаннан кертелгән, дигән, XIX гасыр башында кабул ителгән фикерләр белән килешмәгән. Бу уңайдан ул болай яза: «Фән алдында һәм санскритның борынгылыгы каршында тез чүгеп, бу өлкәдә Гумбольт, Гримм һәм башка белгечләрнең дә фикерләренә һич тә шик төшерергә кыймыйча, шулай да без үзебез бер хакыйкатьне әйтергә җөрьәт итәбез: санскритлык, халыклар һәм патшалыклар аша сикереп, берничек тә Европа уртасында пәйда була алмаган» *(Казем-Бек А. К. Персидская литература.—НА РТ, ф. 1186 (фонд Казем-Бека), оп. I, ед. хр, 14, л.л. 1-2).*

В. Бартольд исә Казем-Бәкнең тарих укытуны телләр укытуга караганда җитдирәк эш итеп тануын искәртә. Казем-Бәк: «Шәрык тарихы рус галимнәре тарафыннан бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән»,—ди.

Шәрык бүлегендә тәрбияләнгән төрек-татар кафедрасы профессоры И. Н. Березин (1818—1896) Казем-Бәкнең шәкерте булган. Ул, Н. И. Лобачевскийның ярдәменә таянып, шәрык тарихи кульъязмаларын җыю һәм бастырып чыгару өлкәсендә гаять зур эш башкара. Укыта башлаганчы, Кавказ арты, Иран һәм Сүрия якларында өч еллык сәяхәттә йөреп кайта.

1845 елда Петербургта булып, И. Березин башкала китапханәләрендә саклана торган төрек-татар кульъязмаларының тәфсилле тасвирламасын эшли. (Березин И. Н. Описание турецко-татарских рукописей, хранящихся в Петербургских библиотеках.—ЖМНП, 1846—1849. Отдельное издание.—СПб, 1850). Казанда И. Березин «Библиотека восточных историков» *(«Шәрык тарихчылары китапханәсе»)* дигән басма чыгара башлый, бу эш шәрык тарихчылары һәм елъязмачыларының монголлар һәм аларның Көнбатышка яу чабулары турындагы хезмәтләрен бергә туплап-тасвирлап Россиядә бастырып чыгаруның беренче омтылышы була. Асылда мөстәкыйль фәнни әһәмияткә ия булган әлеге хезмәтне төзү, филологик һәм тарихи искәрмәләр язу эшенә Казанның иң яхшы ориенталистлары җәлеп ителә, алар арасында беренче бурят галиме Доржи Банзаров та була. Березин Европада беренчеләрдән «Монгол тарихы»ның тулы тәрҗемәсен бастыра (Сборник летописей. История монголов, сочинение Рашид-Эддина. Введение о турецких и монгольских племенах. Труды Воосточного отделения Русского археологического общества (дале ВОРАО) ч. V, 1858 (перевод), 1860 (персидский текст); Рашид-Эддин. История Чингиз-хана от вошествия на престол до кончины. Труды ВОРАО, ч. XV, 1888). Бу хезмәтләр XX гасыр уртасында академик басмалар дөнья күргәнчегә кадәр әһәмиятләрен югалтмаганнар.

И. Березин «Дополнение к тюркской грамматике», «Внутреннее устройства Золотой Орды по ханским ярлыкам», Очерки внутреннего устройства Улуса Джучиева» һ. б. хезмәтләрен дә чыгара.

Университетта өченче булып 1833 елда монгол кафедрасы ачыла, ул бик тиз төп кафедрага әйләнә, Европада беренче һәм бердәнбер монгол теле һәм әдәбияты фәннәре кафедрасы була. Кафедраны оештырганда белгечләр һәм уку әсбаплары белән бәйле кыенлыклар да килеп туа. Россиядә монгол телен сөйләшерлек дәрәҗәдә белүчеләр булса да, алар югары белемле һәм тиешле фәнни-методик әзерлекле булмыйлар. Бераз соңрак академик Я. И. Шмидт белән Н. Я. Бичуринның язган хезмәтләре генә бу җәһәттән тиешле таләпләргә җавап бирә ала. Әлеге кафедраның күренекле җитәкчесе вазифасын, шәрык бүлеген 1854—1855 елларда Санкт-Петербург университетына күчергәнче, О. М. Ковалевский (1800—1878) башкара. Ул хаклы рәвештә Россиядә монгол тарихы һәм мәдәниятен өйрәнүгә нигез салучы булып санала. Монгол кафедрасын ачу кирәклеген дәлилләп, Н. И. Лобачевский Россиянең Монголия

белән күршелегән һәм монгол телен өйрәнүнең бу ике ил арасындагы мөнәсәбәтләрне яхшыртачагын күрсәтә.

Патша хөкүмәте монгол теле укытучысын чит илдән чакыртып китертергә тәкъдим итә, ләкин Н. Лобачевский алдан ук Монголия чик буйларына Казан университетының иң сәләтле студентларын җанлы монгол телен өйрәнергә һәм монгол әдәбиятын туплап кайтырга җибәрә, соңыннан шулар монгол кафедрасының төп көчләренә әверелә. О. М. Ковалевскийның кандидатурасы да ректорның үзе тарафыннан тәкъдим ителә. Ковалевскийга юлдаш итеп университет студенты А. В. Попов (1808—1880) җибәрелә. Ә профессорлар В. Я. Булыгин белән Ф. И. Эрдман сәяхәткә китүчеләр өчен күрсәтмә-кулланма төзеп бирәләр.

Шул рәвешле, университет студентлары, монгол телен өйрәнергә керешәләр. Аларга бу эшләрендә Казан университеты белән күптәннән бәйләнештә булган, монгол телен яхшы белүче А. В. Игумнов булыша. Ковалевский белән Попов аның ярдәмендә үзләренең монголча-русча сүзлекләрен төзи башлый. А. Игумнов сәяхәтчеләргә Пекинда 1817 елда нәшер ителгән монгол законнар җыелмасыннан өзекләр һәм Гэсерхан турындагы риваятьне үзләре белән алырга киңәш итә. Ковалевский белән Попов монгол телле һәм тибет телле кабиләләрнең яраткан халык әсәре Гэсериаданы беренче тиректән өйрәнүчеләр һәм рус теленә тәрҗемә итүчеләр була.

Монгол теле грамматикасы һәм монголча-русча сүзлек төзегәндә авторларга кытай тарихы, мәдәнияте, әдәбияты һәм теле белемендә Россиядә башлап нигез салучы Н. Я. Бичурин (1777—1853) зур ярдәм күрсәтә.

Ковалевский белән Попов монголларның XVII гасырда елъязмачы Саган Сэцэн (Чечэн) төзегән «Эрдэнийн Тобчи» («Кыйммәтле риваят») дигән тарихи әсәренең күчермәсен ала һәм аны рус теленә тәрҗемә итә.

1829 ел башында О. Ковалевскийга Төньяк Монголиягә сәяхәт кылырга җай чыга, ул үзе бу хакта «Казанский вестник»та мәкалә дә язып бастыра *(Ковалевский О. М. Поездка из Иркутска в Ургу. Казанский вестник.—1829.—Ч. 27, кн. II-12, стр. 186-188)*. Ковалевскийның Байкал арты бурятлары һәм бурят хатын-кызлары турындагы хатлары һәм язмалары да кызыклы. Ул бурятларның руслар белән якынаю-аралашу процессында үз хуҗалыкларында, тормыш-көнкүрешендә һәм мәдәниятендә килеп туган үзгәрешләрне күрсәтеп китә, аларның социаль тигезсезлекләре, монгол ярлыларының хокуксыз хәле турында яза, бурят-монгол халыкларын агартуны яклап чыга, «дала балаларының акылына һәм йөрәгенә аң-белем алырга теләү тойгысы үтеп керә башлаган икән» дип искәртә.

Бурят-монголлар арасында биш елга якын яшәп, Ковалевский белән Попов монгол, кытай, маньчжур һәм башка телләрне бик яхшылап өйрәнәләр. Аларның телләр белүен сынап караган Я. И. Шмидт: «Миңа Казан университетын һәм ватаныбызны шундый искиткеч өметләр уятырлык ике яшь кешегә ия булулары белән котларга гына кала»,—дип яза.

1833 елда О. М. Ковалевский Европаның югары уку йортларында беренче мәртәбә К. Бабановский, А. Некрасов, Л. Ибраһимов кебек студентларга монгол телен укыта башлый. Бер үк вакытта монгол теле дәресләре Беренче Казан гимназиясенә дә кертелә, анысын А. В. Попов алып бара.

1833/34 уку елында О. Ковалевский монгол теленең үзе төзегән кыскача грамматикасы һәм Я. Шмидт грамматикасы буенча лекцияләр укый; Кытай, Монголия, Һиндстан һәм Тибеттәге буддизм тарихы турында монгол әсәрләреннән өзекләргә искәрмә-аңлатмалар бирә; монгол әдәби теле белән сөйләм теле арасындагы грамматик аерымлыкларны аңлата. 1838 елда ул үз язмалары буенча монгол тарихын һәм әдәбиятын да укыта башлый. Попов исә монгол һәм татар телләренең чагыштырмача грамматикасын укыта, үзе төзегән хрестоматиядән монгол теленнән рус теленә тәрҗемәләр белән шөгыльләнә. Алар икәү бергә университет, гимназия һәм Духовная академия өчен монгол теле һәм әдәбияты буенча уку-укыту әсбаплары да төзеп бирәләр. Поповның күп хезмәтләре арасында монгол телендәге беренче арифметика дәреслеге дә кызыклы, ул гимназияләргә, бурят училищеларына һәм шәхси йортларга таратыла. Ковалевский исә, дәреслек һәм ярдәмлекләрдән тыш, гимназия белән университет өчен монгол теле программасын да төзи. 1836 елда «Распределение преподавания монгольского и начала тибетских

языков в Первой Казанской гимназии» дигән хезмәтен нәшер итә.

Казандагы монгол белеме галимнәре монгол тарихы, мәдәнияте, әдәбияты һәм теле белемен үстерүнең теоретик-мотодологик нигезе итеп комплекслы өйрәнүне алга сөрә. Ковалевский: «телчеләр, шагыйрьләр, философлар, археологлар, тарихчылар өчен нинди мөмкинлекләр ачыла! Чиксез бай табигатьтә никадәр серләр саклана!»—дип сокланып яза. Халыклар үсешенең тарихи юлларын ачыклау өчен тел белүнең әһәмияте турында А. Попов та яза: «Халык белән якыннанрак танышу өчен аның телен белергә кирәк. Халыкларның килеп чыгышын һәм таралуларын күбесенчә фаразлауларга нигезләп кенә тел белеменнән башка бик гади нәтиҗәләр ясауга урын булмаска тиеш». Бу ике галимнең дәлилләре А. Бобровников, В. Васильев, Д. Банзаров, А. Позднеев, Н. Катанов кебек галимнәр тарафыннан гамәли тормышка ашырыла килә.

1836 елда Троицк-Савск мәктәбе укытучысы, тибет һәм монгол телләрен яхшы белүче Галсан Никитуев шәрык телләрен өйрәнү өчен дүрт бурят малаен Казанга алып килә. Шуларның бары тик Доржи Банзаров дигәне генә, барлык кыенлыкларны, ачлык-ялангачлыкны җиңеп, Казанда башта гимназиядә, аннары университетта укуын дәвам иттерә ала.

1846 елны Казан университетын тәмамлагач, ул Байкал артына кайтырга һәм, хәрби хезмәткә мәҗбүри алыну нигезендә, казак улы буларак, егерме биш ел солдат хезмәте үтәргә тиеш була. Д. Банзаровны казаклыктан йолып алу өчен көрәш башлана. Аңа фән белән шөгыльләнүне рөхсәт итүләрен Н. И. Лобачевский үзе һәм университетның башка профессорлары үтенеп сорый. Дәүләт советы егетне хәрби хезмәттән азат итә, ләкин фәнгә юлын да яба, Банзаровны Көнчыгыш Себер генерал-губернаторының махсус йомышларын үтәүче чиновник итеп билгелиләр. Д. Банзаров турында тарихчы В. Григорьев: «Ул Европа университетларының теләсә кайсысында доктор башлыгын намус белән киеп йөри алыр иде»,—дип яза. Д. Банзаров «Черная вера или шаманство у монголов» дигән кандидатлык диссертациясендә үк үзен җитлеккән галим итеп күрсәтә. Университет галимнәре Россия халыклары арасыннан галим бурят үсеп чыгуы белән Европа алдында горурланып йөриләр. Әмма патша Россиясе аның талантын да, тормышын да һәлак итә. Ул 1855 елда нибары 33 яшендә вафат була. «Отечественные записки» журналы Доржи Банзаров йөзендә «хәзерге фән иң файдалы хезмәткәрен, иң үткен акыллы тикшеренүчесен югалтты» дип язып чыга *(Отечественные записки.—1855.—Сентябрь.—Стр. 83).*

Казан университетында һәм гимназиядә монгол телендә практик дәресләрне унбиш ел буе алып барган Галсан Никитуев үзе дә шундый ачы язмышка дучар була, аның казаклыктан чыгаруны сорап язган үтенече кире кагыла.

Монгол теле белән бергә тибет, кытай, санскрит телләрен яхшы белүче галим казанлы В. П. Васильев (1818—1900) була. Ул Үзәк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия илләрендә ун ел дәвамында сәяхәттә йөри. Тегеяки бу телнең грамматик төзелешен һәм лексикасын тирәнтен үзләштерергә тырыша, монгол телендә сөйләшергә шундый осталыкка ирешә ки, хәтта монголлар үзләре дә аның бернинди акцентсыз һәм чиста-саф сөйләшүенә таң кала.

Шулай итеп, без монгол тарихын, мәдәниятын, әдәбиятын һәм телен өйрәнүнең комплекслы алып барылганлыгын күрәбез. Галимнәрнең тикшеренүләре монгол халыкларының (бурят, калмык һ. б.) теле, этнографиясе, әдәбияты, географиясе, дине һәм тарихына караган була. Бу халыкларны этник төркемнәргә аеру да Казан галимнәренең казанышы, шул халыкларны фәнни нигездә өйрәнү, алар өчен мәктәпләр ачу, уку-укыту әсбаплары һәм программалар төзү эшендә аларның роле гаять зур.

Шәрык бүлегенең алга таба киңәюе кадрларның педагогик һәм фәнни дәрәҗәләренең үсешенә карап алып барыла. 1837 елның май аенда, Россия университетларыннан беренче буларак, Казан университетында кытай кафедрасы да оештырыла, аның җитәкчесе итеп Кытайда рухани миссионерлыкта ун ел яшәп кайткан архимандрит Д. Сивиллов билгеләнә. 1844 елның апрелендә кафедраны кытай һәм маньчжур теле-әдәбияты белгече профессор И. Л. Войцеховский (1793—1850) җитәкли башлый. Ул да шулай ук Кытайда, андагы ярлыларга ярдәм күрсәтеп, ун ел яши, рәхмәтле кытайлылар аңа үзе исән вакытта ук һәйкәл куялар. Войцеховскийдан соң кафедра В. П. Васильев

кулына күчә, ул кытай һәм маньчжур телләреннән лекцияләр укый, аңа бу эшкә А. Сосницкий белән Абу-Кәримов булыша.

Үзенең күзәтүләре һәм тикшеренүләре, Кытай чыганакларын җентекләп өйрәнүе нигезендә В. П. Васильев, Россиядә беренчеләрдән булып, Кытай һәм буддизм турында тарихи-географик хезмәтләрен яза *(Центарльная Азия и главные хребты гор в китайских владениях. ЖМНП, 1852, отд. II, ч. XXIII; Описание Маньчжурии. Записки Императорского Русского географияческого общества, 1857, кн. XII; О реках, впадающих в Амур. Там же; О существовании огнедышащей горы в Маньчжурии. Вестник геогрфического общества, 1855, кн. 5).*

Шәрык бүлеген төзеп бетерү анда әрмән теле һәм санскритология кафедралары оештыру белән тәгәлләнә. Алар икесе дә 1842 елда ачыла, юкса әрмән теле кафедрасын ачу турында карар 1839 елда ук кабул ителсә дә, кафедра өчен профессор эзләү озакка сузыла. Ул кафедрага килергә теләүчеләр арасында Мәскәү университеты һәм Лазарев шәрык телләре институты укытучысы Тигранян, бертуган Арзаковлар, коллежский асессор (патша Россиясендә 8 нче гражданлык дәрәҗәсе) Бероев һәм әрмән әдәбиятына нигез салучы Хачатур Абовян да була. Казан укыту округы попечителе, кемне сайлап алырга белмичә, министрлыкның конкурс оештыруын үтенә. Академик М. Френ исә Дерпт профессорлар институтын тәмамлап, Лобачевскийның ризалыгы белән, әзерлек үтәр өчен бер елга Петербургта калдырылган С. И. Назарьянцны (1812—1879) тәкъдим итә. 1846 елның 19 маенда университетта С. Назарьянц магистр дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклый. Әрмән теле һәм әдәбиятына Россиядә багышланган беренче диссертация була ул. 1849 елның 6 мартында яшь магистр «Рудаки, Дакики һәм Фирдәүси» дигән темага докторлык диссертациясен дә яклап өлгерә. (Диссертациянең кульязмасы Петербургта тарих архивында саклана). Һәр ике диссертация ориенталистлар тарафыннан югары бәяләнә. Соңгысында профессор шәрык дөньясының да борынгы классик дөнья дип йөртелгән чордан фән өчен һич кайтышсыз, игътибарга лаек икәнлеген раслый.

С. И. Назарьянц әрмән теле кафедрасының максат һәм бурычларын «өлегә кадәр монастрь хөҗрәләрендә генә сакланып ята торган әрмән әдәбияты җәүһәрләрен фәнни дөньяга таныту, әрмән истәлекләре аша шәрык тарихының караңгы якларын яктыртуда» күрә.

Санскрит кафедрасын Һиндстан тарихын һәм әдәбиятын тикшерүче галим П. Я. Петров җитәкли. Ул Һинд эпосы җәүһәре булган «Махабхарата»ны рус теленә тәрҗемә итүче буларак та билгеле. Шуның өстенә ул фидакарь нәшир дә була: Казанга Берлиннан санскрит хәрефләре (шрифты) кайтарта. «Санскрит антологиясе»ндә үзе тәрҗемә иткән «Рамаяна» белән «Махабхарата»дан, элек Россиядә һәм Европада билгеле булмаган тагын тугыз һинд шагыйренең иҗатыннан үрнәкләр урнаштыра. *(Петров П. Гьята Карпараль или разбитый сосуд.—Казань, 1844; его же «Санскритская антология».—Казань, 1846, отд. I).*

Шәрык бүлегенең логик-фәнни камиллеккә ирешүе 1843 елда шәрык каллиграфиясе (матур язуы) курсын кертү белән тәгәлләнә. Аны укытырга, махсус белеме булмаса да, тумыштан талантлы татар мәгърифәтчесе, галим М. Г. Мәхмүдов (1824—1891) чакырыла.

Болардан тыш, Н. И. Лобачевский һәм университет Советы тибет һәм яһүди теле кафедралары да оештырырга ниятлиләр. Шул ук елны университет каршысында шәрык телләре институты ачу проекты да төзелә. Әмма бу матур башлангычлар тормышка ашырылмый кала.

Болар барысы да Н. И. Лобачевскийның егерме еллык ректорлык чорында шәрык тарихы, мәдәнияте, әдәбияты һәм теленең фәнни мәктәбен үстерүгә никадәр көч куйганын, аңа зур игътибар иткәнлеген раслый.

Берлин, Вена, Лондон, Париж кебек гыйльми шәркый дөнья үзәкләре Казан галимнәренең уңышларын сөенеп тә, көнләшеп тә күзәтәләр.

Казан университеты өкренләп үз галимнәре хисабына ныгый-көчәя. Бу хакта Н. И. Лобачевскийның Казан укыту округы попечителе М. Н. Мусин-Пушкинга хисап төсендә язып биргән язмасында ачык әйтелә. Аны Мусин-Пушкин, үзгәртмичә диярлек, халык мәгарифе министрына хат итеп юллый. Без дә, тәрҗемә итмичә генә, шул хаттан бер өзек китерәбез. Менә ул: «Мы, имея в своем распоряжении природных учителей для восточной словестности,

особенно в Казани и Астрахани, и всевозможные способы к приобретению неизвестных в Европе рукописей, выписываем за дорогую цену учеников Саси из Парижа и делаем их профессорами той словестности, которой они у нас учиться долженствовали. Иностранцы, выучившиеся восточным языкам по книгам, не только говорить, основательно учить, разбирать даже рукописи не могут». *(Письмо Мусина-Пушкина к министру народного просвещения.– ЦГИА РФ, ф. 733, оп. 40, ед. хр. 86, л. 2).*

Лобачевскийның иң зур казанышы—профессорлар-укытучылар һәм студентларның күпмилләтле булулары. Ул мәгариф министрына: «Шәрык телләре укытылган университет һәм гимназиядә укучылар яхшы уңышларга ирешсеннәр өчен укытучыларның үзләренең иранлы, татар, төрек булулары мәслихәт, әгәр мөмкин икән—алар Европа белеме белән шәрык телләрен һәм теоретик, һәм практик белүләрен берләштергән булсын иде»,—дип яза.

Н. И. Лобачевскийның кадрлар мәсьәләсендәге өлеге сәясәте нәтиҗәсендә университетта да, гимназиядә дә укытучы телчеләр мондый була: руслар—Н. Жуков, Н. Крашенинников, М. Навроцкий, М. Первухин; татарлар—берничә буын Хәлфиннәр, Ә. Дәминов, С. Мортазин, Нури һәм Әхмәт Абдусаттаровлар, М. Мәхмүдов; бурятлар—Г. Никитуев белән Д. Банзаров; аннары Мәккәдән Әхмәд-Бен Хәсән, Мазендараннан Хаҗи Мир Абуталиб Мир-Мөәминов, Әстерхан татары Н. Сонин (христиан диненә күчкәнче—Ибраһим Багиров), иранлы Сәед Алиев, Дербенттан Абдусаттар Казем-Бәк (Александр Казем-Бәкнең туганы), Истанбулдан (Константинопольдән) Хаҗи Осман Кутлуши, Кытай мөселманы уйгур Абу-Кәримов. Әле тагын укытучылар һәм студентлар арасында моннан тыш әрмәннәр, поляклар, немецлар, яһүдиләр һәм башкалар да була.

Шулай итеп, Лобачевский шәркый фәннәрнең үсешенә зур йогынты ясап кына калмаган, ә төрле халык вә милләт вәкилләрен сайлап алуда, эшкә тартуда, тәрбияләп үстерүдә дә турыдан-туры катнашкан. Аның алдынгы профессорлар белән берлектә Д. Банзаров һәм Г. Никитуевны казаклыктан йолып алырга куйган тырышлыклары турында әйтеп үткән идек инде.

Югарыда телгә алынган М. Мәхмүдовның да язмышы күңелсез була. Аның мәсьәләсе буенча университет Советы белән хөкүмәт Сенаты арасында язышу алты елга сузыла. Татарстан Республикасы Милли архивында кызыклы бер документ—«Увольнительный вид» саклана. Ул 1842 елның 19 августында Мәндәл волость идарәсе тарафыннан Мөхәммәд-Гали Мәхмүдовка бирелгән булган. Шул документ нигезендә, аңа нәкъ бер елга «Россия империясенең төрле шәһәр вә авылларына» чыгып йөрү хокукы каралган. Хәйбулла хәзрәт мәдрәсәсе шәкерте М. Мәхмүдов инде унсигез яшендә үк гарәп, фарсы, төрек телләрен бик яхшы белгән. Аның каллиграфик (сәнгатьчә матур язу) сәләтен профессор Казем-Бәк абайлап алган һәм укыту округы попечителенә хат юллаган. «Мәхмүдов,—дип язган ул,—бирєдәге мөселманнардан, ул Казандагы иң яхшы мәктәпләрнең берсенең шәкерте... аның күрсәткән үрнәкләренә караганда... үзенең яшьлегенә дә карамастан, гаҗәеп сәләте белән университетка да, беренче гимназиягә дә зур файда китерәчәгенә шикләнмәскә мөмкин». 1843 елның 25 гыйнварында мәгариф министрлыгы Мәхмүдовны гарәп, фарсы һәм төрек-татар каллиграфиясе укытучысы вазифасына алырга ризалык бирә, әмма егет, университетта 1842 елдан бирле эшләп килгән булса да, штатка алынмаган. Моның сәбәбе М. Мәхмүдовка бирелгән «Увольнительный вид»ның вакыты 1843 елның августында чыгуында була. Егетне ясаклы крестьяннар катлавыннан йолып алу артыннан ректорлар—башта Н. И. Лобачевский, аннары И. М. Симонов үзләре, шәрык факультеты деканы А. Казем-Бәк тырышып йөри. Тамчы тама-тама ташны тишә... Бары тик 1849 елның 18 июнендә генә Сенат указы белән М. Г. Мәхмүдов ясаклы крестьяннар катлавыннан азат ителә һәм укыту бүлегенә хезмәткә раслана. А. Казем-Бәк Н. И. Лобачевскийга юллаган үтенечендә М. Мәхмүдовны бүләккә тәкъдим итә, ул «бернинди түләүсез-нисез шулкадәр күп эшләп, шулкадәр күп файда китерде ки, мин аның хезмәтен һәм тырышлыгын тәкъдир итәргә... югарыга җиткерергә кирәк дип саныйм» дип яза. Лобачевский да М. Мәхмүдовны алтын медаль белән бүләкләү турындагы үтенечне хуплый. Әмма... бүләклиләрме соң «инородец басурманны»?!

Н. И. Лобачевский Оренбургтагы Неплюев кадет корпусын тәмамлаган Салихҗан Бикташ улы Кукляшев (1811—1864) язмышына да битараф калмый. 1930 елда бер үк вакытта Кукляшев Казанның беренче гимназиясендә шәрык

телләрен, ә университетта медицина фәнен өйрәнә. Әмма тиздән ул анатомия дәресләренә җирәнеп карый башлый һәм бик җитди авырып китә. Ректор Лобачевский аның сәламәтлеге белән үзе кызыксына: «Кукляшев, чынлап та, гомуми нерв йомшаруы белән авырый. Күз карашлары сүнгән, пульсы тизләтелгән һәм йомшак, тын алуы кыенлашкан...»—дип яза ул.

Салихҗан Кукляшев, медицина дәресләренә йөрүен туктатып, тулысынча шәрык телләрен генә өйрәнергә карар кыла. 1834 елны ул, Лобачевскийның турыдан-туры ярдәме белән, шәрык бүлегенә күчәргә рөхсәт ала. Уку дәверендә Кукляшев бары тик яхшы һәм бик яхшы билгеләргә генә укый. 1836 елда университетны тәмамлаганда ук аңа кандидатлык дәрәҗәсе бирелә (бу дәрәҗә университет тәмамлаучыларга, кагыйдә буларак, берничә имтихан һәм язма эш тапшырганнан соң гына бирелә торган була). Эшкә кергәндә андый кешеләргә унынчы класслы хезмәт вазифасына хокук каралган. Кукляшев кандидатлык дәрәҗәсенә татарлардан беренчеләрдән лаек була.

Революциягә кадәр университет эшчәнлеген өйрәнүчеләр XIX гасырда Казанда шәркый фәннәр буенча тупланган уңышларның төп сәбәбен шәһәрнең географик урнашуына, ягъни Европа белән Азия чигендә булуына гына кайтарып калдыралар. Шуның белән алар Мәскәү һәм Харьков университетларының шәрык кафедралары эшчәнлегендә XIX гасырның утызынчы елларындагы уңышсызлыкларын аклап аңлатмакчы булалар. Казан университетының уңышларын географиягә генә бәйләп карау ориенталистларның җентекле методик оештыру эшләрен, ректорлар Н. И. Лобачевский белән И. М. Симоновның акыллы җитәкчелеген, шулай ук Казанда элек-электән шәрык традицияләренең нык нигезле икәнлеген күрмәү булыр иде.

Казан университеты китапханәсендә, төрле мөмкинлекләрдән файдаланып, шәрык кульязмалары һәм басма чыганаклар бихисап тупланган. «Университетның ректоры һәм китапханәчесе Лобачевский» дип хатларына кул куя торган галим һәм җитәкче, кирәкле әдәбиятны алдыру максатыннан, төрле шәрык шәһәрләрендә хәбәрләшеп тору пунктлары оештыруны хуп күргән. Китапханә бигрәк тә чит илләргә сәяхәт кылган галимнәр җибәреп торган әдәбият хисабына байый килгән. Мәсәлән, Кытайда булган В. П. Васильев бер 1842 елда гына да Казанга 2737 томнан торган 849 исемдәге әсәр җибәргән! Кавказ, Гыйрак, Иран, Сүрия, Фәләстин, Мисыр, Төркия кебек илләргә сәяхәт ясаган галимнәр И. Н. Березин, В. Ф. Диттельләрдә (1842—1845) шәрык илләре тарихы һәм географиясенә кагылышлы бай материал алып кайткан, алар борынгы язуларның күчермәләрен, кырыклап план-схема һәм өч йөз рәсем дә төшереп алганнар.

Шәрыкны университетта борынгы язма истәлекләр аша гына өйрәнмәгәннәр. Китапханә Каһирә, Тәһран, Истанбул, Вена, Париж һәм башка шәһәрләрдән даими рәвештә газет-журналлар һәм әр-яңа фәнни әдәбиятны яздырып алып торган. Аңа Бөекбритания белән Ирландиянең Король Азия җәмгыятьләреннән, Даниянең борынгы төньяк җәмгыятеннән дә басмалар килгән.

Шәрык кафедралары Көнбатыш Европа һәм Көнчыгыш галимнәре, уку йортлары белән дә даими элемтәдә булган. Казан университеты үз галимнәренең хезмәтләрен Европадагы утыз җиде университетка җибәреп, алыш-биреш итеп торган. Университет типографиясендә лекция каталоглары, укыту программалары, фәнни күзәтүләр, уку ярдәмлекләре, гыйльми әдәбият нәшер ителгән, алар Россия, Австрия, Англия, Германия, Португалия, Франция, Швеция кебек илләрнең фәнни һәм укыту үзәкләренә дә җибәрелеп торган.

Казан университетының шәрык бүлеге халыкара хезмәттәшлек итү үзәкләренең берсе булган, дип әйтсәк, бер дә арттыру түгелдер.

* * *

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ философия факультетының шәрык бүлеген 1854/55 уку елына Санкт-Петербургка күчерү, шәрыкны өйрәнүне шунда үзәкләштерү чаралары үткәрү шәрык телләрен укытуның гомуми күләменә һәм сыйфатына да, Казан ориенталистларының тикшеренү эшчәнлегенә дә XIX гасырның икенче яртысында тискәре йогынты ясамый калмаган, әлбәттә. Әмма объектив тарихи-географик шартлар һәм бигрәк тә XIX гасырның беренче яртысында барлыкка килгән фәнни-тикшеренү традицияләре шәркый фәннәр өлкәсендәге эзләнүләрнең тотрыклы дәвам ителәчәгенә алшарт булып торган.

Галимнәрнең гарәп, бигрәк тә ислам һәм төрки дөнья турындагы фәнни хезмәтләре Казанда да бу юнәлештә шактый гына тикшеренү эшләре алып барылганлыгы турында сөйләргә мөмкинлек бирә. Г. С. Саблуков (1804—1880), Н. И. Ильминский (1822—1891), М. Г. Мәхмүдов, И. М. Холмогоров (1818—1891), И. Ф. Готвальд (1813—1897), В. В. Радлов (1837—1918), Е. А. Малов (1835—1918), Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889), Каюм Насыйри (1825—1902) Н. Ф. Катанов (1862—1922), И. А. Бодуэн де Куртенэ (1845—1929) һәм башка галимнәрнең нәтиҗәле эшчәнлекләре дәвам иткән.

XIX гасыр уртасында Казан университетының гарәп һәм фарсы телләре ординар профессоры И. Ф. Готвальд була. 1849 елдан алып аның бөтен гомере Казан белән бәйләнгән. Хәтта шәрык бүлеге Санкт-Петербургка күчерелгәч тә, ул университетны, аның китапханәсен ташлап китәргә теләми. Озакламый Готвальд китапханәче итеп билгеләнә. Әмма аның төп мавыгуы булып һаман да шәрык кульязмалары кала.

И. Ф. Готвальд бик күп татар галимнәре һәм мәгърифәтчеләре белән таныша, алар аша Урта Азия һәм башка шәрык төбәкләре белән бәйләнешкә керә. 1857—1884 елларда ул университет типографиясенең башлыгы була, 1855—1875 елларда—шәркый телләрдәге китапларның цензоры да. Аның эшчәнлеген сурәтләп биографы Н. Ф. Катанов: «Борынгы һәм яңа шәрык кульязмаларын уку һәм аларга тасвирламалар язу тәҗрибәсе бай булган Иосиф Федорович ориенталистика өлкәсенә караган барлык яңалыкларны да армый-талмый күзәтә, алар хакында махсус журналларга язып тора; әле беркайда да басылмаган төрле кульязмаларның текстларын фәнни чагыштыра, әллә кайлардан кызыклы кульязмаларны үзе сатып яки күчереп ала»,—дип яза *(Катанов Н. Ф. Казанского университета почетный член, профессор и библиотекарь Иосиф Готвальд.—Казань, 1900, стр. V)*.

И. Ф. Готвальдның үз китапханәсендәге китапларының гомуми саны (кабатланганнарын исәпләмичә) 2500 гә якын була. Бу җыелманың язмышы бәхетле: ул тулысы белән сакланып калган. Бастырып алынган каталогы да булгач, аның белән теләсә кайсы тикшеренүче галим таныша ала. Готвальдның җыелмасы һәм шәхси архивы, ни кызганыч, әлегә кадәр җитәрлек өйрәнелмәгән. Шунысын да билгеләп үтик, Готвальд ориенталистларның Петербург (1876), Берлин (1881), Лейден (1883), Стокгольм (1889) съездларында Казан университеты вәкиле буларак катнаша.

Петербург университетында шәрык бүлегенең эшчәнлеген җәелдереп җибәрү билгеле бер авырлыклар белән барганлыктан, аны яңадан Казанга кайтару турында җитди уйлана башлыйлар. Халык мәгарифе министры Е. П. Ковалевский, 1860 елның җәендә Казан университетын карап-тикшереп чыккач: «Факультетны (шәрык бүлеген—С. М.) Санкт-Петербургка күчерү Тышкы эшләр министрлыгының Шәрык институты тарафыннан көндәшлек тә очраткан иде, бу гамәлебез ялгыш булган икән»,—дип кызгану-үкенү белдерә. Үзенең бу фикерләрен министр патшага да җиткерә. Аның язуына патша Александр II мондый резолюция сала: «Сообразить, нельзя ли вновь учредить там (Казанда—С. М.) восточный факультет, упразднив таковой здесь». *(Материалы истории факультета восточных языков.—СПб., 1905, т. I, стр. 527)*.

Беренче Казан гимназиясендә исә шәрык телләрен укыту бер генә елга да тукталып тормый. 1861 елны Казан университетында төрек, татар һәм гарәп телләре укыту яңартыла, 1863 елдан фарсы теле дә өстәлә, укытучылары И. Н. Холмогоров белән Н. И. Ильминский була. Укыту бик авыр бара, чөнки шәрык бүлеге китапханәсенең төп фондлары, күп кенә кульязмалар, нумизматика коллекцияләре h. б. Петербург университетына күчерелгән була. Казандагы унтугыз галим—шәрык телләре белгечләре дә шунда күчеп китә. Шулай да университет шәрык телләре, тарихы һәм этнографиясенә караган байтак китапларны, кульязмаларны саклап кала ала.

Төрки-татар кафедрасына җитәкче итеп куелган Н. И. Ильминский университетка чакырылганчы ук казакъ һәм татар телләре буенча берничә хезмәт бастырган танылган галим, шул ук вакытта рус графикасы нигезендә кайбер халыклар өчен алфавит төзегән, христиан китапларын татар теленә һәм Идел буе, Урал, Себердә яшәүче халыклар теленә дә тәрҗемә иткән дини миссионер да була. Ильминскийның миссионерлык карашлары аның мәгарифкә һәм халык теленә булган мөнәсәбәтендә дә чагыла. Ул татарларның

җанлы сөйләм телен иң элек христианлык идеяләрен гади халыкка тизрәк җиткерү өчен өйрәнә, гарәп-фарсы сүзләре белән чуарланган китап телен артык катлаулы дип саный.

Үзенең хатларында һәм хезмәтләрендә Ильминский татар теленә зур хөрмәт белән карый: халыкның сөйләм телен ул чын-чынлап фәнни тикшеренүләргә лаек дип таба. «Һәртөрле лингвистик тикшеренү җитди фактларга, җанлы халык сөйләменә нигезләнергә тиеш»,—дип башлый ул үзенең университеттагы төрек-татар теле курсына кереш лекциясен. Әйе, ул бик тәҗрибәле педагог була. Аның фәнни-педагогик һәм җәмгыятьчелек эшчәнлегенә бәя биргәндә, һәрвакыт күз уңында миссионерлык карашларын тотканлыгын да онытырга ярамый, әмма галим Ильминскийның төрки фәннәргә керткән өлешен һәм рус булмаган милләтләрнең зыялыларын үстерешкәнен дә инкарь итәргә кирәкмәстер.

1872 елда Ильминский Казанда ачылган руханилар семинариясенә директор итеп билгеләнә.

Безнең карашка, Н. И. Ильминскийга дөрес бәя Зур Совет Энциклопедиясендә бирелә: «Ильминский һәм аның фикердәшләре тарафыннан патша Россиясендәге чуваш, татар, мари, удмурт, якут һәм башка халыклар өчен рус графикасы нигезендә алфавитлар төзү прогрессив әһәмияткә ия булган, чөнки ул бу халыклар арасында рус телендә белем таратуга да ярдәм иткән». Аның, мәктәптә укытуның башлангыч чоры ана телендә укытылырга тиеш, дигән фикере дә игътибарга лаек.

Россиянең XIX гасыр уртасы һәм икенче яртысындагы ориенталистларның танылганнары арасында профессор Гордий Семенович Саблуков та бар. Аның мирасы төрки һәм ислам дөньясын тикшергән хезмәтләрендә чагылыш таба.

1849 елда Г. Саблуков Казан Духовная академиясенә бакалавр булып кабул ителә. Шул ук вакытта ул семинариядә татар теле дә укыта башлый, дини китапларны татар теленә тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә.

М. Френда фәнни өзерлек үткән Саблуковның Алтын Урда тарихы, нумизматикасы һәм археологиясенә караган фәнни эзләнүләре үзенең укытучысы йогынтысында бара. Хатларыннан аның Н. И. Ильминский, И. Н. Березин, Ш. Мәрҗани кебек галимнәр белән дә хезмәттәшлек иткәне күренә.

Саблуков ныклап торып, максатчан рәвештә Коръәнне өйрәнә, аны тикшерә башлый. Билгеле булганча, Саблуков тарафыннан гарәп теленнән рус теленә турыдан-туры тәрҗемә ителгән Коръән беренче тапкыр нәшер ителгәнче, Россиядә XVIII гасырдан башлап Изге китапның Көнбатыш Европа телләреннән тәрҗемәләре генә була. Ислам диненең төп кануннарын бәян иткән Изге китап—Коръәннең рус теленә оригиналыннан тәрҗемә ителеп дөнья күрүе—Россиядә аны өйрәнүнең яңа чоры башланган дигән сүз.

Шул рәвешле, Саблуков Коръәне (фәндә ул шулай аталып йөртелә) үз заманының әһәмиятле вакыйгасы була һәм бик тиздән сирәк китаплар исемлегенә теркәлә.

XIX гасырның икенче яртысында шәркый фәннәрне өйрәнү-тикшерүнең үзенчәлеге шунда ки, ул ислам тарихын ике караштан—миссионерлык һәм фәнни академик караштан торып өйрәнү, шул юнәлештәге фикерләр көрәшенә кайтып кала.

Саблуков аңлатуынча, Коръәнгә берничә яктан килеп карарга мөмкин: беренчедән, Коръән—ислам тарихын өйрәнү өчен иң мөһим беренчел чыганак; икенчедән, Коръән ислам диненең кануннарын туплаган төп китап; өченчедән, Коръән—гарәп әдәбиятының һәм мәдәниятенең иң борынгы истәлеге.

XIX гасыр азагында чагыштырма-тарихи тел белеме зур уңышларга ирешә.

Шул чорда Казан уку округының татар, башкорт һәм кыргыз училищелары инспекторы В. В. Радлов җитәкчелегендә Казан университеты галимнәре И. А. Бодуэн де Куртенэ, В. А. Богородицкий, Н. В. Крушевскийлар алтай телен өйрәнәләр.

1880 елда В. В. Радлов профессор Бодуэн де Куртенэның «Чагыштырма тарихи тел белеме» курсы буенча практик дәресләр алып бара, Себер сөйләшләре һәм, гомумән, туран телләре турындагы үз хезмәтләреннән дә өзекләр китерә.

Бодуэн де Куртенэ университетта ориенталистиканы яңарту, беренче чиратта төрки һәм фин телләре кафедрасы ачу мәсьәләсен күтәрә. «Шундый

кафедраларсыз,—дип яза ул,—Казан университеты рус булмаган кабиләләрнең телен һәм тормыш-көнкүрешен өйрәнү эшендә үз өстенә төшкән җитәкчелек бурычын канәгатьләндерү мөмкинлегеннән мәхрүм».

Күренекле шәхесләрнең инде күп өйрәнелгән биографияләренә нинди дә булса яңалык өстәү кыен. Мәсәлән, шул ук И. Бодуэн де Куртенэның искиткеч әһәмияте турында да бик күп тикшеренүләр язылган. Академик Л. В. Щерба, аның фәндә үткән юлын бәяләп, болай яза: «Чынлап та, аның эшчәнлегенең кайсы халык фәненә караганлыгын әйтү мөмкин түгел. Ул руслар, поляклар, немецлар (Дерптта) арасында эшләгән, полякча, русча, словенча, чехча, немецча, французча, итальянча, литвача язган».

Шулай да бу гаҗәеп шәхеснең байтак кына эшчәнлеге, аерым алганда, Идел буенда фәнни-милли зыялыларны булдырудагы роле галимнәр игътибарыннан төшеп кала килгән.

Бодуэн де Куртенэ Казанда яшәгән чорында татар тел белемен өйрәнүче, халык укытучысы Шаһбазгәрәй Ахмеровка (1854—1900) да юл ачкан.

Ш. Ахмеров отставкадагы губерна секретаре гаиләсендә туа. Гаиләләре ярлы була. Әнисе, үз хисабына укыта алмаганлыктан, мәгариф министрлыгыннан Шаһбазгәрәйгә стипендия билгеләүләрен үтенә. Икенче Казан гимназиясен уңышлы тәмамлаганнан соң, Ш. Ахмеров университетның тарих-филология факультетына Бодуэн де Куртенэ эшләгән чорда укырга керә. Әле студент чагында ук ул «Көньяк-Көнбатыш Русьтагы һәм Киев Академиясендәге фән турында», «Иясез җөмләләр турында» кебек хезмәтләрен яза. Ул хезмәтләргә профессор Е. К. Булич югары бәя бирә.

Ш. Ахмеров мөстәкыйль рәвештә «Татар теленең фигыль формалары» дигән хезмәтен озаклап эшли, бу хакта ул үзенең 1877 ел өчен хисап язмасында әйтеп уза. Бодуэн де Куртенэ, аның хезмәте белән танышып чыкканнан соң, мондый бәя бирә: «Ахмеровның хезмәте татар фигыльләренең төп үзенчәлеген синтаксик яктан бөтенләй мөстәкыйль тикшерү булып тора һәм автор тарафыннан сөйләм телендә грамматик формаларның нинди әһәмияткә ия булуын иң югары дәрәҗәдә аңларга һәм аңлатып бирергә сәләтле икәнлеген күрсәтә. Ахмеров хезмәтенең сыйфат фигыль, хәл фигыль һәм башка фигыльләрне тикшергән соңгы өлеше аерым игътибарга лаек, чөнки алар безнең авторның элгәрләре өлегә кадәр тикшергәннәрдән күпкә тирәнрәк һәм төгәлрәк... Ахмеровның хезмәте бик тә канәгатьләнерлек һәм «5» билгесенә лаек. Бу хезмәттә татар синтаксисы өчен, аерым алганда, фарсы телләре синтаксисы өчен дә бик күп яңа мәгълүматлар булганлыктан, минемчә, аны, әлбәттә, авторның ризалыгы белән, «Записки университета» журналында, һичшиксез, бастырып чыгарырга кирәктер».

Шунысын да искәртик, Куртенэ үзе дә татар телен зур кызыксыну белән һәм бик теләп өйрәнә.

Ш. Ахмеровның «Казан татарлары сөйләшендәге фигыльләрне синтаксик яктан тикшерү» (1895) дигән хезмәте дә бүгенге көнгә кадәр үз әһәмиятен югалтмаган.

Ш. Ахмеров 1878 елда университетны уңышлы тәмамлый һәм Казан татар укытучылар мәктәбенә рус теле укытучысы итеп билгеләнә. Ул үзенең остазлары Бодуэн де Куртенэ, М. Мәхмүдов, К. Насыйрилардан укыту һәм гыйльми эшчәнлекнең иң яхшы алымнарын үзләштергән була. Алар кебек үк, Ахмеров та укытуны аваз әйтелеше алымы белән алып бара, аңлы укуны алга сөрә, татар укытучыларының белемен күтәрү курсларын оештыра. Ул үзенең вафатына кадәр (1900) Казан татар укытучылар мәктәбенең алыштыргысыз җитәкчесе була. Укытучылар мәктәбе өчен дәреслеге (1895) һәм М. Иманголов белән берлектә язылган рус-татар училищелары өчен дәреслеге (1896) телләрне яхшырак үзләштерергә ярдәм итәрлек методик алымнарының төрлелеге белән аерылып тора. Ш. Ахмеров татар халкы мәдәнияте тарихына танылган педагог һәм мәгърифәтче буларак кереп кала. Ул шулай ук күп тапкырлар югары хакимияттән татар телендә «Казан» исемле газет чыгарырга рөхсәт тә сорап карый, ләкин һәрчак үтенече кире кагыла килә.

Бодуэн де Куртенэның кылган изге гамәлләре турында озаклап сөйләп булыр иде, ләкин шушында тукталып калырга мәҗбүрбез.

1893 елда Н. Ф. Катанов Казан университетында төрки һәм татар телләрен укытуын дәвам итә. Әле егерме яшьлек гимназист вакытында ук ул

«Татар теле (сагай сөйләше, грамматикасы, этимологиясе һәм синтаксисы)» дигән хезмәт яза. Белеменең күпкырлы һәм тирән булуы аңа төрле-төрле лекцияләр укырга мөмкинлек бирә: Казан татарлары теленең грамматикасы, төрки халыкларның тарихы һәм этнографиясе, төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы, чыгтай теле—менә аның кайберләре шулар. Алга таба ул шулай ук гарәп һәм фарсы телләрен, алтай теле грамматикасын, төрки әдәбиятын да укыта башлый.

1888—1889 елларда Н. Катанов Себер, Кытай, Монголия, Төркестанга, Уфа, Оренбург һәм башка губерналарга фәнни экспедицияләр оештыра. Алар турындагы фәнни язмаларын «Ученые записки Казанского университета», «Известия общества археологии, истории и этнографии» басмаларын да бастыра. Аның Татарстан Республикасы Милли архивында саклана торган, кашгар сөйләшенә тәрҗемә ителгән кытай кануны күчермәсе дә бик кызыклы. Ул юридик чыганак лингвистик һәм тарихи истәлек буларак кыйммәтле.

1900 елда Н. Катанов андагы шәрык кульязмалары белән танышыр өчен Көнбатыш Европага җибәрелә. Аннан алып кайткан материаллары «Опыт исследования урянхойского языка с указанием главнейших родственных отношений к другим языкам тюркского корня» дигән ике томлык хезмәтенең чыганакларын баетырга-тулыландырырга ярдәм итә. Бу хезмәтендә ул урянхой (тува) шивәсе сөйләше белән генә чикләнеп калмый, тагын төрки телләрдән биш борынгы һәм кырык ике хәзерге сөйләшләрне дә чагыштырып карый. Хезмәт төрки телләрнең алтай төркеменә кергәннәрен өйрәнүчеләр өчен бик тә әһәмиятле була.

Н. Ф. Катановның фәнни тикшеренүләре Россиядә һәм чит илләрдә дә югары бәя ала. Ул берничә рус һәм чит ил гыйльми җәмгыятьләрендә әгъза булып тора. Аның «Опыт исследования урянхойского языка» (1903) дигән докторлык диссертациясе дөнья ориенталистикасының алтын фондына кертелгән.

XIX гасырның икенче яртысында шәрыкны өйрәнү белән татар галимнәре Ш. Мәрҗани (1818—1889) һәм К. Насыйриның (1825—1902) ныклап шөгыльләнүләре әһәмиятле урын тота. Алар икесе дә Казан университеты каршында 1878 елда оештырылган «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең эшчән әгъзалары була.

Каюм Насыйриның фәнни тикшеренү-эзләнүләре күптөрле, аның эш сөючәнлегенә исләрең китәрлек! Ул галим, тәрҗемәче, тарихчы, философ, әдип. Әле тагын ел саен чыгып килгән татар календарьлары авторы, календарь сәхифәләрендә дөнья тарихы буенча кызыклы һәм кирәкле мәгълүматлар биреп килә.

1880 елда Мәскәүдә В. В. Григорьев сүз башы белән Каюм Насыйриның «Поверия и обряды казанских татар, образовавшиеся помимо влияния на них суннитского магометанства» дигән хезмәте басылып чыга. *(Записки императорского русского географического общества.—М., 1880. Т. 6, стр. 243-270).* «Образцы народной литературы казанских татар» дигән хезмәте белән бергә, алар татар халкының тарихи үткәне, мәдәнияте һәм әдәбияты турында киң мәгълүмат бирәләр. Соңгысы «Известия общества археологии, истории и этнографии при Казанском императорском университете» *(1896, т. 13, вып. 5, стр. 374-427)* басмасында дөнья күрә.

К. Насыйри татар теленең грамматик төзелешен һәм әдәби стилен озаклап һәм нәтиҗәле өйрәнә. Татар теленең морфологиясе һәм синтаксисы, рус һәм татар телләренең чагыштырма характеристикасына караган хезмәтләре университет нәшриятында басылып чыга. Алар галимнең тирән белемле, югары дәрәҗәдә эшчән икәнлеген дәлилләр.

В. Радлов белән Н. Катанов та еш кына Каюм Насыйрига ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр. Көнбатыш Европа ориенталистларының да аның хезмәтләрен файдаланганлыклары билгеле.

Шәрык илләре халыкларының тарихы һәм мәдәнияте Казан ориенталистикасының иң яхшы традицияләрен дәвам иткән Шиһабетдин Мәрҗани эшчәнлегендә, аның фәнни мирасында зур урын тота. Фәнни өйләнешкә күп очракта беренче мәртәбә кертелә торган төрле чыганакларга—документлар-актлар, археографик, тарихи-орхеологик, нумизматик, этнографик чыганакларга таянып, ул татар галимнәре арасыннан беренчеләрдән булып Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәсьәләләрен яктыртуны максат итеп куя. Көнчыгыш

белән Көнбатышның рухи байлыклары арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне тукталып, Ш. Мәрҗани аларның үзара йогынтысы һәм бер-берсенә үтеп керүләрен билгеләп үтә. Шәрык илләре халыкларының гомумкешелек тәрәккыятенә керткән өлешләрен югары бәяли. Аның фәнни хезмәтләрендә шәхесләр һәм халык массаларының тарихта тоткан урыны, татар халкының этногенез мәсьәләләре алып тора. Галим, беренчеләрдән буларак, ориенталистиканы үстерү өчен шундый тикшеренүләр кирәклеген төшенеп, шәрык илләрендәге атаклы шәхесләр турында энциклопедик сүзлек төзүгә алына.

Беренче Казан гимназиясе, университет, Казан татар укытучылар мәктәбе, университет каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте кебек танылган үзәкләрдән тыш, җирле телләрне, рус булмаган халыкларның этнографиясен һәм мәдәниятен өйрәнүгә Казан руханилар семинариясе һәм Духовная академиясе дә зур игътибар бирә. Академиядә татар теле 1800 елдан ук укытыла башлый. Укытучылар 1821 елдан Г. Троянский, 1849 елдан Г. Саблуков, 1855 елдан К. Насыйри, 1870 елдан Н. Остроумов, 1897 елдан Е. Малов була. Бу хакта тулырак мәгълүматны П. В. Знаменскийның «Казанская семинария в первое время ее существования» (1868) һәм «История Казанской духовной академии» (1891) хезмәтләреннән табарга мөмкин.

1854 елның гыйнварыннан Казан Духовная академиясендә миссионерлык бүлеге ачыла, аның раскольниклыкка каршы, мөселманлыкка каршы, буддачылыкка каршы бүлекчәләре; татар теле һәм этнографиясе, гарәп теле, мөселманлык тарихы һәм аны фаш итү, монгол теле кафедралары да була. Академиядә төрле чорларда А. Казем-Бәк, А. Попов, А. Бобровников, Н. Ильминский кебек танылган шәрыкчылар эшли.

Миссионерлык эшчәнлеге шәрык илләре халыкларының тарихын һәм телләрен яхшы белүне таләп итә. Казан академиясе бу җәһәттән күп көнә төпле әзерлек белгечләре булу белән аерылып тора, анда укучыларны, кагыйдә буларак, шәрык илләренә озын-озак сәфәрләргә җибәрә торган булганнар.

Академия студентлары бик күп төрле темаларга курс һәм диплом эшләре язганнар. Мәсәлән, «Россиядә мөселман руханиларының юридик хәле» (1879), «Казан төбәгендә христианлыкның таралу тарихы» (1883), «Кыргызлар» (1888), «Башкортлар» (1899), «Казан төбәге инородецларын укыту чараларына тарихи күзәтү» (1903) һ. б. Укытучылар исә Россиянең рус булмаган халыклары телләрендә уку ярдәмлекләре һәм сүзлекләр төзегәннәр.

Академия каршысында рухани-цензура комитеты (1857—1908) оештырыла, ул дини әдәбият һәм дәреслекләр нәшер итүгә җаваплы була. 1856 елдан башлап «Православный собеседник», ә 1867 елдан «Известия по Казанской епархии» журналлары чыгып килә. XIX гасыр азагыннан алып академия ябылганчы—1920 елга кадәр аның укытучылары Н. Ашмарин, Н. Катанов, М. Машанов, С. Малов һәм Н. Фирсов кебек галимнәр була.

Шул рәвешле, Казандагы ориенталистика фәненең аякка басуын һәм үсеш чорларын күзәткәннән соң, галимнәрнең шәрык халыклары тарихы, мәдәнияте, әдәбияты һәм теле белән тотрыклы һәм тирән кызыксынып шөгыльләнгәннәрен күрәбез. Моңа нәрсәләр этәргеч булган соң? Әлбәттә, беренче чиратта, патша Россиясенең административ хакимият даирәләре дә, дипломатиясе дә һәм шулай ук рухани миссионерлык ихтыяҗлары да шуны таләп иткән, шуңа этәргән. Духовная академия һәм семинариясенең XIX гасыр уртасыннан аеруча көчәеп китүе, аларның Идел буе мөселманнары арасында миссионерлык белән актив шөгыльләнүе, мөселманнарны көчләп христианлаштыру, русификаторлык сәясәте алып барулары бәхәссез.

Без исә биредә, сәясәткә кагылмыйча, бары тик Казанда ориенталистика фәненең XIX гасырдагы үсеш баскычларына тәфсиллерәк күзәтү ясарга гына тырыштык.

Киләчәктә, әлбәттә, бу мәсьәләләр тирәнрәк һәм һәрьяклап өйрәнелергә яктыртылырга тиештер.

# СӘНГАТЬКӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Милли сәнгатебез тарихында үзенчәлекле эз калдырган күренекле сәнгать эшлеклесе, педагог, оештыручы, галим, профессор, ватан сугышы ветераны Әзһәр Хәниф улы Абдуллин 40 елга якын гомерен Казан консерваториясенең хор-дирижерлык кафедрасына багышлаган шәхес.

Аның күп кенә шәкертләре музыка факультетлары һәм мәдәният институты мөгаллимнәре, музыка училищеларының дирижерлык бүлеге җитәкчеләре, төрле җыр һәм бию ансамбльләре сәнгать җитәкчеләре һәм хормейстерлары, хор студияләре, музыка мәктәбе укытучылары.



Әзһәр Хәниф улы Абдуллин.
*Эрот Зарипов рәсеме.*

Әзһәр Хәниф улы Абдуллин 1923 елның 20 октябрендә Минзәлә районының Тауасты байлары авылында мөгаллим гаиләсендә туа. Атасы—Хәниф Абдулла улы—Теләнчетамак мәдрәсәсендә укыган, Дәвек, Күзкәй мәдрәсәләрендә мөгаллимлек иткән, гарәпчә яхшы белгән. «30 ел бергә яшәү дәверендә,—дип искә ала Асия ханым Абдуллина—Әзһәр аганың хәләл җефете,—аларның нәсел-нәсәбенең табигый рәвештә музыкага һәвәс булганлыгына инандым. Шулай бервакыт, Әзһәрнең әнисе безгә беренче тапкыр кунакка килгәч, радиодан бик матур яңа көй тапшырдылар. Ул шул көйгә мөкиббән китеп, тавышы белән көйләп торды да, беренче тапкыр пианино күрүенә дә карамастан, шул көйне пианинода җыеп уйнап бирде. Әтисе дә скрипкада уйный иде. Боларны искә алуым шуна, Әзһәрнең таланты нәселдән килә».

1937 елны 13 яшьлек Әзһәр Казан музыка училищесына укырга керә. Виолончель классы укытучысы В. П. Варшавский классында музыка серләренә төшенә башлый һәм бик тиз уңышлар казана. 1939 елда, музыка училищесының 35 еллык юбилеен үткәргәндә, Татарстан хөкүмәте училищеның ин талантлы берничә укучысына махсус стипендия бирү турында карар чыгара. Шулар арасында Әзһәр дә була.

1947 елда Казан консерваториясенә укырга керә һәм 1952 елда аны кызыл диплом белән тәмамлап, Мәскәү консерваториясе аспирантурасының хор-дирижерлык бүлегендә укуын дәвам итә. Шунда профессор Анисимов классында укып, татар халык көйләре темасына багышланган диссертация яза башлый. Аспирантураны уңышлы тәмамлап кайткач, ул консерваториядә хор-дирижерлык кафедрасында укытудан тыш, музыка училищесының симфоник оркестры белән дә җитәкчелек итә. 1956 елда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында оркестр җитәкчесе булып эшли.

Шушы чорда Әзһәр Абдуллин С. Сәйдәшев иҗатын өйрәнүгә, аны яңадан торгызуга күп көч куя. Сәйдәшнең язып бетерелмәгән «Гөлнара» балетының партитурасын архивтан табып алып, берничә ел аның өстендә эшли. Композиторның кайбер башка әсәрләренә дә яңа оркестровка булдыра; «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе», «Наемщик», «Сүнгән йолдызлар» кебек спектакльләргә язылган

бик күп гүзәл әсәрләрнең музыкасын торгызып, яңадан халыкка кайтара. Ул әсәрләрнең кайберләре 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында Әзһәр Абдуллин дирижерлыгында башкарыла һәм хуплап кабул ителә.

Күп тә үтми, Әзһәр Абдуллин Казан консерваториясенең өлкән укытучысы буларак, киң кырлы педагогик эшчәнлеген башлый; сирәк очрый торган табигый музыкальлеге, халык иҗатын һәм дөнья музыка культурасының тарихын һәм тәгълиматын тирәнтен белүе аңа төрле өлкәләрдә уңышлы эшләргә булышлык итә. Әзһәр Абдуллин опера һәм балет театрында бик күп музыкаль спектакльләргә, мәсәлән, Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым»ына үзе аранжировка ясап, үзе үк дирижерлык та итә. Венгр халкының бөек композиторы Золтан Кодайдан үрнәк алып, татар халык җырларының көйләрен системалаштыра, аларны хор белән башкару өчен эшкәртә. Шушы ук әсәрләрне балалар хоры белән башкару өчен дә яраклаштыра. Кызганыч ки, бу әсәрләрне ул аерым җыентык итеп бастырып чыгарырга өлгерми кала.

Консерваториядә аның тарафыннан бик күп талантлы хор дирижерлары әзерләнде. Алар Идел буе регионы республикаларында гына түгел, хәтта Россиянең бик күп шәһәрләрендә, чит илләрдә дә хор культурасы үсешенә зур өлеш кертәләр. Бу уңайдан Россиянең һәм Удмуртиянең халык артисты, Удмуртия Дәүләт премиясе лауреаты, «Италмас» Удмурт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе, композитор А. В. Мамонтов исемен атап китү дә урынлы булыр.

Консерваториядә укыту елларында укучыларда сәнгатькә мәхәббәт һәм ышаныч үята алуы, кеше психологиясен, эчке дөньясын аңлый белүе, тыйнаклыгы, зыялы булуы, һәркемгә ихтирамлы, игътибарлы булуы белән үзенә җәлеп итә, яраттыра иде. Аны берничек тә дан-шөһрәт яратучан дип әйтеп булмый. Гаҗәеп киң талантын, үзенең артык тыйнаклыгы аркасында, вакытында дөньяга танытырга омтылмады. Хор белән эшләгәндә кисәтү-күрсәтмәләре төгәл кыска булып, эшенең асылын күрә, үтемле итеп әйтә белә, хор белән эшләгәндә шәкертләренә комачауламас, аларның башлангычын кысмас, шул ук вакытта бик таләпчән дә була белде. Консерваториядәге укытучыларның музыка өлкәсендәге эшләренә ин төпле тирән анализлы тәнкыйть-рецензияләрне ул яза иде. Шул вакытларда аның белән берлектә консерватория хоры, опера һәм балет театрының хор һәм оркестры белән Татарстан радиосында бик күп язмалар дөнья күрә. «Мәрфуга», «Таң атканда», «Хуш, авылым», «Фазыл чишмәсе» һ. б. әнә шундыйлардан.

1965—1968 елларда Ә. Абдуллин Татар җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе булып эшли. Әзһәр әфәндедән тирән белем һәм иҗади мәктәп алган, аның талантлы шәкерте, Татарстанның халык артисты, Татар җыр һәм бию ансамбле хормейстеры, мөгаллимә Венера Хәсән кызы Гәрәева, аның бик күп эшкәртмәләрен һәм композитор буларак язган әсәрләрен башкарып дөньяга күрсәтте, әле дә бу эшне дәвам итә. Ансамбльдә бергә эшләгән, аңарда белем алган елларны Венера Гәрәева менә ничек искә ала: «Әзһәр ага белән мин бала чактан бирле таныш. Минзәлә театрының баянчысы булып эшләгән әтием белән дуслар иде, театрга да еш килә иде. Профессиональ сәнгать дөньясында аның белән беренче очрашуым 60 елларда ул ансамбльдә эшләгән вакытта булды. Музыкант башкаручы осталыгы аңа тагын бер яңа талантын ачарга ярдәм итте. Бу татар халкының төрле жанрдагы җырларын һәм композиторлар әсәрләрен хор белән башкару өчен эшкәртү осталыгы».

Халкына хас аһәңнәрне югалтмыйча, үз канунннарын саклап гармония белән бизәү—бик зур сәнгать. Әзһәр ага хор өчен эшкәрткән әсәрләрдән: «Фазыл чишмәсе», «Эрбет», «Туган тел», Р. Яхинның «Сорнай моңы», «Агыйдел» сюитасы һ. б. бик күп җырларны атап була. Мәсәлән, «Фазыл чишмәсе» көй ягыннан гади, чылтырап аккан чишмәдәй саф, кояш кебек якты. Әзһәр Хәнифович җырның кушымтасын төрле тавышларда яңгыратып, искиткеч гармоник һәм математик төгәллек белән эшкәрткән. Ә нинди симфоник яңгыраш! Моны исбатлау өчен «Туган тел» әсәрен алып карыйк. Бу көй безнең бишек җырыбыз да, гимныбызда да, динебезне, телебезне сакларга өндәүче дога да. Әзһәр ага «Туган тел»дә мөмкин булган бөтен ысулларны файдаланган. Әсәрнең буеннан-буена полифоник тема «Тәфтиләү», «Туган тел», «Бишек җыры»—кеше тавышы

симфониясе булып яңгырыйлар. Шундый әсәрләрнең тагын берсе—өч кисәкле «Агыйдел буенда» сюитасы. Әзһәр аганың ин затлы эшкәртмәләренең берсе «Сорнай моңы» (Р. Яхин, Ш. Хөсәен). Ул көй Татарстанның халык артисты Шамил Әхмәтҗанов өчен махсус эшләнеп, халык күңеленә дә аның башкаруында кереп калды. Бу бөек әсәрне японнар, алманнар, чехлар, Африка илләрендәге халыклар да аяк өсте алкышладылар. Бу алкышларның төп сәбәпчесе Әзһәр ага иде, билгеле. Әзһәр аганың соңгы эшкәртмәләреннән «Картуф» җыры әле дә ансамбльнең репертуарыннан төшми яши. «Болын» һәм «Әзифә» җырларын ул Ания Туишева тавышы өчен, «Сандугачкай» белән «Зәңгәр чиләк»не Лена Бичарина өчен эшкәртеп, аларга бүләк иткән иде. Әзһәр Хәнифович җырларны бервакытта да бер кушымтаны гел кабатлый торган вариант белән эшкәртмәде, музыкаль фантазиясе бай иде аның. Һәр кушымтаны төрлечә бизәкләп, җырны тулы сюжетлы күренешкә әйләндерә иде.

Ә. Абдуллин хор эшлеклесе генә түгел, олы талант—зур симфоник оркестрлар белән дирижерлык итү сәләте ана тумыштан бирелгәндер, күрәсең. Ул эшкәрткән хор әсәрләре симфония булып ишетелә. Мондый талант татар хор музыкасында сирәк очрый.

1989 елда консерваториядә татар музыкасы кафедрасы ачыла һәм Әзһәр Абдуллинның зур методик, теоретик, гамәли иҗат тәҗрибәсе кафедраның башлангычына нигез ташларын ныгытуга зур терәк була. Ул кафедрага татар музыка фольклоры белгече буларак кучерелә һәм ана профессор вазифасын тапшыралар.

Әзһәр Абдуллинда табигатьне бөтен матурлыгы белән ишетү сәләте була. Мәшһүр дирижер Натан Рахлин да ана карата: «Мөкәммәл ишетүле беренче татарны очраттым...», дигән иде. Натан Григорьевич ниндидер сәбәпләр аркасында, үзе симфоник оркестр белән дирижерлык итә алмаган очракларда, оркестрын бары тик Әзһәр агага гына ышанып тапшыра торган була. «Ул танылган, тәҗрибәле мастер, киң масштаблы талант кына түгел, тирә-ягына җылы яктылык сибеп, үзенә тартып торган тирән фикерле һәм юморлы акыл иясе, сокланырлык кешелек сыйфатлары балкып торган олуг шәхес булып исемдә калды,—ди консерваториянең ректоры Рубин Кәбир улы Абдуллин.—Консерваториянең композиция һәм фортепиано факультетында белем алган кызы Алсуга зур өметләр баглыйбыз, башкаручы буларак та, композитор буларак та этисенең иҗат эшен дәвам итәр дип ышанабыз»,—ди ул.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт университеты хор капелласы җитәкчесе, профессор В. П. Леванов: «Ә. Х. Абдуллин беренчеләрдән булып татар халык җырларының жанр төрлелеген һәм халык җырларын башкару үзенчәлекләрен өйрәнде. Аның бар иҗаты татар музыкасы тарихында М. Мозаффаров, А. Ключаревлардан соң аерым тулы бер чор булып тора...»—дип, ассызыклап искә ала хезмәттәшенең татар хор өлкәсенә керткән өлешен югары бәяләп.

Әзһәр Абдуллин иҗат иткән чорда татар хор культурасының югары биеклектә булуы күзәтелә. Хор җәмгыятенең рәисе буларак та ул бу өлкәгә бәһаләп бетергесез гамәли өлеш кертте.

Габәши, Мозаффаров, Ключаревлардан соң заман миссиясен берүзе күтәреп чыгып, тормышка ашыра алган ул. Аның иҗаты шәхси мөнәсәбәтләр каршылыгыннан югары булды. Нинди генә тармакка тотынса да, һәр эшне югары профессиональ дәрәҗәдә башкарды. Кайсы гына жанрны алсак та, аның үзенә генә хас фикерләү культурасы булганлыгы ярылып ята. Әзһәр Абдуллин хор белән башкаруда академик һәм халыкчанлыкны берләштерә алган әлеге бергәлекне синтезлау юлында алтын урталыкны тапкан һәм аны укучыларында да тәрбияләгән шәхес. Югарыда әйтеп кителгән фикерне аның укучылары Венера Гәрәева һәм Анатолий Мамонтов эш ысулларында ачык күреп була.

Татар җырының бер тавышлы табигатен тоемлап эш итүе, аерым җырчы тавышы белән хорны куша алуы, табигать күренешләре төсмерләрен, башкару манераларын хор «келәмендә» берләштереп сокланырлык итеп чагылдыра алуы, киң фактуралылык, симфониялелек, гомумән, күп тавышлылыкның үз кылын табуы аның әсәрләренә хас сыйфат.

Әзһәр Абдуллин кеше тавышының мөмкинлекләрен симфоник һәм халык уен кораллары оркестрларының янгыраш үзенчәлекләрен яхшы белеп эш итте. Сәйдәшев, Мозаффаров, Ключарев традицияләрен баетып, камилләштереп, заманының эстетик таләпләренә җавап бирерлек итеп дәвам итте. Галим буларак татар халык җырларын жанрларга бүлеп, халык җырларының кайбер башкарылу үзенчәлекләрен ачыклады, фән өлкәсендә нигезле өлеш кертте. Бу өлкәдә ул музыкаль иҗат белән башкаручылыкның бер-берсенә йогынтысы, халык җырчыларының башкару манералары һәм көйнең структурасы белән башкару үзенчәлекләрен ачыклады. Орнаментлы озын көйләрне иркен-импровизацион манерада һәм кызу тизлектәге җырларда, киресенчә, бер тавыштан икенчесенә күчкәндә зур төгәллек белән башкару ысулларын исбатлап күрсәтте.

Идел буе халыкларының хор сәнгате энҗе-җәүһәрләрен җыю белән беррәттән, ул бу халыкларның композиторлары әсәрләренә дә эшкәртмәләр ясап, хрестоматия әзерләде. Әмма дөньяга чыгарырга өлгерә алмады. Бу эшне булдырган очракта, мондый уникаль хрестоматия студентлар өчен бик кирәкле кулланма булыр иде.

1963 елны Ә. Абдуллинның Лебединский редакциясендә матбугатта күп кенә фәнни эшләре һәм «Баянда уйнарга өйрән» китабы татар телендә бастырылып чыга. Бу җыентыкта ул баян өчен үз эшкәртүендә 32 татар халык көен һәм үзе иҗат иткән берничә пьесаны да кертә. Өстәвенә Әзһәр Абдуллин күп кенә авторларның фәнни эшләрен рецензияли һәм редакцияли. Аның 80 гә якын музыкаль язмасы Бөтенсоюз радио фондында саклана. Ул күп кенә әсәрләрнең авторы да. Аларның күпчелеге Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен язылган һәм эшкәртелгән: «Бәхет юлы», «Шат үтә безнен көннәр», тынлы оркестр өчен «Бәйрәм маршы», «Сарман яшьләре» сюитасы, шулай ук «Каз өмәсе» дип аталган вокаль хореографик күренешне дә ансамбль өчен ул иҗат итте. С. Сәйдәшевнең 90 еллык юбилеена «Зәңгәр шәл» музыкаль драмасы аның тарафыннан концерт программасы вариантында эшкәртелде.

Әзһәр Абдуллинның хор өчен татар фольклоры әсәрләренең эшкәртелү ысуллары, үзешчән һәм профессиональ хорлар белән эшләү алымнары хезмәтләре бар. Татар музыка бүлекләре өчен дә укыту методикасы бөтенләй юк дәрәҗәсендә икәнен, соңгы вакытларда татар халык әсәрләрен башкару манерасы турында да күп бәхәсләр баруын истә тотсак, болар соңгы елларда төрле уку йортларында ачылган милли сәнгать бүлекләре өчен уку әсбабы булырлык хезмәтләр. Әзһәр Абдуллинның татар сәнгатенә, хор музыкасына керткән өлеше бик зур һәм бәһаләп бетергесез икәнен белгән хәлдә, аның барлык хезмәтләрен бер китапка туплау— бу сорауларга турыдан-туры җавап та булыр иде.

Әзһәр Хәниф улы Абдуллинның иҗат мирасы хөкүмәтебез, иҗат берлекләре тарафыннан игътибарсыз калдырылмас, йөз белән борылырлар дип ышанасы килә.

**Филүсә АРСЛАНОВА,**
*Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты өлкән укытучысы.*

# АК КАЗЛАР ЧАКЫРУЫ

Мин «Ак каз» исемле китап укыйм... Янда гына Татарстан радиосы сөйләп тора. Аны тыңламыйм, игътибарым—«Ак каз»да. Кинәт радиодагы бер хәбәр, җәрәхәт ясап, анга бәреп керә: җырчыбыз, милли моң пәһлеваны Хәйдәр Бигичевның кабер ташыннан язулы пластинкасын каерып алганнар! Төсле металл җыючыларга сатып исерткеч алу өчендер, мөгаен. Бик ипле Казаныбызда бит бу! Төрле милләтләр гореф-гадәт алмашып дус яши торган баш шәһәребездә... Әйе, мөртәтлекне шул «дус»ларның теләсә кайсы кылырга мөмкин, «үзебездән, татар милләтеннән түгелдер лә», дигән өмет бик кечкенә. Әдәбебезнең аклыгы, бөекләребезнең пакь исеме өчен генә түгел, изге һәйкәлләребезнең, истәлек такталарыбызның бөтенлеге өчен дә хәвеф көтеп яшәр көннәргә калдык. Татар милләте дә дөнья бозыклыгыннан саклана алмады, хәтта мона әллә ни омтылмады да кебек. «Ник яратмасын маржаны, татарның да бар җаны»,—дип җырлый-җырлый, горур кыяфәттә әдәбебезне, гореф-гадәтләребезне бүтәннәрнеке белән тәңгәлләштердек. Ә бит кайчандыр—Бөек Болгарга Ибн Фадлан сәяхәт кылган заманнарда—борынгы бабаларыбыз үзләренең әдәпле тормыш-көнкүрешләре белән сокландырганнар.

Милләтче дигән төркемебез бервакыт: «Казан—Татарстан башкаласы булса, Чаллы—бөтен татарның баш шәһәре» дип сөйли башлаган иде. Хәзер күрәбез: «татар үзәге», Казаннан да узып, наркомания афәтенә суырыла бара, суырыла бара... Янәшәсендә—Сажидә Сөләйманова үз иткән Әлмәт шәһәре, җырда «ал гына, гөл генә» дип мактала торган Бөгелмә. Рәшит Гәрәйнен Минзәләсен аракы мафиясе тетрәтеп-тетрәтеп ала...

Милләт башындагылар да татарның ак әдәбен торгызуга әллә ни йогынты ясый алмадылар һәм «бары—бергә, югы—уртак» дип микән, халык белән бер сафта, «горур кыяфәттә» упкынга таба атлыйлар... Менә тагын матбугатта «сөенечле» бер хәбәр: мингерәйткеч сыра кайнатып сату буенча Татарстаныбыз Россиядә икенче биеклекне яулаган. Димәк, без һәрьяктан Федерациянең ышанычлы икенче урынында. Ә эчүчелек белән беренчелекне үк дәгъвалыйбыз бугай. Кайчандыр ак әдәпле авылларыбызның бүгенге яшьләренә игътибар беләнрәк күз салсаң, шундый хәвефләнү җанны өтеп ала. Эчеп тә карыйлар! Һәм шушы хәл өлкәннәр алдында гаеп тә саналмый.

Мин «Ак каз» китабын укыйм. Баш каһарман, мәктәпкә киләсе елда барачак Таһирҗан, бер урында әтисен болай сурәтли: «Безнең әти әйбәт күңелле, бик тәртипле кеше. Ул гомеренә тәмәке тартмады, аракы эчмәде. Аш янына бисмилласын әйтеп утыра, амин итеп торып китә иде. Әти ашны кызык итеп ашый, кашыкны тәлинкәдән алуга аның астына кин учын куя, авызына кадәр шулай озата».

Менә ул—татар әдәбе! Исерткеч эчмәү дә, бисмилла әйтеп кенә ашарга керешү дә, ашның тамчысын да иләнгә төшерергә теләмәү дә бер-берсенә нык бәйләнгәннәр. Таһирҗан әтисендәге бөтен пакь сыйфатларны күреп тә бетерми, чагыштыра, нәтиҗәләр ясый да белмидер әле. Белсә, күзәтүчәнрәк булса (без бу сыйфатларның өлкәннәрдән безгә күчәсе иң кадерле ядкарь икәнен, аларның бер заман бетәсен, шуна күрә аларны отып калырга, дәвам иттерергә тиешлегебезне

анладыкмыни?), ул чактагы иплелекне кинрәк сурәтләр һәм без әхлакый югалтуларыбызның тагын да күбрәк булуын күрер идек.

«Ак каз»—житмешен тутырган өлкән әдип, Татарстан Язучылар берлегенең Фатих Хөсни исемендәге бүләге иясе Радик Фәизовның өченче меңьеллык башында басылып чыккан яна китабы ул. Җыентык шул исемдәге повесть белән ачыла. Бүген житмешкә житкәннәрнең яшь чаклары хакындагы бу әсәрне укыганда ак казлардай очып кына югалган пакь әдәбебезне юксынудан йөрәк кысыла. Кая омтылдык та, кая килеп чыктык без? Пакь ислам диненнән язуыбыз шушы пычракка тартып керттеме безне? Күпләр әхлаксызлык сазлыгына бата баруыбызның сәбәбен шулай гадиләштереп аңлатырга омтыла. Кайбер танылган гына динчеләребез дә, исламга кадәрге үткәнебезне тоташ каралтып, «кешеләр бербирсен корбанга чалган кыргый чорыгыз» дип кенә жибәрәләр. Тик менә әлеге шул Ибн Фадлан, ислам дине әле урнаша гына башлаган, аның тәрбиядә йогынтысы юк чакта да Бөек Болгар халкын һич тә кыргыйлар итеп сурәтләми. Шулай булмыйча, ул чордагы әби-бабаларыбызның әхлагы, ана кадәрге тәңречелек һәм дини йоладай сакланган матур гадәтләр тәэсирендә, пакь һәм кырыс ислам динен жинел кабул итәргә әзер булган. Рус халкының гореф-гадәтенә һәм яшәү рәвешенә якын да килмәгәнгә. Әнә, Мәскәү кенәзе ислам динен кискен кире каккан.

Таһиржаннар гаиләсенең «үзе шундый зур, гайрәтле, бәпкәләренең берсе дә үлмичә тупырдап үсә торган ана ак казы»н повесть авторы нәкъ менә өлкән әдипләргә хас булганча шундый бер жылылык, сагышлы мәхәббәт белән сурәтли ки: күз алдында каз үзе жанлы булып гәүдәләнә, кайдандыр ерак еллар аръягыннан аның тавышын да ишеткәндәй буласың. Иркенлеккә, сафлыкка чакыру авазын! Юк, яз көне ояда йомырка өстендә утырып та, сынар бәпкә чыгара алмаган, соныннан инкубатор бибиләрен ияртеп йөрергә калган (чөнки повестьтагыдай казларны тәрбияләп үстерә белүче Гайшәбикәләребез сирәк инде, ак казның токымы да бу көннәргә килеп житмәгәндер) бүгенге гап-гади йорт казы тавышы гына түгел бу. Ул тавышта ерак үткәнебезнең, дәүләтле чакларыбызның кыр казлары авазы шәйләнә. Таһиржан да ак казның «әнисе яз көне тау астында йөргәндә кыргый казлар белән кушылган булырга тиеш,—дип уйлый.—Иректә, үзбуйлы яшәгән казлар белән... Кыр казлары якындагы киң болынга очып килгәндә, бик сирәк кенә булса да, тау астына да кунгалыйлар. Үзем күргәнем бар... Безнең ак казның башын югары күтәреп йөрүендә, бибиләрен саклап бик яман ысылдавында, бөтенесен куркытып алуында ниндидер бер кыргый, табигый көч бар. Көз көне, инде бибиләре үзе хәтле булып, Шашы тау башына башак чүпләргә менгәч тә, алар аннан бүтән казлар кебек алпан-тилпән килеп жәяү төшми. Бибиләрен ияртә дә, алар йөгерә-барып, һавага күтәреләләр. Басулар өстеннән авыл ягына очып кына төшәләр... Инде тау астындагы яшел чирәм өстенә төшеп кунгач та, бик озак тынычлана алмыйлар. Киң жәелгән канатларын да жыймастан әрле-бирле йөренәләр, үзара тагын нидер сөйләшәләр. «Һавада очып йөрүләре нинди күңелле. Зәңгәр күктә рәхәт, иркенлек анда. Безгә бу тау астыннан киң болыннарга очып китәргә кирәк!»—дип киңәшәләр бугай... Ә бит теләсәләр, бездән бөтенләй очып китеп, кыргый кардәшләре белән бергәләп, иркенлектә яши аласылар үзләре. Алар ни өчендер моны эшләмиләр һәм бу мина сәер тоела».

Әйе, шагыйрь Марис Нәзировның Венера Ганиева бик яратып жырлый торган искиткеч матур жыр сүзләрендә әйтелгәнчә, «очмыйча син түзеп кара, иннәреңдә канат барда». Радик Фәизовның ак казы халкыбызның ирекккә, сафлыкка, табигыйлеккә омтылу символы булу өстенә, тарихи шартлар нәтижәсендә тау асты тарлыгында гомер кичерергә мәжбүр булганнарның кырыс тормыш чынбарлыгы шаһите һәм хөсетлек, миһербансызлык корбаны да. Авылның мәчет манарасын кисеп төшергән көнне дә «әллә ничә тапкыр бик моңлы итеп кычкыра» ул. Сугыштан соң, әле халыкның хәерчелеге хәттин ашкан елларда, мәжбүри заемга яздырырга кергән клуб мөдире Маһирә дә Гайшәбикәнең аһ-зарын шул ак каз белән томаламакчы була. Янәсе, зарланып маташма, өч мең сум заем күп түгел сина: «Сыер тотасың, ак казың ел саен унбиш бәпкә чыгара».

«Башына әтәч кикриге киеп куйган тавык» Маһирәнең үз әхлагында да

бүгенге авыру җәмгыятьнең байтак билгеләре төсмерләнә башлаган инде. Басудан башак урлап тотылган ач балаларга карата аның миһербансызлыгы ир-ат милиционерны да аптырашта калдыра. Гаҗәп тә түгел, җәмгыятьнең тулаем бозылуы хатын-кызның әдәп кагыйдәләрен санга сукмавыннан башлана ич. Кызлардан комиссарлар, каты күнелле эш атлары ясап, большевиклар ил әхлагына, милләтнең инде калыплашкан, атадан балага күчә барган гореф-гадәтенә, ипле һәм тыйнак яшәү рәвешенә төзәтеп бетермәслек зыян китерделәр. Маһирәнең «ел саен унбиш биби» чыгарган ак каздан да кара күпсенүе һәм ишле бәпкә хуҗасы Гайшәбикәдән заем акчасын күбрәк каерырга омтылуы белән Чатан Саттар малае Вәли гамәле арасында да охшашлык бар инде. Вәли: «Безнең ата казны аздыра, безнең ата каз үзебезнекеләрне басмый аннары» дип, ак казның әчено таяк тыгып кайтара. «Ирләр белән тигез хокуклы» комиссар кызлар үрнәге җәмгыятькә менә кемнәрне тәрбияләп бирде! Маһирә һич тә бер әдип фантазиясе белән генә тудырылган каһарман түгел, ул—тормышның үзеннән. Без аның игезәкләрен Зәки Зәйнуллин әсәрләрендә дә (Чолык Зәйнәбе) күп очраттык, кызганычка, инде реаль чынбарлыгыбызда алар гадәтигә үк әверелеп киләләр. Хатын-кыз явызлыгы күп очракта берниндн җәзасыз кала (Алла күбесен игелексез балалар яки оныклар белән җәзалый анысы, тик бу соңрак була), шунлыктан аның бүтәннәргә әшәке йогынтысы һәм җәмгыять әхлагына җимергеч тәэсире дә көчлерәк була. Шуна күрә җәмгыятьне савыктыру эшен дә әниләр-кызлар белән бик акыллы һәм эзлекле эш алып барудан башларга кирәк, моның канунын булдырырга да вакыт иде, тик без кирәкле эшкә өлгермибез, аның каруы, булачак милләт әниләренең тагын һәм тагын бер буынын чит әдәп кочагына бирә барабыз.

Ризык кадерен белмәү—әхлаксызлыкның йөз төрле чагылышыннан бер генә күренеш әле ул. Бәлки иң беренчеседер. Һәрхәлдә, бала холкында бу башкаларыннан элегрәк чагыла башлый. Без моңа игътибар итеп вакланмыйбыз гына. Алар ачлык күрмәгән, сугыш чоры авырлыкларын кичмәгән шул инде, дип тынычланабыз. Һәм иң зур бәла чыганагыбыз да шушы безнең. Рәсәй халкы ГУЛАГ михнәтен күрмичә ирекнең, сугыш газабын кичмичә тынычлыкның, ачлык афәтендә кырылмыйча ризыкның, вабадай чирләрне янарткаламыйча сәламәтлекнең кадерен белми, шулай күнектерелгәнбез. Бу илдә тыныч үзгәртеп корулар, реформа дигәндә дә әледән-әле танклар хәрәкәткә килә, генераллар хакимияткә күтәрелә. Әле житмәсә һәр буын, «тәрбияле» булу өчен, мондый мәхшәрне үзе татырга тиеш, элгәрләреннән гыйбрәт аласы гына түгел. Тарихыбыз да теге сугыштан бу сугышка, бер ачлыктан икенче ачлыкка, революциядән контрреволюциягә өлешләп кискәләнгән безнең. «Кайгылар күрми ир булмый», дип җырлана борынгыдан килгән җырыбызда да. Өй каршында үскән гөнаһсыз ак каеннар да безгә кайгы телиләр кебек тоела. Ил дә безне михнәтләр аша гына кеше итеп тота белә. Чөнки безнең бүгенгедәй тыныч, чагыштырмача тук һәм ирекле тормышка ярашлы тәрбия чараларыбыз эшләнмәгән, күрәсең, андый тормышның килү ихтималы да күз алдында тотылмаган, элекке пакь гореф-гадәтләр, өлкәннәр үрнәге чорның нинди борылышындадыр өзелеп калган, хәзер бөтенесенә авырлык, сугыш, мохтаҗлык бәрабәренә ирешелә. Без әле «әниләр яисә балалар елы», «яшьләр елы» дигән булып та, рәтле бер гамәл кылмыйча, үз-үзебезне юатып бушка вакыт уздырабыз гына. Вәли җәрәхәтләгән ак казны тагын унбишәр бәпкә чыгарырлык итеп савыктыру өчен Гайшәбикәгә бер ел житсә дә, җәмгыятьнең югалган ак әдәбен кире кайтарырга, авыру әхлагын дәваларга әле бик күп вакыт һәм тырышлык кирәк булыр. Гайшәбикәләребез бүгенгәчә сакланып калган, алар урынын Маһирәләр алып бетермәгән булса ярый әле. Югалтуларыбыз зур бит. Повесть каһарманы Таһирҗан да читтә олыгаеп үз авылына кайткалаганда андагы казларны күреп, «бәлки алар безнең ак казның нәселеннәндер» дип юкка өметләнә, без арттагы күперләрне яндырып, үткәнебездәге һәр аклыктан нык ераклашканбыз, аннан тәмуггагыдай утлы упкын белән бүленгәнбез. Инде шул утта безнең гомерләребез янган.

Елдан-ел четерекләнә барган әдәп-әхлак проблемасы Радик Фәизовның «Узган гомер—янган күмер» повестенда да үзәк урынны били. Арчаның район газетасы мөхәррире Ринат Таҗиев мисалында автор әдәп кагыйдәләреннән,

буыннар аша сыналып калыплашкан яшәү рәвешеннән чак кына тайпылуның да кеше шәхесен таркатуга, ахырдан тәмам югалтуга, олы фаҗигага китерү ихтималын ышандырырлык итеп сурәтли. Радик Фәизов килер алдыннан шунда берничә генә ай булса да эшләп алган кеше булганга, повестьның Арча редакциясендәге тормышны тасвирлаган өлеше, андагы шәхесләр миңа шактый таныш. Нәкъ шул сәбәпле, авторның кайбер фикерләре, аерым алганда, Ринатка кадәр мөхәррирлек иткән Шакир Гафаровка карата әйтелгәне белән шәхсән килешмим дә.

Повестьның бер каһарманы, автор карашынча, җәмгатьчелекнең кешелекле мөнәсәбәте, үтемле сүзе булмаганга гына һәлакәт чигенә барып житә. Ул үз тирәсендәгеләрнең кинәшен һәм аптыраулы карашын инде ишетми-күрми, ә партия райкомында мөхәррирнең әкренләп бата баруына ваемсыз-тыныч карыйлар. Чөнки ул партиягә каршы гамәл кылмый, хәтта урлашмый да, әкрен-әкрен исерткеч тәэсиренә генә бирелә бара. «Аннан кемгә нинди зыян? Барыбыз да эчә». Безнен чит милләт әдәбенә нигезләнгән җәмгыять аракыга шундый мөнәсәбәттә булды, әле дә әллә ни үзгәрмәде. Гомуми калыпка сыймаганнарны исә авыр кабул итте.

Әнә, Арча газетасында мөхәррир булган Тәлгать Мостафинны күпме кеше дөрес аңлады, яшәү рәвешен хуплады икән? Газета өчен гади журналистлардан уздырып баш күтәрми яза, аның өстенә, райкомнан килгән кеше буларак, андагы түрәләр өчен әледән-әле доклад әзерли, редакциянең бердәнбер машинасын колхозга чыга торган егетләргә биреп, үзе Казанда буласы кинәшмәгә поездда китә. Яшәү шартлары—«гомуми йортның кысан гына фатиры» (менә ул—Балтачның басынкы холкы, чөнки Тәлгать абый шушы районныкы бит»). Һәм, әдип әйткәнчә, «гаҗәеп кенә түгел, тыйнакның да тыйнагы» шушы кешегә Радик Фәизовтан башка җылы сүз әйтүче булды микән? Киресенчә, «электә райкомда аз гына эшләп, артын гына җылытып чыккан, болын кебек иркен йортларда, хәтта кайберләре ике катлыларында» яшәүчеләр аннан мөмкинлеге барында умырып калмаганы өчен көлеп йөриләрдер. Бу илдә әхлаклы яшәүчеләрне бик хупламыйлар, шуңа күрә алар аз да. Документаль повестьның «ак каз»ы ул—Тәлгать Мостафин. Иркенгә, очар кошлар биеклегенә күтәрелергә тиеш булып та (Тәлгать Мостафиннар өчен хыялдагы иң гадел җәмгыятьтә—коммунизмда яшәү шундый биеклек булыр иде, мөгаен), ялгызлыклары аркасында һәм хөсетле мохит канатларын каерганга күрә хыял-омтылышларына житә алмыйча калганнардыр алар. Ирексезлек, шул ирексезлекне җаннары белән тою аларның барыр юлын чикләгәндер. Үзләре шундый хәлдә булганнар гына аңлый моны.

Радик Фәизов телсезләрне дә аңлый алучы әдип икән. Аның «Телсез» исемле сокландыргыч хикәясен укыгач шундый нәтиҗәгә киләсең. Тумыштан чукрак-телсез булганлыктан кызлар күзе төшмәгән, шуңа күрә өйләнүдән мәхрүм булган «урта буйлы, киң иңсәле, чем-кара чәчләре дулкынланып торган күркәм, чибәр егет» Хәйдәр һәм аның авылдагы Сәгыйдә исемле яшь киленгә гыйшкы хикәядә шундый матур, җылы һәм саф итеп сурәтләнгән, аларны гөнаһта гаепләү дә кыен. Хәер, егетнең эчкерсез чын мәхәббәте гөнаһлы гамәлләргә житми дә. Кая ул—«Сәгыйдә аның өчен кеше кулы орынырга да ярамаган илаһи зат» бит! Сәгыйдәнең ире тарафыннан җәберләнүен дә күтәрә алмый ич ул! Аның Сәгыйдәгә кечкенә генә тупас хәрәкәте дә хикәя каһарманының күңел кошын күктән җиргә орыр иде.

Килен үзе дә «бик тә чибәр: зур зәңгәр күзле, бит урталарын батырып һәрвакыт елмаеп кына тора». Һәм, менә «бәла»: ул да егетне аңлый! Аңламаса, аның хисләреннән көлсә, егеткә, бәлки, җиңелрәк тә булыр, аның канатсыз килеш кинәт күккә күтәрелгән җаны фаҗигага да барып житмәс иде, кем белә... «Юләрем син минем... Акыллым... Бәхетсез кошым син минем» дигәндә Сәгыйдә егет мәхәббәтенең азагы күңелсез йомгакланасын сизенгәндер. «Бәхетсез кош» ерак оча алырмыни! Каберенә ир хатыны Сәгыйдә килгәләп йөри—менә ул күтәрелә алган иң зур «биеклек». Һәм бер генә кеше күңелендә дә начарлык белән сакланмый ул. Бәхетсезлеген берәүгә дә ягып калдырмыйча, бөтенесен үзе белән алып китте...

«Гөли» хикәясе дә үзенең үтә табигыйлеге белән укучыны сискәндереп җибәрә. Гөли—«табигате балалыктан чыккан» булса да, «акылы нарасыйдан

чыкмаган» 15-16 яшьлек Гөләндәмнен кеше арасындагы исеме. Шул «акылы» белән мәктәптә укый алмаса да, әдип аны тинтәк итеп күрсәтергә теләми. Хәтере әйбәт, хәйлә белми, ышанучан, үзе миһербанлы, мәче балаларын да кызгана. «Бәлки кешелекнен гөнаһсыз сабый чагы тулаем шундыйрак булгандыр?» Житмәсә, гашыйк, чын-чынлап гашыйк Гөли! Телендә көтүче Рәсим генә. «Рәсим янына төшәм!.. Кичәгенәк без болында йөрдек, Рәсим белән... Рәсим миңа болынга тагын төш, диде».

Бу хикәядән дә укучы жанына аклык бөркелә. Көлмиләр бит Гөлидән! Жәллиләр генә. Киресенчә, «акны карадан аермаган гөнаһсыз бала бит, кыз бала, ул-бу килеп чыкмасын, оятлы хәл булмаган дип, авыл егетләре Рәсимне кисәтеп куялар. Бик каты кисәтеп». Рәсим дә мондый хәлдә үз жаваплылыгын һәм кызны төшенерлек икән. «Нәрсә, мин анламыйммыни, егетләр... Аллам сакласын!»—ди ул.

Әлбәттә, хикәя азагында бернинди дә могжиза булмый, чөнки әдип тормыш чынлыгыннан тайпылмый. Көтүче Рәсимнең бүтән авылда яши торган әти-әниләре, «монда эшләрнен буталып китүе дә бар» дип, улларын алып китәләр. Моны белми калган һәм көтү каршына чыгып көн дә егетне эзли торган Гөлигә «кайсыдыр ахмагы» «Рәсимен үлде синен, аны зиратка илтеп күмеп куйдылар» дип тупас шаярта. Һәм Гөли, ышанып, шунда ук каберстанга йөгерә, зират тирәсендә көн саен йөри-йөри сукмак салып бетерә. Камил акыллы кешеләрнең шулай жинел алдашуын, гөнаһсыз хисләрдән көлү аларга берни тормавын кайдан белсен ди ул?! Хикәя безнен үз-үзебезгә, әхлагыбызга нарасый акылы аша карап, аларга төгәлрәк, гаделрәк бәя бирергә ярдәм итә.

Гажәп хәл: телсез Хәйдәрнең, акылы өлгермәгән Гөлинең өметсез мәхәббәтен авылда күпләр анлап, аларның киләчәге өчен борчылып күзәтсә, мәктәп укучылары Сәрия белән Сәүбәннең яна бөреләнгән гыйшкы («Көнбагыш чәчәкләре» хикәясе) укытучылар коллективын тәмам чыгырдан чыгара. Чөнки бередә тигез мәхәббәт ике яшь йөрәкне иректә һәм горур итә, аларның тәртибе кысан кагыйдәләргә сыймый! Юк, беренче саф хисләрдән канатланып яхшырак та укымый, тора-бара зур гыйлем алып дөньякүләм уңышларга да ирешми егет. Әдип шулай тасвирласа—бу әкияттәгедәй килеп чыгар, ышандырмас иде. Чынлыкта, Сәүбән белән Сәрия әллә ниләргә омтылмаганнар да икән. Егеттән аеру өчен Сәрияне бүтән мәктәпкә күчерүгә, Сәүбән дә укуын ташлый һәм әтисе янында тимерчелектә эшли башлый, һөнәр ала. Һәм шул һөнәре белән гомерен үткәрә. Сәриясе белән өйләнешеп, сөеп һәм сөелеп, алты ул, өч кыз үстерәләр. Бөтенесе авылда: ярты авыл—Гаделшиннар токымы. Ә менә яшьләрне бер-берсен яратудан тыярга тырышкан мәктәп директоры гомерен эчүчелектә түгәрәкли. Әхлаклылык үрнәге түгел икән бит ул, ихтыярсыз, рухи кыйблясыз бер жан икән!

Китаптагы «Үкенеч», «Очрашу» хикәяләре дә бик гыйбрәтле, сабак өчен кат-кат укырлык. Моңа кадәр язганнары кебек, бу яна жыентыкта да бер генә «буш» әсәре дә юк Радик Фәизовның. Халкыбызның әхлак дефициты чорында нәкъ шушы әсәрләрне суытмыйча дөньяга чыгарып, Татарстан китап нәшрияты да зур, бик кирәкле эш башкарган.

... Авылларыбызда ап-ак каз төркемнәре елдан-ел кубәя хәзер. Тик алар үзебезнеке түгел, йомыркасын ерак илләрдән кайтартып, инкубаторда чыгарылган бәпкәләр алар. Үзара «сөйләшүләре» дә чит телдә кебек. Нәселгә калдырсан, утырып биби чыгара да белмиләр. Иңнәрендә канат барлыгын тоеп зәңгәр күккә дә күтәрелмиләр, аннан киек кошлар очып үтсә дә, башларын кыегайтып, куркынып карап калалар. Үзебезнекеләр сагындыра... Европача чит әдәп, ят көйләр дә, тыштан бик ымсындыргыч тоелуларына карамастан, рухыбызны күтәрә һәм сафландыра алмадылар. Шуңа күрә, тәмам югалып юкка чыкканчы, үзебезнекеләрне кайтарасы иде. Тын калып тынлыйк әле, алар да безне чакыралар түгелме?!

**Рафыйк ШӘРӘФИЕВ**

# БАЛА КҮҢЕЛЕ

Республика Милли китапханәсе белән Язучылар берлеге үткәргән традицион «Ел китабы» конкурсында Рафис Корбанның 2000 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Куркуын җиңгән куян» җыентыгы иң күп укылганнар исемлегенә кергән. Димәк, балалар Р. Корбанның әсәрләрен кәтеп алалар икән. Язучы өчен шуннан да зур бәхет юктыр дип беләм. Чыннан да, аның әсәрләре кай ягы белән үзенчәлекле, балалар күңелен ничек җәлеп итә? Югыйсә, балалар өчен шактый иҗатчылар яза бит. Сорауга җавап эзләп Р. Корбанның балаларга адресланган китапларына мөрәҗәгать итик.

1991 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Сөзгәк болыт» җыентыгы «Мин бәйрәмнәр яратам» шигыре белән башланып китә. Әйе, һәр бала бәйрәм ярата, көн саен бәйрәм булуын тели.

Шатлыклардан шатлык туа,
Әверелә матур җырга.
Бары тик бер шатлык кирәк
Җир төренсен өчен нурга,—

ди шагыйрь үзенең фикерен дәвам итеп «Шатлык» шигырендә. «Җил» шигырендәге лирик герой да җилнең күңелен күрә, аның да куанып, шатланып исүен тели:

Үзенә генә күңелсез
Булмас җилгә моннан соң—
Шарымны биреп калдырдым,
Рәхәтләнеп уйнасын!

Балалар холкындагы төп сыйфатлар: тапкырлык, хәйләкәрлек, батыр, кыю булырга теләү Р. Корбан шигырьләрендә шактый урын ала. «Каюмның дуслары», «Тапкырлык», «Карак карачкы», «Тимерле чәй», «Әнисе Каюмны санарга өйрәтә» һәм башка күп кенә шигырьләр бу турыда ачык сөйлиләр. «Чикләвеккә баргач» шигыре исә батыр булуның серен дә ачып сала:

Батырлык ул куркудан
Көчлерәк була икән.
Батыр булсаң, яныңнан
Курку тиз шыла икән.

Ә менә «Күрәсем килә» әсәрендә бүгенге көндә әһәмиятле бер мәсьәлә күтәрелә. Лирик героебыз мультфильмнар карарга бик ярата икән, ул инде бик күп халыкларның мультфильмнарын белә.

Тик күрәсем килә минем
Кайчак Камыр батырны.
Шәвәли атлы малайны,
Шүрәлене, Былтырны,—

ди ул, ямансулап.

Әйе, балалар әле дә көтә, тик бу өлкәдәге проблемалар бер урында кала бирә. Ә берничә елдан бит баланың татарча сөйләшәсе үк килми башлаячак! Кече яшьтән үк системалы рәвештә туган телдә сөйләшү, гореф-гадәтләрне ныгыту, истә калдыру мәсьәләсе дәүләт тарафыннан ныклы игътибарга алынмау тәрбия процессындагы өзеклеккә юл куя. Татар телен, халкын саклап калуда татарча кино һәм мультфильмнарның да роле зур булуын без кайчан чынлап аңлый башларбыз икән соң?!

Китап күзәтүебезне дәвам итсәк, Р. Корбанның ел фасылларына бик тә игътибарлы булуын күрербез. Аларның үзләренә генә хас төсмерләрен, үзенчәлекләрен иҗат фантазиясенә төреп нәни дусларына тәкъдим итә ул. Табигатьтә барган катлаулы күренешләрне балалар аңларлык образларда бирә. «Сөзгәк болыт» шигыре бу турыда ачык сөйли. Күк күкрәү, яшен яшьнәү турында сүз алып барганда автор болытларны зур болында чабып йөргән бәрәннәр, колыннар белән чагыштыра. Бәрәннәр үзара сөзешкәндә җиргә утларның яшен булып атылуын, күк күкрәү, аннан яңгыр яву күренешләрен тәфсилләп сурәтли. «Җәйге яңгыр»да бу теманы алга таба дәвам итә, үстерә. Шагыйрь күк йөзендә төрле төсләр белән балкыган салават күперен, яңгыр явуын түбәндәгечә сурәтли:

Салават күперен гүя
Иңнәренә салган да,
Күр җәй кызын, кайтып килә
Чишмәдән су алган да.

Чиләкләре—зәңгәр болыт,
Әй чайкала, түгелә.
Болыннарга яңгыр ява,
Гөлләр күккә үрелә.

Барлык шагыйрьләр кебек Р. Корбан да җәй бизәге—сандугачны читләтеп үтә алмый.

Әрәмәдә сузып-сузып,
Өзеп-өзеп сайрады.
Ахры, шушы таллыкны ул
Мәңгелеккә сайлады,—

ди ул «Сандугач» дип исемләнгән шигырендә. Сандугачның матур итеп сайравын ишетсә дә, билгеле инде, баланың аны үз күзләре белән күрәсе дә килә.

Эзләдем, тик табалмадым.
Күренмәде анда ул.
Яфрак булып шыткан гүя
Үзе шушы талда ул.

Авторның әнә шулай балаларның психологиясен аңлап эш итүе әсәрне нәни укучылар күңеленә якынайта.

Җәй артыннан көз килә... Р. Корбан көзнең дә үзенә генә хас бизәкләрен тапкан. Мәсәлән, аның «Капкорсак һәм бавырсак» китабына *(Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1993)* кергән «Моңны уяттылар» шигырендә шагыйрьнең мондый юлларына сокланмый мөмкин түгел:

Каеннар бишек шикелле
Күренә туган якта.
Сары чыбылдык эчендә
Көзге моң йоклап ята.

Киек казларның каңгылдашып баш өстеннән очуы шушы иркәләнеп йоклап ятучы көзге моңны уята, чөнки галиҗәнап Вакыт һәрчак хәрәкәттә булуны ярата. «Моңны уяттылар» шигыре авторның иҗади уңышына бер мисал булып тора. Шагыйрьнең кыр казлары язын үзләре белән моң, сагыш, ямансулык та алып киләләр, ә көзен, аларны туып-үскән җирләрендә калдырып, китеп тә баралар.

Кошлар киткәч, калды күлләр
Тын булып.
Каурыйлар ятып калды.
Моң булып,—

ди автор «Каурыйлар» шигырендә әлеге фикерен дәвам итеп.

Кышлар үткәч, шул моңнары
Артыннан
Кыр казлары кайтыр әле,
Кайтырлар,—

дип юана аннары лирик героебыз.

Кышны да Р. Корбан яратып сурәтли. Аның шигыре «Тегүчеләр» дип исемләнсә дә, шушы фасылга багышланган:

Кыш болынга юрган сырган,
Туңмасын дип калын иткән.
Ә куяннар юрган читен
Тигез итеп тегеп киткән.

Менә зарыгып көткән яз килә. Бар табигать җанлана, шатлана. Тик, нигәдер, «шәһәрдәге бер өйдә»ге бүреккә генә ямансу. Нилектән икән? «Бүреккә ник ямансу?» шигыре бу сорауга тәфсилләп җавап бирә. Күпмедер дәрәҗәдә бүрек кызганыч та, чөнки яз җиткән, аның кирәге беткән. Шагыйрьчә әйтсәк:

Сагынган ул урамны,
Бик сагынган буранны...

Бүрек кенә түгел, бозлар да кышны ярата икән. Аларның да киң Иделне, туган җирләрен калдырып еракларга китәселәре килми:

Шул чак дәрья актарып
Зур гына боз килде дә,
Ә мин китмим, дигән күк
Ятты, ярга менде дә!

Р. Корбан нәни дусларын хайваннар дөньясының үзенчәлекләре белән дә таныштыра, үсемлекләр дөньясы турында да онытмый. «Ташбака», «Бака яфрагы», «Кәҗә сакалы», «Көтүче сумкасы», «Кашкарый» һәм башка әсәрләре шул турыда сөйли.

Тора-бара шагыйрь үзенең укучыларын фәлсәфи фикер дөньясына алып керә. «Үсәм», «Төн кая китә?» «Сукмак», «Ике агач» шигырьләре нәни укучыны бераз җитдирәк булырга, уйларга өйрәтә. «Үсәм» шигыре күпмедер дәрәҗәдә Агния Бартоның шул ук исемдәге шигыре белән дә авазлаш булып тора. Шулай җитдиләнә төшкәч, автор укучыларын татар халкының тарихи үткәне белән таныштыра башлый. «Сөембикә манарасы» шигыре шул турыда сөйли. Шагыйрь Сөембикә манарасындагы ай тарихы турында укучылар кабул итәрлек рәвештә һәм тарихи яссылыктан чыгып сүз алып бара.

Р. Корбанның шактый гына күләмле булып чыккан «Куркуын җиңгән куян» китабы *(Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2000)* балалар өчен язылган әкият-пьесаларны, шигырьләрне, җырларны үз эченә ала. Автор көчен яңа жанрда сынап карый, аның нәтиҗәләре исә куанычлы. Балалар күңеленә хуш килерлек мавыктыргыч әкият-пьесалар иҗат ителүгә сөенәбез. Биредә җәнлекләр тормышы, аларның яшәү өчен барган көрәше аша әдәп, әхлак мәсьәләләре һәм башка күп кенә проблемалар белән дә очрашасың. Әкият геройларын үзләренчә яратасың, кызганасың. Алар кешелек дөньясында яшәп килгән «нәрсә ул яхшылык, начарлык?» дигән мәңгелек сорауга җавап эзлиләр, иң мөһиме—үзләренең фикерләрен дәлилләргә, мөстәкыйль рәвештә уйларга өйрәтәләр. Язучының әсәрләре кызыклы, алар мавыктыргыч итеп, ягымлы юмор белән сугарылган. Һәр әсәр балалар дөньясының нинди дә булса бер серен ача. Әкият-пьеса һәм шигырьләрнең балаларга якын, аңлаешлы тел, сурәт чаралары белән язылуы нәни укучыны бик тиз җәлеп итә.

Урман шомлы, урман куркыныч.
Карурманда бигрәк күп ерткыч.
Их, нигә мин төлке булмаган?
Бүре булып кына тумаган?!—

дип җырлый «Куркуын җиңгән куян» әкият-пьесасының герое. Ул үзенең куян булып дөньяга килүеннән бер дә риза түгел. Аның да төлке кебек җайлы, бүре кебек курыкмыйча яшисе килә. Бераз моңаеп йөргәч, ул үзенең теләгән тормышка ашырырга керешә, тылсымчы ярдәме белән бүрегә әйләнә. Әмма бераздан болай итеп уңышка ирешеп булмаячагын ул үзе үк таный:

Бүре булып күп йөрдем,
Кайгы-хәсрәтләр күрдем,
Котылдым бу җәфадан,
Куян булдым яңадан!

Әйе, дөньяда иң әйбәте—үзең булып яшәү, ә моның өчен курыкмыйча яшәргә кирәк. Безнең куяныбыз да үзенең куркуын җиңеп, батыр куян булып яши башлый. Шушы ук китаптагы «Керпе малае дуслар эзли» әкият-пьесасы геройлары исә нәниләрне ничек итеп дус яшәргә, әйткән сүзеңдә нык торырга өйрәтә. Төрле авыр хәлләрдә дә дуслыкның кадерен белү кирәк икән. «Патша кызы һәм җырчы» пьесасында кетүче егет Илһамның табигать биргән моңы алдында барлык кешенең, шул исәптән патшаның һәм аның бердәнбер чибәр кызы Айсылуның да, баш июе сурәтләнә. «Бардым күлгә, салдым кармак» әкият-пьесасында татар халык әкиятләре белән рус халык әкиятләре элементлары үрелеп бирелгән. Биредә явызлык һәм гаделлек көрәше төп конфликтны тәшкил итә. Байлыкка гына табынган Шакир бай көлкегә кала. Аның мәкерле хәйләсен аңлап эш иткән Биктимернең максатына ирешүе исә дөреслекнең, яхшылыкның, батырлыкның тантанасын күрсәтә.

Шунысы куанычлы: Р. Корбанның һәр әкият-пьесасы өчен махсус җырлар иҗат ителгән. Алар ноталары белән китапның соңгы битләрендә бирелгәннәр. Бу инде үз чиратында әсәрләрне сәхнәләштерүне җиңеләйтә. Шуны да әйтү урынлы булыр, авторның әкият-пьесалары Казан дәүләт курчак театры, Татар дәүләт яшьләр театрының балалар аеруча яратып караган тамашаларына әверелделәр. Җыр текстлары да, көйләр дә уңышлы чыккан, алардагы һәр образ үзенә генә хас характерлы сыйфат белән бирелгән. Көйләрне композиторларыбыз Фуат Әбүбәкеров, Луиза Батыр-Болгари, Шамил Тимербулатов, Ислам Сафин һ. б.лар язган.

2002 елда Татарстан китап нәшриятында Р. Корбанның «Алмалы төн» дип аталган шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Китап үзенең бизәлеше белән үк балаларның күз явын алырлык итеп эшләнгән.



## Журналыбыз турында

**Билал Мамбет,**

Кырым татары язучысы.

*Әдәби дуслык—зур мәгънәдәге мәдәни дуслык ул. Кырым татарлары белән Казан татарлары арасындагы дуслык бу халыклар дөньяда ничәмә-ничә гасырлар яшәп килгән булса, шул кадәр дәвам итә. Безнең уртак мәгърифәтчебез һәм милләтчебез, атаклы «Тәрҗеман» газетасының нәшире Исмәгыйль бәй Гаспралы бар. Әгәр Казан татары Акчурин булмаса, Гаспралы да булмас иде һәм без аның бүген, бәлки, исемен дә белмәс идек...*

*Төптән карaганда, без бер ата-ана балалары, безнең тамырларыбыз уртак. Без килен-кияү алышып яшәдек, чөнки кан бер, милләт бер. Без татарлар—беребез көньяк, беребез төньяк татары. Инде безнең кырым татарларына 44 елны төшкән авыр тәкъдир һичкемнең башына төшмәсен. Кырымнан, кырым татарларын депортацияләгәннән соң озак еллар безнең әдәбиятыбыз рәсми рәвештә яшәүдән бөтенләй диярлек туктап торды. Ярты милләт кырылганда әдәбиятны яшәтү мөмкинлеге юк иде. Шул авыр елларда, 60-70 елларда безнең Ватанга багышланган хәсрәтле шигырьләребезне беренче тапкыр бастырып чыгарган басма—ул «Казан утлары»—элеккеге «Совет әдәбияты» булды. Әгәр дә ул еллардагы «Казан утлары» сәхифәләрен актарып карасаң, анда безнең классикларыбызның, шул чор шагыйрьләренең әсәрләрен күрергә була. Димәк, бөтен төрки халыклары әдәбияты арасында «Казан утлары» журналы, аның әдипләре, аның мөхәррирләре беренче булып безнең халыкның хәленә кереп, фаҗигасенә төшенеп, үзләренең күңел киңлеген күрсәткән, теләктәшлеген белдергән. Минем бу журналга, анда эшләүче фидакарь кардәшләргә кырым татар халкы, аның язучылары, сәнгатькәрләре исеменнән зур рәхмәтемне белдерәсем килә.*

Шунысын да искәртеп үтик, автор китап исемнәрен бик тә уйлап, нәниләрнең күңелен җәлеп итәрлек итеп куя: «Сөзгәк болыт» (1991), «Капкорсак» (1992), «Капкорсак һәм бавырсак» (1993), «Куркуын җиңгән куян» (2000), «Алмалы төн» (2002). Алар төгәл образларны күз алдына китереп бастыра, шуның нәтиҗәсе буларак укучы балаларда табигый рәвештә зур кызыксыну туа, китап эченә тизрәк кереп китәсе, андагы серләрне беләсе, ачасы килә. «Сөзгәк болыт», «Куркуын җиңгән куян» китапларына кергән әсәрләр балалар, хайваннар тормышында еш кабатлана торган кызыклы мизгелләрне, ел фасылларындагы аерым характерлы билгеләрне образлы итеп, юмористик тонда сурәтләп бирсә, «Алмалы төн» китабы исә, табигатьнең һәркем дә күреп, аңлап бетерә алмаган матурлык дөньясына кунакка дәшә, гүзәллекне күрергә, танырга өйрәтә. Гомумән, Р. Корбан туган як табигате күренешләре аша нәниләрнең саф күңеленә бәхет орлыклары сала.

«Алмалы төн» китабындагы Сабан туе темасы балалар өчен тагын бер яңалык булып тора. Лирик героебыз Сабан туен зур дәрт белән башлап җибәрә («Үзем башлыйм»):

Сабан туе! Сабан туе!
Шундый кызык, күңелле!
Ник чыкмаска көрәшергә,
Мин соң егет түгелме?

Алга таба ул бабасының, әтисенең дә оста көрәшче булуы белән мактанып ала («Батыр бабай»). Шулай да кыюлык, батырлык нәсел буенча оныкка күчмәгән, ахры. Чөнки «Колга башындагы әтәч белән сөйләшү» шигырендә лирик героебыз үзенең колга башына ук менә алмаслыгын чамалап, әтәчкә бераз сабыр итәргә куша:

Сабантуй беткәнче колга
Әле китәр кибеп тә.
Сабан туен күзәт, ул бит
Шәп күренә биектән.

Шактый үткен күренгән лирик героебыз мәйданга чыгып чүлмәк тә вата алмый («Чүлмәк ватканда»). Шулай да, кеше көлдергәне өчен, бүләк бирәләр тагын үзенә.

Бу китаптагы тагын бер яңалык—табышмаклар. Алар нәниләрне фикер, уй дөньясына алып керә, һәр әйбернең, процессның үзенә генә хас сыйфатларын, үзенчәлекләрен күрергә, тоярга, сиземләргә өйрәтә. Табышмаклар төгәллеге, камил эшләнеше белән истә кала. Учак турындагы табышмак үзе генә дә бу турыда ачык сөйли:

Утын салсаң утына,
Ул биергә тотына.
Янып беткәч утыны,
Биюеннән ул тына.

Шагыйрь ел фасылларының матурлыгы, үзенчәлеге турында яратып язды. Алга таба автор матурлыкны төннең үзеннән дә эзли һәм таба, аны төрле үтемле сурәтләү чаралары ярдәмендә укучыларына тәкъдим итә. Р. Корбан «Балачакның бер төне» шигырендә төнге җәйләүгә ат сакларга, «Йолдызлар»да төнлә йолдыз яңгыры карарга дәшсә, «Җәйге бер төн озынлыгындагы шигыр»ендә кояш баюдан таң атуга кадәр булган серле илаһи күренеш белән хозурланырга чакыра. Ә менә «Алмалы төн» шигырендәге әкияттәгедәй йолдызлы төндә:

Офыкта аҗаган
Күктән алма өзә.

Шагыйрь нәни дусларын әнә шундый сихри төндә тып-тын алма коелганны тыңларга, хуш исле алма исләрен иснәп, җәйнең иң матур мизгеле белән бер ләззәтләнеп калырга чакыра. Алмаларның матурлыгы, хушбуйлардан өстен исләре генә түгел, ә тып-тын коелуы да авторга табигатьнең,

яшәешнең матур аһәңе, көе, моңы булып ишетелә. Шулай шул: үзең яшәгән җирнең матурлыгын күрә, табигатьнең моңын, серләрен тыңлый белергә генә кирәк. Матур җәйге төндә алма коелганны ишеткән баланың кешелекле булып үсәсенә шагыйрь чын күңелдән ышана. Шуңа да бу мизгелне бергәләп кичерергә чакыра, балаларның күңелләренә шәфкатьлелек, әхлаклылык орлыклары сала, аны матурлык, нәфислек белән сугара.

Чын кеше булып үсү турында сүз барганда яраткан язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиевнең «Бәхилләшү» әсәрендәге тирән мәгънәле фикерләре хәтердә яңара. Язучы кырау тигән бәрәңге сабагы исен барлык исләрдән өстен күрә, чөнки шул ис аңа туган җирен—газиз авылын күз алдына китереп бастыра. Шул исне белмәгән, бер тапкыр да тоймаган шәһәр кешеләрен ул чын күңеленнән кызгана: болар әбиләр чуагы көннәрендә зәңгәр күктән очкан ап-ак тоҗым җепләрен күрмәгәннәрдер, ди. «Берәр кешенең юньсезлеген күрәм дә уйлап куям: юк, агайне, син шундый бер иртәне күрми калгансың». (Казан: Татарстан Китап нәшрияты, 1996, 88 б.) Әйе, табигать белән бәйләнеш югалу, аның матурлыгын авыл кешеләречә тирәннән тоя алмау адәм балаларының кешелек сыйфатларына китереп суга.

Р. Корбан табигать белән бәйләнешне саклап калуын, ныгытуны игътибар үзәгендә тота. Аның әсәрләрендә авыл табигате, тормышы алгы планга куеп тасвирлана. Шәһәр балаларын шагыйрь чынлап торып кызгана («Авылсыз малай»), чөнки алар авыл исенең («Авыл исе»), авыл сөтенең («Авыл сөте») нинди икәнлеген белмиләр, җиләк («Җиләктә»), гөмбә («Гөмбәдә») җыюның ләззәтен, тәмен татымыйлар, урманга кереп бер уч чикләвек җыяр өчен дә батыр булырга кирәк икәнлеге турында уйлап та карамыйлар («Чикләвеккә баргач»). Ә авыл балалары чыдам, нык, куркусыз, эшчән, кешелекле булып үсәләр—аларга табигать үзе булыша. Печән чабу исә үзе генә дә барлык авылдашлар, яшьтәшләр алдында имтихан тоту, тормышка хәзерлегеңне чынлап күрсәтү булып тора («Печән чапканда»).

Р. Корбан үзе Биектау районының Кече Битаман авылында туып-үскән. Бу турыда аның «Белеп сөйлим» дигән шигыре дә әйтеп тора. Ул авыл табигатьнең бик тә матур җиренә урнашкан. Шагыйрь әсәрләрендә үзе белгән, күргән кара урманнар, челтерәп аккан чишмәләр, йолдызлы, алмалы төннәр турында сөйли. Әйе, ул белеп сөйли, чөнки үзенең нәни геройлары кичергән маҗараларны ул үз башыннан үткәргән, уйнаган, шаярган, үзенекенә дә, бакча карачкысының кесәсенә дә алма тутырган, җиләген, гөмбәсен, чикләвеген дә җыйган, барлык яшьтәшләре кебек печәнен дә чапкан, Ашыт елгасына төшеп, «иң зур балык»ны да тоткан. Аңа ышаныгыз, бераз гына елмаеп, шаярткалап алса да, ул белеп сөйли, дөресен сөйли! Шулай итеп, әйләнә-тирәбездәге яхшы кешеләр, табигый ямь, матурлык турында сөйли-сөйли, шагыйрь гүзәллек дөньясына алып керә. Ә гүзәллек, матурлык дөньясында бер булган кеше тормышта ялгыш адым атламас, чын кеше булып гомер итәр.

**Равия ЗАРИПОВА**





## 34—СӘБӘ (САБА ИЛЕ) СҮРӘСЕ

**Сәбә сүрәсе 54 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. Сәбә—бер төбәкнең һәм шунда яшәүче бер кабиләнең исеме.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Күкләрдә вә Җирдә булганнарның хуҗасы Аллаһка гына мактау тиеш. Ахирәттә дә ул гына мактауга лаек. Ул—хикмәт иясе, бар нәрсәдән хәбәрдар.

**2.** Җир эчендәгеләрне дә, аннан чыкканнарны да, Күктән иңгәнне дә, Күккә ашканны да Ул белеп тора. Ул—миһербан иясе һәм ярлыкаучы.

**3.** Инкарьчылар:

—Кыямәт безгә килмәячәк,—диделәр. Әйт син аларга:

—Ялгышасыз!—диген.—Һичшиксез, киләчәк. Барча яшерен булганнарны белеп торучы Раббы хакы өчен киләчәк. Күкләрдә вә Җирдә тузан бөртеге кебек нәрсә дә Аннан качып калалмас. Хәтта аннан кечкенә булган нәрсәләр дә, аннан зурлары да, хактыр ки, ап-ачык итеп Китапка язылган.

**4.** Аллаһ иман китереп, игелек кылганнарны бүләкләү өчен шулай Китапка *(Ләүхел Мәхфүзгә)* язды. Алар өчен ярлыкау һәм ләззәтле ризыклар бар.

**5.** Аятьләребезнең тәэсирен зәгыйфьләндерергә маташучылар өчен дә, иң хәтәр— әрнеткеч газап булачак.

**6.** Белемле кешеләр Раббыдан сиңа иңдерелгән (Коръән)нең хак икәнен беләләр; аның (Коръәннең) мотлак өстен вә мактауга лаек булган юлга өндәүче икәнен күрәләр, ләкин **(7)** кяферләр үзара әйтте:

—*(Мәетләр)* череп, тетелеп туфракка әверелгәч, янадан тереләчәк, дип сөйләнүче кешенең кем икәнен күрсәтикме?—диделәр. **(8)**—Бәлки, ул Аллаһка каршы нахак сүз сөйлидер. Әллә соң ул җенләнгәнме?

Юк шул. Ахирәткә инанмаганнар гына *(Ахирәттә)* газапка дучар, *(бу дөньяда алар)* адашкан хәлдә яши.

**9.** Күккә—баш очларына, Җиргә аяк асларына карамыйлармыни соң алар? Әгәр Без ихтыяр итсәк, *(Карунны уптырган кебек)* аларны да җиргә уптырыр идек. Яки *(Әйкә халкы өстенә яудырган кебек)* өсләренә Күктән таш яудырыр идек. Шик юктыр ки, монда Раббыга итагать иткән һәр бәндә өчен *(Аллаһның бәндәләрен яңадан терелтәчәгенә)* катгый дәлилләр бар.

**10.** Хактыр ки, Даутка Без (башкалардан) өстенлек бирдек.

—Әй, сез, таулар, аның белән бергә тәсбих әйтегез,—дидек. Кошларга да шулай куштык. Аңа *(Даутка)* күндәм, йомшак тимер бирдек. **(11)**—Тимердән көбәләр *(сугыш киемнәре)* яса, бөжраларын дөрес тез,—дидек.—Игелек кылыгыз. Чөнки Хакыйкать—ул Мин. Ни кылсагыз да Мин яхшы күреп торамын.

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

**12.** Сөләйманга җилне тәгаенләдек, ул иртәнге җил белән бер айлык юлны, төнге җил белән бер айлык юлны үтәр иде. Эрегән бакырдан елга агызуны аңа тапшырдык. Аның әмерендә Раббының рөхсәте илә күндерелгән кайбер җеннәр дә бар иде. Аларның берәрсе әмеребездән баш тартса, аңа көйдерүче җәза татыта идек.

**13.** Ул җеннәр Сөләйман ни теләсә, шуны эшли иде: калалар сала, һәйкәлләр ясый, күл зурлыгындагы су коену кавузлары, ныклы терәккә куелган зур-зур казаннар, дисеңме. Әй, Даут нәселе, шөкер итегез. Ләкин бәндәләремнән шөкер итүчеләр бик тә аз. **(14)** Сөләйманны үлемгә хөкем иттек; ләкин аның үлгәнен берәү дә белмәде, фәкать аның таянган таягын корт ашап бетергәч, мәете егылып киткәч кенә җеннәр аның үле икәнен аңлады. Әгәр дә җеннәр яшерен эшләрне белүче булсалар, мескен хәлдә газап чикмәгән булырлар иде.

**15.** Хактыр ки, Сәбә кавеме яшәгән җирләрдә сабак алырлык гыйбрәтләр бар. Берсе—уңда, берсе сулда аларның ике бакчасы бар иде. *(Аларга әйтелде):*

—Раббыгыз биргәнне ашагыз вә Аңа шөкер итегез. Менә сезгә бай мәмләкәт һәм Аллаһ сезгә мәрхәмәтен мул бирә.

**16.** Ләкин алар йөз чөерде. Шул сәбәпле Без аларга Арим ташкынын җибәрдек. Аларның ике бакчасын да, әче вә ашарга яраксыз җимеш бирә торган, затсыз куаклар гына калдырып, харап иттек. **(17)** Менә, Без аларны шөкерсезлекләре өчен шулай җәзаладык. Без шөкер итмәгәннәрне генә җәзалыйбыз.

*(Тәфсирчеләр: Арим—ул бер үзәннең исеме, коточкыч мул яңгырлардан соң хәтәр ташкын шул үзәндә яшәүчеләрне һәлак итә, дип фаразлыйлар. М. Али әйтүенчә, Сәбә ул Йәмәндәге шәһәр, аның икенче исеме дә бар—Мәараб; ул Санадан өч көнлек юлда торган Мәарабтагы буа ярылып, шәһәрне су ташкыны баса, барысы да һәлак була. Бу—тарихи вакыйга.)*

**18.** Аларның ватаны белән бәрәкәт вә муллык биргән илләр *(Сәбә белән Шам-Сүрия)* арасында, эргәгә-эргә күренеп торган ничә авыл, шәһәрләр һәм юллар салдырдык.

—Төннәр буе, көннәр буе сез һич куркусыз йөрегез, сәяхәт итегез,—дидек.

*(Чыннан да, Корьәндә сурәтләнә торган бу юл, юл буендагы авыллар, шәһәрләр, сәүдә юлы булган. Бу сәүдә юлының ике илне дә бик нык баетканлыгы мәгълүм.)*

**19.** Моңа каршы алар:

—Йа, Раббыгыз, сәфәр юлындагы авыллар арасын ераклаштыр,—дип, үзләренә язык китерделәр. Без аларны төрле гыйбрәтле мәзәкләргә кертеп калдырдык. Һәм аларны *(авылларны)* таратып, ерагайтып утырттык. Шик юктыр ки, бу вакыйгаларда сабырлар, шөкер итүчеләр өчен сабак алырлык гыйбрәтләр бар.

**20.** Хактыр ки, Иблис аларның *(хөсетле)* теләкләрен игелекле дип күрсәтте. Һәм аларның барысы да аңа иярде. Иман китергән берничә адәмнән башкалары. **(21)** Ләкин Иблиснең аларга *(иманлыларга)* куәте җитмәде. Ахирәт көненә ышаныр-ышанмас булганнар белән чын күңелдән инанганнарны аерып күрсәтер өчен *(Иблискә)* аздыру ирекен бирдек. Синең Раббың барысын да күзәтеп сакта торучы.

**22.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйт син аларга:

—Аллаһны инкарь итеп, үзегез уйлап чыгарган илаһларга күпме генә ялварсагыз да, аларның күкләрдә дә, Җирдә дә тузан бөртеген кыймылдатырга да көчләре җитмәс. Күктә дә, Җирдә дә аларның *(Аллаһ белән)* уртак эше юк. Аллаһның да алар арасыннан ярдәмчесе булмас. *(Ул ярдәмгә мохтаҗ түгел.)*

**23.** Аллаһ хозурында *(Үзе рөхсәт биргәннәрдән башка)* бүтәннәрнең шәфәгате файда бирмәс. Ниһаять, аларның йөрәгеннән курку киткәч, алар әйтер:

—Раббыгыз ни әйтте?—диярләр. Алар да:

—Хак булганны боерды,—дип әйтерләр. Аллаһ—бөектер, мәһабәттер.

**24.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйт син:

—Күкләрне вә Җирдән сезгә ризык бирүче кем ул?—дип сора да:

—Аллаһ,—диген. Шулай булгач яки без яки сез тугры юлда, яки икебезнең беребез адашкан. **(25)** Әйт син:

—Без кылган гөнаһларга сез җаваплы түгел,—диген. Без дә сез кылганнар өчен җавап бирмәбез. **(26)** Әйт:

—Раббыбыз барыгызны да бер урынга туплаячак, шуннан соң барыбызны да хакыйкый хөкемгә тартачак. Ул—иң гадел хөкемдар һәм барысын да белеп торучы. **(27)** Әйт:

—Аллаһка тиң санаганнарыгызны миңа күрсәтегез әле,—диген. Юк шул, *(күрсәтә алмаслар)* чөнки бердәнбер җиңүче, барысы белән дә хикмәт илә идарә итүче—бары тик Аллаһ.

**28.** Без сине бөтен кешеләргә бары тик сөенечле хәбәр бирер өчен вә кисәтер өчен генә күндердек. Ләкин кешеләрнең күбесе бу турыда һични белми.

**29.**—Әгәр дә сез хаклы икән, вәгъдә иткәнегез (Кыямәт) кайчан килер?—дип сорыйлар. **(30)** Әйт:

—Сезгә шундый бер Көн вәгъдә ителде ки, ул бер генә сәгатькә дә сонга калмас, бер генә сәгатькә дә иртәрәк килмәс,—диген. **(31)** Кяферләр әйтте:

—Без моннан элек килгән китапларга да, Коръәнгә дә ышанмаячакбыз,—диде. Раббының хозурына китереп бастыргач, син ул залимнәрнең бер-берләренә ничек акырганнарын күрсәң *(исең-акылың китәр иде).* Зәгыйфь *(фәкыйрь)* саналганнар тәкәбберләргә:

—Сез булмасагыз, әлбәттә, без иман китергән була идек,—дип кычкырыр.

**32.** Масайган тәкәбберләр исә зәгыйфь саналганнарга *(Кыямәт көнендә)*:

—Тугры юлга чакырылганыгыздан соң безме сезне адаштырдык? Хактыр ки, сез үзегез гөнаһка баттыгыз,—дип әйтер. **(33)** Зәгыйфьләр тәкәббер залимнәргә:

—Юк,—дип кычкырыр.—Кич-көндез хәйлә-тозак кору булды эшегез. Чөнки сез өзлексез Аллаһны инкарь итүебезне теләдегез. Аңа тиң башка илаһларга табынырга куштыгыз.

Газабыбызны күргәч, алар эчтән ут янарлар. Без дә инкарь итүчеләрнең муеннарына тимер богаулар тагарбыз. Алар бары тик кылган гөнаһлары өчен генә җәзаланачак.

**34.** Нинди генә шәһәргә кисәтүче күндерсәк тә, бай житәкчеләр:

—Без сезгә күндерелгәнне инкарь итәбез,—диделәр. **(35)** Тагын әйттеләр:

—Безнең малыбыз да, балаларыбыз да күп. Шулай булгач, безгә берни дә *(Кыямәт җәзасы да)* куркыныч түгел,—диделәр. **(36)** Син әйт:

—Раббым теләгәненә мул ризык бирер вә теләмәгәненә ризыгын киметер. Ләкин бу турыда күп кеше белми.

**37.** Сезне хозурыбызга малыгыз да, балаларыгыз да якынлаштырмас. Иман китереп, игелек кылганнардан тыш. Аларга игелекләре өчен өстәмә бүләкләр бирелер. Алар җәннәттә иминлек эчендә калачак.

**38.** Аятьләребезне ялганга чыгарырга маташучылар җәзага дучар ителәчәк.

**39.** Әйт:

—Раббым теләгән колларына ризык бирер, теләмәгәненнең ризыгын киметер. Күпме хәер бирсәгез, Аллаһ аның бәрабәренә сезгә нигъмәт бирер. Ризыкландыручыларның иң хәерлесе—Аллаһ.

**40.** Ул Көнне Аллаһ барыгызны да бергә җыячак. Шунда Ул фәрештәләргә:

—Сезгә табынганнар шушылар идеме?—диячәк. **(41)** Фәрештәләр:

—Син—бөек, безнең дустыбыз алар түгел—Син. Бәлки, алар җеннәргә табынгандыр. Күбесе аларга табынды,—дип әйтер. **(42)** Бүген бер-берегезгә файда да, зыян да кыла алмассыз. Залимнәргә Без:

—Ялганга санаган утның газабын татыгыз,—дип әйтербез.

**43.** Ап-ачык аятьләребезне укыган чакта алар:

—Ул—сезне ата-бабаларыгыз табынган потлардан биздерергә теләүче, башкасы түгел. *(Коръәнне)* ул үзе уйлап чыгарган да, ялган таратып йөрүдән башканы белми,—диделәр. Өсләренә Хакыйкать *(Коръән)* ингәч, инкарьчылар:

—Көн кебек ачык, бу күз буудан башка нәрсә түгел,—диделәр.

**44.** Без аларга укып *(бозык)* сабак алырдай *(потларга табыныгыз, дигән)* китап җибәрмәдек, синнән элек *(мөшрик булыгыз дип)* кисәтүче дә күндермәдек. **(45)** Алардан элек яшәгәннәр *(пәйгамбәрләрне)* инкарь итте. Болар *(Мәккә кяферләре)* әүвәлгеләргә *(бөек мәдәниятккә ирешкән Сәбә, Гад һәм Самуд халыкларына)* биргәнебезнең уннан беренә дә ирешә алмадылар. Пәйгамбәрләрне ялганчыга чыгардылар. Мин биргән әҗер *(җәза)* ничек *(хәтәр)* булып чыкты?

**46.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйт син аларга:

—Сезгә бер генә үгет бирәмен. Икешәр, икешәр булып та, берәмләп тә Аллаһ тарафына юнәлегез дә, *(үзбаш)* уйлап багыгыз. Аркадашыгызда *(Пәйгамбәрдә)* һичбер тилелек юк. Ул бары тик сезне *(вакытында хак юлга басмасагыз)* дәһшәтле җәза килеп тотачагы турында кисәтер өчен җибәрелгән бер Пәйгамбәр генә,—диген.

**47.** Әйт:

—Мин сездән һичбер түләү сорамыймын. *(Хәерегез)* яныгызда калсын. Минем әҗерем Аллаһ хозурында. Ул—һәммә барчасына шаһит. **(48)** Әйт:

—Шөбһәсездер ки, Раббым хакыйкатьне уртага куючы. Чөнки Ул бөтен яшертен эшләрне яхшы белеп тора. **(49)** Әйт:

—Хакыйкать *(Ислам, Коръән, Пәйгамбәр)* килде, инде хәзер ямальлык китәр һәм кире кайтмас.

**50.** Әйт:

—Әгәр дә хак юлдан тайпылсам, үз башыма тайпылган булырмын. Тугры юлны тапсам, мин бары тик Раббымның вәхий иткәне *(Коръәне)* аша тугры юлны табармын. Шөбһәсез ки, Ул бик якында гына, барысын да ишетеп тора.

**51.** *(Ий, Мөхәммәд, аларның)* куркуга төшкән чакларын бер күрсәң иде. Инде аларга котылыш булмас, озакламый алар барыбер ерак түгел бер урында тотылачак. **(52)** Менә шул вакытта инде алар:

—Без аңа (Коръәнгә) иман китердек,—дип әйтер. Каян килеп инде *(никадәр көферлек кылган заманнардан соң)* бүген генә иманга кайта алсын? **(53)** Гәрчә, алар моннан алда *(Аллаһны да, Коръәнне дә, Пәйгамбәрне дә)* инкарь итте. Һәм читтән генә яшертен тозаклар корып яталар иде.

**54.** Ләкин моннан әүвәлгеләргә булган кебек, боларның да *(мәкерле)* теләкләре арасына киртә корылды. Шик юктыр ки, алар *(Аллаһ бармы, юкмы, Коръән хакмы, түгелме, дип)* икеләнүчеләре аркасында үзләрен куркыныч мохиткә куйдылар.

# 35—ФАТЫР (ЯРАЛТУЧЫ) СҮРӘСЕ

**Фатыр сүрәсе 45 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Фатыр—юктан бар итүче, яралтучы, булдыручы мәгънәсендә килә. Күп кенә тәфсирләрдә бу сүрә «Фәрештәләр» исеме белән дә йөри.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Күкләрне һәм Җирне яралткан, фәрештәләрне икешәр, өчәр, дүртәр канатлы илчеләр иткән Аллаһка мактаулар булсын. Аллаһ яралтылучыларны,

үзе теләгәнчә *(гүзәл йөз, матур тавыш, акыл, сәләтләрен)* арттырып яралта, үрчетә. Шик юктыр ки, Аллаһның һәр нәрсәгә кодрәте житә.

**2.** Аллаһның инсаннарга ачып сала торган рәхмәтен *(нигъмәт, иминлек, сихәт, гыйлем, ризык, яңгырын)* беркем дә тоткарлый алмас. Аллаһ янындагыларны Аннан башка бирәү дә тәгаенли алмас. Ул—кодрәт вә хикмәт иясе.

**3.** Әй, кешеләр, Аллаһ хозурындагы *(шулкадәр)* нигъмәтне хәтерләп калыгыз, онытмагыз. Сезне Күктән вә Жирдән ризыкландыручы Аллаһтан гайре *(шундый нигъмәтләрне)* барлыкка китерүче бирәр зат бармы? Аннан башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* Тәнре булырдай һичберкем юк. Шулай булгач, нигә *(Аннан)* йөз чөерәсез?

**4.** *(Ий, Мөхәммәд)* әгәр сине ялганчы дип атасалар *(каушап калма, түз, сабыр ит)*, синнән алдагы пәйгамбәрләрне дә ялганчы, диделәр. Бөтен эшләр Аллаһ хөкеменә кайтарылачак.

**5.** Әй, инсаннар, Аллаһ вәгъдәсенең хаклыгында шик юк. Шулай булгач, зинһар, сез дөнья тормышына алданмагыз. Ата ялганчы шайтан, ышанычыгызга кереп, Аллаһ юлында сезне тәп башына утыртмасын. *(Сак булыгыз!)*

**6.** Шайтан сезне дошман күрә. Бәс, сез дә аны дошман күрегез. Ул үзенә ияргәннәрне утлы җәһәннәмгә урнаштырыр өчен тырыша. *(Игелек кылу, гөнаһлы эшләрдән баш тарту—шайтанны дошман күрү булыр.)*

**7.** Көфер гамәлләр өчен әрнетүле газап хәзерләнгән. Иман китергәннәргә, игелек кылганнарга, матур яшәгәннәргә ярлыкау вә бөек әҗер булачак.

**8.** Яманлык кылып, игелексез булганнарга:

—Кылмышларыгыз бик тә яхшы *(көферне игелек)*,—дип күрсәтүче *(Иблис белән тугры юлдагы адәм бер)* булырмы? Шик юктыр ки, Аллаһ кемне шаштырырга теләсә, шуны шаштырыр, кемне тугры юлга бастырырга ихтыяр итсә, шуны тугры юлга бастырыр. *(Ий, Мөхәммәд)* шулай булгач, алар турында уйлап, хафаланма, жаның көймәсен. Аллаһ аларның нинди яманлык кылырга уйлаганына кадәр белеп тора.

**9.** Җилләрне истереп, болытларны куып йөртүче—Аллаһтыр. Без аларны *(болытларны)* үлгән туфраклы җирләргә җибәреп, тергезәбез. Үлеләрнен янадан терелүе дә нәкъ шулай булачак.

**10.** Үзенә абруй-дәрәҗә яуларга теләгән кеше белсен: абруй һәм дәрәҗә Аллаһ хозурында. Аның янына бары тик яхшы сүзләр генә барып ирешә. Аларны да Аллаһка игелекле гамәлләр генә житкерә ала. Мәкерле тозаклар коручылар өчен хәтәр газаплар бар һәм аларның ул тозаклары жимерелер.

**11.** Аллаһ сезне *(башта)* туфрактан, сонра мәнидән яралтты. Аннан соң сезне парлы-парлы *(ирле-хатынлы)* итте. Аның әмере булмыйча, бер генә ана да йөккә уза алмас, бала табалмас. Жан иясенә *(озын)* гомер бирелүе дә, гомеренең кыскартылуы турында да *(Ләүхел Мәхфүзгә)* Китапка ап-ачык язылган. Шик юктыр ки, боларның барысы да Аллаһ өчен бик ансат башкарыла торган эшләр.

**12.** Ике дөнья бер-берсенә тиң булмас. Бусы төчедер, эчеп, сусынны басар өчен яраклы. Монысы тозлыдыр, тәмсездер. Һәр икесеннән дә пакь ит *(балык тотып)* ашыйсыз вә киемнәрегезгә тагар өчен бизәнү әйберләре *(энҗе, мәрҗән, сәйләп)* табасыз. Аллаһның нигъмәтләреннән *(үз өлешегезгә тигәнен)* эзләп табыгыз да, шөкер итегез. Шуның өчен сезгә дингезләрне ярып йөзә торган көймәләр насыйп ителде. Күрмисезмени?

**13.** Аллаһ төнне көн белән аралаштырыр, көнне исә төн эченә кертер. Кояш белән Айны үз әмере белән йөртер. Аларның һәрберсе билгеләнгән

мөддәткә чаклы шулай йөрер. Боларның бөтенесен дә Аллаһ берүзе майтара. Барча милек—Аныкы. Аны инкарь итеп, сез табынган *(потлар, сын)*нар исә хөтта чикләвек кабыгындагы элпәнең бер җепселенә дә хуҗа була алмыйлар.

**14.** Әгәр дә сез аларны *(дога кылып, Илаһка тиңләштергән сыннарыгызны, потларыгызны, һәйкәлләрегезне ярдәм сорап)* чакырсагыз, алар сез чакырганны ишетмәс *(догаларыгызны кабул итмәс)*. *(Чөнки алар җансыз)* ишеткән сурәттә дә, сезгә җавап бирмәсләр *(ярдәм итә алмаслар)*. Кыямәт көнне Аллаһка тиң булудан ваз кичәрләр *(файда да, зыян да эшли алмаслар)*. Бу Хакыйкатьне сиңа барча нәрсәләрдән хәбәрле булган Аллаһтан башка һичкем әйтмәс.

**15.** Әй, инсаннар, сез Аллаһка мохтаҗ. Аллаһ, *(бөтен галәмнәр байлыгына)* хуҗа буларак, бернигә дә мохтаҗ түгел, Ул мактауга лаек. **(16)** Аллаһ ихтыяр итсә, сезне юкка чыгарыр һәм сезнең урынга башка бер халыкны бар итәр. **(17)** Бу эшләрне башкару Аллаһка бер дә кыен нәрсә түгел.

**18.** Һичбер гөнаһкяр башка кешенең гөнаһысын үз өстенә алмас. *(Гөнаһлары)* авыр булып, аларны ташышырга кардәшләрен чакырса да, кеше йөге башкасына төялмәс. Син бары тик, Үзен күрмәгән килеш тә, Аллаһка инанып *(гөнаһ эшләүдән)* курыкканнарны һәм намаз кылучыларны гына тугры юлга күндерә аласың. Пакьләнгән кеше үз файдасына пакьләнә. Кайтышыгыз Аллаһка булыр.

**19.** *(Күңел күзе)* сукыр кеше белән *(хакны аңлаган)* күзле кеше бер булырмы? **(20)** Караңгылык *(наданлык)* белән яктылык *(гыйлем)* берме? **(21)** Күләгә *(җәннәт рәхәтлеге)* белән көйдерүче эсселек *(җәһәннәм)* берме? **(22)** Тереләр белән үлгәннәр тиң булмас. Теләгәнә Аллаһ ишеттерер. Син кабердәгеләргә ишеттерә алмассың.

**23.** *(Ий, Мөхәммәд)* син фәкать кисәтүче генә. **(24)** Без *(игелек кылганнарга җәннәт тормышы булачак, дип)* сөенче алу өчен һәм *(гөнаһ кылганнарга җәһәннәм уты була, дип)* кисәтү өчен сине юлладык. Һәр халык өчен шундый кисәтүче (пәйгамбәрләр) күндердек. Үзенә кисәтүче *(пәйгамбәр)* килмәгән бер генә өммәт тә юк.

**25.** *(Ий, Мөхәммәд)* әгәр дә сине ялганчы, дип атасалар, *(кайгырма)* әүвәлге пәйгамбәрләрне дә шулай мыскыл иттеләр. Ул пәйгамбәрләр аларга ачык могҗизалар, аятьләр, гыйлем нуры чәчүче китаплар алып килгән булсалар да. **(26)** Ахырда мин ул инкарьчыларны җәзаладым. Күрдеңме, Минем җәзам ничек булды! **(27)** Карап бак, ничек итеп Аллаһ Күктән су иңдерде! Шуның белән төрле төстәге, төрле матур җимешләр өлгерттек. Тауларны ашкан ак, кызыл, башка төстәге *(ярлар, упкыннар)* һәм карга каурые кеби кап-кара юллар барлыкка китердек. **(28)** Кешеләр арасында да, хайваннар, мал-туар арасында да шундый төстәгеләре бар. Галим кеше Аллаһның җәзасыннан курка *(чөнки ул—укыган, белемле. Надан кеше генә Аллаһны бар дип тә белми)*. Шик юк ки, Аллаһ һәрвакыт өстен, чиксез ярлыкаучы.

**29.** Аллаһның Китабын укыганнар, намаз кылганнар вә үзләренә бирелгән ризыкны башкаларга күрсәтмичә дә, яшермичә дә *(хәер, садака, зәкят)* биргәннәр зыян күрмичә, төкәнмәс нигъмәтләргә өмет итә алалар. **(30)** Чөнки Аллаһ аларга тиешле әҗерен тәгәл итеп бирер, нигъмәтләрен арттырып та өләшер. Шик юктыр ки, Ул—киң рәхмәтле ярлыкаучы, шөкер иткәннәргә мул мөлкәт бирүче.

**31.** *(Ий, Мөхәммәд)* сиңа вәхий иткән Китабыбыз аннан әүвәл иңдерелгәннәр *(Тәүрат белән Инҗил)*не дөресләүче буларак, иңдерелгән хак Китап. Аллаһ—бәндәләрнең кылмышларын күреп, белеп торучы. **(32)** Соңра бу китапны бәндәләребез арасыннан сайлап алынган кешегә бирдек. Бәндәләр арасында үзенә-үзе зыян кылганнар да, урталыкны тотканнар да, Аллаһ рөхсәте илә игелек кылу юлында ярышканнар да бар. Менә игелек кылу шулай була. **(33)** Гаден җәннәтләре аларның әҗере булыр. Алар алтын

беләзекләр вә энҗеләр белән ясанырлар. Киеп йөри торган киемнәре дә ефәктән тегелгән булыр. **(34)** Алар әйтер:

—Өстебездән кайгыбызны китәргән Аллаһка—дан! Хакыйкатән, Раббыгыз—ярлыкаучы, чиксез нигъмәт бирүче. **(35)** Мәрхәмәте илә безне төп йортыбызга *(җәннәткә)* урнаштырды. Хәзер анда ару-талу да, бернинди мәшәкать тә *(эч пошу да)* булмаячак.

**36.** Инкарьчыларга җәһәннәм газабы бар. Алар анда үтерелмәсләр дә, газаплары да җиңеләйтелмәс. Кәферлектә алда барганнарны Без менә шулай итеп җәзалыйбыз. **(37)** Алар анда:

—Раббыбыз, зинһар, безне чыгар моннан, әүвәл кылган *(игелексез)* эшләребез урынына игелекле эшләр башкарыр идек,—дип үкереп ялварырлар.

—Сезгә уйлап аңларлык гомер бирмәдекме? Сезгә кисәтүче *(Корьән, Пәйгамбәр)* килмәдеме? *(Ни өчен игә килмәдегез!)* Хәзер инде *(җәзасын)* татыгыз! Залимнәргә ярдәм итүче булмас.

**38.** Аллаһ Күкләрдәге һәм Җирдәге бөтен яшерелгән *(байлык, серләр, адәмнәр качырып куйган хәзинә, яшерен гамәлләр)*не белеп торучы. Күңелләрегездә ни бар *(яхшы-яман теләк)*—барысын да ачыктан-ачык белеп торучы—Аллаһ Тәгалә. **(39)** Ул сезне Җир йөзендә мирасчы варис хөкемдарлар итеп яралтты. Бәс, кем кәферлекне сайлый, кәферлеге үз зарарына булачак. Кяферләрнең имансызлыгы Раббы катындагы җәзаларын гына арттырыр. Инкарьчыларның имансызлыгы үзләренә зыяннан башка һичбер нәрсә китермәс.

**40.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйт син:

—Аллаһны инкарь итеп, табынган ясалма илаһларыгызны күрдегезме инде? Миңа да күрсәтегез. Җир йөзендә алар ни-нәрсә иҗат итте? Күкләрне барлыкка китерүдә аларның катнашы бармы?—дип сора. Әллә соң Без аларга берәр Китап күндердекме? Алар шул Китаптагы дәлилләргә таянып, гамәл кыламы? Юк! Ул залимнәр бер-берсен алдаудан башка берни дә вәгъдә итә алмый.

**41.** Шик юк ки, Аллаһ күкләрне вә Җирне тәртипләре бозылмасын, дип әмерендә тота. Хактыр ки, әгәр дә аларның тәртибе бозыла калса, Аннан башка һичбер кем аларны тәртипкә сала алмас. Шөбһәсез, Аллаһ бик тә сабыр һәм ярлыкаучы.

**42.** *(Мәккә мөшрикләре)* Аллаһ исеме белән ант иттеләр:

—Валлаһи! Безгә дә кисәтүче пәйгамбәр килсә, башка халыкларга *(яһүд белән христианнарга)* караганда да без алданрак тугры юлга баскан булыр идек,—диделәр. Пәйгамбәрнең килүе аларның тугры юлдан ераклашуын арттырды гына. **(43)** Чөнки алар Җир йөзендә тәкәббер рәвештә яшәделәр һәм алар мәкерле тозаклар кордылар. Хәлбуки, кеше үзе казыган чокырга үзе төшә. Алар әүвәлдә яшәп *(гөнаһ кылган)* халыкларның *(яман)* язмышларыннан башка берәр тәкъдир көтәләрме? *(Гөнаһка батып та, җәзасын татымабыз, дип өметләнәләрме?)* Аллаһның канунында һичбер үзгәреш табалмассың. Аллаһның канунында читкә тайпылыш күрмәссең.

**44.** Алар бер дә читкә чыгып сәяхәт итмиләрмени соң? Үзләреннән алда яшәп киткәннәрнең тәкъдире ничек тәмамланганын белмиләрмени соң? Гәрчә, алар боларыннан көчлерәк иде. Күкләрдә дә, Җирдә дә Аллаһны бичара хәлдә калдыра ала торган көч юк. Ул—барысын да белүче һәм кодрәт иясе.

**45.** Кылмыш гөнаһларына күрә, Аллаһ инсаннарны җәзалый барса, Җир йөзендә бер генә җан иясе дә исән калмаган булыр иде. Ләкин Аллаһ *(җәза бирүне үзенә генә)* мәгълүм бер билгеләнгән вакытка кичектерә килә. Вакыты җиткәч, *(барысы да үз өлешен алыр)*. Хакыйкатән, Аллаһ колларын күреп тора.

# 36—ЙӘСИН (ЙӘСИН) СҮРӘСЕ

**Йәсин сүрәсе 83 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Исеме хакында фаразлар аз түгел. «Йә сиин»—йә инсан, дип тә аңлаталар. Имештер, Йәсин ул—Мөхәммәд Пәйгамбәр исемнәренең берсе. Йәсин сүрәсе ул—Коръәннең йөрәге, диләр. Йәсин—иң мәшһүр сүрәләрнең берсе. Мәрхүмнәр рухына багышлап укыла.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Йәсин. **(2)** Хикмәт тулы Коръән тотып ант итәмен ки, **(3)** *(ий, Мөхәммәд)* син, һич шөбһәсез, Пәйгамбәр булдың. **(4)** Син тугры юлдан барасың.

**5.** Бу Коръән—һәрвакыт җиңүче, ярлыкаучы *(Аллаһ)* тарафыннан иңдерелгән Китап. **(6)** Аталары *(Коръән белән)* кисәтелмәгән, үзләре наданлык эчендә калган кавемнәрне *(Кыямәт көнендәге җәза белән)* кисәтү өчен иңдерелде. **(7)** Дөресе шул, аларның күбесенә *(вәгъдә ителгән)* сүз *(җәза бирү)* хак булып чыкты бит. Чөнки аларның күбесе иман китермәде. **(8)** Хактыр ки, Без аларның муеннарына шундый богау кыршаулары салдык, ул кыршаулар аларның иягенә чаклы терәлеп тора. Хәзер инде аларның башы-борыны югарыга карап каткан.

*(Әлбәттә, бу гыйбарәләрне күчермә мәгънәдә аңларга кирәк. Богау кыршавы да, башларның югарыга карап катып калуы да аларның тәкәбберлегенә, кирелегенә, үзгәрмәс, буйсынмас булганнарына киная.)*

**9.** Без аларның алдына да, артына да киртә кордык, шулай итеп, аларны уратып алдык. Моннан соң алар инде *(Хакыйкатьне)* бөтенләй күрмәс.

*(Бу киртәләр аларның тәкәбберлеге. Тәкәбберлек, артык горурлык-масаю киртәсе бу халыкка хакыйкатькә ияреп, бөеклек яулау мөмкинлеген каплый, арттагы киртәләр исә Хакыйкатьне инкарь итүчеләрнең ничек һәлак булу тарихын күрергә комачаулый.*

Мөхәммәд Али тәфсиреннән.)

**10.** Кисәтсәң дә, кисәтмәсәң дә, алар барыбер иманга килмәс. **(11)** Син бары тик *(Коръәнгә)* йөз тоткан һәм чиксез мәрхәмәтле ярлыкаучыга *(Аллаһка чын күңелдән)* бөек хөрмәт күрсәтүче кешеләрне генә кисәтә *(иманга өнди)* алырсың. Менә шундыйларны син аларның ярлыкау алачакларын һәм бик тә шәрәфле әҗерләр белән бүләкләнәчәкләрен әйтеп шатландыр.

**12.** Дөресе шул, үлеләрне Без генә, бары тик Без генә терелтә алабыз *(имансызларны бары тик Аллаһ кына иманга китерә ала).* Алар эшләп калдырган бөтен нәрсәне, *(алар кылган бөтен яман гамәлләр турында)* Китапка Без язабыз. Без бөтенесен дә ап-ачык итеп *(Ләүхел Мәхфүз дигән)* Китапка теркәп барабыз. **(13)** Син аларга *(Антакия исемле)* шәһәр халкына илчеләр килгәннән соң булган хәлләрне гыйбрәт итеп сөйлә.

*(«Антиохия яки Антакия шәһәре—юнаннар-греклар тарафыннан безнең эрага кадәр 300 нче елда Сүриянең төньягында төзелгән шәһәр. Шул шәһәргә Гайсә галәйһиссәләмнең илчеләре килә».*

Али Тургут тәфсиреннән.)

**14.** Без аларга ике илче күндергән идек. *(Хәзрәти Гайсәнең сәхабәләре Юханнә белән Бәлвәсне).* Аларны *(илчеләрне)* ялганчы, дип атадылар. Без сәхабәләргә ярдәмгә өченче *(илче)*не җибәрдек. Илчеләр әйтте:

—Дөресен сөйлибез, без сезгә җибәрелгән илчеләр булабыз,—диделәр. **(15)** Алар:

—Сез безнең кебек адәми зат булудан башка беркем дә түгел,—диделәр.—Раббының сезгә һичбер нәрсә иңдергәне юк. Сез *(Аллаһ пәйгамбәрләре, дип кешеләрне алдап йөрүче)* ялганчылар икәнсез. **(16)** *(Илчеләр)* әйттеләр:

—Раббыбыз бик яхшы белеп тора: без, чыннан да, сезгә җибәрелгән илчеләр булабыз,—диделәр. **(17)**—*(Аллаһның хөкемнәрен)* ап-ачык итеп сезгә ирештерүдән башка безнең вазифабыз юк.

**18.** *(Шәһәр халкы)* әйтте:

—Күңелебез сизә: сез безгә бәла китерәчәксез. Әгәр дә сез *(безне мөселман булырга кыстаудан)* ваз кичмәсәгез, сезне таш белән бәреп үтерәчәкбез. Чыннан да, безнең тарафтан сезгә каты җәберләр булыр,—диделәр. **(19)** *(Илчеләр)* әйтте:

—Сезнең бәлагез үзегезнең көферлегегездән килә. Сезгә үгет-нәсихәт бирү—ул бәла китерәмени? Хәер, сез *(әхлаксызлыктан)* хәттин ашкан токымнан икәнсез.

**20.** Бу шәһәрнең иң кырый йортында яшәүче *(Хәбибүн Наҗҗар исемле бер кеше)* йөгереп килде.

—Әй, халкым,—диде ул.—Зинһар, бу илчеләргә иярегез! **(21)** Иярегез, чөнки алар сездән һичбер түләү сорамый. Алар—тугры юлны тапкан затлар. **(22)** Мин үземне яралтканга *(Аллаһка ни өчен)* коллык итмәскә тиеш әле? Сез барыгыз да фәкать Аллаһка кайтарылачаксыз. **(23)** Мин Аннан башка *(ялган)* тәңрегә табынмыймын. Әгәр чиксез мәрхәмәтле ярлыкаучы *(Аллаһ)* миңа бирәр зарар кылырга теләсә, алар *(уйдырма илаһлар)* һичбер файда бирә алмас иде. Алар мине *(җәзадан, тәмугтан)* коткара алмас иде. **(24)** *(Аллаһтан башкаларга табына калсам)* шик юк ки, ул вакытта мин, һичшиксез, юлдан язган кеше булыр идем. *(Шуннан соң иманлы Наҗҗарга таш ыргыта башладылар. Үләр алдыннан Наҗҗар болай диде.)* **(25)**

—Мин сезнең дә Аллагызга иман китердем. Моны *(Хакыйкатьне)* ишетеп калыгыз. **(26)** *(Үлгәннән соң аңа):*

—Бар, җәннәткә кер!—дип әйттеләр. *(Наҗҗарның рухы)* әйтте:

—Аһ, ни кызганыч, **(27)** Раббымның ничек итеп *(шәһид киткәнемнән соң)* мине *(җәннәткә)* лаек иткәнен халкым күрсә *(шаккатыр иде һәм иман китергән булыр)* иде.

**28.** Аның халкына *(җәзалау өчен)* Күктән *(фәрештәләрдән торган)* бер гаскәр дә җибәрмәдек, җибәрергә уебызда да булмады. *(Үч алуның кирәге булмады, чөнки алар инде җәзасын алды.)* **(29)** Аларга коточкыч куркыныч авaздан башка бернинди дә җәза бирелмәде. Алар шундук сүнеп *(үлеп)* юкка чыкты. **(30)** Ләгънәтләр яусын ул бәндәләрем *(кяферләр)* өстенә. Пәйгамбәрләр килә торды, аларны мыскыллап көлә тордылар. **(31)** Әллә соң алар *(мөшрикләр)* күрмиме? Алардан элек яшәп узган күпме *(бозык)* нәселне *(халыкларны)* без һәлак иттек. Алар беркайчан да бүгенге мөшрикләр янына яңадан әйләнеп кайта алмас. **(32)** Һичшиксез, аларның барысын да берәмләп Минем каршыма китереләчәк.

**33.** Без үле туфракка җан бирдек. Туфракта орлык үстердек. Алар *(шул орлык белән)* туена. Боларның барысы да аларга *(үлгәч терeләчәкләренә дәлил)* гыйбрәт—сабак түгелмени? **(34)** Без анда *(туфракта)* хөрмә баглары, йөзем бакчалары ясадык. Әчләрендә ничә төрле чишмәләр бәреп чыга. **(35)** Үз куллары белән үстермәсәләр дә, булдырылган нигъмәттән авыз итсеннәр дип, ризыклар яралттык. Шулай да алар шөкер итмәсләрмени? **(36)** Җир үстереп биргән нигъмәтләрне дә, кешеләрне дә һәм тагын аларга мәгълүм булмаган никадәр нәрсәләрне *(җанлы-җансыз)* парлы-парлы итеп яралтканга *(Аллаһка)* чиксез мактаулар!

**37.** Төн караңгылыгы да *(Аллаһның кодрәтенә)* бер дәлил. Без аннан көн яктылыгын суырып чыгарабыз. Шуннан соң алар төн караңгылыгында кала. *(Җир шарының яктылыгын бу якка суырып алгач, теге ягы караңгыда кала.)*

**38.** Кояш та *(Илаһи бер кодрәтнең дәлиле булачак)* үзенә *(Аллаһ тарафыннан)* билгеләнгән вакытка чаклы әйләнеп йөрер. Бу эшләр чиксез кодрәт иясе, *(һәр нәрсәне)* дөресе белән белеп торучы *(Аллаһ)*нын әмередер.

**39.** Айның хәле исә болай тора: *(әйләнеп йөрер өчен)* Без ана да тугәл тугым һәм фасыллар тәгаенләдек. Ниһаять, ул карт хөрмә агачының нечкә талы кеби, нәзек булып яңадан туар.

**40.** Кояш Айга килеп ирешә алмас, төннең дә көн белән бергә буласы юк. Җисемнәрнең барысы да *(төгәл билгеләнгән).*

**41.** Аларның *(Нухның)* токымын *(Туфан вакытында)* көймәгә төяп йөрткәнебез дә; **(42)** *(утырып йөрер өчен, йөк ташыр өчен, шуңа охшаш башка күчереп йөртү)* әсбапларын бар иткәнебез дә *(Аллаһның барлыгына, берлегенә, Ахирәтнең булачагына)* бер дәлил булып тора. **(43)** Ихтыяр иткән булсак, Без аларны батырып үтергән дә булыр идек. Ул чагында аларга беркем дә ярдәм итә алмаган булыр иде һәм алар котыла алмас иде. **(44)** Без мәрхәмәт итеп һәм мәгълүм бер вакыткача *(тәкъдирләренә күрә)* аларны коткарып, дөньяда яшәттек.

**45.** Аларга *(кяферләргә)*:

—Кылган һәм кылыначак гөнаһларыгыздан куркыгыз, бәлки, сезне ярлыкау көтәдер,—дип әйтелсә дә, алар йөз чөерде *(инкарьчы булдылар).* **(46)** Раббыдан килгән һәрбер аятьне алар инкарь итә торды. **(47)** Аларга:

—Аллаһ сезгә тәгаенләгән ризыктан *(садәка, зәкят)* бирегез,—дигәч, көферчеләр иманлыларга әйтте:

—Әгәр ихтыяр итсә, *(мохтаҗларны)* Алла *(үзе)* туендырсын. Аллаһ туендырырга теләмәгәннәрне ни өчен әле без туендырырга тиеш? Сез, мотлак, адашкансыз? **(48)** Чыннан да, сез дөресен сөйлисез икән, алайса, әйтегез: вәгъдә ителгән *(Ахирәт)* кайчан булачак?—диделәр.

**49.** Алар үзара бәхәсләшеп торганда, үзләре өстенә искәрмәстән килгән коточкыч авазданн башкасын ишетмәсләр. **(50)** Менә шул вакытта алар васыять әйтергә дә өлгермәс. Хәтта гаиләләре янына да әйләнеп кайталмаслар. **(51)** Сур быргысына өрелгәч, алар каберләреннән кубарылып, туп-туры Раббы хозурына ашыгырлар. **(52)** Кешеләр әйтер:

—Баш бетте, йоклап яткан җиребездән безне кем куптарды?

*(Җавабына бер тавыш яңгырар):*

—Бу *(яңадан терелү)*—чиксез мәрхәмәтле ярлыкаучы *(Аллаһ)*ның вәгъдә иткән нәрсәсе. Күндерелгәннәр *(пәйгамбәрләр)* дөресен сөйләгәннәр икән.

**53.** Бу—коточыргыч тавыш ишетелүгә үк, алар бөтенесе берочтан каршыбызга килеп басачак. **(54)** Ул Көнне беркемгә дә бернинди дә хаксызлык кылынмас. Сез дә кылмышларыгыздан башка нәрсә өчен җәза күрмәссез. **(55)** Шик юк ки, ул Көнне җәннәт әһелләре зәвык һәм куаныч эчендә бәйрәм итәр. **(56)** Үзләре дә, хатыннары да *(җәннәт)* күләгәсенә корылган кәнәфиләргә кырын ятып, истирахәт кылырлар. **(57)** Анда аларга саф җимешләр һәм күңелләре ни теләсә, шул китерелер. **(58)** Чиксез мәрхәмәтле Раббыдан аларга сәлам булыр.

**59.**—Әй, гөнаһкярлар, бүген сез *(саф мөэминнәрдән)* аеры торыгыз. **(60)** Әй, адәм балалары, сезгә:

—Шайтанга иярмәгез, ул сезнең хәтәр дошманыгыз,—дип боермадыммы? **(61)**—Мина сәҗдә итегез, тугры юлны табарсыз, димәдемме? **(62)** Дөресе шул бит инде, *(шайтан)* сезнең күбегезне юлдан яздырды. Сез әле һаман да шуны башыгызга китерә алмыйсызмыни? **(63)** *(Фани дөньяда ук сезгә)* вәгъдә ителгән җәһәннәм шушы булыр. **(64)** Имансызлыгыгыз *(кылган гөнаһларыгыз)* өчен хәзерләнгән утта янарга җәһәннәмгә керегез. **(65)** Ул Көнне авызларыгызга мөһер басарбыз, йозак салырбыз. *(Ягъни, кяферләргә, мөшрикләргә сөйләргә, акланырга мөмкинлек булмас.)* Аларның кылмыш гөнаһлары турында куллары сөйләр, аяклары *(һәм башка әгъзалары)* шаһитлек итәр. **(66)** Ихтыяр итсәк, аларның күзен сукырайтыр идек. Алар һични күрмәенчә, бер-берсен узарга тырышып, этешә-төртешә тугры юлны табарга тырышырлар иде. Ничек итеп алар *(күрмәгән килеш)* тугры юлны табар икән? **(67)** Ихтыяр итсәк, аларны торган урыннарында сурәтләрен үзгәртеп, бөтенләй башка кыяфәткә кертер идек *(ташка катырыр идек).* Алар алга китәргә дә, артка чигенергә дә көч табалмас иде. **(68)** Берәүсенә озын гомер бирә калсак, Без аны бөкрәйтеп бетерербез. Шул турыда уйлап бакмыйлармы?

**69.** Без *(Пәйгамбәргә)* шигырь өйрәтмәдек. *(Шигырь чыгару)* аңа килешми дә. Ул *(сезгә китергән)* Китап үгет-нәсихәт һәм *(Аллаһның кисәтүле)* әмерләрен житкезүче бердәнбер Коръән булыр. **(70)** Эчендә жаны булганнарга *(киләчәктә булачак җәзалар турында)* хәбәр бирер өчен. Кяферләргә вәгъдә ителгән жәзаның, һичшиксез, киләчәген раслар өчен *(Коръән иңдерелде)*. **(71)** Без аларга кодрәтебез илә маллар бирдек. Шул малларга алар хужа булды. Шуны да күрмәс дәрәжәдәмени алар? **(72)** Без *(ул хайваннарны)* аларга хезмәткә куйдык. Бәгъзеләренә атланып, йөк төяп йөрсеннәр, бәгъзеләрен суеп ашасыннар, дип. **(73)** Алардан *(хайваннардан)* күпме файда күрәләр һәм алар *(сөтләреннән)* эчемлекләр ясыйлар. Шулай да алар шөкер итми. **(74)** Алар Аллаһны инкарь итеп, үзебезгә ярдәмнәре тияр диеп, башка илаһлар *(сыннар, потлар)* уйлап чыгарды. **(75)** Ләкин аларның ул ясалма илаһлары берничек тә ярдәм итә алмас. Алар *(сыннар, яки Аллаһка тиңләштерелгән затлар)* үзләре дә *(Кыямәттә җавап тотар өчен)* өерләре белән каршыма килеп басачак. **(76)** *(Ий, Мөхәммәд)* алар сөйләгәннәр сине хафага салмасын. Хактыр ки, Без аларның яшертен теләкләрен дә, яшермичә кылганнарының барысын да белеп торабыз.

**77.** Кеше үзенең бер мәни орлыгыннан яралтылганын аңламыймы? Аяныч ки, ул ачыктан-ачык дошманлык кыла. **(78)** Ул үзенең бер мәни орлыгыннан яралтылганын онытып:

—Бу черемеш сөякләргә кем жан өрә алсын?—дип Безгә хәйләле сөаль бирә.

**79.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйт син:

—Аларны иң беренче ералткан *(Аллаһ)* терелтәчәк. Ул һәр яралтылганны асылы белән белүчедер,—диген.

**80.** Ямь-яшел булып үскән агачтан сезнең өчен ут чыгарган Аллаһтыр. Менә шуннан сез ут аласыз. **(81)** Күкләрне вә Жирне яралткан Аллаһ шуңа охшаш тагын башка галәмнәрне дә юктан бар итәргә кодрәтле түгелмени? Әлбәттә, кодрәтле. Ул һәрнәрсәнең асылын белүче, бөтен галәмне юктан бар итүче.

**82.** Аллаһ берәр нәрсәнең пәйда булуын теләсә:

—Бар бул!—дип әмер итә һәм шундук ул әйбер барлыкка да килә.

**83.** Һәммә барча милекне әмерендә тоткан Аллаһның даны никадәр дә бөектер. Барыгыз да аның хозурына кайтарылачаксыз.

صدق الله العظيم

*Əxmət Yerikəynen tuuına 100 yıl*

## CIR QALDIRA ALĞAN ŞAĞİR

*Əxmət Yerikəy—yegermençe yəz tatar şiğerendə in bilgele isemnərnen berse ide, meğəyen. Ğəmere də, icatı da qatlawlı, faciğəle sovet çorının bəten qarşılıqların, eyforiyə qatış rux kütərenkelegen, əmma, bəlki, üze də sizmiçə, xalqının in neçkə yara-qılların tibrətə, cırlıy alğan bu şağir—nəq şul çor balası. Başqortstannın Duwan rayonı Ølkende awılında tuıp, yəşli yətim qalğan, nuja kürep üskən yeget ozaq yıllar komsomol, partiə eşendə eşli, Məskəwdə—jurnalist, aktiv cəməğət eşleklese bula, M. Cəlil, Ə. Fəyzi, M. Maqsud, S. Battal h. b.—suğışqa qədərğe şawlap-gərləp yəşəgən başqala tatar ədipləre belən bergə icatta qaynıy.*

*1945—1950 yıllarda Tatarstan yazuçılar soyuzı idarəse rəise bula, nəq şul yıllarda ike mərtəbə SSSR Verxovnıy sovetı deputatı bulıp saylana; orden-medal'lər belən büləklənə.*

*Ə icatı? Küp sanlı şiğer, poema kitapları bar şağirnen: qalın saylanmaları, yuqaraq cıyıntıqları... Məskəwdə həm Qazanda in küp tərcemə itelüçe, rusça kitapları yış basılğan tatar şağire də ul bulğandır: S. Lipkinnan alıp E. Evtuşenkoğa qədərge tərle buın şağirləre tərcemə itte anı. Ul üze də rus klassikasın—Puşkin h. b. şağirlərnen əsərləren tərcemələde.*

*Əmma Ə. Yerikəyne bügen də xalıq künelendə yəşətüçe, haman da isemen yanğıratuçı janr—ul cır. Üz çorında da, xəzer də anın süzlərenə yazılğan cırlar hər kiçədə, hər konsertta diərlek yanğırıy: yegermençe yıllarda «Komsomolka Gəlsara»nı tınlap üssələr, sonraq «Kəkkük» (S. Ğəbəşinen ataqlı cırı), «Kil, çibərem», «Cırlamıym min cırlarımnı» h. b. bik küp cırları xalıq künelenə yul taptı. (baytaq məşhür kompozitorlarıbız kəy yazdı ana!). Wafatınnan son da yana kəylər yazılu dəwam itte: «Yullar, yullar», «Yəşlegemə kire qaytır idem» h. b.*

*Alarnı icat itüdə, yanğıratuda İlham Şakirov kebek bəyek cırçılarıbız da layıq ələşen kertə. Sonğı yıllarda basılğan kitapları da in yaxşı cır-şiğerlərennən saylap təzelde anın. Həm alar bügen də cır, kəy sonıy.*

*Bu sanda uquçılarıbızğa Ə. Yerikəynen mul mirasınnan saylap berniçə cırın təqdim itəbez.*

## Əxmət Yerikəy

TƏRLE YILLARDAN CIRLAR

### Sirinnər xuş is tarata

Cir yəze yəşərə, şatlana may,
Sirinnər xuş islər tarata;
Yəşərəm yaz kilgəç gəl sıman min,
Künelem yaz yəmen yarata.

Uylarnı tibrətə-tibrətə cır,
Əzderep İdeldə cırlıylar;
Şomırtlar tallarğa: «Saumısez!» dip,
Xuş isle qulyaulıq bolğıylar.

Aldımda bormalı-bormalı yul,
Min karıym yıraqqa-yıraqqa;
Kük küzlər haman da, haman da bit
Tınğılıq bırmilər yərəkkə.

Yılmaya kəkkükle, turğaylı yaz,
Kük küzlər də bəlki yılmayır;
Ay kebek ber genə yılmaysa da,
Yazlarnın ğəmere ozayır...

*1957*

## Tın baqçada

Tın baqçada qoşlar yoqlıy,
Ay yaqtısı su kebek.
Kəmeş təsle ay nurları
Nigəder monsu kebek.

Zəngər küktəge yoldızlar
Bizəklilər yılğanı.
Sin, aqıllım, kürəsenme,
Maturlığın dənyanın?..

Ay yaqtısı bigrək yaqtı,
Bigrək matur nurları.
Sin, aqıllım, iştəsenme,
Çişmələrnen cırların?..

Zəngər küzlər yılmayalar—
Serle maturlıq anda.
İkebez də bez bəxetle
İl bəxetle bulğanğa.

*1934*

## Kəkkük

*Gəlsem Sələymanovağa*

Kəkkük qıçqıra urmanda yaz kilgəç,
Cir yəşərgəç, qırlarda gəl üskəç.
Çut-çut itep tirəklərdə sanduğaç sayrıy,
Şul çağında yərəklərdə yana dərt qaynıy...
Nigə ul şulay?..

Kəkkük tawışın işetəsenme urmanda,
Ni əçen şul çaqlı monlana ul anda?..
Kemne sağına ul haman, xəsrəte bik yaman.
Əzgələnə, yana ul təmam, zarlana biçara.

Ul da şul, meskenkəy, sağınadır qoşqayın,
İn matur, in yaqın, can əzgeç dusqayın.

Kəkkük tawışı monlı diep, yamansulama,
dustım,
«Monlan!»—dip ana üzem quştım.

Ex, monlan, kəkkügem, urmanda!!
Kəkkük tawışı biğrək matur tınlarğa:
Kük-kü, kük-kü, kük-kü!
Bar qoşlarnı sayratırlıq məxəbbətem bar
sina.

Tınla, irkəm, gəl genəm,
Kəkkük tawışın ber genə:
Kük-kü, kük-kü, kük-kü!
Kəkküklərne sayratırlıq məxəbbətem bar
sina.

*1933*

## Künelem ezgələngən minutlarda

Künelem ezgələngən minutlarda,
Eştən buşağanda, kiçləren,
Küzləremə tağın oçramasan,
Sin bulmasan, irkəm, nişlərem?

Sürelerlek tügel məxəbbətem,
Suınırlıq tügel xislərem;
Salqın cillər kersə arabızğa,
Sin taşlasan, irkəm, nişlərem?

İstən çıqmıy sinen əytkən süzen,
Küz aldımnan kitmi təsləren;
Ğəmerem buylarına cəfalansam,
Ontalmasam, irkəm, nişlərem?..

*1957*

## Cəynen ayaz tannarında

1

Cəynen matur ayaz tannarında
Canğa rəxət İdel yarlarında.
Çıq cemeldi miləş yafrağında,
Yılmayalar gəllər bolında.
Qoşlar sayrıy yəşel quaqlarda
Yəşəw maturlığı turında.

2

Minem xəlləremne, minem xisne
İdel dulqınnarı səyli təsle.
Alqın İdel üze teli təsle
Minem belən serdəş bulırğa.
Qoşlar sayrıy yəşel quaqlarda
Yəşəw maturlığı turında.

3

Xəterlətep dulqın uynawların,
Uynıy minem yaqtı xıyallarım,
Məxəbbətem, dərtem, ideallarım
Küper bulır barır yulımda.
Qoşlar sayrıy yəşel quaqlarda
Yəşəw maturlığı turında.

*1959*

## Məmkin tügel

Yomşaq qına cillər: «Onıt!»—dilər,
Qayğırmasqa kiņəş birələr.
«Onıt!» digən təsle neçkə gəllər
Əkren genə cilgə ielələr.

Onıtırğa əndəp çişmə çıltrıy,
«Onıt, onıt!»—dilər bılbıllar.
«Onıt!»—digən təsle cem-cem itep,
Yılmayalar küktə yoldızlar.

Hərkem əytə: «Onıt, başqanı səy,
İke kilməs beznen ğomer»,—dip.
Yərək cawap birə: «Onıtırğa
Hiçber waqıt məmkin tügel!»—dip.

*1938*

## Kil, çibərem!

Kil yanıma, kil, çibərem,
Kil altınım, zəbərcətem,
Allarına gəl sibərem,
Kil, yaqtı məxəbbətem.

Kil yanıma, kiçqırın kil,
Kiç bulmasa, kil irtən;
Min sağınğannı belep kil,
Kilmi kalma, kil, irkəm.

Sine sayrap qarşılarlar
Baqçadağı bılbıllar;
Qaranğı dip, kilmi kalma,
Ay bulmasa, yoldızlar bar.

Kil yanıma, kil, bəxetlem,
Kennərəmə yəm kiter;
Kil, bəğerem, kil, qəderlem,
Künlemə bəyrəm kiter!..

*1946*

## Kətəm sine

Sin qaylarda yərisen ikən,
Altınım, kələç yəzle irkəm?
Qaytırsın dip, min əmet itəm,
Min sine haman kətəm, kətəm.

Kitmisen minem yərəgemnən,
Təşmisen minem tellərəmnən,
Kən sayın, səğət sayın, irkəm,
Min sine haman kətəm, kətəm.

Sağınalar sine asıl qoşlar,
Sağınalar sine yaqın duslar;
Künləm ezli sine kiç-irtən,
Min sine haman kətəm, kətəm.

«Sin» disəm, rəxət bula mina,
Əllə qayan keç cıyıla mina;
«Qət, irkəm!» digən güzəl süzen
Muzıka təsle toyıla mina.

Sinnən başqa ber yəm yuq mina,
Sin qaytmasan, bəyrəm yuq mina;
Tan balqu kebek qayt, irkəm,
Min sine kətəm, kətəm, kətəm!..

*1944*

---

## Киләсе елда укыгыз:

**Марат Әмирханов**. "Тояк эзе". *Роман.*
**Рафаэль Сибат.** "Инабәт". *Роман.*
**Камил Кәримов.** "Сакау күке". *Роман.*
**Галимҗан Гыйльманов**. "Албастылар". *Икенче һәм өченче китап.*
**Гөлчәчәк Галиева**. "Өзелгән өмет". *Повесть.*
**Әсгать Салах.** «Каеннар юлы». *Повесть.*
**Нурулла Гариф**. "Үткәннәргә сәяхәт". *Повесть.*
**Роза Хәбибуллина**. "Кемгә сөйлим серләремне...". *Повесть.*
**Әхәт Гаффар, Барлас Камалов** хикәяләре.
**Гөлшат Зәйнашева, Мансур Гыйләҗев**ләрнең драма әсәрләре.
**Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Фәнис Яруллин, Равил Фәйзуллин, Әхсән Баян, Рәдиф Гаташ, Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗанов** шигырьләре.

Журналда заманыбызның үткен проблемаларын яктырткан публицистик язмалар, бүгенге әдәби процессны анализлаган тәнкыйть мәкаләләре, юмор һәм сатира әсәрләре урын алачак. Корьәннең **Рабит Батулла** редакциясендәге нөсхәсе киләсе елда да журнал битләрендә дәвам итәчәк. Латин имласында уку үрнәкләре биреләчәк.

# ЯКТАШЫМ ГАЗИЗ

ГАЗИЗ МӨХӘММӘТШИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Әйе... Исән булса, Газиз,—үзе әйтмешли, Газизян,—житмешне тутырган булыр иде. Булыр иде...

Эре сөякле, куе кара чәчләре карга канатыдай ике якка аерылып төшкән, шәп кенә борынлы егет, чынлап та әрмәнгә тартым кыяфәтле иде... Күтәренке күнелле, һәрвакыт ачык йөзле Газиз Мөхәммәтшин, кырык яшенә дә житмәстән, арабыздан китеп барды—1972 елның кар-буранлы февраль аенда ук.

Февраль башларында Газиз минем эш бүлмәмә килеп керде. Һәрвакыт көләч якташымның йөзе сүрән иде. «Әни үлем түшәгендә икән, кайтып киләм инде...»—диде ул көрсенеп. Бу безнең соңгы күрешүебез булган икән. Ул туган авылы Яна Бикчәнтәйгә кайтып китте... Анын жәсәден Минзәлә хастаханәсеннән Зәки Нури барып алды. Ни хикмәт, үлеменнән соң да Газизнең йөзе тыныч һәм матур иде.

Газиз Мөхәммәтшин әдәбиятка иртә килеп керде. Әле Минзәлә педагогия училищесында укыганда ук анын шигырьләре район газетасында басылгалый иде. Күбесенчә табигать турындагы шигырьләре. Әмма Газиз тиз арада шигырьдән хикәяләргә авышты. Үз йөзен шунда—көлкеле-шаян хикәяләрендә тапты. Анын «Кадерле бүләк», «Минем характер» кебек хикәяләре 1955 елда «Чаян» журналы битләрендә дөнья күрде. Тәүге хикәяләре булса да, алар камил эшләнгән, телтеш тидерерлек түгел иде. Юкса Газиз Мөхәммәтшин бу вакытта әле Казан дәүләт педагогия институты студенты гына иде.

«Укып бетерүгә безгә киләсен, Газиз!»—диләр ана «чаянлылар». Ләкин ул елларда заманнар кырысрак булды. Газиз Мөхәммәтшин, институт тәмамлауга, Түбән өлкәсендәге бер татар авылына эшкә жибәрелде—мәжбүри ике елга.

Без—«Минзәлә педучилищесы оясыннан очып чыккан кошлар» (Газиз сүзләре)—Ләбиб Айтуганов, Спартак Әхмәтов һәм мин Газизне озатырга вокзалга төштек. Газиз, көләч булырга тырышса да, күзләре монсу иде. Вагонга кереп утыргач, ул: «Менә сез, егетләр, Казанда каласыз, ә мин Себергә үк китәм. Минем каршыма бер бәндәне кертеп утырталар, конвой белән. Мин сорыйм: «Абзый, кая барыш?» Ул әйтә: «Себергә лә! Кеше үтергән идем,—ди.—Ә син кая?» «Мин дә Себергә лә! Институт бетергән идем...»—дип жавап бирәм». Газиз шушы сүзләреннән соң үзенә генә хас көлү белән кеткелдәп куя.

Газиз Мөхәммәтшин Түбән якларында ике ел эшләп (1956—1958), кайтып та төште, озын-озакка сузмыйча, «Чаян» журналына әдәби хезмәткәр булып кереп тә утырды. Анын оештыру сәләтен тиз күреп алдылар: әүвәл «Ялкын» журналына, ә 1963 елны «Казан утлары» журналына баш мөхәррир итеп билгеләделәр.

Әмма Газиз еш кына зарлана иде, үзе зарланганда да елмая: «Үз әйберләренне язарга вакыт калмагач, тормышмыни бу?»—ди иде.

Шулай да ике дистә елга да тулмаган кыска ижат гомерендә Газиз Мөхәммәтшин аз эшләмәде. 1960 елда анын «Сер итеп кенә» исемле беренче китабы нәшер ителде. Көлкеле-шаян хикәяләр китабы. Ул миңа: «Марс дуска! Шушы бәләкәй генә нәрсәмне истәлек итеп зинһар ал әле. Пожалуйста, жәме? 9/V—60. Г. Мөхәммәтшин»—дип язып биргән иде. Бирелә дә Газизнең шукшаян холкы-табигате ярылып ята.

Шул унайдан тагын бер кызык та, кызганыч та вакыйганы искә төшереп узыйм әле.

Минем Татарстан радиосында эшләгән чагым, ә Газиз—«Чаян»да. Ураза көннәре иде. Газиз минем янга килеп керде: «Бер әйбер «пешереп» китердем

але»,—ди. Үзе көлә. Баксаң, ул «Иван мулла» дигән сатирик хикәя язган икән. Хикәяне ошаттык, озакка сузмый гына радиодан да яңгыраттык. Аннары мин тиздән туган якларыма ялга кайтып киттем. Кайтышка ук дигәндәй, Минзәлә педучилищесына барып кердем. Кирәк бит, әдәбият укытучыбыз булган Салих ага Латыйповны очраттым. Ул бик үзсүзле, кырыс абзый иде, мулла нәселеннән. Салих ага мина очып кунды: «Сез анда Газиз Мөхәммәтшин белән икәүләп нишләп безне рисвай итеп йөрисез? Без сезне дингә тел тигезергә өйрәттекме? Ниткән «Иван мулла» ул тагын?» Китте тезеп, китте тезеп! Күзне дә ачырмады. Сонрак Газизне дә эләктергән ул. Газиз миңа: «Бу «Иван мулла» белән яндык бит»,—кенә диде. Артык сүз катмады. Хикәясен дә яңадан күтәреп йөрмәде.

Ә инде соңгы китабы—«Йөрәктәге эзләр» романына Газиз болай дип язган: «Мөҗәһит Дәүләтуллинга—Марсель Давайга—Марс Шабайга якташын, сабакташын Газизяннан яшьлек, студент елларының, монастырьның бер истәлеге булсын! Газиз Мөхәммәтшин. 16/XI—71. Казан. */256-258 б.б./*» Бу сүзләр Газизнең вафатына нәкъ өч ай кала язылганнар... «Монастырь» дигәне пединститутның без яшәгән тулай торагы иде. Хәзер анда Татарстанның дәүләт архивы.

«Йөрәктәге эзләр» Газизнең беренче романы булды. Ул үзе безгә килеп өзекләрен укый, үзе кет-кет көлә: «Мин сине дә, «Азат хатын» журналындагы хатын-кызларны да тарихка кертеп калдырам әле»—ди. Сүзендә торды һәм шулай итте дә. Аның романындагы үзе күрсәткән 256-258 битләрдә мине ул бик көлкеле итеп сурәтләгән, шунда «Азат хатын» хатын-кызларын да санап үткән.

Газиз Мөхәммәтшиндагы жор теллелек романның һәр битеннән бөркелеп тора. Ул, әйтик, болай яза: «Яшь һәм чибәр кәләшләрнең жылы һәм йомшак кочагы, кайнар сулышы, колакларны иркәләгән өзек-өзек пышылдавы кемнәрнең генә жанын эретеп камыр ясамады инде, егетләр, һәм күпмебезнекен эретәчәк әле! Без дә адәм баласы бит, нигез ташы түгел—гади кеше!» Юк, Газиз ижатында гел генә кет-кет көлеп йөрүче булмады. Мәсәлән, шул ук романында ул гажәеп тирән, йөрәкләрне тетрәндерерлек мондый юлларны да ижат итте:

*«Атадан һәм анадан кадерле кем бар дөньяда безнең өчен.*

*Күктә ай белән кояш—бер.*

*Жирдә ата белән ана—бер.*

*Дөньяда алардан башка бары да табыла.*

*Алар безгә тормыш биргән, авырсак—баш очыбыздан китмәгән, ашның иң тәмлесен безгә каптырган, туңсак—күкрәгенә кысып жылыткан, егылсак—күтәреп торгызган, еласак—күз яшебезне сөрткән, кайгырсак—кайгырган, шатлансак—шатланган, без янсак—янган, без көйсәк—көйгән.*

*Алар безгә туган телебезне өйрәткән.*

*Беренче каләмне һәм дәфтәрне безгә алар сатып алган.*

*Көзнең бер якты иртәсендә шулар безне житәкләп мәктәпкә илткән.*

*Әнкәң ничек кенә булмасын, ул сиңа әнкә!*

*Әткәң ничек кенә булмасын, ул сиңа әткә!*

*Ата аркасы—кала аркасы. Жәйләүгә тугай яхшы, яхшыдан ата яхшы.*

*Яратыйк көмеш садак әниләрне!*

*Яратыйк алтын канат әтиләрне!*

*Ата-анасына хыянәт иткән зат Туган иленә хыянәт кылмас дисеңме!?»*

Романдагы бу юллар шигырь булып яңгырыйлар.

Ни кызганыч, Газиз Мөхәммәтшинның гомере озын булмады. Ул үзе: «Көлкеле бер роман язып, татарның Дон Кихотын тудырам әле мин!»—дип хыяллана иде.

Шулай да Газиз Мөхәммәтшин 7-8 китап бастырып өлгерде. Хикәяләреннән күләмлерәк әсәрләргә дә талпынып, «Без әле жирдә яшибез» (1963), «Саумысез, аккошлар» (1971) повестьларын һәм югарыда телгә алынган романын да ижат итте. Болардан тыш ул үзен драматургия өлкәсендә дә сынап карады. Шундыйлардан берсе—«Тынгысыз төн» комедиясе (ул «Казан утлары» журналының 1969 елгы 7 санында басылды), Татар дәүләт күчмә театры сәхнәсендә уйналды.

Якташым-сабакташым Газиз Мөхәммәтшинның әсәрләрендәге тормышчанлык, жыйнаклык-кыскалык, табигый тел-сурәтләү чаралары, жор-шаян теленең халыкчанлыгы аерым бер тикшеренү-күзәтүне сорый.

Мин биредә исә Газиз Мөхәммәтшин турында бик кыска итеп шәхси фикерләремне генә әйтергә тырыштым.

**Марс ШАБАЕВ**

# МӘХӘББӘТНЕҢ ГОМЕРЕ ЧИКЛӘНМӘГӘН

МОСТАФА НОГМАННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Мостафа Ногман әдәбиятка зур тормыш мәктәбе узып килә. Шуна да 1912 елның 22 декабрендә Арча районының Кызыл Яр авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туып-үскән егет иҗатка ашыгып-кабаланып тотынмый. Тормыш тәҗрибәсен тирән белем белән дә баету кирәклеген белеп эш итә.

1931 елда Казан педагогика техникумын тәмамлаганнан соң Татарстан һәм Таҗикстан мәктәпләрендә укытучы булып эшләгән М. Ногманга 1935—1937 елларда Дүшәмбе шәһәрендә Хәрби трибуналда секретарь вазифасын башкарырга да туры килә. 1937—1941 елларда шушы ук шәһәрнең педагогия институтында үзбәк һәм таҗик телләрен өйрәнү буенча белем ала. Бөек Ватан сугышы елларында юстиция өлкән лейтенанты сыйфатында Совет Армиясендә хезмәт итә, 1947—1951 елларда Мәскәүдәге Көнчыгышны өйрәнү институтында фарсы, төрек телләрен өйрәнә. Мостафа Ногман тормышны, яшәүне чын күңелдән яратучы кеше була. Әнә шул сыйфаты да аны, мөгаен, төрле халыклар белән аралашырга мөмкин булсынга—телләр өйрәнүгә сәбәпче булгандыр. Төрки халыкларның күбесе белән ул аларның үз телләрендә җинел аралаша, тел буенча алган тәҗрибәсе, белеме аңа тәрҗемә өлкәсендә зур уныш китерә дә.

Берәүләрнең күңелендә ул тел галиме, икенчеләрендә—балалар өчен поэмалар иҗат итүче, өченчеләрендә исә онытылмас җырлары белән калгандыр.

1969 елны дөнья күргән «XVII—XVIII йөзләрдәге русча-татарча кульязма сүзлекләр», «Иске татар язуы үрнәкләре» (1971) китаплары—М. Ногманның галимлек эшчәнлегенең якты мисалы. Шулай ук К. Насыйри иҗатын өйрәнүгә дә зур өлеш кертә ул.

Татар укучысын атаклы төрек язучысы Назыйм Хикмәт иҗаты белән дә беренчеләрдән булып М. Ногман таныштыра. Н. Хикмәтнең аның тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителгән беренче җыентыгы 1952 елда Казанда басылып чыга. Шулай ук, Рудәкый, Хәйямнәрнең шигырьләрен дә фарсычадан тәрҗемә кыла. Үзбәк язучысы А. Кадыйриның «Үткән көннәр» романын татар укучысы яратып кабул итә.

Заман рухы белән яшәгән шагыйрь буларак М. Ногманның шигырьләре бик күп теманы яктырталар. Аның беренче шигырьләре Бөек Ватан сугышы чорында языла һәм 1944 елда «Давыллы еллар лирикасы» исеме белән аерым китап булып басылып чыга. Шулай ук «Апрель җилләре» (1954), «Таң йолдызы» (1959), «Кокушкино таңнары» (1964) шигырьләр китабы һәм башка русча, татарча җыентыклары дөнья күрә. Заманында укучыларны патриотик рухта тәрбияләү йөзеннән язылган поэмалар да үз вазифаларын үтәгәннәрдер.

Тик шулай да, М. Ногманга шагыйрь буларак танылуны аның җырлары алып килә. «Карлыгандай кара күзләреңә» (1945) исемле беренче җыры ук (З. Исмәгыйлев музыкасы) ул елларда халык арасында яратып тыңлана һәм җырлана. Гомеренең соңгы көненә кадәр М. Ногман җыр жанрына тугры кала һәм композиторлар белән берлектә әле хәзергә кадәр онытылмаслык, хәтта халык җырлары дәрәҗәсендәге җырлар иҗат итеп калдыра. Рөстәм Яхин көйгә салган «Күзләрем тик сине эзлиләр», «Онытa алмыйм», «Ул гына аңлар кебек», «Бөдрә таллар», «Салагыш болыннары», «Әниләр» җырлары әнә шундыйлардан. «Сөн буйлары бөдрә урман», «Арча кичләре» һәм башка бик күп танылган җырлары—С.Садыйкова белән иҗади дуслык җимешләре.

Бер үк вакытта югары уку йорты мөгаллиме дә, шагыйрь буларак та танылган, матур сыйфатлары белән искә алынырлык җан иясен укучысы—танылган язучы Марсель Галиев үзенең «Догалы еллар» әсәрендә әнә ничек сурәтли:

«Мостафа аганың мәшһүр аһәнсаз Рөстәм ага Яхин белән язган «Бөдрә таллар» җырын мин бүген дә тыныч гамь белән тыңлый алмыйм. Әллә каян, бәгырьдән әрнүле сулкылдау күтәрелә дә... Назлы моң үзе үк сине өметсезлектән йолып алып, тирбәтә, юата башлый, талгын сагышлы халәткә кереп җанын тынычлана, чистарып кала. «Бөдрә таллар»—шагыйрьнең дөньялык белән берниди үпкәсез, якты сагыш белән бәхилләшү җыры булгандыр кебек тоела миңа».

Әгәр исән булса, аңа бүген туксан яшь тулган булыр иде. Шигърияткә, милли сәнгатькә эчкерсез бирелгән бу шәхес 1976 елның 4 сентябрендә 64 яшендә вафат була. Ләкин аның җырлары һаман яши, шагыйрь үзе әйткәндәй, мәхәббәтнең гомере чикләнмәгән.

Гөлзадә **БӘЙРӘМОВА**

*Юмор-сатира*

## Дамир Гыйсметдин

### Түләүле тамаша

Авылдан элеккеге күршебез Хөснетдин абый килеп төште. Туган-тумача булмаса да ул үзебезне кайткан саен олылап чәйгә чакыра. Аның белән күрешеп-сөйләшеп утыруы ни тора. Үзе кызыксынучан, үзе мәзәкчән, үзе һәр нәрсәгә борын тыгучан. Аның колхоз рәисеннән башлап Ельцин—Путиннарны сүгүен тыңлап утырганда гел митинглар, Макашовлар, Баркашовлар, Зәки Зәйнуллиннар искә төшә.

Килеп керде бит бу безгә кичатна көнне. Гомергә бер тапкыр дигәндәй... Ә минем эшкә барасы бар. Алдым сервантган бер яртыны, өстәлгә хатын пешереп калдырган ризыкларны куйдым һәм телевизорны кабыздым. Ял ит, мәйтәм, рәхәтләнеп. Бик кирәк булсам, миңа шылтырат. Бүген бераз иртәрәк тә кайтырмын әле, Алла боерса.

—Рәхәт яшисез, агайне. Бөтен нәрсәгез бар. Ярый кайгырма, әйдә бар эшеңә... Мин үземә берәр шөгыль табармын...

Эштән кайтып фатир ишеген ачып җибәрергә өлгермәдем—коридорда бераз кызарынган Хөснетдин абый күренде. Күзләре аптыраштан алҗыраган, тик йөзендә сихри нур балкый. Өстәлдә буш шешә тора һәм ниндидер кәгазь кисәге ята иде.

—Бу телевизорны, әйтәм, Хәкимҗан, әллә нинди каналлар бар икән сездә. Әллә нәмәрсәләр күрсәтәләр, малай. Канны кыздыралар, мәйтәм... Кызык та яшисез инде...

—Әйтмә дә инде, Хөснетдин абый.

Кунагым телефон өстәлчеге янындагы кәнәфигә барып утырды.

—Уш китмәле, Хәкимҗан энем... Менә досуг та, досуг, дип язалар телевизорларыгызда... Шылтыраттым шуларның берсенә, аннары икенчесенә... Нәрсә икән ул, мәйтәм?

Мин сагаеп калдым.

—Йә, шуннан?

—Думина сугалармы, шахмат уйныйлармы, тансы-мансымы, кәнсиртме? Шуны белергә дип, кат-кат шылтыраттым. Мөлаем тавышлы яшь кызлар белән сөйләштем.

—Нәрсә диделәр соң, Хөснетдин абый?

—Сәгатенә дүрт йөз тәңкәгә пулный программа диләр. Теләсәң имеш, кәрт сугарбыз, теләсәң тансы-манчы ясарбыз, курай уйнатырбыз... Әдрисеңне бир, агай, акчаңны хәстәрләп куй. Калганы, имеш, безнең эш... Аңлавымча, болар фатирга килеп кәнсирт күрсәтүчеләр булып чыга.

Мин бераз пошына башладым.

—Әдрисне бирмәгәнсеңдер бит, Хөснетдин абый!

—А как же...—Ул сәгатькә күз салды.—Тагын биш минуттан килеп тә җитәрләр...

Мин башымны тоттым.

—Хөснетдин абый, алар бит теге... ниләр... Мәрьям кайтып керсә, башлар себер китә бит, валлаһи газыйм!

Сүземне бетерергә өлгермәдем, ишектә кыңгырау шалтырады.

—Хөснетдин абый, зинһар, ача күрмә!

Ләкин авылдашым мине ишетмәде, ул юлбарыс кебек алга сикерде:

—Үзем! Хәзер!

Коридорда иреннәрен лачтырдатып кызылга буяган кыска итәкле ике яшь нәрсә пәйда булды.

—Сез Хуснутдинмы?—дип сорады берсе, нечкә бармаклы кулын алга сузып.—Мин Гуля. Только деньги вперед...

Икенчесе кереп җитмәс борын Хөснетдин абыйның муенына сарылды.

—Ну что, бабайка, акча бармы?

Хөснетдин абый кызларның бу кыланышларын аңлап бетермәсә дә, эшнең кая тәгәрәгәнен шәйли башлады.

—Карале, Хәкимҗан энем, болар эшне бик фырт тоталар, әй!

Үземне кочаклаган чибәркәйнең кулларыннан ычкынып, мин:

—Ишкәнсең ишәк чумарын... Болар бит фәхишәләр!—дип, Хөснетдин абыйга кычкырдым. Тик авылдашым югалып калмады...

—Әй, Хәкимҗан, бер картлыкта, бер яшьлектә. Чукынып китсен! Как раз ике айлык пенсия алган идем. Матурлар бит, карасана! Сара апаң рәнҗемәс әле.—Һәм күзләре үгезнеке кебек кызарган кунагым чибәркәйнең берсен безнең йокы бүлмәсенә алып кереп китте.

Монысы инде бөтенләй көтелмәгән борылыш иде!

—Хөснетдин абый, нишлисең?! Хәзер Мәрьям кайта, харап булабыз бит!—дип ыңгыраштым мин, гарьләнүемнән нишләргә белмичә.

Күрше бүлмәдән Хөснетдин абыйның чаптар аттай мышнавы гына ишетелде. Бу хәлләрнең ничек бетүен күзаллыйсыздыр сез, җәмәгать.

Әлбәттә, кәнсиртнең иң кызык җирендә, өйгә хатын кайтып керде... Әлбәттә, фатирда зилзиләләр купты, яшен яшьнәде... Әлбәттә, бу ямьсез хәбәр бик тиз арада Сара апаның колагына барып иреште... Әлбәттә, без хәзер Хөснетдин абый белән икебез дә буйдаклар...

## Язып кара!

Фельетончы Сәгыйть авырып киткәч, гәҗитнең баш редакторы очерклар махиры Газизҗанны чакыртты.

—Агайне, заманалар кырыс, халык авыр яши хәзер. Давай, кызыклы-мәзәкле усалрак нәрсәкәйләрне язып кара әле син...

Гадәттә тонналар, литрлар, үтәлгән йөкләмәләр турында гына язганга күрә, Газизҗан бераз аптырашта калды. Яхшы кешеләр, матур күрсәткечләр турында язу бер нәрсә... Ә фельетон, тәнкыйть... Тырышсаң, кулдан килмәслек эш түгелдер, әлбәттә. Аласың бер кимчелекне, кем әйтмешли, саласың кәстрүлгә, су кушасың, болгатасың, кайнатасың, тозын-борычын өстисең дә—менә сиңа фельетон!

Шулаен шулай да, икенче ягы бар шул, каһәрнең: шырдый-бырдый, усал нәрсә язып бирәрсенең ачуын китерсәң, үпкәләтсәң? Тәнкыйть бит ул сиңа сыра да, ширбәт тә түгел. Хәзер кеше сүз күтәрми. Бигрәк тә, начальство. Дары кебек кабынып китәләр. Җитмәсә, шәһәре дә кечкенә. Агайне ак-мыек, бер-беребезне яклыек дигәндәй, җүнле урыннарга район башлыгы Хәсән Галиевичның туган-тумачалары кереп оялаган. Ә Газизҗанга фатир аласы, телефон куйдырасы бар...

Озак баш ватты ул. Фельетон өчен темалар чәчелеп ята. Мәсәлән, юллар начар. Әйтерсең лә, бомбага тотканнар үзләрен, танклар белән үтүкләгәннәр. Язасы иде шулар хакында. Халык та рәхмәтле булыр иде. Фельетонның бәреп ега торган беренче җөмләсе дә әзер: «Рәсәйдә ике бәла бар—юллар һәм

тилеләр». Шул тармак өчен җаваплы идарә фәкать түрәләр бистәсенә асфальт салдыру белән мәшгуль. Тә-әк, ә идарә башлыгы кем? Әйе, Гали... Галиевич... Главаның абыйсы. Язып кара син ул хакта! Кулыңа кәҗә билеты тоттырып, егерме дүрт сәгать эчендә районнан сөрәчәкләр!..

Тагын уйланды Газизҗан. Кәнишне, фатирлар төзү һәм бирү идарәсендә дә сазлык. Андагы хәлләр турында фельетон гына түгел, сатирик вә криминалистик роман язарлык. Редакциягә жалулар да килеп тора. Нинди шәп нәрсә сырлап булыр иде. Билләһи газыйм, халык гәҗитне типографиясе белән бергә йолкып алып китәр иде дә, рәхмәт әйтә-әйтә укыр иде. Елдан-ел аска тәгәрәгән тираж бер мизгелдә күтәрелеп китәр иде. Язып кара, Газизҗан! Тәвәккәллә! Шундук фатир алыр идең. Идарә башлыгы Кәрим Галиевич икенче көнне үк кәҗүнни йорттан тимер рәшәткәлесен, кояшлы яктан бирдерер иде. Бернинди чиратсыз!

Озак уйланды Газизҗан. Бәлкем, җир бүлү турында язаргадыр... Анда да безобразие бит! Алып-сатып, үзләштереп бетерделәр җирне. Урман-күл буйларын, кәүсәр суларын дус-ишләргә тараткан җир комитеты башлыгы Харис ... Галиевичны өтәләргә иде... Өтәләрсең, бар... Главаның энекәше шул...

Янә уйланды Газизҗан. Әйе, иномаркаларның чамасыз күбәюе турында да шәп фельетон язып булыр иде. Һәр түрәнең аяк астында джип бит! Шуларны фотога төшерәсең, «мерседес»ларының асларына бәһасен язасың, янәшәсенә түрәләрнең рәсми хезмәт хакын сырлап куясың. Шуңа кыска гына бер-ике чеметә торган җөмлә өстисең дә—вәссәлам! Укы халык, мә сиңа—фельетон! Тикшер, эш кузгат, хөкем ит! Хәсән ... Галиевичтән башлап... Чү! Әллә нәрсәләр керә башка...

Озак уйланды Газизҗан. Темалар күп, фаш итәрлек фактлар буа буарлык, ә булачак фельетон геройларына якын барырлык түгел... Болай да, тегеләй дә, аксак кәҗәгә атланып та. Күңелдәге «кирәк» һәм «ярамый», ниһаять көрәшеп ардылар.

Көн кичкә авышканда Газизҗанның талчыккан йөзе кинәт яктырып киткәндәй булды. Ул кулына каләм алды, тиз-тиз нәрсәдер сырлап, шуны редакторга алып керде.

Гәҗит башлыгы тәмәкесен көйрәткән килеш кем беләндер телефон аша сөйләшә иде. Ниһаять, сүзен очлап, ул Газизҗанга төбәлде.

—Нәрсә, яздыңмы?

—Яздым, Галимҗан Галиевич,—диде журналист һәм язганын тиз генә шефның өстәленә салды.

—Бу нәрсә?—дип гаҗәпләнде редактор, кәгазьне боргалап.

Газизҗан күзен челт-челт йомгалады:

—Ни... Гариза ул, Галимҗан Галиевич. Икенче ел бит инде отпускасыз эшлим. Бик ардым. Ялга җибәрегез инде, пожалыста!..

# *«Казан утлары» архивыннан*



*«Совет әдәбияты» («Казан утлары»ның 1933—1965 еллардагы исеме) журналы хезмәткәрләре (сулдан уңга) Нил Юзиев, Малик Хәмитов, Яхья Халитов, Вил Ганиев шагыйрь Хәсән Туфан белән. Илленче еллар ахыры.*



*Бер төркем балалар язучылары (сулдан уңга) Абдулла Әхмәт, Зәкия Туфайлова, Җәвад Тәрҗеманов, Госман Бакир, Әминә Бикчәнтәева. Житмешенче еллар башы.*

# 2002 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

Татарстан Республикасы Президенты указы. 2002 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләрен бирү турында. N6

2002 елда булачак Бөтенроссия халык санын алу уңаеннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының татар халкына мөрәҗәгате. N3

Казан ханлыгы җимерелүгә 450 ел тулу уңаеннан Бөтентатар иҗтимагый үзәге мөрәҗәгате. N6

Бөтендөнья язучылар конгрессы резолюциясе. N11

**КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА**

Мөхәммәди Ә. Казан шәһәренең барлыкка килүе һәм аның борынгы исемнәре. N10

**III БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ**

Шәймиев М. Татар халкының киләчәгенә өмет белән карыйм. N11

Таһиров И. Без бербөтен, бүленмәс милләт. N11

Хәким З. Һәр замана безне сыный. N11

Бөтендөнья татар конгрессының III корылтае резолюциясе. N11

**«КАЗАН УТЛАРЫ»НА—80 ЕЛ**

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев котлавы. N5

Фәйзуллин Р. Бу гасырда да балкыр! N5

Арслан А. Халыкка хезмәт итү бәхете. N5

Әхмәтҗанов И. Тормыш китабы. N5

Бәйрәмгә шигъри бәйләм (И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Ә. Баянов, М. Шабаев, Р. Харис, Г. Рәхим, Ш. Маннап, Р. Гаташ, Р. Миңнуллин, З. Мансуров, Мөд. Вәлиев, Р. Низами, Н. Гамбәр, Н. Акмал шигырьләре). N5

Гайфуллин В. Милләт бөтенлеген кайгыртучы журнал. N4

Галиев Ә. Милләтебез горурлыгы. N3

Гыйләҗев А. Юл башында нурлы яктылык ул. N3

Гыйлемханов С. Ул мине гомер буе озата килде. N4

Закиров Ш. Хәзинә таптым! N4

Иванов В. Рухи терәгебез. N4

Мириханов Н. Саллы сүз мөнбәре. N4

Мостафин Р. «Совет әдәбияты»ннан—«Казан утлары»на. N2

Сафиуллина Ф. Әдәби-мәдәни юлдаш. N6

Сибагатуллин Ф. Милләтнең үзәк кашы. N5

Фәтхетдинов Ә. Кадерле яктылыклар. N3

Фоторепортаж. N10

Юсупов Р. Мөгаллимнәр мәктәбе. N5

Яруллин Ф. Гомерлек өстәл китабым. N2

**ЖУРНАЛЫБЫЗ ТУРЫНДА**

Гыйләҗев А., Өнәр М. N11

Госманов М., Мамбәт Б. N12

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XIV КОРЫЛТАЕ**

Президент Минтимер Шәймиев. Әдип каләме хаклыкка хезмәт итсен. N8

Вәлиев Мөд. Сөенсеннәр әле сабыйлар! N4

Вәли М. Тәнкыйтьне җанландыру—уртак бурыч. N8

Вәлиуллин Ф. Нефть төбәгендә әдәби мохит. N8

Габдрахманов Р. (Равил Фәйзуллин). Татарстан Язучылар оешмасы тарихыннан. N9

Галимуллин Ф. Нәтиҗәләр һәм бурычлар *(Татарстан Язучылар берлегенең XIII—XIV корылтайлар арасындагы (1999—2002) эшчәнлеге турында хисап доклады)*. N8

Имамов В. Күңелне борчыган уйлар. N8

«Казан утлары» яктырак балкыр! *(1999—2002 елларга хисап)*. N8

Корбан Р. Балалар китабына мөнәсәбәт. N8

Сафин Ф. Гыйбрәт алыйм дисән. N9

Сверигин Р. Гасырлар чатында. N4

Хәмид Р. Татар драматургиясе миллиме? N4

Татарстан язучыларының XIV корылтае резолюциясе. N9

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Фәйзуллин Р. Яна елда янарган уйлар. N1

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Вәлиев Р. Биш патрон. *Хикәя.* N8

Гадел Ә. Өрәк һәм аучы. *Хикәя.* N9

Галиева Г. Барсам. *Хикәя.* N12

Галиуллин Т. Жир алмасы. *Хикәя.* N6

Гариф Н. Кыска хикәяләр *(Мәгъсум Хужинның кереш сүзе белән).* N1

Гыймадиева Л. Капка. *Хикәя.* N3

Закиров Х. Ләхет. *Хикәя.* N12

Зәйнуллин З. Гарасатлы юллар. *Повесть.* N1

Ибраһим Х. Арыш арасыннан йөгерүче бала. *Хикәя.* N11

Ихсанова Л. Күнел күзе күргәндә. *Парчалар.* N4

Кәбиров М. Сары йортлар сере. *Повесть.* N2

Кәримов К. Ак бүрек. *Повесть.* N6

Маликова М. Өермә. *Детектив роман.* NN11,12

Мирхәйдәров Р. Һәрнәрсәгә—акчалата. *Роман.* NN7-10

Мөдәррисова Х. Бәйге хакы. *Повесть.* N5

Салах Ә. Сонгы вальс. Повесть. N10

Сафин Ф. Саташып аткан тан. *Роман.* NN4-6

Сирматов И. Бүре баласы. *Хикәя.* N6

Поварисов С. Ожмахка бер адым. *Роман.* NN2,3

Фәизов Р. Рәхим итегез, сэр! *Фантастик хикәя.* N5

Хәбибуллин М. Йөрәккә тамган язгы тамчылар. *Хикәя.* N12

Хәлим А. Бөркетле баганалар. *Хикәя.* N1

Хөснияр З. Айның туган-тумачасы юк. *Хикәя.* N5

**ШИГЪРИЯТ**

Аймәт Р. Кая бакма—жәйрәп ята ирек. *Шигырьләр.* N1

Акъегет Р. Язмыш Атлантидасы. *Шигырьләр.* N8

Әгъләм М. Ходай бирде безгә ярлыкны. *Шигырьләр.* N2

Әхмәтжан Роб. Дастаннар жире. *Шигырьләр.* N8

Әхмәдиев Н. Дөньяларны гаярь ир бизәр. *Шигырьләр.* N4

Баян Ә. И. гомер, дип өзелә гел. *Шигырьләр.* N12

Вәлиева Р. Бәхетле булыгыз, дусларым. *Шигырьләр.* N7

Гаделша Ш. Себер ягы—мон ягы. Шигырьләр. N6

Галиев Ш. Сез дә, без дә түгел тамырсыз. *Шигырьләр.* N11

Гамбәр Н. Исән чакта... *Шигырьләр.* N11

Гыйләжев И. Туйкә буйларыннан кояш калка. *Шигырьләр.* N7

Ерикәй Ә. Халкыма. *Шигырь.* N12

Закир М. Вакыт аты. *Шигырьләр.* N10

Зыялы С. Сөю дәвамы. *Шигырьләр.* N7

Зөлфәт. Сүзләрнен бар шундый кәрваны... *Шигырьләр.* N3

Идиятуллин Р. Шул бер гомер эчендә. *Шигырьләр.* N5

Иксанова И. Кышларның суыгын жылытып. *Шигырьләр.* N3

Кәримов М. Китәсе килми. *Шигырьләр.* N2

Корбан Р. Мин бер генә яшим дөньяда. *Шигырьләр.* N6

Латыйп К. Канатлы алмалар. *Шигырьләр.* N5

Мансуров З. Ике еглау. *Поэма.* N10

Мәхмүдов Ә. Ак төшләр. *Шигырьләр.* N7

Мингалим Р. Онытылмас хатирәләр. *Шигырьләр.* N4

Мостафин К. Юлчы турында баллада. *Шигырьләр.* N11

Мулла Гали С. Үлемсез булыйк. *Шигырьләр.* N9

Низами Р. Ике мөһажир. *Шигырьләр.* N1

Садә Г. Каридел аръягында. *Шигырьләр.* N7

Сафина Н. Жырны—жырга, серне—сергә. *Шигырьләр.* N8

Сәгадәт К. Кайтып киләм. *Шигырьләр.* N3

Сибгат К. Бурыч. *(Басылмаган шигырьләреннән.)* N2

Синугыл Ә. Төрки болаклар. *Шигырьләр.* N6

Танчулпан. Мәнгелек йөрәге. *Шигырьләр.* N6

Тарханова Ф. Исемебездә—сер, көч бар... *Шигырьләр.* N8

Фәйзуллин Р. Яна шигырьләр. N4

Шагыйрьжан Л. Дөнья базары яхуд яна «Америка фажигасе». *Лирик-публицистик поэма.* N9

Шәрифуллина Э. Каюм коесы. *Поэма.* N3

Шәрипов Р. Ил эчендә—ил. *Шигырьләр.* N4

Шиһап Р. Моннар яшь жирдә. *Шигырьләр.* N12

Юзеев И. Яна шигырьләр. N1

Юныс Р. Габделвәли бабама. N2

Юнысова А. Сөенче. *Шигырьләр.* N9

Янсуар Л. Әле кош мин—күкләрендә. *Шигырьләр.* N11

Яруллин Ф. Тауларга карап. *Шигырьләр.* N5

### ҺӘР ТӨБӘКТӘ—БЕЗНЕҢ КАЛӘМДӘШЛӘР

Гыйлфан Ф., Мортазин Ф., Сабиров И. шигырьләре. N1

Апушев П., Вафин М., Мусин Ч., Сафин М., Сәгыйдуллина Л., Суфияров Ф., Шәех Ф. шигырьләре. N12

### ЯҢА ИСЕМНӘР

Габделхакова Р. Хикәяләр *(М. Закирның кереш сүзе белән).* N11

Латыйпов Х. Өшегән йолдызлар яктысы. *Шигырьләр (Р. Гаташның кереш сүзе белән).* N4

### ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Гали Г. Харис Саттаров. N3

Еники Ә. Әйтелмәгән васыять. N12

### ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Мингалим Р. Дүрт кешелек утыргыч. *Драма.* N11

Салихов Д. Мөгезле Мәүлихан. *Комедия.* N4

Фәттах Н. Сармат кызы Сәринә. *Тарихи драма.* N7

### ӘДӘБИ МИРАС

Мәҗитов З. Рәнҗемәгез. *Шигырьләр.* N8

К. Маркс, Ф. Энгельс, И. Джугашвили (Сталин), А. Луначарский, Ю. Андропов, Мао Цзедун, Хо Ши Мин шигырьләреннән тәрҗемәләр. *(Ә. Рәшитовның кереш сүзе белән.)* N6

Шамов А. Гомерем танында. *Автобиографик повесть.* N6

### ПУБЛИЦИСТИКА

Абдуллин М. Авыл яшәсә, ил яшәр. N11

Әхмәтжан М. Сәяси уйланулар. N2

Борһанов Ә. Дөнья күзгесендә—урыс гамәле. N4

Борһанов Ә. Татар! Дәреслекне бел! N10

Гарипова Ф. Сан алудагы сырт санау. N8

Гариф Н. Син яшәсән, без дә яшәрбез. N7

Гәрәев М. Солтанатлы генерал. N10

Госманов М. Янадан танышу яки фидакарь хәйриячеләребез хакында. N5

Зарипов М. Садриевча сөрү. N6

Зыятдинова Ф. Россия федерализмының яна мәсьәләләре. N8

Михайлова С. XIX гасырда Казан университетында шәрык телләрен өйрәнү. N12

Саттаров Г. И газиз телем! N7

Таһиров И. Татарлар—мәңгелек халык. N8

Хәким Р. Кем син, татар? N7

Хәлен ничек, татар китабы? *(«Рухият» нәшриятында «Шәхесләребез» сериясе чыга башлау уңаеннан түгәрәк өстәл янында әңгәмә).* N7

Хәлим А. «Яңа сагыш китабы». N9

Хәмидуллин Л. «Бәр, мылтыгым, бәр...» *Эссе.* N11

### МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

Надиров И. Төркиядәге ике милләттәшем. №8

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Гаташ Р. Йолдызларны танып, сөенә белик... N3

Гафиятов А. Сөйләр сүзләр әле никадәр. N11

Җәләлиева М. Тойгы катламнары. N11

Закир М. Йомшак агачны корт баса. N1

Мостафин Р. Бәхетлеләр һәм бәхетсезләр. N6

Рахмани Р. Кыйбласына тугрылык. N4

Хатипов Ф. Традициядән тайпылып. N1

Хафизов С. Очмыйча син түзеп кара... N7

Яна гасыр, иске проблемалар *(«Казан утлары» журналы редколлегиясенең киңәйтелгән утырышыннан).* N2

**ТЕЛ ДӘРЬЯСЫ ТИРӘНДЕР**

Сафиуллина Ф. Хәзерге әдәби телебез үсеше. N11

**ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА**

Гыйләжев Т. Габделбари Баттал— тәнкыйтьче. N2

Миннегулов Х. Исхакый васыятенең иясе. N6

Минһажева Л. Халык иҗатыннан көч алып. N3

Рахман Р. Төрек-татар әдәби бәйләнешләренең кайбер сәхифәләре. N7

**ТАРИХ**

Габдүш Х. Бөек «Кушлавыч» ятиме. N1

Гайнанова Л. Рәшит Рәхмәти Арат һәм Гаяз Исхакый. N3

Кляшторный С. Татарларның Үзәк Азиядәге дәүләтләре *(Монголларга хәтле чор).* N9

Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда. N3

Миннегулов Х. «Яңа милли юл» журналы һәм Тукай. N1

Сабиржанов Г. Әхмәтһади Максудиның иҗади мирасы сәхифәләреннән. N7

Солтан. Габдулла Тукай. N1

Урманче Ф. Мең ярым ел элек. NN7,8

Хәмидуллин Б. 1552 ел фаҗигасе тарих битләрендә. N9

Шәмси С. Низаглы йортта. N1-6

**ЮБИЛЕЙЛАР**

ӘХМӘТ ЕРИКӘЙНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Редакцион мәкалә. N12

РӘХИМ САТТАРНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Редакцион мәкалә. N8

ӘХСӘН БАЯНГА 75 ЯШЬ

Гаташ Р. Өлкән каләмдәш Әхсән Баянга бер лирик бәян. N12

МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИНГА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. N12

МӘХМҮТ ӘХМӘТҖАНГА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. N2

КАВИ ЛАТЫЙПКА 75 ЯШЬ

Гаташ Р. Үҗәт яугир, самими шагыйрь. N5

САФУАН МУЛЛА ГАЛИГӘ 75 ЯШЬ

Гаташ Р. «Татарның тулы йортыннан...» N9

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Галимуллин Ф. Олы юлның юлчысы. N10

КАМИЛ МОСТАФИНГА 70 ЯШЬ

Гаташ Р. Физик та, лирик та... N11

РИФАТ СВЕРИГИНГА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. N8

ГОМӘР САТТАРОВКА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. N7

ЛИРОН ХӘМИДУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. N11

ГАЗИЗ КАШАПОВ-ҮЗИЛЕНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Нәҗмиев Т. Үзи авылының Газизҗаны. N8

КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Шабаев М. Сөенә дә, көенә дә күңел. N2

АЙДАР ХӘЛИМГӘ 60 ЯШЬ

Шагыйрь, әдип, милләт хадиме. N1

ӘХМӘТ ГАДЕЛГӘ 60 ЯШЬ

Галиуллин Т. Җанында халык гаме. N3

АЗАТ ГАНИЕВКӘ 60 ЯШЬ

Вәли М. Рухи куәт. N5

РАЗИМ ВӘЛИУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Гайнетдин М. «Яшәүне ул миндә калдырды». N1

РӘФКАТЬ КӘРАМИГӘ 60 ЯШЬ

Вәли М. Чынлык көче. N2

ЛӘЛӘ ГЫЙМАДИЕВАГА 55 ЯШЬ

Латыйфи Ф. Без—бер төркемнән. N3

ФЛЕРА ТАРХАНОВАГА 55 ЯШЬ

Гаташ Р. Шигырьдә—наз ияләре. N8

**КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ**

19—Мәрьям сүрәсе. N1

20—Та-һа сүрәсе. N2

21—Әнбия (Пәйгамбәрләр) сүрәсе. N2

22—Хаҗ сүрәсе. N3

23—Мөэминун (Мөэминнәр) сүрәсе. N3

24—Нур сүрәсе. N3

25—Фуркан (Яхшылыкны яманнан аеручы китап) сүрәсе. N5

26—Шөгарә (Шагыйрьләр) сүрәсе. N6

27—Нәмел (Кырмыска) сүрәсе. N7

28—Касас (Кыйссалар) сүрәсе. N8

29—Ганкәбут (Үрмәкүчләр) сүрәсе. N9

30—Рум сүрәсе. N9

31—Локман сүрәсе. N10

32—Сәҗдә сүрәсе. N10
33—Әхзаб (Төркемнәр) сүрәсе. N11
34—Сәбә (Саба иле) сүрәсе. N12
35—Фатыр (Яралтучы) сүрәсе. N12
36—Йәсин сүрәсе. N12

### ХӘТЕР

Камалов Х. Заман кешесе. N9
Фәйзуллин Р. Үзбәк абый үз иде. N3

### СӘНГАТЬ

Арсланова Ф. Сәнгатькә багышланган гомер *(күренекле сәнгать эшлеклесе Әзһәр Абдуллинның тууына 65 ел)*. N12

Гамбәр Н. Беренчеләр *(композитор М. Мозаффаровның тууына 100 ел)*. N3

Миншин М. Язмышны булмый алдап *(галим-педагог һәм музыкант Рәгъде Халитовка 60 яшь)*. N2

Минлебаев К. Еракмагы якын дустым. N11

Миннуллина Ф. Сәнгать—ул җанлы хәтер. N6

Монасыйпов Ш. Бакый Урманче шәмаилләре. N2

Сафиуллин Ю. Мактау гына аз... N11

### КИТАП КҮЗӘТҮ

Зарипова Р. Бала күнеле. N12

Мәхмүтов Х. Төрек теле аша—төрки дөньяга. N5

Сафин Ф. Татарныкымы, әллә... N1

Шәрәфиев Р. Безнен дә әниләр бар иде... N3

Шәрәфиев Р. Ак казлар чакыруы. N12

### ЮМОР-САТИРА

Болар—безнең хезмәттәшләр, фикердәш-каләмдәшләр *(Л. Лерон шигырьләре, А. Алешин рәсемнәре)*. N5

Галиев М. Чәк-чәк фикерләр. N6

Гыйсметдинов Д. Юмористик хикәяләр. N12

Дусай М. Алай түгел, болай ул... N8

Мәннан Р. Үртәмешләр. N9

Нәҗмиев Т. Хикмәтле хәлләр. N7

Саттар М. Такмаклар. N3

Саттар М. Галимулла күрше. N11

Сөләйман. Үртәмешләр. N8

Хәсәнов Ә. Шаян хикәяләр. N8

Шиһапов И. Юмористик хикәяләр. N9

Яруллин Ф. Бәхетле пар. N3

### УКУЧЫ СҮЗЕ

Фазуллин И. Рәхмәтемне белдерәм. N11

Хатлардан юллар *(С. Поварисов, Р. Мирхәйдәров, И. Гариф, Н. Шакирова хатлары)*. N5

Хәбибуллин Х. Чын мәхәббәт бармы? N2

Шәмсетдинова З. Латин алфавитында уку һәм язу унайрак. N3

### БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Атылган йолдыз кебек *(Тәбриз Мөбәрәковның тууына 70 ел)*. N2

Бәйрәмова Г. Мәхәббәтнен гомере чикләнмәгән *(Мостафа Ногманның тууына 90 ел)*. N12

Кәшшаф Әмировның тууына 80 ел. N4

Латыйфи Ф. Болын чәчәкләре күп булсын *(Галимҗан Латыйпның тууына 90 ел)*. N1

Хәйдәр Гайнетдиновның тууына 50 ел. N11

Шабаев М. Якташым Газиз *(Газиз Мөхәммәтшинның тууына 70 ел)*. N12

### ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Шаһиева Р. Казан тәхете. N2

Шаһиева Р. Ай шәүләсе астында. N3

Шаһиева Р. Казанны сагыну. N9

Шаһиева Р. Татар рыцарьлар поэзиясе. N10

### ЛАТИН ИМЛАСЫНДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

Арсланов Н. Төрле еллардан. *Шигырьләр*. N9

Бәйрәмгә шигъри бәйләм *(һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, С. Хәким, Н. Арсланов, З. Нури, Рәш. Әхмәтҗан шигырьләре)* N5

Вәлиев З. Бәхетсезләр бәхете нинди була? N2

Гарданов С. Хатлардан юллар. N4

Ерикәй Ә. Төрле еллардан җырлар. N12

Иделле Ф. 90 еллыгын да бергәләп үткәрергә насыйп итсен. N5

Лапыйп К. Минем нәсел. *Шигырь*. N1

Мәжитов Р. Ала каргалар. *Әкият*. N3

Мостафин Р. Бер рәсем тарихы. N7

Рәсемнәрдә—журнал тарихы. N5

Саттар И. Васыять. *Нәсер*. N8

Саттар Р. Бер сүзен. *Шигырьләр*. N8

Укучы сүзе *(А. Кадырова, Н. Гыйзетдинов хатлары)*. N7

Шабаев М. Июнь иле. *Шигырь*. N6

Шамун Фидаи. Ялкынлы теләк. Шигырьләр. N6

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан N1-12

## Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### «ПРЕССА—2003» КҮРГӘЗМӘСЕ

24 октябрьдә Мәскәүдә Бөтенроссия Күргәзмә үзәгендә «Пресса—2003» күргәзмәсе—унынчы, ягъни юбилей күргәзмәсе ачылды. Анда Татарстан массакүләм матбугат чараларының берләштерелгән стенды куелган иде.

Күргәзмәдә катнашучылар фикеренчә, Татарстан стенды иң саллы һәм иң заманча экспозиция формалары буенча бизәлгән стенд булды. Монда республиканың төрле рәвешле милектәге кырыктан артык республика һәм район басмасы белән танышырга мөмкин иде.

Күргәзмәне ачуда РФ Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм багланышлар министрлыгы, РФ Элемтә министрлыгы, Россия Журналистлар берлеге, Россия иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре, матбугат таратучылар, нәшер итүчеләр катнашты.

«Пресса—2003» күргәзмәсе директоры Михаил Ненашев Татарстанга «Алтын бейдж» тапшырды. Күргәзмәне оештыручылар Татарстанны бу бүләк белән бирердә бик теләп катнашучы буларак кына түгел (республика массакүләм матбугат чаралары бу күргәзмәдә 1994 елдан бирле катнаша), ә берләштерелгән экспозиция идеясен чынга ашырган беренче катнашучы буларак та билгеләп уздылар.

Шул ук көнне «Татарстан массакүләм матбугат чаралары: кичә, бүген, иртәгә» дигән матбугат конференциясе уздырылды. Анда ТР элемтә министры Ринат Җәләлов, Татарстан массакүләм матбугат чаралары җитәкчеләре катнашты.

### ГОМЕРЛӘР КИСЕЛГӘН ҖИРДӘ

Вице-премьер Зилә Вәлиева җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе Алманиядә булып кайтты.

Алар Плетцензеедагы фашизмга каршылык күрсәтү мемориалында яна экспозиция ачу тантанасында катнаштылар. Бу экспозициянең аерым бер стендында каһарман шагыйрь Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренә багышланган материаллар бар. Экспозициядәге төп экспонатларның берсе—Җәлилгә һәм җәлилчеләргә чыгарылган үлем карарларының төп нөсхәләре. Делегация составында күренекле язучы-публицист Рафаэль Мостафин да бар иде.

### «ТАТАРСТАН» РАДИОСЫНА—75 ЕЛ

Бөтенроссия дәүләт телерадиокомпаниясенең региональ телевидение һәм радиотапшырулар департаменты җитәкчесе П. Земцов «Татарстан» телерадиокомпаниясенең хезмәткәрләрен һәм ветераннарын үз радиотапшыруларын алып бара башлауга 75 ел тулу уңае белән котлады.

Коллектив бу елларда ирешелгән уңышлары белән чын мәгънәсендә горурлана ала. Милли үзаң һәм халыклар дуслыгын ныгыту, гореф-гадәтләрне саклауда радиотапшыруларның роле бәясез, дип әйтелә котлауда.

Бөтенроссия дәүләт телерадиокомпаниясенең региональ телевидение һәм радиотапшырулар департаменты җитәкчесе компаниягә яңа иҗади уңышлар теләде.

### ЖУРФАК ЮБИЛЕЕ

Казан дәүләт университетының журналистика, социология, психология факультеты шушы көннәрдә үзенең 40 еллык юбилеен билгеләп үтте.

1962 елда профессор Иван Пехтелев җитәкчелегендә оешкан бәләкәй генә кафедра соңгы 12 елда тагын да үсеп, зураеп, үзе 5 кафедрадан торган зур көчкә—факультетка әверелде. Шушы көннәрдә генә анда «Электрон гаммәви-мәгълүмат чаралары теориясе һәм практикасы» дигән яңа кафедра пәйда булды.

Юбилей уңаеннан, башта факультетта «Кремль урамында—40 ел» исемле фәнни-гамәли конференция, ә кич белән УНИКС концерт залында тантаналы кичә үткәрелде. УНИКСның тамаша залы берьюлы моның кадәрле каләм әһелләрен күптән күргәне булмагандыр, мөгаен. КДУны төрле елларда тәмамлап, хәзерге вакытта күпсанлы радио, телевидениедә, газета-журналларда эшләүче «дүртенче хакимият» әһелләре бирердә үзләренең укытучы остазлары, бергә укыган курсташлары белән очрашып хатирәләр яңарттылар.

40 ел эчендә журфак 3 меннән артык белгеч әзерләп чыгарган. Алар арасында әдәби хәрәкәттә актив катнашучы язучылар да бар.

Журналистика факультетын озак еллар Флорид Әгъзамов җитәкләде, ә бүген исә бу вазифаны Васил Гарифуллин башкара.

## ТАТАРЧА ФИЛЬМ КАРЫЙБЫЗ

Соңгы дәвердә Татарстанда беренче мәртәбә тулы метражлы «Күктау» дигән нәфис фильм төшерү тәгалләнде. Ул Татарстан Мәдәният министрлыгы каршындагы кинематография идарәсе тарафыннан Казан кинохроника студиясе базасында эшләнде. Фильмның сценарием Мансур Гыйләжев язган, куючы-режиссеры—мона кадәр татар тамашачысына «Бәхеткәй» исемле фильмы белән таныш булган Илдар Ягъфәров. Операторы—Рафикъ Галиев. Баш рольләрдә—Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, актер Фәрит Бикчәнтәев һәм аның улы Йосыф. Калган рольләрне танылган татар сәнгать осталары Ринат Тажетдинов, Әзһәр Шакиров, Фирдәвес Хәйруллина, Равил Шәрәфиев, Шәүкәт Биктимерләр башкара.

Фильмның эчтәлеге язмыш тарафыннан сынауларга дучар ителгән ике кеше: Кәрим һәм Йосыфның бәхет-сәгадәткә омтылышлары турында.

Фильмның премьерасы 4 ноябрьдә Г. Камал исемендәге театр бинасында үтте.

## ЮБИЛЕЙ ДӘВАМ ИТӘ

Безнең өчен 2002 ел «Казан утлары» елы булды дип тә әйтә алабыз. Бәйрәми һәм эшлекле рух иртә яздан башланып кышкача дәвам итте. «Казан утлары»ның 80 еллыгына багышланган зур бер әдәбимузыкаль кичә Чаллыда узды. Шәһәрнең 52 номерлы мәктәбендә узган кичәдә журналның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, бүлек мөхәррире Рашиф Гаташ катнашты. Бәйрәм шатлыгын Чаллыда яшәүче каләмдәшләребез Фәүзия Бәйрәмова, Рәшит Бәшәр, Мансур Сафин һ. б. да уртаклашты. Шагыйрьләребез шулай ук Чаллы мэриясе житәкчеләре белән дә очрашып, журналны халык арасында күбрәк тарату мәсьәләләре турында сөйләштеләр.

## ОЧРАШУЛАР ДӘВАМ ИТӘ

Төркиянең Малатиа шәһәрендә төрки телле илләр шагыйрьләренең III Халыкара очрашуы булды. Аны Тюрксой Генераль дирекциясе оештырды. Әлеге җыенга Әзербайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Төркия, Төркмәнстан, Татарстан, Башкортстан, Кипр, Тува, Хакасия, Гагауз җөмһүриятләре вәкилләре чакырылган иде. Барлык очрашулар да шушы илләрнең дәүләт флаглары астында үтте. Пленар утырышларда туганлаш халыкларның бүгенге көнүзәк бурычлары, мәдәни бәйләнешләр аша уртак тамырлы бөек телебез тирәсенә туплану һ. б. мәсьәләләр турында эшлекле сөйләшүләрдән тыш, вилаять башкаласының үзәк конференц-залында, шулай ук университетта төрки шагыйрьләр кичәсе үткәрелде. Кунаклар Тюрксой илләре рәссамнары күргәзмәсен ачуда катнаштылар, төрек халык музыкасы концертын карадылар, С. Төркмәнбашы исемендәге туку фабрикасында, 1224 елда төзелгән мәчеттә, ат заводында, Арабкир, Султансу районнарында, шәһәр һәм өлкәнең истәлекле урыннарында булдылар. Шагыйрьләрне губернатор Мостафа Елдырым үз резиденциясендә кабул итте, ике тапкыр—килеп төшкәч һәм китәр алдыннан үз өенә кунакка дәште.

Халыкара очрашуда Татарстаннан танылган шагыйрь, «Мәдәни җомга» газетасының баш редакторы Зиннур Мансуров катнашты. 2000-2001 елларда үткән I һәм II Халыкара очрашуларда шагыйрьләребез Ренат Харис һәм Равил Фәйзуллин катнашкан иде.

## КҮРШЕЛӘРЕБЕЗДӘ

Драматург Туфан Миңнуллин, шагыйрь Гәрәй Рәхим Удмуртия республикасының Глазов шәһәрендә булып кайттылар. Язучылар шәһәр хакимиятендә «Милли проблемаларны чишү буенча тәҗрибә уртаклашу» исемле «Түгәрәк өстәл» очрашуында катнаштылар. Бу юнәлештә Татарстан Дәүләт Советының эшчәнлеге турында сөйләделәр. Бу сөйләшүгә җирле газета, шәһәр телевидениесе һәм радиосы журналистлары чакырылды. Ижевскидан килгән вәкилләр дә бар иде. Кичен шәһәрнең «Россия» мәдәният сараенда язучыларның халык белән очрашуы булды. Казан кунаклары кичәсенә Удмуртиянең Балезино, Юкамен районнарыннан да милләттәшләребез килгән иде.

## АНДА ДА БЕЗНЕҢ ТАРИХ

Татарстан Республикасы яшь белгечләре төркеме Касыйм шәһәренә (Рязань өлкәсе) барып кайтты. Әлеге эшлекле сәяхәт Касыйм шәһәренең 850 еллыгы уңаеннан ТР яшь галимнәр һәм белгечләренең иҗтимагый хәрәкәте, ТР Фәннәр академиясе Тарих институтының яшь галимнәр һәм аспирантлар советы, Татар яшьләре ассоциациясе тарафыннан БТК Башкарма Комитеты һәм «Инициатива» яшьләр программаларын үстерү иҗтимагый фонды ярдәме белән оештырылды.

Касыймда Татарстан делегациясе шәһәр хакимияте вәкилләре һәм шәһәрнең татар җәмәгатьчелеге белән очрашты. Касыймлылар тарихи урыннарда экскурсия оештырып, кунакларны татар ханлыгының мәшһүр нәселләре, үзенчәлекле корылмалары белән таныштырды. Казанлылар, үз чиратында, срактагы кардәшләренә татар әдәбияты, аудио-,видеокассеталар, компактдисклар белән сөендерде. Очрашу вакытында Татарстанның яшьләр иҗтимагый оешмалары белән Касыйм шәһәре хакимияте, шәһәрнең татар мәхәлләсе арасында хезмәттәшлек турында сөйләшенде.

Рязань өлкәсенә сәяхәт барышында икенче тукталыш Подлипки (элеккеге Шырын) авылында булды. Бу авыл үзенең Ширин морзаларыныкы булуы белән мәшһүр. Хәзер исә биредә 50 ләп кенә татар яши. Шуңа да карамастан, алар кунакларны концерт-чыгышлары белән каршы алдылар.

Касыйм шәһәреннән соң яшьләр Түбән Новгородтагы татар яшьләре вәкилләре һәм Татарстан Республикасының бу өлкәдәге сәүдә-икътисади вәкиллек җитәкчеләре белән очраштылар.

### ХӘТЕР ЯҢАРТУ

Татарстан Республикасы милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге IX-XIV гасырларда Урта Идел һәм Чулман буе тирәсендә яшәгән Болгар дәүләтенең тарихи-археологик ядкарьләренә багышланган күргәзмә әзерләде.

Күргәзмәнең максаты: XIX йөздә һәм XX гасыр башында нәшер ителеп, бүген сирәк очрый торган басмалар белән таныштыру.

### ӨЛКӘННӘР ШУРАСЫНДА

Татарстан Язучылар берлеге каршында эшләп килүче Өлкәннәр шурасы инициативасы белән 14 ноябрьдә өлкән яшьтәге язучы һәм шагыйрьләр Казан дәүләт университетының археология һәм этнография кафедрасы мөдире, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, профессор Әзһәр Мөхәммәдиев белән очраштылар. Язучылар Казан тарихына бәйле бик күп кызыклы мәгълүматлар белән таныштылар.

### МӘГЪНӘЛЕ ЯЛ КӨНЕ

Балык Бистәсе районы авыл хуҗалыгы җитәкчеләренең зур бер төркеме—йөзләп кеше Казанның Тукай музеена килделәр, экспозицияләр белән таныштылар, бөек шагыйрь исемендәге премия лауреаты исемен йөрткән иҗат әһелләре белән очраштылар. Алар—Балык Бистәсе районында туып-үскән якташлары—шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, артист Равил Шәрәфиев. 2 ноябрьдә булган бу очрашу бик җанлы үтте.

«Авыл хезмәтчәннәренең менә шулай бердәм рәвештә җыелышып Тукай рухына сәҗдә кылганнары юк иде әле»,—диде музей директоры Мөҗип Низамиев.

Район хакимияте башлыгы Равил Хәйруллин җитәкчелегендә килгән бу делегация шул ук көнне Татарстан агробизнес институтында булды (бу институтның ректоры—Сәлимҗан Шәрипов, Балык Бистәлеләрнең Казандагы җәмгыяте рәисе), кичен Г. Камал театрында спектакль карадылар.

### ЯЗУЧЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Мәскәүнең Асадуллаев йортында язучы Миргазиян Юныйска 75 яшь тулу уңаеннан, очрашу булып үтте. Мөхәммәт Миначев җитәкчелегендәге «Ватан» татар халык демократик фиркасе оештырган бу кичәгә язучының дуслары, аның иҗатын яратучылар җыелган иде.

Кичәдә Казаннан килгән әдәбият галиме Равил Рахмани, профессор Әгъдәс Борһанов, шагыйрь Әхмәт Саттар, танылган тарихчы Газиз Гобәйдуллинның оныгы, профессор Эдуард Кулпин, дипломат Йолдыз Хәлиуллин h. б. чыгыш ясады.

### ОНЫТЫЛМЫЙ

Традиция буенча һәр елны 1 ноябрьдә җәмәгатьчелек күренекле композитор Сара Садыйкованың туган көнен билгеләп үтә. Быелгы ел аеруча хәтердә калырлык булды: композитор озак еллар эшләгән бинага—Бауман урамында урнашкан элеккеге М. Горький исемендәге мәдәният йорты диварына аның барельефы төшерелгән истәлек тактасы куелды.

### ШАГЫЙРЬНЕ ЯД ИТҮ

Алабугада шагыйрь Фазыл Шәехнең каберенә таш куелды. Узган ел вафат булган шагыйрьне искә алырга республикабызның төрле почмакларыннан замандашлары һәм каләмдәшләре җыйналды.

### МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен рәссам **Абрек Әмир улы Абзгильдин**га, Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, «Россия Федерациясенең атказанган рәссамы» дигән мактаулы исем бирелде.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Кышкы манзара—*фотоэтюд*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Госман Гомәр.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Бертуган Рәмиевләр**: Фәнни-биографик җыентык—Казан: Рухият, 2002.—368б.—(«Шәхесләребез» сериясе). Төзүче-авторлар: Л. Хәмидуллин, Р. Мәрданов, Р. Миннуллин.




Бертуган Рәмиевләр—Шакир (1857—1912) һәм Закир (1859—1921) татар милли-мәдәни тарихында күренекле шәхесләр саналалар. Закир Рәмиев (Дәрдмәнд)—шагыйрь, Шакир Рәмиев—алтын прискалары хуҗасы, матбагачы—нашир буларак киң мәгълүм. Ике бертуганның эшгамәлләре, фикер-мәсләкләре милләт мәнфәгатенә хезмәт итү, татар халкының аң-мәгърифәтен киңәйтергә омтылудан гыйбарәт.

Китап эчтәлеге белән бик бай: Рәмиевләрнең нәсел шәҗәрәсе, әти-әниләренең тәрҗемәи хәлләре, бертуганнарның иҗтимагый һәм сәнәгати эшчәнлекләре, архивларда саклаган хатлары, фотолары... Җыентыкта тупланган мәгълүматлар милләтебезнең үткәне белән кызыксынучы һәркем өчен файдалы булыр. Китапның фәнни мөхәррире—академик Миркасыйм Госманов, бизәлеш рәссаме—Шамил Насыйров.

**Татар теле—шагыйрьләр теле.**—Казан: Мәгариф, 2002.—95. Төзүчесе—Флера Сафиуллина.





Бу китапка туган телебез, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйланып язылган шигырьләр тупланган. Аларда телебезнең байлыгы, фикри куәте, шигъри аһәңе чагыла.

Нажар Нәҗминең «... Туган җирең кебек назлы, җырдай моңлы татар теле» дигән юлларына Зөлфәт кушылып китә сыман: «Шигырьле тел—фанилыкка бәйсез, үлемгә баш бирми андый тел...»

Мөхәммәдьярдан алып Роберт Миннуллинга кадәр (китапка барлыгы егерме биш шагыйрьнең—Тукай, Дәрдмәнд, Такташ, Х. Туфан, С. Хәким, Г. Афзал, Р. Фәйзуллин, И. Юзеев, Л. Шагыйрьҗан, М. Әгъләмов һ.б. әсәрләре кергән) дәверне иңләгән, күренекле шагыйрьләребезнең туган телгә мәдхия-догаларын затлы тәсбих итеп тезгән-туплаган китап тагын бер ягы белән үзенчәлекле: һәр шигырь халкыбыз XX гасырда кулланган ике графикада—кирилл һәм латин язуында тәкъдим ителгән. Димәк, латин язуын үзләштерү өчен дә файдалы әсбап булачак бу китап.

Индекс 73210




Госман Гомәр

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)